ISSN 0206—4189

# Казан утлары

7. 1998



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



**Robert Miꞑnullin** Kopenhagenda Andersen həjkəle janьnda. *1997 jьl.*



**Razil Wəlief** Bɵtendɵnja kitapxanələre assosiatsiəse Kongressьnda. Pekin. *1996 jьl.*



**Təlƣət Ƣəliullin, Xaris Əşrəfçanof** Ƣ. Isxaqi qəbere janьnda. Urtada ədip icstɵlegenə qɵrən cьgucь tɵrek xəzrəte. Tɵrkiə, *1997 jьl.*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

*1998*

# 7

**(909)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марс ШАБАЕВ. Балачагым башкаласы. *Шигырьләр* .... 5

ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Гомер тәлгәшләре. *Эссе* .... 10
ЗӨЛФӘТ. Аулак сукмак. *Шигырьләр* .... 52
Суфиян ПОВАРИСОВ. Күкнең җиденче катында. *Роман* .... 58
Рәшит ГАТАУЛЛИН. Күзләр күзгә охшап килми икән. *Шигырьләр* .... 99
Нәжибә САФИНА. Әйтегез яшен... айның?! *Шигырьләр* .... 102
Айдар ХӘЛИМ. Авылдаш. *Хикәя* .... 106

ПУБЛИЦИСТИКА

Тәүфикъ ӘЙДИ. Себер үзебезнеке .... 123

СӘЯХӘТНАМӘ

Ягъсуф Шәфыйков. Әмирлекләрдә очрашулар .... 135

ХӘТЕР

Рафаэль МОСТАФИН. Фаҗигале язмыш *(Мин Шабай турында яңа мәгълүматлар)* .... 140
Шамил ӘХТӘМОВ. Бәян Гыйззәт хатлары .... 144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Барлас КАМАЛОВ. Хәзинәгә өстик әле .... 150

СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Равия АБДУЛЛИНА. Телне каләм саклый .... 154

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Рамил ИСЛАМОВ. Алтын Урда әдәбияты .... 160

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Энгель НИГЪМӘТУЛЛИН. Тоткынлыкта .... 166

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Гурий ТАВЛИН. Кушаматлы - югалмас .... 176

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Хикмәтле сүзләр .... 182
Латин имласында уку күнекмәләре .... 187
Укучы сүзе .... 189
Котлыйбыз .... 190
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": окончание романа С. ПОВАРИСОВА "На седьмом небе", эссе Т. ГАЛИУЛЛИНА "Гроздья судьбы"; рассказ А. ХАЛИМА "Односельчане"; стихи М. ШАБАЕВА, ЗУЛЬФАТА, Рашита ГАТАУЛЛИНА, Н. САФИНОЙ.
"Публицистика": статья Т. АЙДИ посвящена проблемам татар Сибири; "Встречи в Эмиратах" - повествование о путешествии Я. ШАФИКОВА.
"Память": статьи Р. МУСТАФИНА "Трагическая судьба" и Ш. АХТЯМОВА "Письма Баяна Гиззата".
"Литературная критика": Б. Камалов "Дополнения к толковому словарю татарского языка".
"Проблемы культуры речи": статья Р. АБДУЛЛИНОЙ о чистоте родного языка.
"К истории литературы": статьи Р. ИСЛАМОВА "Литература Золотой Орды"; Э. НИГМАТУЛЛИНА "Книга написанная в заключении".
Юмор-сатира.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Письма читателей.
В номере отмечаются юбилеи Т. Галиуллина, Д. Валиева.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: летний пейзаж —фоторепродукция Д. Бунтукова; драматург Юнус Сафиуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": the termination of POVARISOV novel " In the 7th sky ", essay T. GALIULLINA " As fate willed it "; the story A. KHALIM'S story "Countryman"; verses M. SHABAEV ZULFAT, RASHIT GALIULLIN, N. SAFINA.
"Publicism": the article of T. AIDI is devoted to problems of Siberia Tatars; " Meetings in Emirates " - narration about J. SHAFICOV'S trip.
"Memory": R. MUSTAFIN'S article " Tragical fate " and SH. AHTAMOV'S article "The Letters of Bajan Gizzat".
" Literary criticism ": B. KAMALOV " Additions to explanatory dictionary ".
" Problems of culture of speech ": R. ABDULLINA'S article about cleanliness of native language.
" To a history of the literature ": R. ISLAMOV'S article "The literature of Gold Orda"; I. NIGMATULLIN'S article" The Book, written in the conclusion ".
Skills of reading on the basis of Latin script
The letters of the readers.
In number the anniversaries T. GALIULLIN, L. VALIEV are marked.
The diary of social and cultural life.
In our covers: A summer lands cape D. Buntukov's fotoproduction; a playwright U. Saphiullin.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.06.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 14095. Заказ Я-298
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Марс Шабаев

### БАЛАЧАГЫМ БАШКАЛАСЫ

* * *

И авылым!
Балачагым башкаласы.
Безнең юллар бар да синнән башланасы.
Көтә булыр бусагада яңа көннәр —
Ашкындыра әллә ниләр, әллә кемнәр!
Тизрәк, тизрәк, йорт-оядан, канат ярып,
Очып китик, йөрик әле ду кубарып!
Шундый хыял, шундый теләк куды безне.
Абына-абына эзләдек без юлыбызны.
Сәрбиләрдә эленеп калды бала сагыш —
Шуннан бирле алга гына, алга барыш.
Үксез авыл елап калды, кулын болгап —
Без таралдык, без чәчелдек дөнья буйлап.
Бездән башка иза чикте туган авыл,
Бездән башка өр-яңадан туган да ул.
Ул ныгыган, ул яңарган, ул яшәргән —
Арынып калган бер кирәксез вак эшләрдән.
Олы җанлы авылкаем, кичер безне!
Синнән башка рәхәт тормыш кичәрбезме?
Булдыкмыни без ябышмас кискән икмәк?
Синнән башка ничек мөмкин гомер итмәк?
Өметләнәм: онытмассың, ташламассың,
И авылым!
Балачагым башкаласы.

### Күңелемә, әткәй, кайтып кер...

Дөньям онытып, дөнья кусам мин,
Ваклык, чүп-чар белән тулсам мин,

Тик үземне өстен куйсам мин:
— Оныттыңмы? — диеп әйтеп бер,
Күңелемә, эткәй, кайтып кер,
Күңел бикле булса, ватып кер!
Кайт та ерак, кырыс еллардан,
Син онытма миннән сорарга:
— Синме, — диеп, — истән чыгарган?
Винтовкаңны асып үт, эткәй,
Йөрәгемә басып үт, эткәй,
Хакыйкатьне ачып үт, эткәй!
Илең өчен соңгы минутта
Ничек кергән булсаң син утка,
Шулай күрен миңа... Онытма:
Синең сурәт хәтер түрендә,
Шинель кигән килеш күренә,
Кырыс солдат булып терелә.
Кызыл солдат булып ул миңа —
Үзенең дәвамчысы — улына
Васыять әйтә төсле тоела.
Васыятендә — авылым таңнары,
Ык сулары, Байсар таулары...
Аның васыятендә аннары
Хыяллары, изге теләкләр —
Әйтелгәннәр алар киләккә,
Уелып калсын өчен йөрәктә.
Шуларнымы бүген оныттым?!
Онытмадым... Бары курыктым...
Әткәй, синнән калган ул утның
Аңда сүнүеннән курыктым,
Канда сүнүеннән курыктым,
Җанда сүнүеннән курыктым.
Хәтеремне шуңа яңарттым,
Тормыш ваклыклары каралткан
Тутык күңелемне агарттым...
Рәхмәт, эткәй!
Ешрак кайтып тор,
Күңел бикле булса, ватып кер!

## Китап сүзе түгел

*Китап сүзләре генә сөйлисең
икән син, апаем!*

Авылдаш агай сүзе.

Яшел чирәм иде
Авыл урамнары,
Җылы, йомшак иде
Туфрак-тузаннары.
Яланаяк чаклар
Эзсез узганнармы?
Безнең чабаталар
Инде тузганнармы?
Көлгә күмә идек
Бәләк-бәрәңгеләр,
Була иде алар

Тәмледән-тәмлеләр.
Күгәрченнәр аулап
Чорма чатларыннан,
Бер әйләнер идем
Малай чакларымнан...

Китап сүзен белми,
Матур сүз сөйләми,
Без үскәнбез... Чөнки
Әйләнә-тирәли
Матурлык бит үзе
Төреп торган безне.
Җиргә салгач эзне,
Нигә китап сүзе?!
Калды яшел чирәм —
Аерылдык җирдән...
Шәһәр — зәңгәр хыял —
Һавадагы торна! —
Авыл малайларын
Һаман кызыктыра.
Малайлыктан шулай
Тартып алды Казан.
Вагон-вагон китап
(Мин укырга язган!),
Шома асфальт урам
(Мин таптарга язган!),
Гүзәл шәһәр кызы
(Унҗиденче яздан!) —
Көтеп торган мине,
Кызыктырган мине.
Телдә китап сүзе
Менә шуннан бирле.

Малайлыктан һаман
Ераклаша барам,
Асфальт урамнарга
Яраклаша барам.
Яраклашкан саен
Ярлылана күңел:
Шәһәр туфрагы шул —
Уңдырышлы түгел.
Шәһәр — гүя том-том
Аңлатмалы сүзлек:
Асыл мәгънә эзләп,
Ничә еллар гиздек,
Китапларда йөздек,
Җирдән тәмам биздек!
Кем генә булмасын,
Кеше онытмасын,
Онытмасын икән
Авыл әлифбасын.

## Икмәксез...

Ә кайдадыр кемдер икмәксез...
Әшсезлектән пычак тотыга,

Яшь балалар елап утыра...
Икмәксез шул — тормыш хикмәтсез.
Ә кайдадыр кемдер икмәксез...
икмәксезгә кирә теләнче,
Сынык сорый ул да үлгәнче:
"Икмәксезне читкә типмәссез..."
Ә кайдадыр кемдер икмәксез...
Икмәксезне кем соң кадерләр?
Авызын ача шыксыз каберләр...
Каберләрне гаеп итмәссез.
Икмәксез бит кемдер кайдадыр...
Елый-елый яшь кыз бирелә...
Ничек хәлләренә керергә? —
Моңлы күзләренә ай багар.
Икмәксез бит кемдер кайдадыр...
Йорт ташланган, ишек йозаклы...
Түзәр икән мескен озакмы?
Аңа бәхет, бәлки, айдадыр...
Икмәксез бит кемдер кайдадыр...
"Икмәк юкмы? Алыйк кулга таш.
Беткән бетсен инде безнең баш!
Ват! Кыр!! Җимер!!!
Бәлки, файдадыр?!"
Икмәксез бит һаман кемнәрдер...
Өметсезләр үзенә кул сала...
"Түз, ач яңак, бераз булса да..." —
Дип күршесе, бәлки, кергәндер.
икмәксез бит һаман кемнәрдер...
Кайгы-хәсрәт чиккән яшь егет,
Төшмә әле, төшмә син җебеп:
Икмәксезләр көче — бергәдер!
Икмәксез бит һаман кемнәрдер...
Чык басуга, кемнәр ач йөргән!
Сөр-чәч — сиңа ходай җир биргән:
Иген икмәк гамәл — сездәдер!
Ә кайдадыр кемдер икмәксез...
Көтә булыр шундый хикмәт сүз.

## Авыл язмышы

*Күперел торган кардай ак болытлар —*
*Йолдызларга мендәр:*
*Йокласыннар...*
*"Нигә көндез янмый йолдызлар?" — дип,*
*Кемнәр генә чаңнар сукмасыннар —*
*Көндез янмый йолдыз...*

Йолдыз сүнә —
Авыл уянадыр.
Киерелеп ачыладыр ишек.
Таң чыгында битен юа авыл...
Төнге татлы төшен, — күрдең ничек! —
Сыпырып ала да ул, шат елмая
Күтәрелеп килгән ал кояшка!

**“Фәлән вакыт ят та, фәләндә тор!” —**
**Мондый уйлар ахмак кайсы башка**
**Килер икән, димсең?**
**Ә бит булды:**
**Өйрәттеләр кайчан торырга да...**
**Телефоннан гына акырдылар**
**Кайчан чәчеп, кайчан урырга да.**
**“Юк, син инде, агай, сыер тотма!**
**Колхозны бел!**
**Сөт кибеткә килсен!”**
**Авыл агаемы оныта алсын**
**Җылы абзар исен, маллар исен...**
**Килмәде сөт!**
**Көтүчеләр бетте...**
**Көтүчегә илдә хәзер кытлык.**
**Сөт урынына агай хәмер эчте —**
**Шулай китереп сукты иман юклык.**
**Яшьләр таралдылар — авыл ятим...**
**Авыл калды тәмам күтәрәмгә.**
**Мәгънәсезгә түккән хәләл хезмәт**
**Исраф була торды гел әрәмгә...**

**Публицистик фикерләрне бүлеп,**
**Шигыремә кирә лирик агым:**
**Ябыштырып ирен читләренә**
**Яңа сауган сөтнең күбек агын,**
**Чыгып бастым авыл урамына —**
**Авыл таңда матур уяна ул!**
**Чыбык тоткан яшь киленнәр булып**
**Көтү куа иде минем авыл.**
**Кереп китеп тузан арасына,**
**Эреп беткән безнең малай чаклар...**
**Күпме шәһәрләшеп кыланмасын,**
**Күңел һаман авыллыгын саклар.**
**Тәүге йолдыз күктән күз кысуга,**
**Ут сүндерер, ятып йоклар авыл.**
**Сискәндереп уятмагыз аны —**
**Вакытын белеп, үзе уяна ул.**

# Чәчмә әсәрләр

## *Тәлгат Галиуллинга 60 яшь*



*Тәнкыйтьче, язучы һәм әдәбият фәне галиме Тәлгат Нәби улы Галиуллин 1938 елның 20 июлендә Татарстанның Норлат районы Кычытканлы авылында туа. Күрше авыл Яңа Әлмәттә унъеллыкны тәмамлаганнан соң, бер ел Свердловск өлкәсенең Краснотуринск шәһәрендә заводта эшли. 1956 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факульте-тына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, аны уңышлы тәмамлагач, 1961-1962 елларда шул ук бүлекнең татар теле кафедрасында ассистент булып эшли. 1962 елдан 1965 елга кадәр Г. Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм тарих институтында кече гыйльми хезмәткәр вазифаларын башкара.*

*1965 елда Т. Галиуллинны Алабуга педагогия институтына эшкә күчерәләр. Анда аңа татар һәм рус әдәбияты буенча лекцияләр уку, гамәли дәресләр алып бару тапшырыла. 1967 елдан 1971 елга кадәр шул институтның укыту һәм фәнни эшләр буенча проректоры, 1971-1986 елларда ректоры булып эшли. Ул эшләгән чорда институт уку-укыту өлкәсендә, фәнни юнәлештә зур уңышларга ирешә, тугыз факультеты булган беренче категорияле югары уку йортына әверелә. Тәлгат Галиуллин галим буларак та шул чорда җитлегә.*

*1968 елда "Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты" дигән темага кандидатлык, 1981 елда Алма-Ата шәһәрендә 20-30 нчы еллар татар поэзиясе тарихы буенча докторлык диссертациясе яклый. 1983 елдан — профессор.*

*Казанга кайтып берничә ел Казан педагогия институтында эшләгәннән соң, аны Казан дәүләт университетына чакыралар һәм татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасын оештыруны тапшыралар. 1988 елдан бүгенгә кадәр ул шул факультетның деканы һәм кафедра мөдире.*

*Тәнкыйтьче буларак, Т. Галиуллин матбугатта алтмышынчы еллар уртасында чыгыш ясый башлый. "Казан утлары" журналында шул чорда аның "Балладаларыбыз турында", "Поэманың барыр юллары", "Шигъри ачышлар һәм югалтулар аша", Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис иҗатларына багышланган, күзәтүләргә бай, фәнни әзерлекле мәкаләләре дөнья күрә. Алтмышынчы-сиксәненче еллар поэзиясенең үсеш үзенчәлекләрен ачуга багышланган бу тикшеренүләр соңыннан "Яңа үрләр яулаганда", "Еллар юлга чакыра", "Безнең заман — үзе җыр", "Шагыйрьләр һәм шигырьләр, "Дәвамлылык", "Гомер учагы" кебек җыентыкларның нигезен тәшкил итә. "Здравствуй, поэзия" исемле китабы Мәскәүдә, "Современник" нәшриятында басылып чыга. Татар поэзиясенең 1941 елга чаклы үсеше "Социалистик реализм юлыннан" һәм "Дыхание времени" исемле гыйльми монографик хезмәтләрендә яктыртыла.*

*Бу хезмәтләрендә аның төп максаты — татар поэзиясенең тиңдәшләре арасында тоткан урынын ачыклау, укучыларга яхшыны уртакулдан, ачыны үзешчән сорылыктан аерып күрсәтү. Нәкъ менә шул ноктада тәнкыйтьче Галиуллин укытучы-педагог белән кушылып китә. Чынлыкта ул республикабызда укытучылар әзерләүгә зур өлеш керткән олы шәхесләрнең берсе.*

*Тәнкыйтьче, әдәбият галиме, академик (Россия гуманитар академиясе академигы, 1995) Т. Галиуллин, соңгы чорда публицистика һәм проза өлкәсенә күчеп, үзен үзенчәлекле язучы итеп тә танытты. Аның иҗаты тулысы белән диярлек бүгенге көн проблемаларына багышланган. "Замана балалары" (1993) китабы публицистика белән сәнгатьлелек берләшүенең уңышлы тәҗрибәсе булды. Автор бу әсәрендә Татарстанның элеккеге һәм хәзерге җитәкчеләре турында исем-фамилияләрен әйтеп, аларның кылган гамәлләре турында үзе уйлаганны, күңелендәгесен ачыктан-ачык бәян итте, соңгы дәвердә әдәбиятыбызда сурелә төшкән тәнкыйди рухны яңартты. "Дәгъва" (1995) әсәре күпмедер дәрәҗәдә "Замана балалары"ның дәвамы булып тора. Т. Галиуллин, шулай ук, үзен хикәя жанрында да уңышлы эшли алырдай әдип буларак танытты ("Кияү", "Спид вә мәхәббәт", "Һавада татарин", "Колючник" һ.б.); күпчелек хикәяләренең нигезендә тормыштан, аерым алганда, автор озак еллар дәвамында эшләгән Алабуга якларында булган гыйбрәтле хәл-әхвәлләр ята ("Туган көн", "Урман хуҗасы", "Ниткән хат ул", һ.б.). Язучы сурәтле фикерләвенең, слубенең төп үзенчәлеге — үткәндәге вакыйгаларга бүгенге көн күзлегеннән килеп бәя бирү, җиңелчә киная, ирония, юмор, тәртмә тел, җорлык. Соңгы елларда Т. Галиуллин үзен роман жанрында да сынап карады. "Тәүбә" (1996) әсәре бүгенге катлаулы чорыбызны җанлы тасвирлавы, истә калырлык образлар, шулай ук ироник тел ярдәмендә хикәяләве белән үз укучысын тапты. Аның дәвамы — "Элмәк" әсәре, "Казан утлары"нда (1997) басылып чыгуга, укучыларның игътибарын җәлеп итте.*

*Тәлгат Галиуллин — 1972 елдан Язучылар Берлеге әгъзасы. Төрле елларда ул — "Почет билгесе" ордены, медальләр белән бүләкләнде, 1993 елда "Татарстан республикасының атказанган фән эшлеклесе" дигән, ә 1997 елда әдәбият өлкәсендә Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек булды. Ул, шулай ук, бүгенге көндә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, Габдулла Тукай җәмгыятенең Президенты.*

**Тәлгат Галиуллин**

# ГОМЕР ТӘЛГӘШЛӘРЕ

Истәлекләр урамына кергәндә...

***Гомерлеккә хәрби хезмәткә алынган солдат шикелле — кире кайтмаска, дип, үткәндә калган балачак хатирәләре — күңел көзгесендә яңара. Анда миңа бик тә якын, кызыклы кешеләр яши. Алар могҗиза ияләре, күрәзәчеләр түгел, синең, минем шикелле гади, гадилекләре белән бөек, олуг шәхесләр.***

***Галиҗанәб вакыт шәрифләренең кайбер исемнәрне, сөенечле йә көенечле вакыйгаларны хәтердән сызып ташлый торган миһербансыз гадәте бар. Әмма сәхифәләрнең беришесе, борынгы рәссамнарның хәзергәчә сере ачылмаган буяулары белән язылгандай, күңелдә мәңгегә урнашып кала. Хәтта синең теләк белән санашмыйча да. Истәлек язу өчен сынны, булганны күңел күзе, хәтер белән күрү, иңләү генә җитми, аларны акыл казанында кайнатып, җиз иләк аша үткәрәсе була.***

***Кызыклы шәхесләр, фикерле кешеләр, күрә, аңлый белсәң, һәр нәселдә бар, аларның барысы турында сөйләү, язу мөмкин түгел.***

***Тарих — булып үткәнне өйрәнә, әдәбият исә булуы ихтимал хәл-әхвәлләр белән***

**эш итә, дигән караш яши. Әмма дәһшәтле, вә фаҗигале XX гасырда тарих белән әдәбият, чынбарлык белән сурәтле фикерләү бик нык якынлашты, үзара керешеп, ялганып китте. Укучы уйдырма мифлардан, ясалма, чынбарлыкны бозып, берьяклы күрсәткән әсәрләрдән туйды. Әдәбиятта күргән, белгән, үз башыннан кичергән, һич югында ишеткән вакыйгаларга корылган әсәрләр, нәфис публицистика алгы рәткә чыкты.**

**Тәҗрибәм артык зур булмаса да, истәлек-хатирәләр, тормыштан алынган, яшәр көнебез тудырган вакыйгалар, кул бирешеп яшәгән кешеләр турында язганым бар. “Хәзер һәркем истәлек яза, үзен күтәрә, берсе дә бүгенге авыр, болгавыр көннәрне бәян итәргә алынмый”, — дип зарланучылар бар. Бу сүзләрдә дөреслек юк дип булмый. Ләкин хәзерге халәтебезне аңлау өчен үткәнне белү дә кирәк. Рухи дөнья бер көндә генә туа, калыплана алмый.**

**Мин үзем яхшы белгән, башымнан узган хәлләр, дусларым, танышларым, үз дөньям турында гына сөйләргә җыенам.**

**Яшьлек, балачак еллар әүвәл бик еракта тоела, күзеңне йомып аласың да, үткәнеңне кичә генә булган шикелле хис итә башлыйсың. Бер шагыйрь: гомер үтми, без гомер аша үтәбез, дигән. Хак күзәтү.**

**Айлар артыннан еллар уза, яшьлекне картлык йөгәнли. Мәхәббәт хисе, сөю, сөешү сагышлары язгы ташулар кебек уза да китә. Ә су ага да ага... Яшь чакта бер үк суга ике тапкыр кереп булмый дигән гыйбарәгә ихластан ышана идек. Хәтер канатында үткәнгә әйләнеп кайтып була икән.**

**Истәлек-хатирәләр урамына чыкканда, мине, яшәп киткән кешеләрне телгә алу, кылган гамәлләре, сәер кыланышлары хакында сүз алып бару аларның җанын рәнҗетмәсме, дигән сорау бимазалады. Өлкәннәрне, инде арабызда була алмаган шәхесләрне, дөреслеккә хилафлык китермичә, шул ук вакытта шомартмыйча, бизәмичә искә алганда, “үпкәләмәсләр” дип уйлыйм. Киләчәк буыннар үзләренең нигез тамырларын белергә тиешләр. Башкача җәмгыятьне явыз саранча болыты төсле маңкортлар, тарихын белергә теләмәгән, бер көн белән яшәгән “нәселсез” адәмнәр басып китәчәк. Мисаллар җитәрлек.**

**Минем автобиографик язмаларым менә шул хакыйкатьләр турында уйландырыр дигән ышанычта калам.**

**Әлеге истәлек язмаларда мин вакыт-ара тәртибен саклауны күздә тотмыйм. Заманым тарихын язуга да дәгъва итмим. Чорымны, шуның бер вәкиле буларак, үземне ничек күрсәм, шулай бәян итәргә булдым.**

## Авылның рухы — мәңгелек!

*Балачагым кайтып керде,*
*Мөлдерәмә карый.*
*Кара әле, шайтан малай,*
*Онытмаган — таный.*

Мөдәррис Әгъләм.

Минем кендек каным тамган Кычытканлы йөзләгән, меңләгән татар авылларыннан бер ягы белән дә аерылып тормый дисәм, зур хата булмастыр. Үзгә яшәү урыннарындагы шикелле үк, биредә дә халык гомер гомергә иген игә, печән чаба, бәрәңге чүпли, нәкъ Тукай Былтырыдай, “алны-артны, уңны-сулны белмичә утын кисә”, бәхетле елларны каһәрле корылык алыштыра, кемдер сәгате житкәч, мәңгелек йортка күчә, аңа алмашка, шул ук язмышка дучар булачак нарасый туа, кемдер илаһи ләззәткә чумган көнне икенче бер бәхетсезен хатыны ташлап китә... Илдә барган зәхмәтле вакыйгалар жиле Кычытканлыга да килеп житә: бик еракта, бөтенләй башка-үзгә милләтләр сугыша, ә ирләрне татар авылыннан алалар, еш кына кире кайтармыйлар, һич сорамаганны, әйтик, кумәк хуҗалыклар төзүне, хәзер шуларны таркатуны, юкка чыгаруны көчләп тагалар...

Тарих хәтере күренекле, шөһрәтле авылларны күп белә. Тукай — әнисе, үзе туган, яшьлеге узган авылларны мәңгеләштереп калдырды. Юкса, Сосна Пүчинкәсе, Өчиле, Кырлай гадәти яшәү урыннары булып калырлар иде. Шагыйрь аларны данга күмде, үстерде, дөньяга танытты. Шулар янына сихерле матурлыклары, исләре, төсләре белән Яуширмә, Сыркыды, Пешлә, Мостафа авыллары килеп өстәлде. Аларнын йолдызын шунда туып-үскән Исхакый, Такташ, Ш. Камал, Җәлилләр кабызды. Лермонтовны бирмәсә, Тарханны кем белер дә, Толстой яшәмәсә, Ясная Поляннаны кем җиһанның изге урыннарының берсе итеп санар иде икән?

Такташ Тамбов урамнарының илаһи көчен, серле моңын, куркыныч дәһшәтен, матурлыгын шигырьдә калдырды. Урманнары инде киселеп беткәндер, ә әдәбиятта алар яшәячәк, кешене һаман да тәрәккыятькә әйдәп торачак. Матурлык — мәңгелек.

Йорт саны, кеше исәбе ягыннан мин туып-үскән авылдан күпкә кечерәк Күлле-Киме татар әдәбиятына берничә шагыйрь бүләк итте. Сибгат Хәкиме дә бик житкән иде, юк шул, авыл саранлык күрсәтми, сәләтле балаларын үстерә, күтәрә тора.

Татарстаннан шактый еракта, күрше Башкортстанның үзәгенә оялаган Каргалы, Дәүләкән авыллары, анда көн иткән нәселләрнең шәҗәрәсен Ә. Еники "Соңгы китаб"ында бәян итмәсә, без алардагы яшәеш, иҗтимагый вәзгыятьләр турында каян белер идек? Үзе, гаиләсе, аннан күтәрелгән затлы кешеләр белән таныштырып, язучы әхлакый-фәлсәфи карашыбызны киңәйтте, тирәнәйтте. Тормыш безнең авыл, таныш кишәрлек, күрше вилаять белән генә чикләнми, дөнья матур, дөнья киң икән бит.

Туфан гадәти бер мишәр авылы Иске Карматтә үскән гөл-чәчәкләрнең илаһи матурлыгын сурәтләп кенә калмады, аларны хисле, жанлы, тоемлы кеше дәрәҗәсенә күтәреп җырлады.

Сибгат Хәким бер дүртьюллыгында татар шагыйрьләренең иң гадәти, хәтта сәер исемле авыллардан чыгуына игътибар иткән иде.

Кайдан татар шагыйрьләре?
Котлап, мактап мин кул чабам:
Талантлылар, ә үзләре
Такталачык, Дүртмунчадан.

Яхшымы бу, начармы, бәя бирү, аныклау шагыйрь бурычы түгел. Ул булганны искәртә. Әйтте — бетте.

Менә бу яктан караганда, кара урман эчендә, табигатьнең илаһи бер җирендә утырган, сәер исемле минем авылдан әллә ничә шагыйрь, һич югы көйче, артист, бигрәк тә биюче (кычыткан өстендә аякны озак тотып булмый, Шүрәле мәсле үрле-кырлы сикерәсең) чыгарга тиеш иде. Әнә ут күрше авыллардан Габдулла Кариев, Салих Баттал, Нәби Дәүли, Шамил Маннапов, Салих Маннапов кебек ничаклы олы шәхесләр, сәхнә, сүз осталары, җәмәгать эшлеклеләре күтәрелгән.

Күрәсең, авылым халкы артык реалист, барлыгы белән җиргә, урманга береккән, яшәү өчен көрәшкән, айга карап, кошлар сайравын тыңлап моңланырга вакыты калмагандыр. Ул авылга катлаулы исем эзләп баш ватмаган, үзенең беренчел килеп утырган, урман эчендәге аланында нинди үсемлек күпчелек булган, шуннан чыгып исемне дә биргән: Кычытканлы. Урысчага турыдан-туры тәрҗемә юлына басмыйча ("Крапивник" дип түгел), Кичкальня дип яздырган. (Кычытканның чеметеп алып, үзен хөрмәт иттерүе, сугыш һәм аннан соңгы чорда күпләрне ач үлемнән йолып калган ризык булуы, бик күп "тере" витаминнарны үзендә саклавы өчен ихтирамга лаеклы үсемлек икәнен истән чыгармыйк).

Яңа урыннарны үзләштерүчеләр авылларына атама таба алмый интеккәннәр, шуннан тезелеп киткәннәр: Яңа Әлмәт, Яңа Әмзә, Яңа Карамалы, Яңа Каргалы, Яңа, Урта, Кече Тигәнәле... Иске Әлмәт... Бөгелмә Әлмәте.

Кычытканлы авылының янә бер "милли" үзенчәлеге — аның олы юллардан ифрат еракта, "җәһәннәм" читендә урнашкан булуындадыр.

Аңа тиз генә зыярәт кылып кайтырга уйлаган беркатлы кешенең, алданганнан соң, тиз генә кияүгә чыгу турында хыялланган, ышанучан кыз бала көненә калуы ихтимал. Дөрес, барлык юллар Римгә алып бара дигәндәй, Кычытканлыга күп төрле хәрәкәт чаралары белән кайтып була. Тик җиңеле, ансаты миңа мәгълүм түгел. Иң ышанычлы саналган тимер юл белән кайтырга ниятләсәң, бер тәүлеккә якын кара вагонда дык-дык килеп иләнгәннән соң, район үзәге Нурлатка килеп төшәсең, аннан инде Кычытканлыга... нибары 60 чакрым юл кала. Әмма син атнасына бер-ике бара торган автобуска соңарган булып чыгасың һәм попутка эзли башлыйсың. Бәхет мәсьәләсе синең кайсы йолдызлык астында туганыңа бәйле.

Казаннан йәисә Чаллыдан кәеф-сафа корып, су юлы белән кайтырга уйласаң, рәхим итеп, Чистайда төшеп, шулай ук очраклы машиналарда 120 чакрым баганалы, тузанлы юлны үтәргә тиеш буласың.

Җомга көн кич белән, җиңел машинаңа утырып сәфәр чыксаң, Саескан тавында паром көтеп куныл, борынгы Болгар юлына чыгасың да, Базарлы Матак, Алпар, Колбай-Мараса, Карамалы, Яңа Әлмәт кебек авылларга сәлам индергәннән соң, Кычытканлыга кайтып егыласың.

Әтрафлы мохиттә туган авылыңны яманлау, рәнҗетү кабул ителмәгән. Һәркайсының үз яме, матурлыгы, күңелгә ятышлы хикмәтләре бар. Берәү дә милләтен, ата-анасын, туасы ятагын сайлап ала алмый. Анысы Хак Тәгалә кулында.

Дөрес, күктән йолдыз чүпләп, коянтә-чиләге белән айда адашып калган Зөһрә кызга "запросто" күз кысып йөргән гаярь студент елларында, каникулларга кайтканда, тымызык салкыннарда, кар бураны уйнаганда яисә челләдә узгынчы машина, трактор, һич югында ат көтеп утырганда, бабайларны "карадагынай урман" эченә, кычыткан аланына килеп утырганнары өчен, яшерен-батырын гына "тәнкыйть утында" көйдергән чаклар булгалады. Беткәнмени Чулман, Нократ буйларында, Чистай тирәсендә, кара туфраклы, балыкка бай сулы, тал-тирәкле урыннар, һич югында тимер юллы Нурлат ышыгында берничә мең гектар чирәм җир табылмаган булыр идемени? Хәрәкәт "әсбабларын" көтү озакка китеп, суык, аяк аша үрмәләп, җелеккә, бәгырьгә менеп җиткән мәлләрдә, яшь зиһен үзенең кырыс катгыйлыгында чал тарихка ук кереп китә: "Ерак бабаларыбызны әйтим инде, үзләре үстергән йөзем белән карбыз, кавын белән хөрмә тәмләп, рәхәтләнеп җылы якта каласы урынга, яшәү өчен җайсызрак, җәе, тиле яшьлек төсле кыска, кышы ялгыз картлык мәсле озын-озак тоньякка күчеп утырганнар. Чаяланып киткән төрки телле хәзәрләр, вакытлыча бәйдән ычкынган гарәпләр белән уртак тел табып, иелгән башны кылыч кисмәс дип, буйсынган булып, Каспий, Азау диңгезе буйларында, Таман ярыматавында калып булмадымы икәнни? Бабаларыбыз авыр киләчәкләрен, язмышларын эзләп, Урта Идел буена менгәннәр. Җылы якларда калган булсак, дөнья Президентлары үзләре безгә кунакка, кояшта кызынырга килерләр иде".

Салкын кышлы якка күчеп килүләре өчен эчтән әрләсәм дә, туып-үскән җиребезне "бетереп" ташлавым белән артык кызып китүемне дә аңлыйм. Чит-ят җирләргә сәфәр кылганда, Татарстан табигатенең иннек-кершән якмаган кыз шикелле тыйнак матурлыгын, мул сулы елгаларын, болын-тирәкләрен сагына башлыйсың. Согуд Гарәбстанының ялангач таш юл, таулардан торган, бездә кызыл кирпеч сугарга гына яраклы балчыктан "ясалган" җирен күреп, 60 градуслы эссесеннән әлсерәгәч, үзебезнең май аенда гәүдәгә матурланып килгән укучы балалар, июньдә оялчан киленнәр, июль-августта тәненә сыеша алмаган хатыннар кебек гүзәл, төс-бизәкләргә бай табигатебезне юксынасың, сагынасың. Без әле аның кадерен белеп бетермибез!

Җиребез куенында шифалы су чыганаклары бик күп икән. Ә без, хакимият башлыкларын, башка дәрәҗәдәге җаваплы түрәкәйләрне, су эчәргә, көчләп диярлек Чехиягә озатабыз. Шул чыгымнарны үзебезнең

жирле санаторий-курортларда калдырсак, җөмһүриятебездә әллә ничә менә дигән ял урыннары тернәкләнер иде. Ульян өлкәсендә “Ундор” (“ындырдан” үзгәртелгән) ял йорты бар. Суы ифрат файдалы, диләр. Рекламасы заманча дәрәҗәдә куелган, күрәсең. Бу санаторийда Татарстаннан, шул тирә як кешеләре, бигрәк тә “кара май” чыгаручылар күпләп ял итә. Баксаң, бу сихәтле эчемлек безнең Тәтештән килә икән. Без суын озатабыз, ә кемдер аннан акча “суга”.

Гафу, гафу... читкәрәк киттем. Сүзем Кычытканлы авылына кайту михнәтләре турында гына иде ләбаса.

Һәр шөгыльнең бер начар, бер яхшы ягы бар шул. Патшалар мәхәббәте кебек. Юл матавыкларын исән-сау үтеп, Кычытканлыга кайтып егылсаң, тиз генә кире чыгып китәсең килмәс... Бердән, ифрат арыган, йончыган, талчыккан булырсың, икенчедән, өйдән-өйгә йөртеп чыкмыйча, кунакчыл авыл халкы сиңа чыгу капкасын ачмас. Инде “авылыгыз бигрәк еракта, галәм читендә урнашкан, кайтсаң — китеп, китсәң — кайтып булмый”, — дип зарлана башласаң, авыл фәлсәфәчеләре синең белән һич тә килешмәс, “тау башында үскән иң озын агач башына менеп карасаң, чуаш Юхмачасы, Базарлы Матак, Ульян Мәләкәсе, икенче якта Самараның чите күренеп тора, Бүләр районы исән чакта, безгә үзәк якын иде, хәер, налог салымчылары хәзер дә бер дә ерак дип тормый әле, вакытында килеп җитә”, дип тәфсилле аңлатма бирерләр. Ашыкмыйча, Муллалар тавыннан искән, куенга сарылып иркәли торган җилгә кытыршы битен куеп сөйләшергә яратучы мәчет картлары, иншалла, әлегә бар. “Җир шарында ике матур авыл булса, һичсүзсез, знамо дило, шунын берсе Кычытканлы”, дип тә өстәргә күп алмаслар.

Авыл илсөярләре урманнарның киселеп, кырылып, черетелеп, бетүгә йөз тотуы турында тел шартлатып сөйләмәсләр, мактанырлык нәрсә түгел. Кычытканлы халкын сихәтле чәй белән сыйлап торган умырзая аланы чәчү планын үтәү өчен генә сөреп ташланган, үзендә берни үстерелми. Чишмә бәреп чыккан тау читендә үскән, яшьләрнең мәхәббәттә аңлашу шәмдәле карт имән дә юк инде.

Чыннан да, үз вакытында авыл урманга бай булуы белән тирә-якны көнләштереп яшәгән. Шомлы, серле, адаштыргыч кара урман халыкны ашаткан, җылыткан, киендергән, ачлык, сугыш елларында үлемнән саклап калган. Андагы җиләк-җимешнең, чикләвек-гөмбәнең исәбе-хисабы булмаган. Урман халыкның яшәү рәвешен, зәвыгын, дөньяга карашын тәрбияләгән, әхлагын калыплаган. Шуңар да Кычытканлы элек-электән тигез итеп сайланган, бер-беренә ипле ятышкан, гәрәбәдәй сары бүрәнәле дүрт почмаклы йортлары, кояшка караган тәрәзәләре белән генә түгел, балта осталары белән дә тирә-якта дан тоткан. Юкә күплектән чабатаны матурлап, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәреп үрә белгән бабаларыбыз. Шул ук агач мунчаласыннан аркан, бау, киндер ишкәннәр, кап сукканнар, сука, тырма, тубал кебек җир эшкәртү, чәчү әсбаплары да урманнан “килеп” торган.

Урмансыз авыллар булса да, кечкенә генә инеше, суы, елгачыгы, тирәннән, җир куенынннан күтәрелгән шифалы сулы чишмәсез татар авылы юктыр дөньяда. Кычытканлы бу тарафтан да бәхетле. Аны ике яктан елгачыклар иркәли. Берсе — Кече Чирмешәнгә коя торганы — “Мораса елгасы каян башлана”? —дигән сорау белән дәреслекләргә кергән. Кычытканлы укучыларының җавабы әзер: “Каян булсын, безнең урманнан, суы бәреп чыккан урында булганыбыз бар”.

Олы елгалар белән бәйгегә чыгарлык дәрт-дәрманнары булмаса да, бу инешләрнең тегермән әйләндерерлек, балык үрчетерлек, мал-туар эчерерлек, каз-үрдәк үстерерлек һәм бала-чагага пычранып кайтырлык сулары бар иде мин яшь чакта. Аларга тау итәкләреннән, урман эченнән бәреп чыгып, ак күбекләрен һавага чөеп, ничәмә чишмә килеп кушыла. Чишмә суы җыелган иңкүлек төбендәге ташлар кояш нурларында иркәләнеп, күгелҗем, энҗе, алтын, көмеш төсләргә керәләр.

Менә шул хакта да сөйләми калмаслар картлар авыл кунагына. Әле илленче елларда да бу инешләрдән чуртан, чабак, кызылканат ише балыкларны гади сәнәк белән чәнчеп ала идек. Сугыш чорында шактый кешене ач үлемнән коткарып калды елга балыклары. Марсель Галиев әйтмешли, "тәм хәтере" һаман саклана. Иң кызганычы: урман киселде, елгалар кипте, балыклар бетте... Күңелдә әллә ниткән моңсулык. Кешелекнең кая баруын Кычытканлы кебек урман куенына кереп оялаган авыл язмышыннан да чамалап була. Аның тарихы турында язма истәлекләр, хатирәләр сакланмаган диярлек. Татар халкының чын тарихы — авыллар тарихы. Һәр авыл язмышында халыкның үткәне, милләтнең халәти рухиясе күзгедәгедәй чагыла.

Сәбәбе аңлашыла булыр: һәр дәвердә җиңүчеләр көч һәм мәдәният, алдынгы фикер һәм борчу үзәкләре булган калаларны юкка чыгарганнар; кылыч аша уздырылмаган, исән калган җирле халык сөрелгән, куып җибәрелгән, китапханәләр, язма-басма истәлекләр яндырылган, урлап кителгән.

Тормыш итү өчен җайлы урыннарга басып алучылар күчеп утырган. Болгар, Биләр, Казан, соңрак төзелгән Бөгелмә, Чистай, Алабуга шәһәрләре шул сәясәтнең ачы җимешләре, шул тәҗрибәнең моңсу шаһитлары. Заманында мөстәкыйль дәүләтләргә исем биргән беренче ике шәһәрдә татар-болгар кешеләре бөтенләй калдырылмаган. Казан тирәсенә дә татарның әрсез балалары соңгы гасырларда гына килеп урнаша башлаган. Анда да явыз хәтерле коммунистлар республикага исем биргән халык вәкилләренә мантып китәргә, сан ягыннан булса да өстен чыгарга бирмәгәннәр: хәрби заводлар китереп салганнар, хәрби училищелар утырткannар, Короленко, Волгоградская һәм башка урамнарда биек-биек йортларны Камчатка, Сахалин кешеләренә сатканнар...

Үз милли шәһәрләре булмаган халык дөньяга танылa, парламентларда яңгырый алмый. Халык күп яши торган хәрби-мәдәни үзәкләрне юкка чыгару халыкның хәтерен юуның, тарихын бозуның иң ышанычлы, сыналган алымы.

1552 елда Казан ханлыгы егылмаса, мөэмин-мөселман халкын көчләп чукындыру башланмаса, җир шарында, бәлки, XVI — XVII гасырлар алышыну чорында Кычытканлы дигән сәер исемле авыл да барлыкка килмәс иде. Кем инде үз ихтыяры белән, яшәгән урынын ташлап, һәр яктан урман китереп кыскан, иген игү өчен артык җайлы булмаган урынга күчеп, беренче мәлне, бурсыклар төсле, җир базларында яшәргә разый булсын, ди. Язмыш йөртә шул адәм баласын. Телдән-телгә күчеп килгән риваятьләргә, нәселле гаиләләрдә сакланган шәҗәрәләргә, авыл халкы бик кадерләп, карап тоткан зыяратта калган язмаларга игътибар иткәндә, хәзерге Кычытканлы урынына кыю, үткен гаиләләр Болгар якларыннан һәм, бигрәк тә, хәзерге Әлки районына кергән Үзи авылыннан күчеп утырганнар.

Район үзәгендә, Нурлатта чыга торган "Дуслык" газетасы Кычытканлының үткәне хакында болай дип язган иде: "Бу —тирә-ягы кеше үтәлмәс карурманнар белән капланган, кычыткан һәм әрем котырып үскән бердәнбер алан булган. Биредә беренче килүчеләр яр буена землянкалар казып, үзләренә тору өчен урын, агачлар төпләп җир хәзерләгәннәр, игенчелек, терлекчелек, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр. Халыкның төп терлекләре — кәҗә, сарык булган" (1980 ел, 18 июнь). Урман юлларында төрле кавемнәр, шивәләр очрашкан, катнашкан, аралашкан, кан куерган, тел баеган. Туган авылым сөйләшендә мишәреңә хас ягымлы төсмер-бизәкләр, ызба, чәпәк, кәнди, наным, әзи, гөмбахар, нүеш кебек "списифик" сүзләр булса да, аның теле Чистай якларыннан, хәтта күрше Әлмәт, Әмзә авыллары сөйләменнән йомшаграк, әдәби телгә якынрак.

Авыл тирәсеннән алтмышынчы елларда көбә күлмәкләр, сугыш балтасы табылу аның тарихлы булуына ишарә ясый. Җире бодай кебек нәзберек бөртекне үстерү өчен бик үк кулай булмагач, арыш, житен,

киндер, арпа, көнбагыш чәчкәннәр, умартачылык, балыкчылык, аучылык белән шөгыльләнгәннәр. Урманында болан, аю, бүре нәселләре гөжләп торган. Куян, төлке ишене җәнлеккә дә санамаганнар. Буыннан-буынга сөйләнә-сөйләнә безнең көнгә шундый хикәят килеп җиткән.

Чиллә. Тубал төсле зур кояш түбәдә эленеп тора. Рәхимсез яндыра. Хатын-кыз артны-алны карамыйча, ду килеп, урак ура. Ирләр ындырда, чабагач белән арыш суга. Шул мәлдә яннарына, арыш чүмәләләре артыннан, арткы аякларында көрмәкләнеп, олы бер аю килеп чыкмасынмы. Һөҗүм итәргә ашыкмый. Алгы аякларын, өйрәтелгән биюче аюдай, өскә күтәргән килеш тик басып тора. Усал нияте, чибәркәйләрнең берәрсен урлап китәргә омтылуы сизелмәсә дә, чыр-чу, тавыш куба. Һәркем качып котылу җаен карый. Кычытканлы аюлары хәйләкәр мишәр токымыннан булгандыр, мөгаен, шылу хутын алдан ук бикләп куйган булалар. Як-яктан, кизүдә янә ике йөнтәс басып тора икән. Ә тегесе шыңшып, гасабиланып, күз яшьләрен агыза-агыза нәрсәдер әйтмәкче була. Теле генә юк, имди. Шунда хатыннарның иң чаясымы, чит ир-атка күз ташларга яратканымы, анысы инде гасырлар сере, аю ягына борылып карый. Бахырның бер аягына имән агачы кыйпылчыгы кадалган да, шуны алуны үтенә икән. Бар кыюлыгын йөрәгенә төйнәп, ханым аю янына килә, башыннан сыйпый, шырпыны тартып ала һәм яраны башындагы яулыгы белән бәйләп тә куя (һәр кавем, табигый ки, барча көрәшен үзен Борис Годунов оныгы, дип санаган мәсле, "ул хатын безнең нәселдән булган", дип раслый). Икенче көнне аю хатынга кыргый бал тәпәне күтәреп килә. Үзе белгәнчә, аңлаганча, булдыра алганча рәхмәтен әйтә, ихтирамын белдерә. Кеше үзе турында хатирәне туачак буыннарга табигать сыны, аңа биргән атамалар аша китереп җиткерергә тырышкан. Хабетдин сукмагы, Бәшир юлы, Хәматша канавы, Хәлил ызаны, Зилә умарталыгы, Вәли умартасы, Муллалар тавы, Мулла чишмәсе кебек исемнәрнең артында куәтле шәхесләр торганны чамалавы кыен түгел. Халык теленә кереп, сакланып калуның җинел түгел икәнен чамалыйлар затлы нәсел балалары. Авылның Чебил дип аталган калкулык өлешендә заманында чуашлар яшәгән, диләр. Хәзер аларның теленнән менә шул урын атамасы гына калган, үзләре эрегән, сеңгән, күчеп киткән.

XVIII гасырда авыл халкы лашманчылыкка тартыла. Калын-калын имәннәрне 20-30 ар ат бергә тартып, Чистайга китерәләр, аннан агачлар Русиянең яңа башкаласы Санкт-Петербург нигезенә, субайга озатыла. Җан тартмаса, кан тарта, диләр. Кычытканлы урманыннан киткән имәннәр якташларын "чакырып" алганнар. Безнең авыл халкы, Мәскәүдә Сергач мишәрләренә көндәшлек тудырмыйча, күчеп утыру өчен Русиянең рухи башкаласын сайлаган. Кычытканлыдан чыккан нәселләрнең токымнары шактый яши Питерда. Кыз фамилияләре буенча Галиуллина Фатыйма, Рәйсә апалар балалары, оныклары белән шунда дөнья көтәләр. Араларында фән кандидатлары бар. Халыкның бер өлеше Урта Азиягә күчеп китә, үзбәк, кыргыз, таҗик халкына хезмәт итә. Урал ягына юл алганнары башка халыкның санын арттыра.

XX гасыр башында, сәүдә тәмен сизеп, кесәләренә акча төшергән авылның хәлле кешеләре агач йорт белән тарихта калып булмасын аңлап, балчык эшен, кирпеч сугуны җайга салганнар. Кычытканлының кыл уртасында кызыл кирпечтән эшләнгән ике ташпулат пәйда була. Берсен Шакир бай, икенчесен элгәре белән ярыша-ярыша Шәһит бай өлгертә.

Озак еллар дәвамында колхоз идарәсе, авыл советы, сату-алу оешмалары — хуҗаларының берсе атылган, берсе сөрелгән шул ике бинада яшәделәр. Соңгы ун-унбиш елда гына яңа таш йортлар үсеп чыкты. Агач хәзер мунча салу, койма кору, мич ягу өчен генә тотыла. Кычытканлы халкы да янәдән "таш гасыр" заманына күчеп бара.

Кайсы гына районны бизәми Кычытканлының эшчән халкы. 1930 елда ул яңа оешкан Биләр районына кертелә, 1935 елдан Тельман (үзәге Мамык авылы) вилаятен бизи, Хрущев башбаштаклыгы заманында. 1958

елда, янә Биләр районына кушыла. 1962 елдан бирле Нурлат районының көньяк чикләрен саклый. Сәясәт дөньясындагы йомычка диярсең, ничек кирәк, шулай бутыйлар.

XX гасырның шаукымлы жилләре Кычыткanлыга да килеп житә. Авылның гаярь егетләре Беренче дөнья сугышында катнаша, Махно, чех фетнәләренә каршы көрәшә, басмачылар дип аталган милли хәрәкәтне бастыру кебек пычрак эшләргә тартыла. Һәр авылның үз батыры булган кебек, Кычытканлының да Жиһангир Рәжәпов атлы, Октябрь борылышына ихластан инанган, аның җинүе өчен янып-көеп йөргән кызыл комиссары килеп чыга. Табигый ки, аның язмышы фажигале бетә: хәлле авылдашлары тарафыннан сатылып, качкан жиреннән алдап чакырылып, ул дошман кулына эләгә, чехлар тарафыннан атыла.

Икенче дөнья сугышында Кычытканлының 115 ир-егете чит-ят жирләрдә ятып кала. Һәр йортка диярлек бер югалту. Беришесендә икешәр, өчәр... Кем өчен, нинди бәхетле тормышны яклап һәлак булганнарын берәү дә белми, аңлата алмый.

Авылның тагын бер үзенчәлеге — аңга-белемгә омтылу. XIX йөзнең икенче яртысында ук, авыл картлары Чистайга барып, Бикчурин фамилияле мулла алып кайталар. Ул Кычытканлыда тирән тамыр жибәрә. Күрше авылларда да аларның нәсел жепләре укыту-агарту эшенә мөһим өлеш кертә. Вәли агай Кычытканлыда беренче мөстәкыйль мәктәпкә нигез сала. Тарихта Бикчура атлы, монголларга каршы сугышкан хан исеме сакланып калган.

Безнең якта шактый киң таралган бу фамилияне йөртүчеләр әле дә аз түгел. Исхак Бикчураны галимнәр, язучылар Тукайга нисбәтән еш телгә алалар. Аның турында, фәнни хезмәтендә, М. Мәһдиев язып чыккан иде. Р. Батулланың "Кылдан нечкә, кылычтан үткен" повестендә дә бу шәхескә зур урын бирелә. Ул — еш кына салмыш хәлендә Тукай бүлмәсенә килеп керә, үзен артык иреклe, дорфа тота. Кыскасы, безнең алда үз кыйбласын таба, билгели алмаган шәхес. Ничек кенә булмасын, ул зыялы, Тукайның якын кешеләреннән берсе. Аның үз-үзенә кул салуы чынбарлыкны катлауландырып кабул итүеннән, үз юлын барлый алмавыннандыр.

Шул нәселнең ботак очы, дәвамчысы Нәриман Бикчурин мәктәп директоры булып бик яхшы эшләде, озак еллар Нурлат районының мәгариф бүлеге мөдире вазифаларын башкарды. Чын мәгънәсендә интеллигент, эш өчен янып-көеп йөри торган кеше иде. Русчасы яхшы, дөнья тарихын, татар тарихын чыганаклар буенча белүе белән хәтердә калган. Ул вакытта Исхак Бикчура турында белми идем. Нәриман Вәли улыннан сорап кала алмадым.

Элек-электән мәгърифәт үзәкләре булып, тирә-юньгә нур чәчеп утырган мәдрәсәле, мәктәпле авыллардан үрнәк ала-ала, Кычытканлы халкы аңга, мәгарифкә тартыла. Югары белемгә омтылыш аеруча көчле. Яхшылыкка омтылучан халык яши бирeдә. Нәтиҗәсе күз алдында: авылжөмһүриятебезгә ике фән докторы (филология һәм медицина буенча), журналистлар, хакимият хезмәткәрләре, абруйлы житәкчеләр, белгечләр бүләк итте. Егерме бишләп колхоз, совхоз рәисе генә чыккан икән Кычытканлыдан. Галиуллин Әсхәт Түбән Кама, Әхмәтвәлиев Марат Югары Ослан районнарында авыл хуҗалыгы идарәләре житәкчеләре булып эшләделәр. Алар хәзер дә җаваплы хезмәттә. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган, жөмһүриятнең күренекле авыл хуҗалыгы белгече Вәлиев Фалис турында ишетмәгән кеше юктыр. Озак еллар дәвамында ул мәктәп директоры, колхоз, Зәй районының райсовет рәисе булып эшләде, хәзер совхоз директоры, халык депутаты. Көче, дәрте ташып торган бу шәхеснең авылдашларына ярдәме күп тиде. Оргсинтез заводында элек эшләп чыгару цехы башлыгы булган, үзгәртеп коруның, базар мөнәсәбәтләренең рухын аңлап, түмен беренчеләрдән булып татып, хәзер үзенә мөстәкыйль тармак ачып чыккан "яңа бай" Рәшит Ваһаповның да якташларына ярдәме тияр дигән өмет бар. Ул

атаклы татар артистының исем, фамилиясен юкка гына йөртми, үзе дә җырларга ярата.

Халык авыллардан күпләп күчеп киткән чорда да Кычытканлы йорт һәм яшәүчеләр санын киметмәде. Урта мәктәп тотарлык балалары да туа, үсә тора. Тик яңа бер вәзгыять туган: буйдак ир-егетләрнең саны арта бара икән. Кыз-кыркыннар урта мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә юл тота. Югары уку йортына керә алмаганнары техникумга, училищега башын тыга, һич югында эшкә урнаша, мәгәр туган авылына кайтмый.

Егетләрне армия көтә. Хезмәтен үткәннән соң, кичәге солдат, кирза итекләрен аркасына асып, туган авылына, карт әти-әнисе янына кайта. Ул аларны үз гаиләсе саный, ташламый, авылдан китми. Хатын-кыз өчен гаилә учагы бөтенләй башка төшенчә. Ата-анасына мәхәббәте, дөньяга китереп, үстергән өчен рәхмәте чиксез булса да, аның аң төпкелендә үз токымы —ире, туачак балалары шәүләсе утыра. Кызык кына хәл килеп чыга: илдә элеккечә үк хатын-кыз ирләрдән сан ягыннан күпкә артык (алар сигез-ун елга озаграк яшиләр), ә Кычытканлы газиз башларын кая куярга белми каңгырып йөргән, хәсрәтен бастыру өчен кибет ягына юл тоткан буйдак ир-егетләр белән тулы. Үзенә күрә бер фаҗига. Җөмһүриятебезнең социологлары шуны тикшереп, бу хәлгә бәя бирергә, яшьләргә киңәшләрен әйтергә, чыгу юлын күрсәтергә тиешләр дип уйлыйм.

Хәтер йомгагына уралып үткәндә калган балачакны искә алу, юксыну — туган авылыңны сагынудан башлана икән. Мин дә, башка юеш борынлы яшьтәшләрем кебек үк, дөньяның бар матурлыгы безнең авылга бирелгән, иң гүзәл, күркәм төсләре безнең елгаларга, болыннардагы чәчәкләргә иңгән дигән ышанычта үстем.

Иртәләрен кошлар, бигрәк тә сандугач сайравына түзәрлек түгел иде. Мактаулы антик хорың бер якта торсын. Уңышсыз, сагышлы, шатлыклы мәхәббәтләр белән телгәләнмәгән йөрәк урыныннан чыгып китәрдәй булып тибә, табигать моңын үзенә сендерә. Кичләрен Кычытканлы күген алмаз белән энҗе-мәрҗәннәр бизи. Кара урманның явыз шәүләсе күңелгә сагыш бөрки, билгесезлек рухын индерә, хәятның мәңгелегенә инандыра. Күкне каз мамыгы түшәгедәй калын болытлар каплаганда да үз йолдызыңны эзләп табасың...

Урамнарны, йорт эчен, каралты-кура тирәләрен ямь-яшел, Иран келәме төсле калын каз бәпкәсе үләне каплаган. Язгы, көзге пычраклар сизелми дә, аяктагы ләмне чирәм "ялап" ала, тузанны да, юеш туфракны да үзенә сендерә. Балачак кебек ямьле, тәмле үлән өстендә мал-туар шаяра, чүл гарәбе кебек чем кара эт малае Тузик аяк астында бутала, чуаш хатыннарының Хужалар тавына табынырга барганда кия торган күлмәкләре шикелле чуар кикрикле әтәч-патша бик вәкарь генә тавыкларын-хатыннарын барлый.

Без үскән авыл шундый иде, хәзер ул юк инде. Түшәме салам, юкә кабыгы белән капланган, җиргә сеңеп утырган йортларны сагынуым түгел. Мине танымый торган яшь буынның үсүе, ике катлы таш мәктәп, бик күп кирпечтән салынган башка биналар корылуы табигый. Тормыш яхшы якка үзгәрә. Әнә кече энебез, агроном Әхәт, "барыгыз да шәһәргә тайды, мине генә авылда, төпчек малай буларак, әти-әнине сакларга калдырдыгыз", — дип зарланып йөрде-йөрде дә, ак, кызыл кирпечләрдән менә дигән коттедж салып куйды. Алпавыт ташпулаты аның йорты янында мескен бер хибарка булып калган. Әхәтне шәһәр кызыксындырмый, аркан белән сөйрәп китереп булмый. Вакытында кайнар мунчасында, каен себеркесе белән аркасын иркәләп, агу кушылмаган шпиен, үзе үстергән әтәч ботын кимереп, өч бала үстереп ята. Бар борчылганы: "оланнар биредә калмас шул, укырга Казанга китәрләр. Саматны монда калдырасы иде".

Әхәтнең кече малае — Самат "особый" малай. Ул әтине күмгән көнне, өченче майда дөньяга килде. Төшкә кадәр әтине җиргә тапшырдык, өйләдән соң Нурлат хастаханәсеннән "Сания малай тапты", дигән хәбәр алынды. Без әтинең изге жаны онызына күчте, дип юрадык. Мәңгелекнең

адәм баласы аңлап, таныш житкерә алмастай әллә нинди серләре бар. Нәсел башлыгының фани дөньяны ташлап киткән көнне анын дәвамы тууы очраклы хәлме? Әллә бу туры килүнең нииндидер тирәнрәк серләре бармы? Татар халкы яшәде һәм яшәячәк дигән билге, ишарә киная түгелме?

Балачакнын, олы дөнья мәшәкатьләре белән маңгайга-маңгай бәрелгәч кенә, соңарып аңлый, бәяли торган үзенчәлек-сыйфатлары күп икән. Үзеңнең кылмаган гөнаһлары, эшләмәгән явызлыклары өчен каһәрләнгән, тарих читенә кысрыкланган, башка милләтләргә яхшылык-лары өчен рәхмәт ишетмәгән халык баласы икәнеңне белми, аңламый үсәсең. Татар мәктәбендә белем эстәп, барча фәннәрне анаң телендә үткәч, борынгы лөгатеңнең юкка чыга, йотыла баруыннан бихәбәрсең, үзеңне әдәбият, тарих, география фәннәре буенча таныш башка халыклар белән, урмандагы агачлар, көтүдәге маллар кебек, тигез хокуклыга санап йөрисең. Жиденче сыйныфны тәмамлаганчы, синең өчен олы дөнья — кыр капкасы белән Муллалар тавы һәм ике инеш арасына сыя. Барча бәхәсләр, дөньяви вәзгыятьләр Түбән як белән Югары оч һәм Чебил малайларынын кичке, төнге очрашуында, кечкенә йодрыкларнын күбәләкләрдәй һавада очышында, каядыр килеп төшүе барышында хәл ителә.

Кычытканлыда хәзер унъеллык мәктәп гөрләп эшли дигән идем. Безгә андый бәхет тәтемәде. Сигезенче сыйныфка күрше авыл — Яңа Әлмәткә йөрергә мәҗбүр булдык. Белемен дәвам итәргә теләгәне инде, әлбәттә. Көчләү юк. Беренче елларда хәтта уку түләүле иде.

Ике авыл арасы — биш-алты чакрым. Шул юлны көненә ике тапкыр үтәсе. Язын, көзен, табигать адәм баласына кемлеген күрсәтеп, елгаларын ярларыннан бәреп чыгарганда, Иске Әлмәт авылы аша әйләнеп йөрергә туры килә. Андагы кешеләр үзгәрәк тормыш белән яшәп, башка телдә сөйләшәләр икән.

Хәер, син укый торган мәктәптә дә урыс класслары бар, аларда күбрәк татар балалары, кемнәрнеңдер газизләре укый. Соңрак, киләчәкне билгеләү, һөнәрле булу дигән диварга килеп төртелгәч, ошбу аксөякләрне ата-анасынын, максатчыл рәвештә, уку-укыту эшләрен урысча гына алып баручы югары уку йортларына әзерләгәннәрен аңлыйсың. Бәгырең, тургай хәтле генә йөрәгең, үзенә беренче агулы укны ала: синең телең ачылган, мөкиббән киткән аралашу чарасының дәрәҗәсе, даирәсе кыр капкасын чыгуга бетә, абруе иртәнге рәшә төсле юкка чыга икән.

Кемдер үпкәләр, бәлки рәнжер (борынгылар: "Әфләтун син хаклы, тик дөреслек беренчел", дигәннәр), әмма татарыңны сыйфатлаучы бер аянычлы, "кәфер" күзәтүем белән уртаклашмый булдыра алмыйм. Бу — алдан күрүчәнлекме, үзеңне саклаумы, яраклашумы, әллә Алтын Урда дәвереннән килгән сатылумы, ахыр бәяне өстемә алмыйм, мәгәр Чистай-Нурлат төбәгенең укымышлы, абруйлы, дәрәҗәле гаиләләре балаларын татар мәктәбендә, татар телендә укытмады. Кагыйдә буларак, әти-әниләре Кычытканлы, Яңа Әлмәт, Шәрбән кебек чиста татар авылларында, татарча дәресләр алып бара. Ник берсе, кәмит өчен, чагыштырып багу өчен булса да, баласын татар сыйныфына биреп карасын. Әлеге авылларда урыс класслары булмаса, баланы биш-ун чакрым тәпи-тәпи йөртеп булса да, үзгә телдә укыткан мәктәпкә тапшыралар. Татарча белем алуга, татар теленә тискәре мөнәсәбәт "сеңдерү" эшенә авыл педагоглары мөһим "өлеш" кертте, дип уйлыйм.

Халык аларны монафыйклыклары, икейөзле булулары өчен яратмый, татар теле белән тамак туйдырган кешеләрнең лөгатебез өчен көрәшәсе урынга, шәхси "примирлары" белән аның тамырына балта чабуын гафу итә алмый.

Салмыш колхоз рәисе, аумакай авыл советы хезмәткәре, кибетче, хисапчы кебек авыл зыялысы балаларын "ходай ташламаса, дуңгыз ашамас" дип, татар мәктәбенә бирергә мөмкин. Алар ким-хур булмадылар, араларыннан халкыбызның йөзек кашы булырдай кешеләр аз чыкмады. Укытучылар катламы мондый ташламага бармады. Сәвит чорында бер төрле

сөйләп, үзгәчә яшәү — татар зыялысының (әлбәттә, аның гына түгел) бер мотлак үзенчәлеге иде.

Шул ук вакытта, дөнья барышын, җәмгыяви үсеш юнәлешен сиземләве көчле, гаклый ата-ананы артык кырыс тәнкыйтьләү дөрес түгелдер. Алар да замана балалары. Сер түгел: кесәсендә татар мәктәбен тәмамлау турында таныклык йөрткән сәләтле бала югары уку йортына үтә алса да, аның ике-өч ел гомере урыс телен ныклап үзләштерүгә сарыф ителә. Ә иҗтимагый шөгыльгә, аерым алганда, комсомол җитәкчелегенә, өлгерләрне түбән курслардан "чукып" алалар. Татар телле студент бу чакырылышка эләкми. Шуңар да комсомол өлкә комитетының сәркатибләры арасында милли мәктәп тәмамлаган кешеләр булмады. Җитәкчелеккә үрмәләү өчен урысчаны шатырдатып белү, телең телгә йокмау, акцентсыз сөйләү — төп шартлардан иде. Партия аппаратында да шул ук хәл иде.

Бүген дә яшьләр белән эшләү комитетында хәлләр әлләни үзгәрмәде. Анда да татарча белүнең хаҗәте дә, ихтыяҗы да юк. Бу инде татар теле гамәлгә керүдән ерак тора дигән сүз. Вәзгыятьне үзгәртү өчен татар телле югары уку йортларын булдыру лязим.

Урыс телен үзләштерүдә мин үзем зур кыенлык кичермәдем. Аңламаган сүзләрне сорарга әүвәл Галиулла бабам, аннан әти бар иде. Иң зур рәхмәт хисләре Кычыткалының урыс теле укытучысы — Фоат Шәһиевка. Ул үзенең камил методикасы белән генә түгел, кырыс, таләпчән холкы, дәрестә гел "чит телдә" сөйләшүе белән дә урыс лөгатенең нечкәлекләренә керергә ярдәм итте. Мәктәптә аңардан куркып, дер калтырап торалар. Ә кичен ул иң абруйлы кеше, авыл халкына һәр "пәрдәдән" соң, кинофильмны татарчага тәрҗемә итә. Беренче рәтләрдә буш урыннар булса да, без Фоат абый яхшырак ишетелсен, аңлап барылсын дип, аның тирәсенә, идәнгә утырабыз, тезләнәбез, балык төсле сузылып ятабыз.

Базар мөнәсәбәтләрен яхшы үзләштергән киномеханик Фоат абыйдан билетка акча алмас өчен җан талаша (ә укытучыга бушлай керергә оят), чөнки ул килмәгән көнне залның яртысы буш. Тылмач юк. Нәкъ Райкинча, "кирпеч бар, раствор юк".

Менә шул кеше, хәзер инде мәчет карты, миңа урыс теленнән ныклы нигез салып җибәрде. Яңа Әлмәт мәктәбендә дә өлкән агайның лөгате бәхетле булып чыкты. Безне олы яштәге, өстенә яшел френч кигән абзый (фамилиясе Васильев бугай) укытты. Ул чорда Американың Тарзан турындагы трофей сериалын күрсәтәләр. Безнең хыялыбыз, зиһенебез Америка урманнарында, Тарзан булып кычкырулар, фил кебек мөгрәүләр, юлбарыстай сикерүләр дисеңме... Кабатламаган нәрсәбез калмады.

Урыс теле укытучысының калын иренле авызы шактый алга чыгып тора. Битендәге җыерчыклары тирән, сакал-мыегын сирәк кыра. Үзеннән гел карамель конфеты исе килә. Тәмлетамак. Шуңа күрә без аңа Тарзанның якын ярдәмчесе, яраткан маймылы исемен бирдек — Чита. Үзе юкта кушаматы белән генә атадык: Чита күрендеме, Чита бүген диктант яздырамы, Читадан өй эшен әзерләдеңме...

Вакыт узгач кына, без аны нахакка рәнҗеткәнебезне аңладык. Урыс теленнән ул безгә шактый тирән, заманча белем биргән булып чыкты. Миңа шул чүпрә унынчыны тәмамлагач, урыс заводында эшләгәндә таяныч булды. Татар теле һәм әдәбияты бүлеген бетереп, Алабуга педагогия институтында урыс әдәбиятын, аның да тоташ шигърияттән торган XIX гасыр ахырын, XX чор башын укытканда да авырлык кичермәдем.

Яңа Әлмәт урта мәктәбе мин укыган чорда күтәрелештә иде. Беляевләр нәселен җөмһүриятебездә белмәгән янсә алар хакында ишетмәгән зат юктыр. Аларның иң олысы, иң кешелеклесе, чын галим-педагог Гайнан Кыям улы озак еллар дәвамында Яңа Әлмәт урта мәктәбенең директоры булып эшләде. Үзе турында ядкарь-истәлек итеп, ике катлы таш мәктәп, тагын әллә ниләр төзетеп калдырды. Аксыл-саргылт чәчле, як-якка киткән маңгайлы, төз гәүдәле Гайнан ага барча туганнары

арасында да гаделлеге, рәхим-шәфкатьле булуы белән аерылып торды.

Үзе укыткан тарих фәнен яратып, безгә ихластан белем бирергә тырышты. Миннән тарихчы чыгар дигән иде. Тәнкыйтьче булдым.

Хатыны Әлфия апа ап-ак чырайлы, күгелҗем күзле, керт-керт атлап, үз кадерен белеп яши торган, көяз хатын иде. Безгә математикадан керде. Начар укымадым, шулай да Әлфия-укытучы "синнән хисапчы, математик чыгар", дип әйтмәде.

Энесе Рәис Чаллыда, КамАЗ төзелеше белән җитәкчелек итеп, Татарстанның күренекле кешеләренең берсе булып күтәрелгәч, Гайнан агай Әлмәт авылын Әлмәт шәһәренә алыштырды. Әүвәл райисполком рәисе урынбасары вазифаларын башкарды, аннан җитәкчелекне үз кулына алды. Шуннан, кем әйтмешли, лаеклы ялга чыкты.

Башка укытучыларымның да игелекле эзләре истәлек-хатирәләр урамында нурланып яши.

Безнең авылда Татарстанның халык язучысы, күренекле сүз остасы Мөхәммәт Мәһдиев берничә тапкыр булды. Ленинград блокадасын кичергән минем әти — Нәбиулла Галиуллин турында "Картайма әле, ветеран" исемле мәгънәле очерк язып чыкты. Мәктәптә, балалар бакчасында очрашулар уздырдык. Әле генә балалар бакчасына килгән нәниләрне башларыннан сыйпап, санап, "милләт үлми икән әле", дип сөенгән иде. Егерме бер бала... Ике йөздән артык йортлы авыл өчен күп түгел инде. Кемдер "элек Нәбиулла әзи белән аның сеңлесе Зәйнәп апада шул чаклы бала үсә иде", — дип шаяртты.

— Татар авылларына ут кертеп хата эшләделәр шул, — дип көлдерде әдип.

Һәркайсы турында аерым китап язарлык шәхесләрне күп биргән һәм бирәчәк әле Кычытканлы авылы. Аның таркалырга, үлчәргә, күчәргә нияте юк. Татар халкының моңы, көе, гореф-гадәтләре, әхлак кагыйдәләре шундый авылларда саклана. Әлбәттә, Кычытканлының әлегә Рим, Париж даннары юк. Әмма аның киләчәге өметле. Тәрәзәләре кояшка караган. Гумилев әйткән пассионарлык көче бер ачылмый калмас әле.

## "Писарь" Галиулла

Олы бер нәселгә исемен фамилия итеп калдырган Галиулла бабай мифик батыр, олы галим, халык азатлыгы өчен көрәшкә күтәрелгән милләтпәрвәр шәхес түгел. Ул хәтта генерал да була алмаган. Дөрес, Борис Пастернакның "Доктор Живаго" романында аның исемен йөрткән бер поручик сурәтләнә. Үзе ышанмаган, тузга язмаган нәрсәләргә кешене ышандыру сәләтенә ия Әфхәт энекәшнең ул поручикның безнең бабай булуында бер кәррә шиге юк.

— Безнең бабай ул. Вакыйга Беренче дөнья сугышы вакытында бара. Бабай Петроград тирәсендә сугыша, шунда яралана. Бәлки, поручик дәрәҗәсендә үк булмагандыр. Сез, язучылар, арттырырга, күпертергә яратасыз. Шуннан башка сезне кем укысын! Ни өчен безнең апалар шунда барып урнашкан, Питердә яшиләр? Чөнки анда аталарының каны тамган. Шул тарта.

Үз заманасы өчен укымышлы гаиләдә туып үскән, гадәти авыл кешесе минем Галиулла бабам. Мәдрәсәдә белем ала, вакыты җиткәч, күрше Карамалдан хатын ала. Беренче бөтендөнья сугышына ике малаен калдырып китә. Телләргә сәләте булгандыр, күрәсең. Ялкаулык хөсетенә бирелмичә, фронтта урысча укырга, язарга, сөйләшергә өйрәнә, немецка әсирлеккә төшкәч тә, югалып калмый, байга хезмәт иткән арада дошман телен үзләштерә. Соңгысын белүе ни дәрәҗәдә камил булгандыр, хәзер тикшереп булмый, шәхсән, Кычытканлыда аның алманча яхшы сукалавын шик астына алырлык кешесе табылмый ул чорда. Кушаматны тиз тагалар: "писарь" Галиулла.

Нурлатта нәшер ителүче "Дуслык" газетасында ( 1980 ел, 18 июнь) журналист Р. Нуретдинова болай дип язган иде: "Кычытканлыда революциягә кадәр аз-маз хәреф танучы берничә кеше, ә русча укый-яза белүче бердәнбер кеше — Галиулла Хафизуллин булган. Хәзер, кайчандыр надан, томана халык яшәгән авыл кешеләре арасында фән кандидатлары да байтак. Йөзләгән Кычытканлының күкрәгендә югары уку йортын тәмамлау билгесе бар".

Әсирлеккә бабай үз теләге белән төшмәгәндер дип уйлыйм. Кан саркып торган аяк ярасы үлгәнче төзәлмәде. Шуннан иң гади мантыйкый фараз: алманнар кулына ул яралангач барып эләккән.

Пленнан аны Брест солыхы кайтара. Инкыйлабны ул язмыштан узмыш юк дип, жинел кабул иткән һәм авыл советында сәркәтип вазифаларын башкаруга керешкән. Тоткынлыктан азат ителү шатлыгы чиксез булган күрәсен, бабай белән әбинең бер-бер артлы алты кызы — минем булачак "гувернерларым" дөньяга килә. Ир-егетләрнең киләчәк сугышлар өчен чимал буласын сизенгән бугай хәйләкәр карт — "писарь" Галиулла.

Герман сугышына чаклы туган уллары Нәбиулла белән Хәбибулла икенче дөнья сугышына алынып, берсе аягына төзәлмәс ярчык алып кайта, кечесе, юридик техникум тәмамлаганы, хәбәрсез югала. Эзләтүләр берниндн нәтижә бирмәде.

Мәктәптә укыганда, хәтта студент елларында, әгәренки, Хәбибулла абзыебыз исән калып, берәр бай мәмләкәткә, һич югында Төркиягә, гарәп илләренең берсенә барып урнашып, адвокат, дәүләт эшлеклесе булып, баеп китеп, үләре алдыннан туплаган малын кая куярга белмичә, варисларын эзли башласа кызык булыр иде кебек тиле фикерләр күңелгә килмәде түгел. "Без ул менә, абзый, рәхим ит, без күбәү, үзең белеп, бүлгәләрсең шунда. Янына чакыртып алсаң, яхшырак булыр. Безнең илдә рәхәтен күрергә бирмәсләр барыбер", — дип, тегенәргә хат юллыйбыз.

Кызганычка каршы, Хәбибулла табылмады, читтән берниндн байлык та безгә иңмәде.

Өй тулы хатын-кыз. Әти яшь хатыны Исламияне "багарга" әнисен һәм сеңелләрен калдырып, кырыгынчы елны ук авылдан чыгып китә. Язмыш димә инде. Әүвәл әти (мине дә соңрак насыйбым шунда китереп чыгарачак) Алабуганың кызыл үгез тиресе төсле кирпечтән салынган епархиальное училищесы бинасында сержантлар мәктәбендә укый, аннан фин сугышына озатыла, тын тартырга да өлгерми, "жиңүчене" икенче орыш үз кочагына ала, анын да иң әшәкесенә — Ленинград блокадасына эләгә.

Әти кырык өченче елда аягына төзәлмәс яра алып (соңрак аны кистерергә туры килә), өйгә кайтып егылганчы, мин апалар өчен уенчык, жанлы курчак булдым.

Барысына да бер уртак эш кушыла. Минем авыздан йотарга өлгермәгән кәгазьне тартып чыгару; кәгазьгә ихтыяж миндә бик яшьли уянган икән. Газета кисәгенме, дәреслек, дәфтәр битенме ертып алам да, өстәл астына качып, авызыма тутырам, күреп өлгермәсәләр, йотып та жибәрәм икән. Кәгазьдә нәрсә тапканмын инде? Берәр төрле витамин, тешләргә нагрузка житмәгәнме, әллә гел шул зәхмәт белән бәйле киләчәк язмышыма юл салганмынмы? Нәрсәдер бардыр. Шагыйрь әйтмешли, йолдызларны да бит тикмәгә генә кабызмыйлар.

Башка балалар шикелле үк, үземне таный, һәрхәлдә, йорттагы малтуардан аерып карый башлаганда, сугышның иң хәтәр, хәлиткеч борылыш вакыты иде. Чирле булуына карамастан, хужалык дилбегәсен кулыннан ычкындырмаган, гадел хөкемдар Галиулла бабай бердәнбер туендыручыбыз. Хөкүмәт паегы шулчаклы авызга ярты көнгә дә житми: ай күрде, кояш алды. Писарь бабам балыкчы һөнәрен иярләргә мәжбүр була.

Һәр иртән, кичен, ялалы аягын гәүдәсе ихтыярына буйсындырып, бакча артында ярсып яткан, хәзер язын гына мутланып алган елгага төшә, иң тар жиргә үзе үргән нәрәтәне куя. Вак-төяк балык картны кызыксындырмый, алары чыбыклар арасыннан шуышып чыгып бетә. Ул

һәркайсы кимендә ике-өч килолы чуртаннарны гына балыкка саный. Симез шүкәләрнең идәндә сикерешкәне, суга җибәрүне таләп итеп, койрыклары белән идәнгә шап-шоп сугулары һаман күз алдында. Хәзер бу тамашалар еракта, томан артында, әкияти дөнья кебек тоела.

Рәхмәт яугыры балыклар безнең ишле гаиләне генә түгел, тирә-күрше, туган-тумачаны да ач үлемнән коткарып калды. Көндезен ясалма җәтмәләр, бидәлләр белән без, малай-шалай, балыкка төшәбез. Дөмберт белән куып карасак та, олы чуртаннар безгә эләкми. Тәүфыйклы песигә җитәрлек тотып кайтсак, без бәхетле.

Нык игътибар, вакыт таләп иткән авыл советы эше бабайга авыррак бирелә башлый. "Фәрештә белән шайтан картаймый", дип шомартырга яратса да, һәр эшнең үз вакыты була. Галиулла карт үзен элемтә бүлегенә, хат ташучы итеп күчерүләрен сорый. Авыл советы кебек мөһим киштәрне теләсә кемгә ышанып тапшырырга ярамый. Бәрәч, анын кызы — җинел сөякле, очып кына йөри торган, төз гәүдәле Фатыймасы үсеп җиткән ләбаса. Белеме бар, урысчасы — түзәрлек. Тормышка чыгып, Петроградка күченеп киткәнче, туу, үлү таныклыклары, эш кәгазьләре анын аша узды.

Бабай бер генә бүлемле, ифрат зур, кара күн чантасын муенына элә дә, һәр ходай бирмеш көнне элемтә үзәге урнашкан Иске Әлмәт авылына юл ала. Әле без, яшь җилкенчәкләр, ике авыл арасын — бер ягы биш чакрымны — зарлана-сыктый уза идек, алтмышның өске ягындагы, аксак бабайга ул кыямәт юлы кебек тоелгандыр. Нишләмәк кирәк, олы гаиләне алып барасы бар.

Кычытканлының яше-карты, бигрәк тә хатын-кыз сугыш барган яктан хәбәр-хат көтә. Яңалыкларның иң ачысын, фаҗигалесен дә, сөенечлесен дә халыкка хат ташучы Галиулла ирештерә. Берәрсенә кара хәбәрле мәктүб килсә, намуслы, һәркемгә бәхет, шатлык теләгән, инсафлы карт үзен гаепле сизә. Әйтерсең лә, аңардан тора. Тора шул: ундүртенче-уналтынчы елларда немецны җиңеп, оясында тукмап кайткан булса, хәзер анын иленә бәреп керергә җөрьәт итмәс, революциясе дә шартламас, ике малае янында булыр иде. Өйләнеп, яшь чибәр хатыннары янында туйганчы йоклап та кала алмадылар бахырлар. Яман "сөенеч" алганнары арасында: "...лүтче иремнең, йөрәк парәмнең батырларча үлеме турындагы хәбәрне китермәсен иде чатан бабай, көтәр идем әле, може, бер әйләнеп кайтыр иде", — дип, эчтән рәнҗүчеләре булгандыр. Һәммәсенә дә Муса Җәлилнең хат ташучы Тимербулаты кебек гел шатлыклы яңалыклар гына китереп торасы иде дә, каһәр суккыры герман явызы бирәүне дә аямый.

Күпчелек хатны "писарь" Галиулланың үзенә укып, шатлыкны, кайгыны фронтовичкалар белән уртаклашып, ирләренә, туганнарына җавапны үзенә язарга туры килә.

Фин кампаниясе, 1941 — 1945 еллар афәте чорында анын кулы аша узган конвертларның исәбе-хисабы билгесез. Авыл халкы гарәп, латин әлифбасы белән сәлам хатның үзен яза алса да, урыс графикасын, бигрәк тә телен белүче юк. Карт зарланмый, аягының сызлавына түзеп, керосин лампасы, чыра яктысында җину намына яза да, яза. Авылның ул белмәгән бер сере дә калмый.

Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач дигәндәй, сигез хатын-кыз янында ир-ат затыннан Галиулла бабай белән мин генә. Ул — баш, мин анын артыннан, бер адым калмый ияреп йөрүче маэмай.

Соңгы көннәрен яхшы хәтерлим. Хәзергә чаклы бер вакыйганы исемә төшереп, оялам, кызарам.

Бабайның тамагыннан ризык үтми. Әби аңа кош теледәй кечкенә, нечкә, илләм тәмле коймаклар пешерә. Янганраклары миңа. Әби чыгып китүгә, минем авыздан сорау төшә.

— Бабай, әллә син коймак яратмыйсыңмы? Акрын ашыйсың.

Хозер Ильяс кебек ап-ак күлмәктән, киҗе юрганга төренеп утырган, ап-ак сакаллы бабам, әби киткән якка карап ала да, коймакларны миңа суза. Кайнарларын алып кергән әби канәгать: карты тамагына каба

башлаган, иншалла, терелер. Хужабикә гаип булуга, шыксыз үрдәк баласының авызы янәдән ачыла.

— Бабай, әллә коймак тәмсезме?

Минем якка янә ике коймак оча. Бу юлы тотылам. Минем арт якка, йомшак кына, ак сөлге төшә.

— Малай актыгы, бабаңны хет ашаганда борчыма.

Әби — йорт иясе. Укымышлы, зыялы нәселдән. Язмышы-ирен озаграк яшәтәсе килә. Хат ташучы — минем адвокат.

— Тимә. Минем янда утырсын. Може почтальон булыр. Кара сумканы чыгарып ташламагыз. Әйдә, улым, коймакны икәү хәл кылыйк.

Бичарадан ни чара әби, ак сөлге белән коймакка һөҗүм башларга рөхсәт бирә. Икәү дигәнебез мин һәм минем ач корсагым булып чыга. Бабайда рак, тамагыннан берни үтми, кире чыга. Әби белән бабайның җылы карашларын тоеп, коймак мәсьәләсен уңай якка хәл итеп куям.

Алар бәхетле: нәсел кала. Әби белән бабайның шул чордагы кинәнечтәэсирләрен, шатлыкларын оныгым Әскәр туып, аяк астында бутала башлагач кына аңладым. Бер алманы бишкә бүлү чоры узды. Без үскәндә туйганчы ашый алмаган тәмле коймаклар юк инде хәзер.

Еллар узган саен бабайның йөзе, гәүдәсе онытыла, холкының аерым сызыклары җуела бара. Шул ук вакытта аның үз чоры өчен фидакарь, алдынгы карашлы, ярдәмчел кеше булуы ачыграк, тулырак күзаллана.

Ә безгә, оныкларына, аның кушаматы, тәхәллүсе калды. Матурлык, уңганлык, булганлык, сәләт буыннан-буынга күчмәскә, югалырга мөмкин, ә кушамат, ялагай төлке коерыгы кебек, бозга да катмый, кадерле бүләктәй, атадан-балага күчә килә. Өлешенә тигән көмешең. Без — писарь Галиулла балалары, һәрберебездә бу шәхеснең көче, җегәре яши, дәвам итә.

## Әти һәм аның даирәсе

*Гомерем буена тормышны иярләргә хыялланып яшәдем.*
*Ул мине иярләде.*
*Тормышны почмакка куып кертергә тырышып карадым.*
*Барып чыкмады. Ул мине китереп кысты.*
*Бирешмәдем тәки. Үземнән сигез баламны калдырам.*
*Аларның балалары үсеп килә. Шуларга ышанам.*
*Киңәшем бер генә: тормыш белән*
*булышмагыз. Кешенең гомере һай кыска.*

Әти көндәлегеннән.

Гомер бакый бер килә торган вакыйга дип, әтинең җитмеш еллыгын олылап, иплэп, бәйрәм итеп, авылда уздырырга килештек. Сүз бирешкән кешеләр — Нәбиулла картның үз янындагысын санамаганда, читтә көн итүче җиде баласы, күп санлы сеңелләре, киленнәре, кияүләре, оныклары...

Сиксән икенче елның гыйнвары кар-бураннарга мул булды. Жепшек, коры, бөртекле карны юлларга сылап кына тора. Менә бүген дә, матчадагы бишек кебек тирбәлеп, сыланып күбәләк кар ява. Әтине тәбрикләп, күктән шулай сафлык, игелек агыла сыман.

Юл авыр булса да (юл газабы — гүр газабы, дип әйтеп калдырганнар борынгылар), әйткән сүз аткан ук, кем Казан, кемсәбез Алабуга, Чаллы, Мамадыш тарафларыннан әйтелгән вакытка берничә машина белән төп йортның биек агач капкасы янына килеп бөялдек.

Машиналардан чыгарга да өлгермәдек, өченче сыйныфта укый торган оныгы хәтле генә әни, зур галошларын шапылдатып, яныбызга очып килеп тә җитте. Шатлыгы эченә сыймый, күгелҗем күзләрендә дөнья

сөенече, галәм балкышы. Беребезне дә аерып куймыйча, рәнжетмичә, бер үк якынлык, якты нур белән кочаклый, аркабыздан сөя. Татарда чапы-чопы үбешү кабул ителмәгән. Аннан әти-әни белән балалар арасындагы якынлык кимеми, үзара галәкә үзгәрми, киресенчә, туганлык җепләре нииндидер илаһилык, галәмнән иңгән җылылык белән кушыла. Әнинең кечкенә кулларыннан иңгән мәрхәмәтлелек барыбызга да уңай тәэсир итә, кәефне күтәрә.

Бу дөньяда кабул ителгән һәм үтәлергә тиешле тәртип бар бит әле. Без күчтәнәчләрне машинадан бушаткан арада кече капкадан әтинең тавышы ишетелә торган иде. Үзенең соңгарак калып чыгуын (агач аякны киясе, сөйрәп чыгасы бар) шаян нотага күчерә.

— Карале син аны, кунаклар бар икән. Числиннек укып утырып, сизми калганмын. Анда, Нәбиулла әзи, малайларың сөйләшелгән сәгатькә кайтып җитсәләр, ул көнне кызыл кар явар, дигән...

Кул биреп күрешкәннән соң, машинаны йортка кертү хәстәрен күреп, әти олы капканы ача башлар. Алып кайткан әйберләренә, бүләкләренә исе китмәгәндәй, битараф булып кыланыр.

Олуг юбилейга махсус җыелган кешеләрнең чанталары, сеткалары, төенчек-биштәрләре, ягъни мәсәлән, күчтәнәчләре, машиналардан өйгә күченә башлады, әти күренми, аз гына карлыккан, мәгәр һәрвакыт көр тавышы да ишетелми. Дөнья тулы түгел, нәрсәдер җитешми.

Әни безнең арада. Ашык-пошык бәйләү аркасында башында чак-чак эленеп торган, маңгаена төшеп аптыраткан йон яулыгын күтәребрәк куя да, оныкларын сөя башлый. Җанын телгәләп, өләшеп, бүлеп чыгар иде балаларына.

“Десантта” яшь ягыннан иң өлкәне буларак, сорауны мин бирергә тиеш булам: “Әти күренми, чирләп китмәгәндер?”.

Каз саклаганда, бәбкәне тилгәннән алдырган бала кебек, әни гаепле, шул ук вакытта шаян күбекле тавыш илә җавап тота:

— Әйләнеп керәм әле, көткәндә вакыт акрын уза, эчем поша, дип чыгып киткәние. Сәгать берләр тирәсендә үк. Һаман юк. Әтиегезне беләсез. Чаланка белән бер булды инде. Китсә, кайта белми.

Әнинең чагыштыруы күңелебезгә хуш килде. Дәррәү кычкырып көлеп җибәрдек. Кызган, майсыз табага борчак ташладылар диярсең.

Безнең бәгырьдә утыра ул Чаланка иптәш турындагы чебиле истәлекләр. Сүз сөлек кебек шома гәүдәле, дөм кызыл тиреле, иләм азгын сыер турында бара. Үз гомерендә (ул сыер гомере өчен озак яшәде) кызык өчен генә булса да, бер тапкыр да көтү белән өйгә кайтмады.

Кызыл сыер һаман минем җелегемдә, канымда утыра. Ул чор вакыйгалары исемә төшсә, күз алларым караңгыланып китә.

Иртәнге өчләр-дүртләр тирәсе. Бала йокысының иң татлы, ләззәтле төшләр белән булышып яткан мәле. Әни янына килеп, иңбашемә чүгәли, арканнан сөеп: “Улым, сыер тагын кунарга кайтмады, бар, эзләп кер инде, бүреләр ашаса нишләрбез. Иртәгә Әфхәтне җибәрермен”.

Әнине аңлап, ишетеп ятам. Тик күз шәрифләренә һәркайсы кимендә берәр пот гер асып куйганнар диярсең, ачып кына булмый. Уятучы психикага барып житәрлек алым куллана: “Йокы — ялкаулар бәлеше, тор”.

Шуннан соң, уяныр-уянмас (киенеп торасы юк, бар да үземдә), абына-сөртенә чыгып китәсең.

Сыер эзләп йөргәндә иртәнге көннең хозурлыгын, ачыла килгән чәчәкләрнең матурлыгын күрмисең. Кояш нурлары да сине сөендерми. Калтырап торган чык тамчысын үземә охшатам да, алга таба атлыйм. Тургайлар: “Ташла шул юньсезне, эзләмә, берәр түмгәккә утырып безне тыңла да, ял итеп туйгач, кайт, сыерың өеңдә булыр”, дип эндәшәләр сыман тоела. Юк, аларны тыңламыйм, кечкенә йодрыклар белән ярым йомык, томанлы күзләремне уам да, тирә-якны айкау, агач араларын “тентүне” дәвам итәм. Соңрак мин бу үҗәтлекнең намус, җаваплылык хисе дип аталганын белдем. Өйдә сөт көтәләр... Имчәк балаларына, әти-

әнигә чәй эчәргә, барчабызга сөт кирәк. Ә сөт "фабрикасы" — сыер мәнсез, намуссыз, качып йөри. Сонрак, Дәрдмәнднең "Сөт калыр, Ватан китәр", дигән юлларын анламыйчарак йөрдем. Ә ул чорда безнең гаилә өчен сөт ватанның синонимы иде. Тук тормышка сатылу түгел иде.

Чыклы, бәсле болыннарны, урман буйларын, аланнарны, колхоз басуларын күпме генә айкасаң да, син Чаланканы таба алмыйсың. Бизар булып, хәлдән таеп, йортка керсәң, сыер синнән ярты сәгать иртәрәк кайткан булып чыга. Ул акыллы, монсу, менә-менә җиргә тәгәрәп төшәрдәй булып алга чыккан бигөнаһ күзләре белән сиңа карап тора. Шул ук вакытта аның карашында, "аягынны кыраудан ашатып та, мине таба алмадыңмы, канатым", кебек кинаяле мыскыллау да бар кебек. Ачуың казандагы көнбагыш маедай чыжлап, өскә сикереп, түшәмгә житсә дә сыерга кул күтәрелми. Сәбәпләре төрле. Бердән, әни йөзендә Чаланканың теләсә нинди исемле хөкемдардан көчлерәк яклаучысы бар. Икенчедән, аның сөте сепараттан чыккан каймагың кебек куе. Тәме турында әйтеп тә тормыйм. Безне ачлык тырнагыннан йолып калган изге җан. Шул азгынлыгы да булмаса... Гомумән мал рәнҗетү, кыйнау, дорфалык кабул ителмәгән.

...Әнинең бу чагыштыруы белән ни, нәрсә әйтергә теләгәнен тиз төшендек, озын-озак анлатып торуның кирәге калмады.

Әтинең күрше авылга, Иске Әлмәткә чыгып керергә ятратканын белгәнгә, машина белән шул якка юнәләбез. Караңгы төшеп килә. Ашыгабыз, авылыбыз читендә, калкулыкта урнашкан, әби-бабаларыбыз яткан зыяратны узуга, әтинең озын буен шәйләп алдык. Агач аягын яннан алдырып, көрткә кереп батса, кулы белән тартып чыгарып, юл уртасыннан берүзе кайтып килә. Бүреге чалышаеп янга төшкән, олы текә маңгае манма су. Без, Әфхәт, Әсхәт, бер-беребезгә карашып, елмаешып алдык. Бу дөньяда ирләр генә аңлый торган бәләкәч кенә, мәгәр бик ләззәтле серләр була. Безне таныгач әти шатланып та, отыры кызарып та куйды. Садә күзләре бәхетле. Барган җиреннән алып кайткан сөенечеме бу, әллә өч малаен бергә күрү шулай шатландырдымы, анысын бер ходай гына белә.

— Бапков янына төшкәнием. Һәр елны минем туган көндә шулай очрашып алабыз. Сез кайтыр дип, ашыгам.

Бапков дигәне мифик зат түгел, әтинең күптәнге ахирәте. Туфан Миңнуллин пьесасы каһарманы Әлмәндәр картның Евстигнее кебек үк, аралашып яши торган урыс кешесе, тирә-юнендә, әтрафында бердәнбер ветврач. Халык аны чын йөрәктән ярата, хөрмәт итә, ышана; соңгы тиенен илтеп бирергә риза, нарасыйларын сыерсыз гына калдырмасын. Татарча белмәгән Бапков (аның исемен дә, атасының исемен дә атаучы юк) белән урысчаны ипи-тозлык кына сукалаган татар хатыннары арасында үзенә бер "эсперанто" лөгате, аралашу чарасы туа.

— Бапкоф, Бапкоф, сыерымны карале. Салам да ни ашайт, печән дә ни ашайт, авызында бер-бер нәрсә ниттыр бит, — кебек монологларга ул инде күнеккән. Халыклар арасындагы дуслык турында, патриотизм хакында берәү дә сафсата сатмый. Бер-береңә ярдәм итү, сузылган кулга сугып җибәрмәү, кәкрене турайту, караңгы чырай күрсәтмәү дуслык дип атала торгандыр, мөгаен.

Бүре тиресеннән тегелгән малахаеның колакларын челләдә дә төшереп йөри торган, кое баганасы кебек озын буйлы Бапков татар хатынының сүзләреннән көлми, һәрхәлдә, сиздерми, малны тикшерә, диагноз куя, дәвалый башлый. Абрue искиткеч зур. Әти шул зат яныннан кайтып килә имди...

— Интегеп йөрмәсәң шунда. Бергәләп, машина белән барып кайткан булыр идек, — диешкән булабыз.

— Сез мишәйт итәсез. Дуслыкның кадерен белмисез шул әле. Без аның белән фин сугышына бергә алынган идек. Герман сугышына да бер көнне киттек. Төрле фронтларга эләктек, —дип, тәмләп истәлекләргә бирелеп алды.

Өйгә дөбер-шатыр килеп, бергәләп кайтып кердек. Үзебез дә гаепле кеше сыман әнидән шөллибез. Күпчелек хатын-кыз бу очракта туарылып тавыш күтәрмәсә дә, тыенкы кисәтүсез калмас иде. Хуҗабикә әчендәгесен сиздермәде, хәтта кунакларны көттереп кайларда йөрүе хакында да сорашып, саруын кайнатып тормады, иренең күңелен рәнҗетмәде, рухын сындырмады. Керфекләрен авырайтып, күгелҗем күзләрен бастырыклап алды да, оештыру эшләрен дәвам иттерде.

— Әйдә, Нәбиулла, кулыңны ю да, утыр. Кунакларны табынга чакыр. Бәлешемнең бәрәңгесе төсен югалта башлар, күптәннән тыкканыем. Рюмкалар өстәлдә.

Әтинең туган көнен дусты белән дә билгеләгәне сизелә. Мәҗлесне шаяртып, көлеп үзе алып барды.

Аракы белән дуслыкны ташласа да, бәйрәмнәрдә үзен ким-хур итүне мәгкуль күрмәде, сиксәнгә җитеп килгәндә дә әти, карчыгы күрмәгәндә, кайнар чәенә затлы коньяк тамызып, шәп борынын рәхәтләндереп утырырга ярата иде.

Ул вакытта әле дөньяда һәр нәрсәнең вакытлы, бер мизгел генә икәнен белми идек. Инде әти гүр иясе булганга берничә ел үтте. Югалтуларга күнегәсең икән. Каберләрнең, шагыйрь әйтмешли, туган елы гына бар шул.

Бер аягыңны агачка атландырып шул чаклы бала үстереп, сиксән бер яшькә җитү — мәртәбә вә егетлек. Әти ирләр узарга тиеш "сират" күперләренең берсен дә әйләнеп узмады. Хак тәгаләбез җибәргән ипиен ашап, һавасын сулап, тыныч кына, үз ятагында фатиха-киңәшләрен әйтеп, фани дөньяны ташлап китте. Үлгән кеше картаймый, исәннәр күңелендә шул килеш —килбәте, холкы-фигыле белән төпләнеп кала.

Соңыннан әни кат-кат сөйләде:

— Әтиегез үләсен сизенде. "Карчык, мине алырга килгән әҗәлем. Озак тормам. Менә шулай-шулай җирләрсез мине. Балаларымның барысына да бәхиллегемне әйт, тапшыр", — диде. Үзе шулай сөйләшеп ята. Бер мәлне тынды. Иреннәре кипкәндер, сүзен әйтергә җегәре беткәндер дип, җиңеләеп, кечерәеп калган башын күтәребрәк, авызына баллы су каптырсам, су кире чыга... Шунда соңгы сулышын алды. Тынды. Ак эзе сызылып калды дөньяда әтиегезнең. Аңа охшарга тырышыгыз.

1912 елның башында туып, әти дәвернең иң катлаулы, дәһшәтле вакыйгаларын башыннан уздыра, 1917 ел борылышының "җимешләрен" татый: ике сугышта катнаша, аягы мәңге төзәлмәс ярага таргач, 1943 елда туган авылына, хатыны Исламия кочагына кайтып егыла.

Кулда чүкеч, балта уйнатуны артык яратмый, булганлыгы да чамалы, шундый тәкъдим кергәч, җиң сызганып кибет эшенә керешә. Электән калган таш бинаны бирәләр. Эчке үзгәреш-янарышларын үзе рәтли. Бер-ике ел ял итеп, тулаем унсигез елдан артык авыл кибетенең мөдире булып эшли Галиулла угылы Нәбиулла.

Ул заманада хәзерге мәгънәдәге сату-алу юк иде. Хөкүмәт сәүдәсендә эшләү җинелрәк, нәрсә бүлеп бирәләр, нинди мал алып кайта аласың, шуны сатасың. Кул кушырып, алма пеш авызыма төш дип утырсаң, анда да эшең алга китми, "буксовайт" итә. Хәләл кәсеп, хәрәме — кулыңнан килгәнчә булгандыр инде. Әти күп әйберне үзе сөйләшеп таба, бер базар көнне, сабан туйларын калдырмыйча, район үзәкләренә — Мамыкка, Биләргә, Базарлы Матакка ат белән, 20 — 40 чакрымга кибет алып бара. Җәй көннәрендә кучер урынына мине утырта. Кукраеп барам-барам да, изрәп йоклап китәм. Арбабыз юл читендәге чокырга төшеп китә, егыла, әти белән тәмәке, менләгән шырпы тартмаларын үрмәли-чүнти җыябыз.

Әти — тиз аралашучан, компания кешесе, мәҗлес күрке булырга ярата. Халыкны "җыру" дәрәҗәсенә җиткерәсе, кәеф-сихәтен күрәсе була. Бу яктан аңа тертмәле, үткен теле, ситуациягә бәя бирә белүе ярдәм итә. Җырга осталык бездә юк. Әтинең берничә яраткан мәүзугы бар:

Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт куйыйк сезгә.

Печән чапканда, утын әзерләгәндә авыз эченнән генә шыңшын йөри торган икенче җыры келт итеп искә төшә.

Күк күгәрчен күрке бар, түбәсендә бүрке бар.
Утын биргән бер ходайның суны бирсә — ирке бар.

Үзең инде фәлән яшькә житеп, фәлән дәрәжәгә ирешкәч тә, әтиле булу олы бәхет икән дип утырасың. Адәм баласына тук тормыш кына житми, аңа мәзәге, жыры, чынбарлыкны үзгәртеберәк күзаллавы да лязем. Әти юктан гына тәм, кызык табып, үз күңелен үзе күреп яши, үзеннән, авылдашларыннан җиңелчә көлеп, шаяртып, сугыштан соңгы авылның бертөсле тормышына ямь, жылы дулкын кертеп яши белде.

Кибеткә сатин, ефәк ише тукымалар кайта. Хатын-кыз ябырылып ала. Гайшәбикә апа соңарып, кичке якта гына керә.

— Нәбиулла, матурлары беткәндер инде? Калмадымы яхшырагы? Ярар инде, менә тушысыннан биш митр кисеп бир әле.

— Үзенә аласыңмы?

— Соң кемгә булсын. Ник алай сорыйсың?

— Артык акчагыз бармы әллә диюем.

— Каян килсен инде артык акча. Вәли тапканын эчеп бетерә бара. Әлмәт базарында май, йомырка, йон сатканыем. Күлмәкләрем чистый бетте. Кеше арасына керерлегем калмады, —ди хатын, ихластан ачылып китеп.

— Бер төследән икешәр күлмәк текмиләр инде. Кайчан туздырасың әле. Туйдыра бит ул.

— Биш митр гына алам. Аннан нишләп ике күлмәк чыксын. Мин бит озын итеп тектерәм. Кызлар тегел. Знамо дило.

— Картың да шундыйны, тоже биш метр алып киткән иде иләгә чаклы гына.

Хатынның йөзе яшькелт-кызгылт төскә керә, авызы су дип, ялгыш серкә капкан кешенекедәй чалышая. Тотлыга ук башлый.

— Ни... миңа әйтмәде. Әбиткә кайткание... Ашап китте. Берни калдырмады. Аның кибеттән аракы белән тәмәкедән кала гумергә берни сатып алганы юк.

— Белмим тагын, — дигән була сатучы, йөзенә ваемсызлык пәрдәсе индерергә тырышып.

Гайшәбикәгә шул арзанлы шом, коткы олы вәсвәсә чыгарырга житә кала. Күңеленә коточкыч манзаралар, айны йоткан кара болытлар, яшенле бозлы яңгырлар килә, авылның барча чибәр, аеруча инде карт кызларына, тол хатыннарына тирән нәгъләт ява. Кибетче аның үзгәргән, бозылган, крахмал төсенә кергән йөзеннән шуларны күрә, укый...

Хатын бөтен вәхшилекне каһәрли-каһәрли, кибеткә ник кергәнен онытып, чыгып китә. Дөрес, ул үзе чамалый: аның Вәлие чүпрәк-чапракка акчасын әрәм итмәс, тапканы үзенә житми, аңа күптәннән инде аракы белән тәмәкедән башка нәрсә кирәкми. Әгәр Нәбиулла ялгышмаган булса... Кем белә, үгез яши-яши аза диләр.

Беравыктан, Гайшәбикә йончыган йөзле Вәлине җилтерәтеп кибеткә алып керә. Ир пычрак суда мингерәгән балык кебек, берни аңламый. Икесе ике яктан агач прилавкага килеп сөяләләр. Эчке ярсуы битенә, күзләренә чыгып, чибәрләнеп киткән Гайшәбикә рәхәтләнеп тузына.

— Нәбиулла, карале, син бу ялганчы, жир бит тинтәккә. Күлмәклек материал сатып алганын танымый. Берәр сөйрәлчегенә итеп бирергә өлгергән. Бөген кибеткә якын да килмәдем, ди. Ялганчы тәре. Каргана, әпәй белән ант итә, мур кыргыры нәстә.

Берни аңламаган Вәли, уйсыз маэмай мәсле, башын аска иеп тәк тора. Хатыны аны фермада тирес чыгарган жиреннән: "Әйдәле, сине кибетче чакыра", дип алып килде.

Ми кыймылдатып, җавап бирүгә, уйлауга караганда, ат җигүне, урман кисүне, утын ярганда сулышны чыгару җаена бүкәнгә китереп сугуны файдалырак күргән әзмәвердәй ир берни аңламый, ызанны таба алмый интегә.

Хатынның сүзен чынга алуыннан, уеннан уймак чыгу ихтималыннан бераз шөлли калган кибетче, артка чигенеп, бәхәсчеләрне тынычландырырга ашыга.

— Гайшәбикә, артыгын кызма әле? Мин Вәлине може башка берәү белән бутаганмын. Исемә төште. Ул — теге, кем әле, әйе, майор булгандыр. Точно. Ситсыны майор алып китте. Алар Вәли белән шул кадәр ошаганнар, игезәкләр диярсең. Көннең көне кибет артында торып, күзләр тона, кешеләрне кинодагы шикелле бер-берсе белән бутый башлыйсың.

"Майор" дигәннәре шул ук Кычытканлы кешесе — Сәгыйров була. Үз тарихы бар. Күбесенең кушаматы нәселдән, ерактан, ә Илгизнеке әле яңа табылган, буявы да кипмәгән "збежий", һәр атаманыкы шикелле, "майор"ның үз тәварихы бар.

Озак еллар дәвамында, хәзерге Нурлат, ул вакытта Октябрь районы белән Габбас Кыям улы Гыйматдинов җитәкчелек итте. Кимендә чирек гасыр районның "кара чемоданы" аның кулында булды. Әле пенсиягә чыккач та, Нурлат сәясәтендә, вафатына чаклы, аның кулы уйнады. Ак чырайлы, үткен күзле, мәһабәт гәүдәле, үз кадерен үзе белеп, иркәләнеп кенә яши белгән бу кешенең кулы ифрат каты, талканы коры иде. Аңардан башка беркем бер мәсьәләне хәл итми, рөхсәтеннән узып, бер капчык иген дә читкә җибәрелми.

Ул җитәкчелек иткән чорда район узышчы ат кебек ыргылып алга чыкмады, беренче мөкам-дәрәҗә, урын өчен талашмады (андый мөмкинлеге бар иде: халкы эшчән, җире уңдырышлы), шул ук вакытта төшеп калганнар рәтендә йөрмәде, уртачадан өстенрәкләр исемлеген бизәде. Ургылып алга чыксаң, гел алдынгылар рәтендә булырга кирәк, ә бу гамәл киеренкелекне, уяулыкны, мәҗбүрәнлекне таләп итә. Тыныч, иркен, шул ук вакытта тук, абруйлы, үз күңеленне күреп, яхшы чырай белән тереклек итүгә ни җитә.

...Районны дер калтыратып тоткан Габбас ага Кычытканлының колхоз идарәсенә, бу юлы элемтәчеләр ярдәменнән баш тартып, турыдан-туры үзе шалтырата. Бу — гадәти хәл түгел. Колхоз рәисен тикшереп, йә эшеннән алырга, йә башка югарырак урынга күчерергә җыена, дип фараз кылырга гына кала. Кадир хуҗаның нинди кәеф, уй-гамәл белән эзләвен берәү дә белми, күрәзәлек итә алмый.

Колхоз идарәсендә көзге чебеннәр хуҗа. Иске телефон аппараты агач өстәлдә оста биюче кебек урында тыпырчына. Эче пошканнан, әле генә бүлмәгә сугылган салмыш Илгиз Сәгыйров трубканы күтәрә.

— Мин кая эләктем?

— Военкоматка, — дигән җавапны ала вилаять хуҗасы.

— Кем белән сөйләшәм?

— Майор Сагиров вас слушает. Доложите!

Үзен юри ирештерәләр, үртиләр, көләләр (аның тавышын районда кемнендер танымавын күз алдына китерә алмый Беренче), хәтта үзенә каршы әшәке бер гамәл кылына дип уйлап, шундук авылга милиция нарядын җибәрә. Тегеләр яңа туган майорны шул ук бүлмәдә, изрәп, мәлҗерәп утырган хәлендә табып, "җылы килеш" районга алып килеп, зурлап, аерым камерага бикләп куеп, Беренчегә хәбәр салалар. Үзе белән шаярткан кешенең авырткан башына тимер таяк эзләп йөргән салмыш пожарник икәнен белгәч, Габбас көлеп җибәрә һәм сәрхүшне авылга машина белән озаттыра.

Майор булмаган кешене кем инде ГАИ машинасы белән районнан китереп алдырсын да, башында кызыл, яшел, сары, әчкелтем утлары биеп торган араба белән кире китереп куйсын. Әлбәттә, Илгиз Сагиров — майор, шик-шөбһә, ышанмау булырга тиеш түгел.

Илгизнең әнисе, гомерен Кычытканлыда уздырып, саф татарча сөйләргә, намазлар укырга өйрәнгән урыс кызы гына улының яңа "дәрәҗәсенә" артык мөкиббән китми: "Майорын майор, но барыбер эчүен ташламады", — ди.

"Майор" сүзе берәрсенең теленнән төшү — көлүгә чакыруны, күнел көрлегән, болай да авыр тормышны чәбәләндермик әле диюне аңлата. Гайшәбикәнең иреннәренә дә елмаюга охшаган күбәләк канаты иңә.

Фронтовик-кибетче тылда дошман калдырырга ярамаганны чамалый, хатын-кыз затын бигрәк тә. Сыер дуласа, атың бер янда торсын. Дошманлык хисе ноктәле үпкәгә, үч алуга китерергә мөмкин.

— Хатасыз дөнья — сансыз дөнья, диләр. Миңа да, кем әйтмешли, үз гумеремдә бер хаталанырга ярыйдыр шәт. Ачуланыштан, үпкәләштән булмасын, Гайшәбикә, без бит туганнар. Әйдәле, ситсының иң матурын, йөзенә, гәүдәнә килешеп торганын, үземнең хатынга дип калдырганын үлчәп бирим әле.

Күлмәклеккә түләү вакыты җитүгә, Вәли гаип була, шыпырт кына чыгып сыза. Ут чыкканда, җил уңаенда тормавың хәерлерәк.

Гайшәбикә вәкарь белән яшел өстенә ак, сары чәчәкләр төшерелгән сатинны култык астына кыстыра да, кибетченең колагына үрелеп:

— Син, Нәбиулла, Вәлинең күлмәклек сатып алды дигәненә бу тиле-миле ышанды дип уйласаң, ялгышасың. Беләм мин үземнең хәчтерүшемне. Ирләр ялганлый беләмени. Мин сине сразы сиздем. Ну, рәхмәт үзенә. Шәп булды әле. Ату минем исерек баш, кеше хатыннары кебек, көнләшә дә белмисең, якын итмисең мине, дип теңкәмә тиядерие. Пувыт табалмый йөрдем. Шәп булды әле. Чукындырам әле мин аны. Фермада, малакаем, сәнәк күтәреп, кая күлмәклегең дип, өстенә киттем. Күрсәтермен мин аңа кеше хатынына күлмәклекне. Алдан балаларын әпәйгә туйдырсын.

Хәзер инде шаян сатучының авызына серкә капкандай чалышаерга чират җитә. Хатын-кыз төпсез кое икән чистый. Кара су өстендә үз йөзеңне күрәсең, ә калганын төсле түгәрәкләр каплый.

Гайшәбикә чабышта беренчелекне алган бия төсле башын югары тотып, җилфер-җилфер чыгып китүгә, кибет эчендә, әлегәчә качып-почып торган Вәлинең нурсыз йөзе пәйда булды.

— Ачуланма инде, Нәбиулла. Минем хатын шундый көнче инде. Ник дисәң, үлепләр ярата. Таш атканга аш белән ат диләр, әйдә бер стакан салып бир инде. Бурычка.

Кибетченең башка хуты юк.

— Әйдә, үзем кунак итәм. Хатыныңның "күлмәкләре" өстендә тузсын!

Гаепсездән гаепле ир канәгать булып кайтып китә. Әтигә юморы өчен түләргә туры килә. Вәлинең бурычлары ахирәткә күчәсен ул яхшы белә.

Кибеткә халыкны интектергән шырпы, чәй, шикәр, керосин кайта башлады. Селедка балыгы да күренгәли. Гавамның яраткан тәгамы — килька. Чөнки ул арзан, татарның төп ризыгы бәрәңге белән яхшы бара. Чуаш халкы бу кечкенә балыкка ни өчендер аеруча мөкиббән китә. Берәү, күрше авылдан, безнең кибеткә килька алырга килгәч, телгә кереп калган сүзен әйтә:

— Мин Сталин пульсам, килька гына ашар идем.

Авыл халкына үртәшергә бу җөмлә озакка җитте. Шул арада әти, уртача күләмле агач мичкә белән, сәер бер азык алып кайтты. Ачып җибәрсәләр, май эчендә кара уылдык, безгә таныш булмаган икра ята. Берәүләр аны карабодайга тиңли. Икенчеләре, шул ук килька балыгының күзләре, дип бәяли. Авыз итеп караганнарның мөһере уртак:

— Тозлы, тәмсез, житмәсә кыйммәт.

Үзенә тиешле бәя, аңлау һәм яклау тапмаган уылдык кибеп, тоташ бер каты массага әйләнгәч, аны каядыр алып киттеләрме, чыгарып ташладыларммы шунда.

Авыл кибетчесенең эш көне прилавка артында торып, сату итү белән тәмамлана алмый. Еш кына анын өе шәһәрнең ресторанын, төнге кабагын алыштыра. Тынгы юк, йокы бүленә. Мина, күңелендәгесе теленә күчкәч өлкәннәрне тынлап яту — кызык, бушлай театр, тормыш мәктәбе.

Кычыткынлыкның сәхабиләре — колхоз, авыл советы рәисләре, мәктәп директоры, парторг, хуҗалык мөдире кебек түрәләр район үзәгеннән киңәшмәдән, көн саен диярлек булып торган җыелышлардан кайтканда, болай гына тамаклары кымтырыклаганда, безнең капкага кагалар.

Әти үз кеше, әнидән оялган, гафу үтенгән булалар:

— Исламия апа, ачуланма. Тундык. Балаларны уятмыйча гына утырыйк.

Шул арада биленә чалбарын тартып өлгергән әти килеп чыга. Аны сагынып, яратуларына түзә алмыйча кермәгәннәрен белсә дә, мәсьәләне хәл итүне суза: зарыгып көтелгән шешәне өстәлгә чыгарырга ашыкмый.

— Нәбиулла әзи, берәр шешә тап инде.

— Егетләр, өйдә тотарга ярамый. Сельпо рәисе төнә генә эт итеп сүкте.

— Бардыр әле, бик өшедек.

— Исламия, синең ярып куйганың булса, чыгар инде, — дигән була, тәүфыйклы песиләнеп, яхшатланып.

Әни, йокыдан уятканнары өчен канәгатьсезлеген сиздермәскә тырышып, өстәлгә салкын бәрәңге, май, ипи кисеп куя. Шешәне әтинең кулына тоттыра.

Хәзерге шикелле бозыклык юк. Стакан берәү генә. Шуннан гына эчәләр. Башкаларына соңрак чәй ясала.

Утлы суны беренче булып матди байлык хуҗасы — колхоз рәисе үзенә алырга тиеш. Ул эчкәндә башкалар, соң чиккәчә җиткән нервыларын шартлатмаска тырышып, аның ягына карамыйлар, ә каһәр суккан муен бизләре, хуҗадан сорап тормый, бер өскә менә, бер аска төшә. Шуннан да авыр көтүләр, текә сынаулар юктыр ир-ат өчен.

Колхоз рәисе сыекчаны эченә үткәргәч тә ашыкмый, стаканны кысып тоткан килеш, икенче кулының аркасы белән авызын сөрткән була, гомергә саф һава күрмәгән кешедәй, борын яфракларын киңәйтеп, эчкә сулыш үткәрә, шуннан соң гына ипигә үрелә, аны тәмләп иснәгәч, бер чеметемен авызына озата, кайнар сыекчаның тиешле, кирәкле җиргә төшкәнен тикшергәндәй, сул кулы белән корсак шәрифләрен сыйпап куя. Шундый ук рәхәт мизгелләрне икенчесе, өченчесе кичерә. Үзе бер сәнгать, үзе бер дөнья.

Тәннәренә җылылык иңеп, аракы куәсе миләренә менеп җиткәч, дөнья, район, авыл хәлләре турында гәп корып җибәрәләр.

Авыл совете рәисе, карт коммунист Галиуллин Исхак сүз ала.

— Сельпога прсидәтель эзлиләр, Нәбиулла, мин сине тәкъдим иткән идем, член партии тегел, ярамый диделәр.

Колхоз рәисе — тамада.

— Сон, без аны тиз генә партиягә алыйк. Үзем рекомендация бирер идем, ярамый, туган сеңлесе миндә кияүдә.

Таң әтәчләрен уятып кергән кызмача кешеләрнең фикерен әти җитдигә алмый, гадәтенчә шаяртуга, юморга бора.

— Юк, рәхмәт, анда бик зур взнос түләргә кирәк, ди. Минем балаларым күп.

— Причем монда балалар, — дип сүзгә кушыла мәктәп директоры Замир Яруллин.

— Взносны бала башыннан алалар дип ишеткән идем, — ди әти, шактый хәтәр шаяртып. Хатасын төзәтергә ашыга. Урамда әле илленче еллар башы гына.

— Рәхмәт, ышанычыгыз өчен. Уйлап карармын. Тагын берне ачыйммы?

Әлбәттә, инде тагын һәм тагын берне ачтыралар.

Әтигә партиягә керергә "кулак кызы" — әни бирмәде бугай. Мәгәр

Галиулла улы советларга, Сталинга турылыклы калды, берсенә дә авыр сүз әйттермәде, үзе яшәгән чорны, тарихны бирмәде. Шул хакта Мәһдиев белән сүзгә килешкәннәре хәтердә. Әтисен Сталин режимы юкка чыгарган, халык дошманы баласы дигән исемне күтәреп йөргән Мөхәммәт ачулы, үчле, үткәнне ярсый-ярсый сүгә.

Әти, агач аягын ныгытыбрак терәп куя да, бүгенге азгынлыкны, явызлыкны, кадерсезлекне әрли башлый.

— Элек тәртип барие. Шәһәрдә дә курыкмыйча, урамга чыга ала иден. Сталин үзе берәүне дә атмаган, аның исеменнән кылган явызлыкларның күбесен ул белмәгән дә.

Әтидән: "Ни өчен сугыштың?", — дип, кат-кат сораганым булды.

— Азатлык өчен, — ди.

— Нинди азатлык инде ул. Сугыш беткәнгә күпме вакыт узды, без һаман хәерче, әнә немец, япон ничек яши. Без һаман кол.

Аптырагач: "Бездән сорап тормадылар, тоттылар да алып киттеләр", — дип, дөресен әйтте.

— Мин политик тегел, мин крәстиян, — дип өстәүне тиешле тапты. Барыбер үз ышануы, үз иманы белән китте җиһаннан. Советларны, коммунистларны хәзер ничек кенә әрләсәк тә, сәяси бөтенлек һәм ышандыру (бәлки, куркытудыр) көче булган аларда: кешенең миен агулый, җанына үтеп керә белгәннәр. Безнең илдә элеккеге җитәкчеләрне, урыныннан китүгә, үлүгә, фаш итү, эттән алып бүрегә салу, бөтен житешсезлекләрне аңа сылап калдыру кабул ителгән. Хрущевны, Брежневны, Горбачевны, башкаларны пычрак суда коендырдык. Сталин үлгәннән соң да шактый яшәгән якын әшнәләре, аларча әйтсәк, көрәштәшләре Молотов, Каганович, хәтта маршал Жуков та, күпме генә кыссалар да, халыклар атасы — хуҗалары турында начар сүз әйтмәделәр. Ерак татар авылы мажигы Нәбиулла карт та аны бирмәде. Нәрсә бу? Каян килгән дүрт сыйныф белемле грузинга шундый ышандыру көче? Гипнозмы? Гади акылга сыймый торган башка берәр феноменмы?

Гайре табигый күренгән бу вәзгыятьнең төбендә бик гади нәрсә ятмыймы икән? Шундый бер мәзәк искә төшә.

Яшь егет бабайдан сорый икән:

— Әйт әле, бабай, син кайчан яхшырак яшәдең? Теге вакытта, коммунистлар заманындамы, әллә хәзер, хакимияткә демократлар килгәчме?

— Әлбәттә, коммунистлар заманында! Мин ул чорда хатыным белән йоклый, кодага атна саен кунакка бара идем. Хәзер хатын белән аерым түшәкләрдә ятабыз, ә кода бусагасыннан да уздырмый.

Әтинең кибеттә эшләү дәверендә төрле чорлары булды. Ревизорларның, финанс әһелләренең бездә кунак булып ятканнарын яхшы хәтерлим. Авылда, чын-чынлап тикшереп карасаң, туган булмаган кешене таба алмассың. Халыкта акча юк, колхозда бушка, "таякка" бил бөгәләр. Әтигә сатарга, ә халыкка товар, керосин, тоз, шырпы, ирләргә шулар өстенә тәмәке белән аракы кирәк.

Соңгылары, сырны авызында тоткан карга янына килгән хәйләкәр төлке кебек, бурычка соранып, әти кырында бөргаланалар: "Бурычка, икеләтә язып куй журналыңа, зинһарлап сорыйм, салып бир, үләм бит инде". "Нәбиулла әзи, әллә миңа ышанмыйсыңмы, күзләремә кара, алар алдакчы күзләренә ошаганмы?", — дип, телләренә салынып, ниятләренә ирешәләр. Түләү көне житкәч, табигый ки, күбесе баш тарта: янәсе, журналга кибетче теләсә нәрсә сырлап куя ала, каләм үзенеке, имза аныкы.

Ревизорга кем түләсә дә барыбер. Ырастрата, халык әйтмешли, Африкада да ырастрата инде ул.

Әтинең Нурлатта яшәүче сеңелесе, гаярь журналист Разия апа хәл белергә килә. Абыйсының кибетне тапшырганын ишеткән.

— Әзи, синең урынга кем керде?

— Сыер керде, — ди әти.

Үз чоры өчен Нәбиулла картның исәп-хисап эшенә шактый маһир кеше булганлыгын хәзер генә аңладык. Агач төймәле "санаучы" белән ул бик зур суммаларны чыгара, үзәктән килә-китә торган оста тикшерүчеләр аның ялгышын, хатасын таба алмый интегә. Каядыр очны яшергәнен, шомартканын сиземлиләр, исбат итә алмыйлар. Әтинең баш мие ике өлештән торгандыр (Хрущевның рәссам Неизвестный ясаган һәйкәлендәге аклы-каралы башы кебек): бер ягы исәп-хисап эше белән җитәкчелек итә, икенчесе тел шәрифләренә "ризык" әзерли, көндәлек язуга этәрә.

Шуңа күрә аның балалары фикерләү рәвешләре буенча кыл икегә аерыла. Уларының берсе табиб гыйлемлеге буенча китсә дә, икесе зоотехник, агроном саналса да, алар барысы да филологлар, нигездә тел белән "эшлиләр".

Кызларның күбесе төгәл фәннәргә өстенлек бирде. Әфхәт өчен теләсә нинди темага сәгатьләр буе нотык тоту бернинди кыенлык тудырмаса, Чаллы шәһәрендә урта мәктәп директорының уку-укыту эшләре буенча урынбасарлары, физика-математика факультетларын тәмамлаган, төгәл фәннәр тарафдарлары — сеңелләрем Салихова Лилия белән Сәмигуллина Сәрия озын-озак тост урынына идән юып ташлауны, берничә мисал чишеп алуны җайлырак күрәләр. Артыгын таләп итмичә, балалар үстереп, булганына шөкер кылып, халыкка хезмәт итеп яталар.

Күлтәгин язмаларының ерак нәбирәсе — оныгы чатан Нәбиулланың янә бер йомшак ягы турында әйтеп китми булмас. Ул — мин белгәннән, хәтерләгәннән бирле көндәлек алып барды. Бүлекнең башында шуннан бер фәлсәфи өзек тә китердем. Күп тапкырлар күченеп йөрү, янгынга юлыгу сәбәпле язмаларның күбесе сакланмаган, юкка чыккан. Истәлек-хатирәләрендә ул миңа тирәнрәк, максатчанрак тоела, гади бер авыл кибетчесеннән тирәлек, хәтта галәм белән "әңгәмә" алып барырга, аңлашырга тырышкан шәхес буларак калка. Күрәсең, ул табигатьтән килгән рухи җегәрен, дөньяга карашын кәгазьгә төшергән, үзен аңларга тырышкан. Кемдер укысын, тарих тәгәрмәченә кертеп җибәрсен, дип язмаган ул көндәлекләрен. Безгә халык иҗатының энҗе-гәүһәрләрен китереп җиткергән "шәкерт дәфтәрләре" кебек үк, үзе өчен генә алып барган.

Әтинең сурәте әле дә булса күз алдында: һәр кичне диярлек, "амбарная книга" дип тышына язылган дәфтәрне исән тезенә куеп (өстәл тирәсендә буш урын юк, бала-чага дәрес әзерли, чыр-чу, тавыш), үткән көн алып килгән, алып киткән яңалыкларны, яшәеш вәзгыятьләре тудырган уй-хисләрен кара белән дә, буш каләм табылмаса, карандаш белән туры сызыклы битләргә төшерә башлый. Бу мизгелдә ул, каты кабыгы ак савыты эченә яшеренгән ташбака төсле, үз эченә — дөньясына китә, башыннан узган вакыйга-хәлләрне янәдән кичереш күзәнәкләре аша уздыра. Аркасы туры, маңгай сырлары тирәнәеп, өскә, кыска киселгән ак чәчләре янына менгән, зур соры күзләре акыл казанынан төшкәнне тикшереп, барлап тора. Әдәбиятчылар бу гаҗәеп манзараны иҗат процессы диярләр иде. Әти ул хакта белми: Сибгат Хәким әйтмешли, ана просто рәхәт.

Татар ирләренә хас, әлегә җәмгыяви, мәгънәви нигезләре ачылып җитмәгән бу үзенчәлек, ягъни кәгазь-каләм, китап белән дуслык, билгеле ки, минем әтигә хас үзенчәлек кенә түгел. Кычыткалы авылының укый-яза белгән күпчелек ир-затлары бу шөгыльгә бик теләп алына.

Ошбу хәл татар атлы кавемнең элек-электән әлифбалы, укымышлы халык булуына бер дәлилме, әллә хыялый дәрвишлеген (кемдер бу мавыгуны вакытны заяга сарыф итү дип санар) күрсәтүче бер билгеме, йә күренекле язучы, фамилиясенең төрки чыгышын беркайчан яшермәгән, хәтта горурланып йөргән Михаил Булгаковча фикерләп, "кульязмалар янмый", аны кылыч аша үткәреп булмый, дигән фараздан чыгып, киләчәк буынга үз хәятлары турында нинди дер мәгълүмат калдыру хыялы кулларына язу әсбабын тоттырганмы? Тукаебыз да: без тарихта эзлебез дигәндә,

бәлки, язма-басма истәлек-ядкарьләрне күз алдында тоткандыр? Шагыйрьнең бу фикере һаман да бәхәсләр, төрле-төрле аңлатулар тудыруы табигый. Тирән фикер беркатлы була алмый.

Дөресен әйткәндә, әтинен көндәлекләрендә искитмәле фикер, сурәтләү яңачалыгы, сискәндереп җибәрә торган кыюлык та юк шикелле. Гадәти көнитеш, яшәеш күзәтүләре. Яз ничек килгән, чәчүгә кайчан чыкканнар, арыш ничәсендә серкәгә утырган, умырзая белән себеркене кайчан җыйганнар, кышкы буранны ерып кемгә кунакка барганнар. Иң тулы мәгълүматлар явым-төшем турында.

Язның беренче көннәре елның ничек киләсен ачыклау өчен иң җайлы вакыт. Фәнни, гыйльми нигез кирәк. Кышның кышын пожарка янында домино сугып, буш сафсата корып утырган туры, кәкре аяклы, кытыршы куллы, сакаллы вә сакалсыз агайлар исбатлама артыннан өйләренә юл ала. Күбесенең үзләре өчен бик кадерле язмалары бар.

Мичнең балалар кулы җитми торган бер җиренә яшерелгән яисә матча ярыгына кыстырылган көндәлек бөти төсле үк изге әйбер. "Амбарная книга"ның ачык битенә бөгелгән бармагының сөяге белән төртә-төртә әти үзенең фаразын игълан итә.

— Июнь башында көчле яңгырлар булыр. Ун көнләп салкынлык төшәр. Икенче көчле яңгыр июль ахырында гына килер. Печәнне яхшы җыеп алырбыз.

Иң канәгать кеше әти. Аның көмешсу йөзендә гыйлемлек чаткылары бии. Аны бу мизгелдә йолдызлар, галәм кырлары белән элемтәгә кергән күрәзәче, әле генә мәгарәдән чыккан Әбугалисина белән бутарсың. Әмма аның фикере бердәм кабул ителде дип уйласагыз, Кычытканлының табигать, төгәл фәннәр, хокук белгече булмый калган ирләрен бәяләп җиткермәвегез булыр. Аерым алганда, күп кызлы, авыл фәлсәфәйе, кечкенә буйлы, мәңгелек бәхәсче Әбелгаз абзый тиз генә бирешмәс! Үзенең дәфтәрен актарып, бер сары битенә тукталып, беркатлы, саф күзләренә килешмәүчәнлек төсмере йөгертеп, җиз тавыш белән үзенекен тәкърарларга керешер:

— Юк, Нәбиулла, минем язмалар буенча синеке дөрескә чыкмый. Ачуланма. Син обещайт иткән яңгырлар соңрак, июнь урталарында гына Кычытканлыга килеп җитәр. Әлмәт ягыннан тегел, урман аркылы килер.

Мондый үтергеч төгәллек, кискенлек хискә китереп бәрә. Шулай да каршы як сөлгене ташларга җыенмый. Бер үпкәле, кара-кучкыл, тимгелле йөзле, тырпайган кашлы Исхак Галиуллин авыл советы рәисе кәнәфиен озак еллар биләгән, фирка җыелышларында сөяк ныгыткан кеше. Болай гына бирешмәс.

— Икегез дә ялгышасыз. Нәбиулла дөреслеккә якынрак тора. Һава торышы унике елга бер туры килә. Июнь ае, минем юравымча, яңгырлы, но салкын булыр.

Элеккеге заманалар кире кайтып, Исхак абзый, җаваплы вә төшемле урынында утырса, һәр инсан берәр ярдәм, кәгазь, мөһер сорап барасын уйлап, аның белән баш өсте дип, килешер иде. Хәзер таяныч мөнбәре юк, ул Нәбиулла, Әбелгаз, Габдрахман, Сафа, Әхмәтшалар кебек үк пенсионер. Може акчасын гына күбрәк ала торгандыр.

Һәр шәйне шик астына алырга яраткан, бәхәс кайнаган пожарка каршында гына яшәгән, безнең ут күрше, әнинең апасының улы Хуҗа Вагыйзы, язма алып бармаса да, үзенең Киек Каз йолдызлыгы астында туганын онытмый.

— Синең прогнозларың беркайчан да акланмый, Исхак әзи, бу сиңа сельсоветта кирәкмәгән төшкә пичәть сугып утыру тегел. Монда баш кирәк.

Мәгәр кыска буйлы, кинчә сөякле, тыгыз мускуллы, эшләргә дә яраткан Вагыйзга җәелеп китәргә "диктатор" Халисә ирек бирми. Чибәркәенең йодрыгын җиденче тоемы белән сиземләп, арка күзе белән күреп алган Вагыйз олы кәвешләрен каккан, чистарткан булып, өй тарафларына юл ала.

Вагыйзны дошмани көчләр арадан суырып алды дип кенә бәхәс туктый алмый. Күрәш барганда, баррикадаларда кешесе табылып торган кебек, һәркем үзен күрсәтеп калу ягын карый. Һәр нәрсәне шик астына алу — бәйтегә хас эш.

Җырлауга охшаган тавышлы тагын берсе үз фаразы белән уртаклаша. Әти үз фикерендә гранит ташы кебек нык тора. Ул бер генә кешенең язмаларын житди кабул итә, аның белән кылыч чәкештерергә разый.

— Әбелгаз әзи, ачуланма, мин хаклы. Менә монда карале... Илле беренче елда болай дип язганмын. Илле сигездә һава хәлләре кабатланган. Алтмыш икедә погода былайрак торган. Корылык, сонарган яңгыр... Малларны җыеп алдылар. Малайның малае туды.

Барысыннан да гәүдәгә кечкенә, йөзе, тән тиресе белән башкалардан аерылып торган, сүз сугышы чукмары Әбелгаз кыза, тәмам туарыла, нәгъррәләр ора.

— Нервыда уйнама, саннарың белән муеныма төймә. Син миннән яшьрәк тегелме әле?

— Сыныкка сылтама. Фикеремә тышау салма, мин хагын әйтәм.

Дөреслек бәхәстә табыла, дигәннәр борынгылар. Китә текә, әмма бер-берсенең шәхесенә тимичә аңлашу, чакмадан ут чыгару. Иң акыллы фикерләре соңрак килә, "поезд киткән" була. Һәркем: "шылайрак әйтәсе булган" дип, үзен битәрләп йөри. Аларны тыңлап утыруы үзе бер гомер. Уйлап куясың: тормышлары әлләни чибәрдән булмаса да, үзләренә юаныч табалар авылның акыл ияләре.

Әлбәттә, көндәлек тормыштан күтәрелебрәк яшәргә омтылган хыялый кешеләр бер Кычытканлыда гына икән, дип раслаудан мин ерак торам. Татар исемен йөрткән, яза-сыза белгән ирләрнең бик күбесе үзен кәгазьдә "бушата" икән. Хатын-кыз моңлы җырында, шигырендә, бәетендә...

Җөмләдән, Равил Моратов "Юлны эзләгән табар" ("Дорогу осилит идущий") китабында әтисенең истәлек-ядкярьләренә киң таяна. "Бүген, аның көндәлекләрен янәдән актарганда, аның ихтыяр көченә һәм гайрәтлелегенә сокланам. Ул гадәттән тыш хезмәт сөючән кеше иде. Аның эш көне, кагыйдә буларак, иртәнге 4-5 тән башлана һәм сәгать 11 дән дә иртә тәмамланмый". Фатыйх агайны ни-нәрсә борчыганны, эш көнен ничек уздырганны улы әтисенең язмалары аша күз алдына бастыра.

"Истәлекләр, — ди ул, — аның өчен җан азыгы булган. Аларда ул ихласлырак, гаделрәк һәм, әйтер идем, үзенә якынрак, ихтыяҗлырак яшәешкә кереп китә".

Мин дә әтинең хәреф хаталары белән тулы, нокта белән өтерне санга сукмаган, бары тик үзе, яшәешенә ярдәм итү өчен алып барылган көндәлекләрен нәкъ шулай бәяли алыр идем. Ел фасыллары, дуслары Зыя, Гәрәй, Исхак, Әбелгаз белән сөйләшеп утырулары турында прозаик сөйләмгә айның кайсы көнне урактай матур булып калкуы яисә, оятын тәмам югалткан, түгәрәк битен тулысы белән кешеләр хозурына боруы турындагы ярым шигъри юллар килеп керә.

Язмаларда олы сәяси мәсьәләләр күтәрелмәсә дә, 1964 елның октябрендә болай дип язып куйган әткәй: "Хрущевтан котылдык. Мәтәлде. Хәзер може халыкка хайван асрарга бирерләр".

Арзанлы плафон башлы житәкченең илгә, аерым алганда, татар халкына китергән явызлыклары санап бетергесез. Ул Мөхәммәт Мәһдиев "бәхилләшкән" таза хәлле, нык әхлаклы, милләтнең умыртка баганасы вазыйфасын үтәгән авылны юкка чыгарды. Бер яктан, шәһәрләргә, төзелешләргә күпләп күченү китсә, икенчедән, нарасый балалардай табигать кочагына сыенып утырган җыйнак авылларга "бесперспективный" дигән ярлык тагып, аларны юкка чыгару — һәлакәт-инкыйраз юлына этәрде. Ошбу торак урыннарында башлангыч, җидееллык мәктәпләр ябылды. Урта мәктәпне, олы авылларда укыту урысча алып барыла. Шул чорның чүбеген әле дә булса түкереп бетерә алмыйбыз. Әтинең сөенечен аңлап була.

Шул көннәрдә үк эти: “Ат үлгәннән соң абзарны төзәтеп маташуының кемгә кирәге бар”, — дип язып куйган. Ни, нәрсә әйтергә теләгән Нәбиулла карт бу йомры җөмләсе белән? Без хәзер дә атсыз абзарда көн итәбез түгелме?

Тагын бер гыйбарәсе хәтердә калган.

— Ашарга сораган өчен балага җәза бирергә ярыймы?

Ә бит язу-сызу белән шөгыльләнгән өлкәннәр безгә юк-барга вакыт уздыручылар кебек тоела иде. Барча сусауны су гына баса алмаган икән, кеше, башка җан ияләреннән аермалы буларак, рухи азык эзләгән, фикри таяныч барлаган.

Татар кешесе шулай да гел тормыш, җир турында уйлый, олы сәясәткә катнашмый. Көндәлекләрендә дә ул шундый. Зыялылар гына вакыт-вакыт татар теленең барын да белмәгән дөнья, Мәскәү түрәләренә туган ләгатьләрендә кыю-кыю кинә-кизәнүләр ясап алалар анысы. Эт өрә, кәрван бара бирә.

Мәскәү астында, Переделкино дигән иҗат йортында ял иткәндә, станциядә электричка көткәндә ике “өлкән агай” вәкиленең хуҗаларча, белдекле булып сөйләшкәне колакка чалынды.

— Юк, мин риза түгел, — ди яшькелт сырма фуфайка кигән озын буйлысы.

— Кайсы ягы белән ошамый сиңа Лебедь, — ди өстенә коңгырт кыска тун кигән тәбәнәгрәк буйлысы.

Сүз Чечняда кан коешны-сугышны туктаткан, хәзер Президент кәнәфие өчен көрәшкә чыккан Александр Иванович Лебедь турында бара икән. Озын буйлысы бик катгый, кырыс булып чыкты.

— Юк, мин Лебедьны куярга риза түгел. Бик кырыс генерал. Куликовларның башы очачак.

Курач буйлысы “тәкъдиме” узмаганга аптырап калмады.

— Очса ни, алар барысы шул ук кошлар нәселеннән... Карга карганың күзен чукымый.

Йөгереп барганда туктарга мәҗбүр ителгән ат төсле пышкыра-пышкыра электричка килеп туктады. Юк буенча урыс ирләренең “кыюлыгына” сокланып бардым.

Кеше — иң сәер җан ияләренең берсе. Ул бик тиз яңа чорга иләшә, якын кардәшләрен, дус-ишләрен югалту белән килешә. Килешмичә кая барсын, тәкъдирдән узып нишли алсын ул. Тарих — үткән аша бүгенгене күрсәтү чарасы дибез икән, яшәп киткән кешеләрнең изге гамәлләре, хыяллары, өмет учаклары яңа, яши дигән сүз. Эти дә исән-имин сигез баласында, илсөяр оныкларында, инде аларының нарасыйларында яши.. Аның көндәлегендәге тормыш турындагы фәлсәфәсенең нигезендә менә шул дәвамлылык ята торгандыр әле.

## Әни һәм аның мөхите

Безнең гаилә нәкъ ун кешедән, эти белән әни һәм сигез баладан гыйбарәт. Башкалардан сан ягыннан да, сыйфат тарафларыннан да аерылып тормый. Күбрәк балалы йортлар да бар... Шуңа тарта алмаганнары да җитәрлек.

Шулай да җир йөзендә бер-берсенә тач ошаган бәндәләр булмаган шикелле, һәр гаиләнең үз яшәү рәвеше, башкалар күзенә кылчык булып кереп тормаган “милли колориты” була. Шагыйрь әйтмешли, күрә белергә күңел күзе генә кирәк.

Төшке ашка, һич югында кичке чәйгә бергә җыелырга тырышабыз, барча сәяси, җәмгыяви мәсьәләләр шунда карала. Электән калган гадәт. Ак чырайлы, тамырлары гына калдырылган кыска чал чәчле, комлыкта, иркенлектә үскән нарат бүрәнәседәй төз, озын буйлы әти самавырдан чәйне үзе агызып бирергә ярата. Безнең өйдә татар халкының милли

ризыгы булып киткән ошбу эчемлекнең куесын, үгез канын хәтерләткәнен яраталар. Дөрес, әти бераз хәрәмли, безгә сыек ясый.

Әни мич урнашкан кече як белән түрдәге олы, киң калын такталардан ясалган өстәл арасында бөтерелеп йөри, аягы җиргә тими, биюче Нуриевларың бер якта торсын. Ризык ташый. Мин аның ашыкмыйча, йөгермичә йөргәнен яисә безнең белән озаклап, җәелеп утырып ашаганын хәтерләмим. Аның көндәлек яшәешендә өстәл янында озаклап вакыт уздыру каралмаган. Башкача йортны, гаиләне алып бару мөмкин түгелдер. Һәр гадәтне зарурият, ихтыяҗ тудыра.

Дастархан янында гаделлек, мәрхәмәтлелек, мөмкин булганча, тигезлек хөкем сөрә, каядыр җәбер, золым бардыр дип уйламыйсың.

Гаиләдә әти сүзе — үтәлергә тиешле канун, әнинеке — ачыкламыш, юнәлеш, өстәмә аңлатма. Соңгысының төп чарасы сиземләү, вакыйгаләр агышын алдан күрә белү, "кризис"ка житкермәү. Филнең дөядән биегрәк икәнен аңлатып торасы түгел.

Әти телгә, сүзгә оста, җор кеше булса да, хискә бирелеп, туарылып китүне ир-ат өчен мәртәбә санамый. Терәге — әни. Ул аның янында, дәртле, үз бәясен белгән күркә төсле, умыртка баганасын турайтып, аркасын катырып утыра.

Әни кечкенә гәүдәсенә, жыйнак түгәрәк йөзенә буйсынучан бирелгәнлек кыяфәте чыгарып, хәйләле елмаюын, матур, серле күгелҗем күзләре тирәнлегенә яшереп, әтинең һәр карарын, тәкъдимен хуплап, җөпләп бара. Әти безгә шелтә-мазар белдерсә, канәгатьсезлеген сиздерсә, әни, кирәк тапканда, нәтиҗәне бераз йомшартып, каттыйлек төсмерен алып, тулаем аның фикерен рәсми хуплый, һәм дөрес эшли. Бу чигенү түгел, мәсьәләгә иҗади килү.

Хәзерге хатын-кызның күбесе азатлык, хөрлек төшенчәләрен ялгыш, берьяклы, аны ир белән тигез хокук дип кенә аңлап, үз вазыйфалары хакында онытып, орышу, тавыш чыгару юлына басып, икенче яртысының теләгенә, сүзенә игътибар итмичә, тыңламыйча үҗәтләнеп, бик нык ялгыша, иптәшен үзе үк тайгак, ялгыш юлга этәрә.

Татар хатын-кызларына васыятен Гаяз Исхакый гасырның беренче чирегендә үк "Ул әле өйләнмәгән иде" әсәрендә анык әйтеп калдырган.

Повестьның сәнгатьчә эшләнешенә, табигать күркен, тирәлек ямен искиткеч оста сурәтләвенә, психологик бәя алымнарының байлыгына тукталып тормыйм. Урыны ул түгел. Катнаш гаиләләр арта барган, рәсми хупланган заманда әсәрнең фикри вә фәлсәфи юнәлешенә күз салу урынлы булыр дип уйлыйм.

Алдынгы фикерле иптәшләренә ияргән өчен мәдрәсәдән куылган Шәмси Петербургка килеп, приказчик ярдәмчесе булып эшкә урнаша, белемен күтәрү нияте белән, театрга йөри башлый һәм тәҗрибәле урыс хатыны Анна Васильевнаның үрмәкүч җәтмәсенә килеп эләккәнен сизми дә кала. Анна — мөләем, акыллы, ир-атның кадерен белә (кияүдә булган) торган ханым. Ул Шәмсигә каршы әйтү, карышу түгел, аның һәр теләкниятен алдан күреп, санап чыгарып, сизеп алып, якынына һәр тарафтан ярарга тырыша. Ул гына да түгел: кадерлесенең укымышлы, уңган, чибәр татар кызына өйләнү турындагы хыялына тыштан каршы килми, беркатлы Шәмсигә ияреп, мөселман кызлары җыелган кичәләргә бара. Мәгәр икесенең дә күңеленә хуш килерлек кызны каян табасың: йә йөзе, йә үзүзен тотышы, аяклары, ахыр чиктә белем дәрәҗәсе туры килми. Үзенә ни, нәрсә кирәген тәгаенләгән Анна Шәмсигә бер кыз бүләк итә, тиз арада икенчесен алып кайта, балаларын "ялгыш" кына чиркәүдә чукындырып чыга.

Шәмси өйләнү нияте белән туган авылына кайтып киткәндә дә, ләм-мим каршы сүз әйтми. Тик кызны ярәшеп, куллар бирешеп кайткан көнгә балакайлары белән төшкән карточкасын һәм мәхәббәт мәктүбен җибәрергә онытмый. Шәмси ата-анасын, кыз баланы ифрат кыен хәлгә куеп, әзер туйны ташлап, мәгъшукасы янына чыгып китә, Анна

Васильевнаның җылы кочагына кайтып егыла. Кыскасы, йомшак җәеп, каты утырта ярым зыялы егетен тәҗрибәле хатын.

Г. Исхакый татар хатын-кызларына мөрәҗәгать итеп, Шәмсиләрсез каласыгыз килмәсә, сез дә ирләрегезне Аннадай иркәли, тәрбияли, сиздермичә генә үз әргәнегезгә биетергә өйрәнегез, ди кебек.

Безнең гаиләдә мәсьәлә нәкъ менә шулайрак, якташыбыз Гаяз Исхакый теләгәнчәрәк хәл ителгән дисәм, әтинең җаны рәнҗемәс, дип уйлыйм. Хәзерге төшенчә белән әйтсәк, әти — хуҗа, абруй, әни — түбә (крыша). Өйдә кемнең ахыр өстенлеген сирәк кеше белә. Мин үзем дә аның серенә гаилә белән яшәп, ике малай үстергәч, фән докторы булгач кына, азмы-күпме төшенә башладым. Чөнки ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәттән дә катлаулырак сәнгать, буталчыграк фән юктыр дөньяда. Генетика, нисби теория, фараз кебек гыйлемнәрнең барысы да икенчел.

Әти — тиз кызучан, яна, шартлый, сүтелә (үзе беркадәр артист та, тышкы сурәтне ярата), әни — ут сүндерүче. Инде бүртелгән тал чыбыгы безнең аркага төшәргә торганда, әни кечкенә, хәрәкәтчән бармаклары белән хәләл җефетенең иңнәренә орынып ала, әти шундук ярларына кайтып төшә, өянәге тынычлана.

Әни — реклама яратмый, кәпрәю, масаю аның холкына туры килми. Шулай да ул үзенең хәлле нәселдән, ак куллы (укы: кулак) токымнан чыкканын онытмый. Сугыштан соңгы чорда, хәерчелек, житешмәү эзәрлекләгәндә дә, аңа үткәне рухи таяныч, терәк була.

1917 ел түнтәрелешенә кадәр авылның кыл уртасында кызыл кирпечтән салынган ике ташпулатның берсен аның туганнары салдырган, әтисе — Шәфигулла агачтан кирәк-ярак әйберләр ясауга оста булган, һөнәренә башкаларны өйрәткән, тирә-юнь авылларны чана, көпчәк, камыт, агач көрәк, киле, имән мичкәләр белән тәэмин итеп торган. Хәзер дә әнинең туганнарын алтын куллы, диләр. Шәфигулла картның балалары, оныклары авылда иң оста балта осталары, мич чыгаручылар. Техника чоры житкәч, иң алдынгы комбайнчыны да шул нәсел бирде.

Табигый ки, ярлы-ябага — шариковларга йөз тоткан сәвитләргә булдыклы кешеләр кирәкми. Ике йөз йортлы Кычытканлы авылыннан биш кулак "тапшырырга", дигән разнярадка килә. "Безнең авылда ул чаклы бай кеше юк, санны киметегез", — дип ялваруларның файдасы тими. Яхшы йортлы, бигрәк тә калай түбәле, бернечә ат тоткан кешеләрне кулакка чыгарып, бар байлыгын талап, әрәм-шәрәм итеп, шул исәптән Шәфигулла бабайны да, "төзәлергә" хезмәт фронтына алып китәләр. Бабай сугыш алдыннан туган авылына үләргә генә кайта.

Шәфигулла картның җиләк-җимеш, алма, чия, карлыган, грушалар гөрләп үсеп утырган бакчасы илленче еллар башында гына юкка чыкты. Равил Фәйзуллинның "Әтием портретына бер штрих" шигыреннән әлеге юллар искә төшә:

Хәзер...
Синен йөзендәге шадралар кебек,
чокыр-чакыр гына бары
такыр калган тау битләре.

Ике яшь бала белән тол калган, кайгыдан күзләре сукырайган Камилә әби әнине унтугызы тулыр-тулмас килеш кияүгә бирә. Вак яңгырлы, тымызык бер иртәдә әни яна хөкүмәткә күчкән, кулларында балта тота белмәсәләр дә, күз белән телгә үткен, язу-сызу эшенә һәм сөйләү хасиятенә маһир Галиуллиннарга килен булып төшә. Сугыш алдыннан "писарьларга" ике малай бүләк итә. Миннән соң туган Фоат энем ике яшендә үлеп китә. Әти уңган, чибәр, "телсез", карышусыз кулак баласын яратып яши. Шул чорда ук реаль "влачның" шактый өлешен ычкындырганын, Шәмси шикелле үк, сизми кала. Аны Англия, Дания, Бельгия, Швеция корольләре кебек, абруйда яшәү канәгатьләндерә, вак-төяк вәкаләтләргә ябышып ятмый.

Мәктәп белән мөнәсәбәт, ягъни мәгариф департаменты, безне уку-укыту мәсьәләләре әнигә ышанып тапшырыла. Һәрхәлдә, мин беренче сыйныфка кергәндә, эти фронттан кайткан булса да, үзен әнидән белемлерәк санаса да, әлифбага мине, күрше балаларын Шәфигулла карт кызы өйрәтте.

Әни олы гаиләгә хезмәт итеп (кайната, кайнана һәм һәркайсы үз холыклы алты каенсеңел), буйсынып яшәргә тиеш булса да, эчке бәйсезлеген югалтмый.

Яңа туганнарын күп сөйләүләре, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче дип кенә эшләүләре, гамәли эштән бигрәк фәлсәфәгә өстенлек бирүләре, йорт шөгыльләрен үзе әйтмешли, әштер-өштер башкарулары өчен яратмаса да сиздерми. Тавыш чыгарып торганчы, теләсә нинди эшне, җиң сызганып, үзе башкарып ташлый. Бөтерчек кебек урында әйләнеп, һәр шәйгә өлгерә. Чөгендер басуына, бәрәңге кырына чыкса, аның артыннан өлгерәм дип хыялланма. Эре чүп үләннәрен җыярга, вагракларын матык белән егарга, җирне йомшартырга өлгерә.

Әмма чүпрәсе артыграк эләккән камыр кебек, дәрте ташып торган эти аңа чөгендер эшләргә ирек бирми: бала артыннан баланы "бүләк итә" тора. Ел аралаш кендек киселә. Аларны ничек үстерү, киендерү турында уйлау юк. "Бала үз бәхете белән туа", дип фараз кылгандыр инде Нәбиулла агай.

Ул хаклы булып чыкты. Әни күкрәк астында йөрткән ун баланың сигезе — дүрт малай, дүрт кыз — исән-имин, дүртесе Чаллы шәһәрен күтәрә, өчесе мәркәзебез Казанда дөнья көтә.

Минем белүемчә, эти белән әни тату яшәделәр. Кочаклашкан, үбешкән чакларын күрмәдек. Ә кичләрен, эшләрне бетереп, ишекләрне келәгә утыртып, чәчәкле чаршау артына, тимер караватларына кереп яткач, алар пар күгәрченнәр кебек, талгын гына бик озак сөйләшеп яталар. Сүзләрен аңлап булмый. Кеше талашса, тавышны ярдәмгә чакыра. Ә биредә иртәнге, тыныч күл өстен хәтерләткән талгынлык. Нәрсә турында сөйләштеләр икән алар шулай төн ката? Безнең турыдадыр дип уйлыйм. Ата-ананың бәхете дә, көенече дә баладан.

Аларның бер-берсен аңлап, хөрмәт итешеп, дустанә яшәүләрен тою безнең өчен таяныч, үрнәк-өлге булды. Урамда янәшә барганда этинең озын буе, киңчә аркасы янында әни кеп-кечкенә булып кала. Киенеп, ясанып ашка, мәҗлескә барганда, хуҗасыннан берничә адымга арттарак калып атлаган әни күренми дә. Безгә кызык кирәк, юри ирештерәбез.

— Янәшә бар, бераз алгарак чыксаң да ярый. Эти бит нибары буйга дигәнне аркылыга язып утырган писарь Галиулла малае, хәерче, син кулак кызы, бай кеше баласы.

Безнең мәзһәбчелек коткысы морадына ирешми. Кулак кызы шул, хәйләкәр.

— Тәңре шулай язган, — дигән була әүвәл.

Аз сүзле әни безнең наянлыкны кабул итә.

— Әтиегез ышыгында рәхәт. Җил тими, яңгыр үтми.

Без аңа артык бәйләнмибез. Алда әйтелгәнчә, озын-озак сүзләрне яратмаса да, шук колынын тәртипкә чакырып, кинәт тешләп алган бия кебек, турыдан ярып яисә шаян сүзе белән теләсә кемне урынына кую сәләте бар безнең әнинең.

Галәмгә карап уфтану, моң-зарыңны айга сөйләү, сыктану, романтик тилерүләр үтеп китә. Мәхәббәттән нәрсә кала?

Төннәр буенча сөйләшеп, киңәшеп туя алмау, кирәк чакта бер-береңә ышыклык бирә алу, арка терәге була белү кала торгандыр.

Мавыгып, читкәрәк киттем бугай. Бүген чәй янында, көн тәртибендә минем киләчәк хәл ителергә тиеш.

Июльнең егерме бише килеп җитте. Кыбырсынам. Эти минем кат-кат искә төшерелгән гозеремә бүген анык җавабын иңдерергә тиеш.

Сузарлык вакыт калмады. Сүз минем Казанга укырга керергә бару-бармавым турында...

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, инде болай да Уралга эшкә китеп, алтын балдактай кадерле бер елымны суга салдым. Мин кайтып төшәр алдыннан гына, кадерле кунакка сөенеч әзерләгәндәй, өебез янган булып чыкты. Дөньяда уку, китап, язу кебек илаһи төшенчәләр барын онытып, җәй буе бүрәнә ышкыладым, мүк төйдем, балта белән кизәндем, пычкы тарттым...

Әтинең тискәре җавабы әзер булып чыкты.

— Син, Тәлгат, быелга калырсың инде. Ызбаның эшен бетерәсе, лапасны корасы бар. Эш муеннан. Бер елга түзәрсең.

Нечкә муенымда кан тамырларының шартлардай булып, бүртенеп чыкканын сизеп, тоеп утырам. Күгемне металдай кара болытлар каплады. Кашыгымны куйдым. Бүрәнәләреннән урман исе аңкып торган яңа өйдә иске тынлык урнашты.

— Укымаганнар да ачтан үлми. Әнә тракторчы Вакыйф әзиен, комбайнчы Вагыйз ничек яхшы яшиләр, каерып икмәген алалар, теләгәнчә малын асырыйлар. Язын, ғөзен Хучти малае әйтмешли, дуфкумга, тирләп эшләп алалар да, кыш буена буран тавышын, бүре улавын, әтәч кычкыруын тыңлап, яхшы һавалы, майдан җылы өйләрендә рәхәтләнеп яшәп яталар. Кунак-кунак йөрешәләр, таң атканчы җырлашып утыралар.

Әти бармагын һавада уйнатып ала. Озак сөйләве эчке ышанычының җитеп бетмәвеннән килә бугай. Миннән тракторист, комбайнчы, тәрәзә рамнары ясаучы чыкмасын белә. Үзенә охшаганмын.

“Укырга иде, барып карарга иде, әле керә аласыңмы, юкмы”, — дип эчтән шайтан кымтырыклап утырса да, әтигә каршы барырга җөрьәт итмим.

Мич янында әтинең монологын колагына элеп торган әни лып итеп урындыгына килеп утырды. Чыраенда бер сеңере дә селкенми. Сүз Уганда яисә Конгодагы хәлләр турында бара диярсең. Хәсән Туфанның ае кебек битараф.

— Каймак әтиегезгә калсын. Җитте сезгә, балалар. Хәзер ит белән бәрәңге чыгарам.

Колакларыма ышанмыйм. Менә сина милли пәрәмәч: бәрәңге һәм кеше язмышы, каймак һәм адәм баласының киләчәге. Башым чынлый, иреннәрем җилгә тарган көзге яфрактай калтырана. Әни, берни булмагандай, Һолланд сыры кебек эре тишекле түгәрәк күмәчен кисә... Шул ук ваемсызлык, баласының язмышына төкереп карау. Үги баланы да болай какмыйлардыр.

Бәхетле кеше берни эшләмичә, кул кушырып утыра ала. Ә кайгы-хәсрәт эзләнү, хәрәкәт юлына этәрә. Берни майтара алмасаң да, боз өстендәге балыкчыдай, калкавычка кадалып, тәк кенә утыра алмыйсың. Әнигә дә ышаныч калмады.

“Әтигә башка вакытта сүз катып, подход эзләп карарга булыр, бәлки, кичен салмыш кайтыр”, — дип күңелемне юатып торган арада, әнинең артсыз урындыктан өнсез-тавышсыз гына төшеп, янынннан узганда, әтинең иненә, саба җиле кебек кенә кагылып, өстенә ак яфраклар төшерелгән чаршау артына кереп киткәнен сизми калганмын.

Әни күзгә күренми торган өй хуҗасы кебек, тавыш-тынсыз хәрәкәт итә, гел еларга, сыктанырга күнеккән идән дә шыгырдамый.

Әтинең агач аягының елак бала белән бишек сиртмәсе тавышларын бергә кушкандай шыңшып алуы мине мәлҗерәгән хәлемнән уятып җибәрде. Безнең якка борылып та карамыйча, әти, сырлы муенын күрсәтеп алды да, шул ук мич алдына кереп китте.

Чаршау артында “корылтай” барган мәлдә өстәл тирәсендә ыгы-зыгы, зилзилә купты. Һәркем үз җаен карый. Иң авыры каймакка эләкте. Ак тимер кәнди (савыт) белән түгәрәк кызыл авызлар арасында очып йөргән кашыклар артыннан күз белән ияреп баруы мөмкин түгел иде.

Бусы — кызлар хәрәкәте. Терекөмеш кебек тынгысыз, елгыр Әфхәт тә "абруй" белән "түбә"нең гаип булып торуыннан файдаланып калырга ашыга. Максаты күңеленә ярашлы: самавыр янына оялаган шәмәхә савыттан, карга борын белән вакланган шикәр кисәкләрен эләктереп калу. Артыннан үсә килгән Сөгъдә, Сөльма, Сәгъдияләр кебек мәче ризыгы — сөтөстенә аның бик исе китми.

Безнең нәселдә шикәр, конфет ише татлы әйбергә гашыйк, җанын бирердәй мөкиббән киткән, әниенең яшереп тоткан тәмле әйберләрен "чәлдереп", әлбәттә инде, ахыр тотылып, күп мәртәбәләр дөм караңгы идән асты базында утырса да, баллы нигъмәтләргә җылы карашын үзгәртә, мәҗүси омтылышын җиңә алмаган бер генә кеше бар. Ул — Әфхәт. Бер "ужымга" чыккан биләмче хатынны азгынлыктан биздереп булмаган кебек, аны да сайлаган юлыннан яздырырлык алым, кодрәт табылмады. Шомлы көч аны шул юлга этәрә тора. Алгарак китеп шуны искәртәсе килә: җөмһүриятнең табиблык дөньясында танылган, олы шәхесләрнең берсе булып күтәрелүенә карамастан, ул балалык зәвыгына турылыклы калды. Аңа затлы аракың, әрмән коньягың, шифалы шәрабың кирәк түгел, ә ирисны, карамельны суырмыйча тора алмас, бу мәсьәләдә теләсә нинди дәрәҗәле тәмлетамакны бәйгегә чакыра алыр.

Әфхәт кичә генә "ашаган" тал чыбыгы тәмен онытып, кесәсенә шикәр тутыра. Кичәге хәлләр болайрак булды. "Тикшерү" эшләре әниенең рәсми белдерүеннән соң башланды.

— Нәбиулла, келәттә шикәрем кәми дә кәми. Ачкычын да күлмәк кесәмдә йөртәм. Аптыраган, — ди әни, барыбыз да ишетелерлек итеп.

Кемнең бүреге янганны чамаласак та, тотылмаган бур карак түгел, җиһанда гаделлек булырга, дөреслек җиңәргә тиеш.

Ошбу хәбәрне тырпаеп торган колаклары аша зиһененә үткәргән әтинең күтәртмәле иреннәренә хәтәр елмаю иңә, кашлары һавадагы сыерчык коерыгыдай өскә күтәрелә. Эндәшми. "Шикәрне кем чәлдерде", — дип сораудан файда юк. Дураки нема. Берәү дә өстенә алмаячак.

Соңрак әти, берәүгә дә сиздермичә генә, күзәтү эшен хәзер үзәк балалар китапханәсендә эшләүче, үткен күзле, туры сүзле Сөльмага тапшыра. Чая, елгыр, симез шамбы балыгы кебек шома Әфхәтне ул гына эләктерә алачак. Аның артыннан килгән Сөгъдә белән Сәгъдия әләк, чагу, күзәтү, кебек житди эшкә ярамыйлар. Түземлекләре житми. Әфхәтнең болай гына калдырмасын да беләләр. Үч алдан, акыл арттан йөрсә, эш харап. Апаларының күлмәктән "чыгуын", аяк киемнәре үзләренә кечерәюен көтеп йөргән Лилия әле житди йомыш кушарлык яшьтә түгел.

Сөльма өстенә йөкләтелгән бурычны пионерларча жиренә житкереп (барыбызга да тансык шикәр ни өчен әле Әфхәтнең күңелен генә күрергә тиеш) үти, карындашының лапас башындагы юкә кабыгын, бәрәңге бакчасы ягыннан каерып кереп, тар гына тишектән елан кебек эчкә шуышып төшүен күрүгә, сөенечле хәбәрен төшке ашка кайткан әтигә ирештерә.

Тешне камаштыра торган салкын сулы, үтә күренмәле чишмә кырында Әфхәтне дус-иш көтеп ята. Сихәтле суга манчып суырган шакмаклы шикәр балыннан да тәмлерәк, татлырак нәрсә бармы икән бу фани дөньяда? Бәлеш төбе, кызлар теле, Бохар кәләвәсе бер якта торсын.

Ни кызганыч, бу трит шикәр тәмле тамакларга тәтеми. Җайдак кебек аякларны аерып куеп, таныш бүрәнәләрне кармалый төшкән жайга, угрыны су эчендә зарыгып, пешеп яткан тал чыбыгы каршылый. Татар телендә тәрбия алган кешегә пальма, кипарисларга караганда тал якынрак, таныштрак. Шул ук вакытта аның "теле" бәйнәлмиләл. Һәркем аңлый торган ләгать: чыж да пыж, пыж да чыж. Бернинди толмач кирәк түгел.

Тәрбияви гамәлен әти кеше малайның җилкәсеннән тотып, ихластан башкара. Аркаданмы, әллә инде корбанын кызганган тал чыбыгыннанмы, шарлап кан ага. Әфхәтнең коңгырт соры күзләреннән тәүге каен суыдай үтә күренмәле, кристалл төсле саф шарлар тәгәрәсә дә, мондый очракта

акырыш, бакырыш, тавыш белән җылау кабул ителмәгән. Рәхәт яшисен килсә, тотылма!

Дөресен әйткәндә, эти ике үчне берьюлы алды бугай. Малай берничә көн элек кенә, этигә сатышырга ярдәм иткән булып, затлы хушбуйның исерткеч тәмен тузалмыйча, кечкенә шешәне кесәсенә шудырткан. Дөрес, аны үз шәхси мәнфәгатьләре өчен алмый, чәчәк-гөл маен бер сыйныфка түбәнрәк укучы кызга бүләк иткән. Мондый фидакарьлектән кайбер шагыйрьләр шаклар катып, газәлләр иҗат итәр, Хәй Вахит "Беренче мәхәббәт" дигән пьеса язар иде. Эти, пнимаете ли, тормыштан бер адымга артка калып бара, яраткан улының хисси дөньясын, тәвәккәллеген анларга теләми.

Әтинең кызышуы җиткән иде. Тамашаны әни туктатты.

— Житте, Нәбиулла, ул бүлше урламыйм, диде.

Әти шул сүзне генә көткәндәй, җәһәт кенә чыбыгын җиргә ташлады. Әни бакчадан олы әрекмән яфрагын өзеп алып, угрының аркасына куйды, күлмәге белән каплап, ыштанын күтәрде.

— Бар, өйгә кер. Корсагына ятып тор.

Безгә чыбык "ашату" эти өчен дә мәҗбүрән нәрсә түгел. Ул нәрсәнең гонаһ, нәрсәнең яхшы булуын үзе аңлаганча, булдыра алганча аңлатырга тырыша, нәселдән нәселгә, атадан балага күчә-күчә килгән әдәп-әхлак кагыйдәләренә, халык педагогикасына таянып тәрбияли. Димәк ки, анда бу алым да каралган, хупланган. Безне фани дөньяга китергән кешеләрнең төп максаты: урларга, әйберне сорамыйча алырга ярамый, дигән иманга китерү. Шикәрне кызганудан бигрәк (анысына да кытлык), безне түземлелеккә, чыдам булырга, бер мизгеллек ләззәткә кызыгып, намусыбызны югалтмаска өйрәтү, шуны канга сеңдерү (тал "малае" ярдәме илә булса да).

Чыбык белән кыйналу җитди җәза түгел инде анысы. Урам сугышларында күбрәк эләгә. Аның иң әшәкесе — әхлакый ягы — карап торучылар, шаһитлар булу.

Мин урта гасыр экзекуциясен күреп тордым. Әле чыбык эзләре ямалып бетмәгән Әфхәтне минем көймәмнең комга килеп төртелүе артык көендермәве табигый.

Укырга китәргә дигән хыялымның, өлгергән кабак кебек ташка төшеп шартлавын күргән энекәш, булачак медицина фәннәре докторы, профессоры, академик, кулларын күргәзмәле-тасвирый рәвештә өстәл өстенә урнаштырып (янәсе, ул бернигә кагылмаган, берни чәлдермәгән, тәүфыйкъ иясе, вак-төяк белән алыш-биреше юк), бишенче сыйныфны тәмамлаган чыраена, коңгырт бөдрә чәчләренә ифрат эшлекле кыяфәт чыгарып, сорап куя:

— Хәзер нишлисең инде?

Үз өстемә берни аласым, вак-төяк халык белән җәелеп, аралашып утырасым килми. Бәгырь әрнүенә түзеп булмый: "Үзләренә Уралдан күпме бүләк, күчтәнәч алып кайттым, җәй буе өй салышып бил бөктем. Рәхмәте шул".

— Эти үзе хәл итәр. Ничек язган, шулай булыр.

Сорау тиктомалдан, кызыксынудан гына бирелми. Малай —хәйләкәр, мин авылда калсам — аңа җиңеллек. Мал-туарны карау, утын-печән әзерләү һәм каралты-кура тирәсендәге тавык чүпләп бетергесез вак-төяк эшләр минем җилкәгә өеләчәк.

Үч алу хыялы белән алгысынган Әфхәт этинең гамәлен эчтән хуплап утыра булыр. Дөнья күләсә, янәсе, бер әйләнгәндә миңа басса, икенчесендә синең авырткан сөяленә китереп сылавы ихтимал. Тычканга үлем, мәчегә көлке. Урыннар алышынды.

Гавам өстәлдәге нигъмәтне "җыештырган" арада, акшары кибеп житмәгән олы мич артында югары дәрәҗәдәге киңәшмә дәвам итә. Күрәзәче, әүлия булмасам да, "разборка"ның миңа кагылганын сизенәм.

Шул арада эти чаршауны эре генә читкә тибәреп, "баланы", ягъни мәсәлән агач аякны бер-ике шыңшытып алып, Хафизулла, Галиулла

бабайлардан мирас булып калган, буявы коелып, уңып, швед токымлы сыеры түсенә кергән бердәнбер артлы урындыкка урнашты.

Ашыкмый. Тыныш билгеләрен урыннарына утыртырга ярата. Суынган чәен йоткан булды. Чырае балтасы суга төшкән кешенеке кебек моңсу, сагышлы, хәсрәтле.

— Син, малай, укырга барырга әзерлән. Монда эш бетмәс. Чуаш хатынының үлгәч тә өч күнлек йомышы калган, ди. Түбәбез бар, яңгыр тими.

Минем инде укырга барасым килми икән. Өйдә рәхәт, тынчу, авызда каймак тәме.

— Әзерләнергә вакыт калмады инде. Бәлки, киләсе елга барырмын, программаны кабатлап.

— Сине күзгә барыбер армиягә алачаклар, ике елыңны шунда әрәм итәсең киләме? Тиз генә җыен да, юлга чык. Ике әйттермә. Бар булган запас акчабызны әниең бирер.

Безнең өйдә еш кына авыр мәсьәләләр менә шулай хәл ителә иде. Әни илаһи тәэсир көчен сиздермәс, кешегә күрсәтмәс, әтинең минминлегенә тимәс, мәгәр тавыш күтәрми, каршы әйтми генә үз фикерен, сәясәтен уздырыр.

Әлбәттә, быел сиксәнен тутырган әни шактый картайган, йончыган, кайчандыр өйне, безнең күңелләрне яктыртып, нур сирпеп торган күгелҗем күзләре тоныкланган. Яраткан малае — Әфхәтне күренекле табиб булуына карамастан, коелган тешләрен куйдыруга ризалашмый. “Булганы житкән, ит ашамыйм, миңа теш нәрсәгә, тешләшер кешем юк”, — дип шаяртып котыла. Мәсьәләне үз аңлавы бар. Әни дөньяны сабырлыгы белән җиңде.

Гайбәттән курыкмады, яшеренеп яшәмәде, көнчелек, саранлык, хәсәтлек кебек нәрсәләрне белмәде. Тормышы ифрат авыр булуына карамастан, түземлелеге һәм әлеге сыйфатлары өчен аңа табигать-анабыз озын гомер, бәхетле картлык биргән.

## Апалар, сеңелләр...

Беренче укытучы... Нинди илаһи, ягымлы, таныш һәм серле сүзләр. Олы дөньяны, матурлыкны, тирә-юньне танырга, сәер таяклар-хәрефләр артына яшеренеп яткан эчке мәгънәгә үтеп керергә, әдәби телдә сөйләшергә, санарга, үлчәргә өйрәткән бу изге зат хакында бик күп җылы, акыллы сүзләр әйтелгән, җырлар, шигъри багышлаулар язылган булса да, һаман аз тоела. Ник дисәгез, йөрәге астында йөртеп, күкрәк сөте белән үстергән, һәр адымың өчен янып-көеп яшәгән анадан кала мәдрәсәдә, мәктәптә белем, тәрбия алган кеше өчен беренче укытучы иң якын вә мөкатдәс кешедер. Әнә Чыңгыз Айтматовка шул исемдәге әсәре дөньякүләм шөһрәт алып кайтты.

Беренче укытучы турында, аның кем булуына, кайда яшәвенә карамастан, язылмаган кануннар тудырган, әзер өлгеләре белән күргәзмәле сурәте яши: ул ифрат гадел, ярдәмчел, белемле, акыллы киңәше белән бүлешергә һәрдаим әзер, тәрәкъкый пәрвәр шәхес. Ул кеше турындагы фикер гадәти үлчәмнәргә, әзер калыпларга сыймый. Ә менә беренче укытучың Каф тавы артыннан иңмичә, фәрештәдәй канатларын җилпеп күктән төшмичә, кычыткан шулпасын, язын колхоз кырыннан казып алынган бәрәңге көлчәсен, тары боткасын бер табак-табадан сугыша-сугыша ашап, малны бергә көтүгә куып үскән апаң булса, нишләргә? Аны романтик биеклеккә күтәреп, идеаллаштырып сурәтләргәме? Әллә бизәмичә, ясалма уенчыклар такмыйча, тормышта ничек булган шул рәвештә күрсәтергәме? Миңа соңгысы кулайрак күренде.

Дөрес, беренче сыйныфта берничә ай Илһамия исемле бик өлкән яшьтәге апа-әби укытты (сугыштан соңгы беренче ел, ярдәм итүен сораганнардыр инде), исәнлеге какшап, ул безне бик тиз ташлап китте.

Мәгәр бер сыйфаты белән күңелдә мәңгегә калды. Колгадай озын буйлы (бәлки, шулай күренгәндер), кара тут йөзле, яңаклары эчкә тартылган, янган каен күмере кебек чем кара күзләре тар маңгае астына тирәнгә кереп утырган ошбу укытучы ифрат явыз кеше иде. Усаллыгы озын агач линейкасында. Метрлы линейка баш өстендә бөркет төсле очынып йөри, куркудан баш эшләми, йөрәкләр туңа. Сугуы сирәк, әмма иң авырта торган җиргә, кул бармакларына китереп сылый.

Без аңардан котылуга сөенеп бетә алмадык. "Агач линейканы" әтинең иң кече сеңелесе Рәйсә апа алыштырды. Ул әле генә Кычыткан-лыдан унике чакрым ераклыкта урнашкан Колбай-Мораса авылында урта мәктәпне яхшыга тәмамлап кайткан. Заманасы өчен укымышлы кеше.

Безнең якта Алпар, Үзи, Камка, Базарлы Матак кебек мәгърифәт нуры чәчеп утырган, элек-электән мәдрәсәләре белән дан тоткан, театр сәнгатенә татар Станиславскиен — атаклы режиссер Габдулла Кариевны биргән авыл иде Колбай-Мораса. Авыр сугыш елларында да ул урта мәктәбен саклый алды, дөресрәге, ул безнең төбәктә тулы белем биреп чыгара торган бердәнбер саф татар мәктәбе булып калды. Борынгы мәшһүр калабыз Биләргә якын утырган, табигатьнең илаһи, ямьле, тормыш өчен җайлы (елгачыгы бар, җире уңдырышлы, әрәмә-куралары җитәрлек) бер почмагына кереп оялаган Колбай-Мораса бик борынгы авыллардан булырга тиеш. Исеме буенча ул Болгар-Биләр дәүләте чәчәк аткан чорда ук туган дигән фаразга нигез бар. Ул дәвердә "кол" сүзе белән башланган исемнәр ("Кыйссаи Йосыф"ның иҗатчысы Кол Галине генә искә төшерик) еш очраган. Ә биредә "колы" янына "бае" өстәлгән, соңрак, ачыкламыш рәвешендә, шунда җәйрәп агып яткан елга исеме дә өстәлгән: Колбай-Мораса. Күрәсең, бу авыл Биләр ханының яисә аңа якын бәкнең, бинең җәйге биләмәсе, ял урыны булгандыр. Шәһри Биләрнең даны, шаны җир астында, зәңгәр томанлы риваятьләр, җырлар канатында гына калган, изге җирен башка кавем халкы, маллары таптый. Колбай-Мораса тамырын, борынгы халкын, мәдәни нигезен саклап кына калмаган, минем беренче укытучымны оясыннан очырган, аңа тәрбия биргән.

Авыр, озын линейкалы Илһамия апа урынына укытырга Рәйсә керә башлый дигән хәбәрне мин сөенеп каршы алдым: үз кеше, якын кеше, рәнҗетмәс, икеле чәпәмәс... Блат, ягъни мәсәлән, әшнәлек, туган-тумачалык, кода-кодагыйлык кебек төшенчәләр адәм баласының канына, зиһененә ана сөте белән үк сеңә торгандыр, мөгаен.

Рәйсә апа безнең нәселнең бар матурлыгын үзенә җыеп алган, чибәрлеге белән тирә-юньдә дан тоткан кыз, сугыш чоры ризыклары — бәрәңге белән ботка да юкка чыгара алмаган нечкә бил, умырткада, чәч төпләрендә сәер сискәнү уятырдай, мөлдерәп торган зур күзләр, үпкәләп, җылы сүз көтеп торган баланыкыдай алга бүлтәеп чыгып торган тулы, дымлы иреннәр, кичә генә акшарлаган мичтәй ап-ак тән, тулы бармаклар — һәммәсе аңа килешеп тора. Кара коңгырт чәчләре дулкын-дулкын булып иңбашына төшкән. Җитмәсә, үзенең бәясен белеп, табигать болай да мулдан кыланган гүзәллегенә, сугыштан соңгы чор мөмкинлек биргәнчә юнәтелгән, көяз-ыспай кием-салым. Пөхтә, нәфис, затлы итеп киенә белү — хатын-кызның бәхете. Йөзендә һәрвакыт җитдилек белән ярым шаян кызыксыну. Үзенә көлү килешә. Ник дисәң, тешләре ап-ак, тигез. Авыр колхоз эшендә иртә картайган хатын-кыз белән чагыштырганда, иркә үскән Рәйсә апа гүзәллек үрнәге, мәхәббәт алиһәсе булып тоелгандыр.

Кызганыч ки, минем мәктәптә башланачак рәхәт тормыш турындагы гоманым акланмады. Апаның укытучылык тәҗрибәсе юк, бала үстергән кеше түгел. Беренче көннәрендә дәреслегеннән аерыла алмый интекте, тактага яза башласа, каушый, акбуры кулыннан төшеп китә. Ә без, Илһамия апаның агач тактасына буйсынырга өйрәтелгән юеш борыннар, дилбегә бушаганны сизгән тук ат мәсле, тәртипсезләнә, шаулаша, сугыша ук башлыйбыз. Яхшылыкның, кешечә мөнәсәбәтнең йомшаклык булуы мәҗбүри түгел икәнен аңлау өчен вакыт, тормыш тәҗрибәсе кирәк шул.

Апам өчен әчтән гарьләнәм, көенәм, дулкынланам. "Жир битләр, әрәм тамаклар, ничек оялмыйча шаулыйсыз, авылның иң чибәр кызы бит ул, минем әтинең сеңелесе, сезгә яхшылык тели", — дип, күңелемнән кайнап утырам. Башкача ярдәмем юк. Яшь мөгаллимәгә терәк, таяныч булырга тиешлегемне эчке тоем белән чамалап, телеграф чыбыгына кунган чыпчыктай, селкенергә куркып, пуфылдатып һава чыгармаска да тырышып, тәрбиялелек үрнәге булып утырам. Тик миннән өлге алучы гына күренми.

Рәйсә апага педагоглык орлыгы тумыштан салынган булып чыкты. Яңа бер тәрбияви алым уйлап тапты тәки: парталар арасында тыз-быз килеп, йөгерепатлап йөрде дә, "укучылар шауламагыз, тыныч утырыгыз", дигән сүзләреннән эффект күрмәгәч, минем янга килеп, кара туфлиенең очлы башы белән минем тез астындагы сөяккә каты итеп китереп типте. Дөнья зең итеп китте. Тәрәзәләр калтыранды. Күзләремә читләре кызыл караңгылык инде. Күздән ирексездән бәреп чыккан тозлы суны туктата алмасам да, кычкырып еламыйм, авыртуны учыма, йөрәгемә төйнәп, түзәм. Иң гаҗәбе шунда: Рәйсә апа "ачкан" бу методик алымның файдасы тия, шуклар тынычлана, укытучыны кешегә саный башлый. Аларда да миндәге сөякләр бар ич. Апаның туфлие үзенеке, бурычка алган нәрсәсе түгел.

Ул чорда апаның "кеше баласын" сыйныфташларым каршында типкәләвен авыр кабул иттем. Күңелем рәнжеде.

Рәйсә апага үпкәләвем тирәнгә китә алмый, ул бусаганы атлап үтүгә, "наным ачуланма инде, яме", дип башымнан сыйпауга, күңелдәге боз эри дә төшә. Әти-әнигә әләкләмәвемне дә ошатты бугай.

"Кабыргамны сындырмады, тешләр урынында, кан чыкмады", дип беренче укытучымның әшәке гамәлен йомшарту юлына басам. "Аның каравы карабаш, уҗым бозавы, мәче, тәкә, ефәк корты малайлары, кызлары минем апамда укый". Шул мизгелдә нәни күңелемдә, шагыйрь әйтмешли, бер горурлык хисе кабына. "Ул балдай татлы, матур итеп сөйләшә белә, безне кеше юлына чыгара", — ди-ди полный аклау алымнарын эшкә җигәм. Бала күңеле нөктәле үчне озак саклый алмый. Бөгелүле-борылышлы тормыш низаглары, сугыштан соңгы ачлы-туклы яшәеш авырлыгы бу вакыйганы тиз онытгыра.

Дөрес, беренче укытучым педагогика дәреслекләренә һаман кереп китә алмаган ачышын ел дәвамында, тәкате корып, янәдән берничә тапкыр кабатлады. Әмма мин инде тәҗрибәле, коры кул белән тотып булмый: тез астына йомшак чүпрәк кыстырып киләм. Һич югында, үз каланчамнан дөньяны тигезләп, "тәрбиягә" икенче аягымны чыгарып кую хәстәрен күрәм. Бу мизгелдә укытучымның күзләре еланныкы сыман салкын, кырыс, явыз, матур йөзе чит, ят күренә.

Апам педагогия институтына читтән торып укырга керде. Шунда ул үзгәрде, үсте, татар әдәбиятына гашыйк булып кайтты. Аның белән бергә безнең өйгә Кандалый, Тукай, Такташ кебек шагыйрьләр, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни кебек прозаиклар керде. Кичләрен керосин лампасы яктысында апа безгә Фатих Әмирханның "Хәят"ын укый. Тәрәзә артында өйгә керергә сорап, таләп итеп буран дулый. Бүре улаганы, этләрнең куркудан шыңшыганы колакка керми, безне татар кызының бераүнекенә дә охшамаган язмышы тетрәндерә, сискәндерә. Минем әдәбиятчы, язучы булып китүемә Рәйсә апа, кичләрен бергәләшеп әсәрләр уку тәэсир ясагандыр, зәмин әзерләгәндер дип уйлыйм.

Хәятның насыйбын без үзгәртә алмыйбыз. Инде өлкән сыйныфларда эшләгән, абруйлы укытучы булып үсеп җиткән апама да киләчәген билгеләргә, үз оясын корырга вакыт җиткән.

Егетләргә кытлык юк. Мәхәббәт хисләренә чыдый алмыйча, апаның артыннан балык көтүе кебек өерелешеп йөриләр. Кул изәгәнне генә көтеп йөрүчеләре дә булгандыр. Җөмләдән, күрше Яңа Әлмәт авылы укытучысы, олпат гәүдәле, көчле тавышлы Сахип абый Рәйсәгә битараф түгеллеген яшерүне кирәк санамый. Юк-бар йомыш табып, туктаусыз килеп явып торган теге болыт кеби, бик еш авылда, мәктәптә пәйда була, әтинең хәлəхвәлен белешкәндәй итә.

Тәкәббер Рәйсә апа аны салгаларга яратканы, аракы белән дуслыгы өчен кире какты. Сәбәбе, бәлки, тирәндәрәк яткандыр.

Сонрак мин Сахип абыйда укыдым. Физика кебек авыр, катлаулы фәнне ничектер җиңел итеп, тормышка бәйләп анлатуы белән күңелдә калган. Миңа канықмады, якламады, берни сиздермәде. Егет кеше иде.

Үзебезнең авылдан апа кулына дәгъвачы Илгиз берничә йорт аша гына яши. Күптән түгел күчеп утырган гаилә. Янә ике малайлары бар: Револь, Ревинер... Авыл халкы, бигрәк тә өлкән буын, Әсма апа малайларының исемен әйтә алмыйча телләрен сындырып бетерә язды. Сизенгәнсездер инде: мондый исемнәрне укытучылар гына газиз балаларына куша ала. Революция рухы, аңа бирелгәнлек, махмыр төсле, ерактан аңкып торсын.

Олы уллары Илгиз ошатмаслык түгел: кин җилкәле, төп шикелле таза, кайдадыр читтән торып укый. Әти янында "Нәбиулла абый, бирәр ярдәм кирәкмиме", дип биеп, ярарга тырышып йөри. "Кемгә жизни дип дәшәргә телисең", дип миннән сораучы-мазар булса, "бары тик Хажи абый белән укытучы Әсма апа малае Илгизгә", дип шартлатып җавап бирер идем. Сораучы гына булмады.

Апа анын мәхәббәтен бусагадан кире какты. Янәсе, әйткән имеш: "бозау Илгизенә кияүгә чыгып (кушаматлары шундый иде), авылда бозау карап ятасым юк".

Чибәр кыз ашыкмый, үзенең тажлы җефетен көтә, шул арада, дипломын алып кайта. Минем белүемчә, Кычытканлы авылыннан ул беренче булып югары уку йортын тәмамлаган кеше.

Яшь бара, анын кулын сорап йөргән егетләрнең күбесе башлы-күзле булды, чиләгенә күрә капкачы табыла тора. Апаның да битенә гөл үсмәгән. Ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәт ул ике яклы пычак кебек, мәхәббәт белән нәфрәттән тора. Берсеннән икенчесенә күчеш бик җиңел ясала.

Рәйсә апаның язмышы хәрбидән булган икән. Илленче елларда погонлы кешеләр модада, алар белән мавыгу ифрат көчле иде.

Русиядә мундирлы вә мылтыклы кешеләрнең абруе гел зурдан булды. Чөнки бу ил сугышсыз яшәүне белмәде, кимендә һәр ун елга, тышкы мәмләкәтләр белән булмаса үз илендә, азатлык, бәйсезлек, тигезлек таләп иткән үз халкы белән сугышты. Төп таянычы хәрбиләр булган режим (патша булсын, коммунистик чор булсын) сакчыларына яхшы түләде, яшьли һәм саллы акча белән пенсиягә чыгарды, Мәскәүдән кала барлык шәһәрләрдә тиз арада тораклы итте.

Хәрби уку йортларына конкурслар искитмәле зур булу да аңлашыла. Чөнки илнең чикләре бикле чорда бу халыкка гына чит илләрдә яшәү, хезмәт итү мөмкинлеге бар иде. Иләс-миләс хатын-кызга ГДР, Болгария, Венгрия, Чехославакия кебек сүзләр үк бөтенләй башка дөнья, оҗмах капкаларына ачкыч сыман тоела. Кыскасы, хәрбигә, бигрәк тә чит илдә хезмәт итүче офицерга кияүгә чыгу бәхет, мәртәбә санала. Андагы затлы кием-салым дисезме? Бирегә гомергә таба, эзенә төшсәң дә, акчасын житкерә алмаслык Казан туннары анда шалкан бәясе генә тора, ди. Менә шундый имеш-мимешләр хатын-кызның миен агулый, күзен тондыра. Хәрби киемле кеше төшләренә керә башлый.

Үз чорының әхлагыннан сикереп үтеп булмый. Рәйсә апа да замана баласы булып чыкты. Җирле егетләрдән баш тартып, Германиядә хезмәт итүче, яшь офицер, танкист Хәким Гирфановка өстенлек бирде.

Без Рәйсә апа белән дуслар идек. Инде туйлар узгач, үзен генә туры китереп, сорарга җөрьәт иттем.

— Син аны, жизнине яратасыңмы?

Җавабы ике яклы булды.

— Кем беләндер тормыш көтәсе. Миңа ул ошый. Яратам дип күкләрдә очмыйм, ялкын суламыйм. Әмма аны бирәүгә дә бирмим.

Шунда ук, кем алдында ачылып ташлаганы исенә төшеп, мине сүгеп атты.

— Дурацкий сорауларың белән сару кайнатып йөрмә әле. Тот капчыкны, китапларны тутыр.

Германиядә аның дипломының кирәге булмады. Ике кыз үстерде. Сирәк-мирәк кунакка кайткаласа да, туган җирлектән аерылды. Кырыс табигатьле Хәкимҗан җизни кыска гомерле булды, подполковник дәрәҗәсенә җитеп, чибәр хатынын ташлап теге дөньяга китте. Дөрес, язмышын сизенгән кешедәй, гаиләсен Санкт-Петербургка күчереп, фатирлы ясап калдырырга өлгерде. Рәйсә апа исән-сау, ике кызы белән Нева буйларында яшәп ята, балалар бакчасында эшли.

Әтинең башка сеңелләре дә, югары белемнәре булмаса да, чын филологлар, табигатьтән телгә-сүзгә маһир кешеләр.

Араларында тумыштан иң сәләтлесе, һичсүзсез, әтинең өлкән сеңелесе (алар Гөлсем апа белән игезәкләр, үз чиратларында икесенең дә игезәкләре бар) Зәйнәп апа булыр. Сүзе чишмә суыдай агылып торган кешеләргә нисбәтән халык "телләреннән бал тама", ди. Бу, тулаем, югары бәя. Әмма безнең апа өчен бу йомшак бәяләмә, аерткан сөт кенә. Шайтан үзе дә, кәефле чагына туры килсә, билләһи дим, азау тешен алдыргандагы шикелле, авызын ябарга онытып тыңлаячак һәм ахыр чиктә көнчелектән үз төкерегенә үзе тончыгачак. Зәйнәп гадәти мәгънәдәге гайбәтче, вәсвәсә таратучы түгел, ул — илаһият кешесе.

Апа бигенаһ яшькелт-соры күзләрен тыңлаучының йөзенә төбәп, тулы иреннәрен бер-берсеннән теләр-теләмәс кенә аергандай итеп, сүзен тәсбих төймәләрен барлаган шикелле салмак кына башлап җибәрер, олы сәясәткә, дөнья хәлләренә кыскача гына бәя биреп үткәннән соң, балаларын искә алып, "минем Фуатым" дип, яраткан малаен уч төбендә биетеп алганнан соңра, туры сүз таш яра, ялган сүз баш яра мәкаленә таянып, авыл хәлләренә кереп китәр. Саргылт йөзенә илаһи нур кунар, әмма елмаю, көлүнең, җитдисезлекнең эзе дә булмас. Аның хыял җимеше белән чынбарлык арасындагы чик кылдан нечкә, кылычтан үткен булыр. Сөйләм агышын салмак дулкында тотып, авылны бер урап чыгар, ике әйләнер һәм, үзе уйлап тапкан, өстәгән, тулыландырган хәл-әхвәлләргә үзе үк ышана башлар. Икенче очрашуда, мәҗлестә инде баягынак үзе уйлап чыгарган нәфис сүзне, сөйләкне Гөлсемнән, Халисәдән, Мәзкура, Зәмзәмия апалардан ишеттем дип, "кош балаларын" икенче түгәрәккә очырып җибәрер. Халык иҗаты гәүһәрләре —мәзәкләр, әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, хәтта табышмаклар шулай туганнардыр дип уйлап куясың.

"Без ун бала анасы Зәйнәп апаны яратып, хәтта эчтән аның табигый сәләтенә сокланып, нәселнең идеологы — Сусловы (коммунистик режим чорында дистә еллар секретарь булып утырган кеше — соры кардинал) дип үрти, ирештерә идек. Аңа вакытында югары ук димим, урта белем бирсәң дә, һичшиксез, журналист, язучы, сәясәтче, җәмгыяви эшмәкәр чыгар иде.

Ә мондый бәхеткә тарган яшьләр, хәтта Казан университетында укунын да кадерен белмиләр. Хәтер йомгагына шундый бер сөйләшү чорналып калган. Университет профессоры, күренекле тел галиме, академик Диләрә Тумашева, хәл-әхвәл сорашканнан соң, зарлана башлый.

— Тюркология фәненә керештән бищ группадан имтихан алдым. Башым тубал кебек.

— Мин сезне аңлыйм. Факультет бик нык үсте шул. Ихтыяҗ барында, телебез, әдәбиятыбыз буенча яшьләрне күбрәк әзерләп калдырыйк. Сәясәтне белмәссең, бүген болай, иртәгә тегеләй, — дип, мөхтәрәм укытучыны тынычландырырга ашыгам.

— Эш күплектә генә түгел. Катып калган штамп җавапларны тыңлавы кыен. Саруларым кайный.

— Тел белеме, математика кебек үк, төгәл фән шул. Кабатлауларсыз булмый торгандыр.

Ул һаман үзенекен:

— Бер тамчы су кебек буш җөмләләрдән торган җаваплар җанымны үтерә, — дип, ихластан зарлана.

— Алай ук түгелдер. Яхшы җаваплары да бардыр. Кибәксез ашлык булмый.

— Тыңлап карагыз: мин якты көн дәвамында бер үк калыптан төшкән шундый җаваплар тыңлап утырырга мәҗбүрмен. Революциягә чаклы туган тел галимнәренең барысы да урта хәлле яисә ярлы крестьян гаиләсендә туган, әтисе укымышлы булган, малаена аң-белем бирергә тырышкан. Мәдрәсәдә укыту эше бик начар куелган булган, укыту бик искечә, реакцион алып барылган, мәдрәсәләрдән надан кешеләр генә чыккан. Ну фәлән фәләнович андагы схоластик белемгә генә ышанып ятмаган, үзлегеннән укыган. Ана телен бик яраткан.

1917 елдан соң авылга азатлык килгән, яңа, якты мәктәп ачылган. Анда укытырга төрле яклардан алдынгы укытучылар килгән, яхшы укытканнар. Фәлән фәләнович тырышып укыган, аның өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Ул тиз үскән һәм татар халкының зур, сөекле галиме булып киткән...

Гариф кызы Диләрә бик күп галим-голәмә, журналист, язучы халкының, шул исәптән, минем дә укытучым. Хисси монологны бүлдермичә тыңлап торам да: "Соң нигездә дөрес сөйлиләр бит. Дәреслекләрдә шулай язылa иде", — дип куям.

— Дөрес дип инде. Примитив. Шуннан артыгын белмиләр. Безнең чор галимнәре Зәкиев, Саттаров, Хаков, Ганиевләр турында да шуны ук сөйлиләр. Революциягә хәтле, революциядән соң... Хәзерге студент бөтенләй укымый...

Кызганычка каршы, остаз хаклы. Яшьләрнең күңеле китапка ятмый, чыганаклар белән кызыксынмый, агымдагы әдәбиятны укымый. Замана шуңа өйрәтәме, әллә җиңел килгән бәхет шулай кадерсез буламы?

Галиуллиннар гаиләсендә телгә һәвәс кеше Зәйнәп апа гына дип уйласак, дөреслеккә хилафлык кылыр идек. Туган сеңлем, зәңгәр күзле, ак чырайлы, ай битле Сәгъдия пешерү эшенә осталыгы янына, "гыйсъянчылык-ка" бирелеп алырга ярата.

"Син Зәйнәп апа урынына каласы кеше, телеңне гел чарлап тор", — дип ирештерүләргә бик исе китми. Сиземләвемчә, мондый тинләү аның күңеленә сары май булып ята. "Мин зур апага житкерә алмыйм", — ди-ди тыйнакланган булып кылануы күзгә төтен җибәрүдән, эчке канәгать-лекне яшереп маташудан үзгә шәй түгелдер.

Дөрес, медицина хезмәткәре буларак, тел-сөйләү сәләтен, хыялый фикерләвен үстерергә вакыты азрак, аннан килеп, Чаллы каласында урман кычытканлысындагы кебек беркатлы, ышанучан, авыздан төшкән сүзне табадагы коймактай көтеп ала торган, һәрхәлдә сиңа ихлас күңелдән ышанган кеше рәвешенә кердә белгән рәхмәтле аудиториясен каян табасың! Зәйнәп апа "тамашачысы" Чаллыда юк инде ул.

Әтинең сеңелләре арасыннан минем рухыма ин якыннарының берсе — Рәһбәр, безнеңчә, Шәкерт апа. Соңгы ачыкламышы кушамат түгел, ә кешенең җисеменә, һөнәренә, табигый сәләтенә яраклап әйтелгән мактаулы, яратулы, иркәләүле билгеләмә. Минем "гувернанткаларым" арасында ул мөнәзе белән иң гадие, халыкчан һәм ихласы иде дип беләм.

Кинчәрәк битле, сылу, зифа буйлы Рәһбәр апа пөхтә итеп киенә, булганны саклап тота белүе белән яшьтән аерылып торды. Аның һәр хәрәкәте, алдан уйланылып куелган шикелле, табигый килеп чыга. Әйтик ул кулларын, мәшһүр җырчыларыбыз кебек, кая куярга белмичә интекми. Аларга һич югында гамәли эш табып тора.

Безнең, нигездә, филологлардан торган нәселдә ул беренчеләрдән белемле математик, физик. Укытучылар институтын уңышлы тәмамлагач (сугыштан соң Чистай, Алабуга, Бөгелмә шәһәрләрендә тулы булмаган югары белем биргән шундый уку йортлары эшләп, кадрларга кытлыкны каплап килде), аны Аксубай вилаятенең Карасу авылы мәктәбенә җибәрәләр. Язмышы, насыйбы шунда булган икән.

Укытырга китәсе көнне, бик ерак сәфәргә чыгасы кешедәй, Рәһбәр

апа бик озак саубуллашты, мине кочаклап жылады. Бер Тәлгат белән шулай чын күңелдән саубуллашып, икенче Тәлгатнең куенына барып керәсен күңеле сизенгәндер. Хатын-кызда күрәзәлек, киләчәкне чамалау тоемы бик көчле була, диләр.

Шәкерт апаның кече малае, Чаллы педагогия институты ректоры, профессор Зиннур Шәрәфетдинов исемнәрнең туры килүе белән шаяртырга ярата:

— Мине физик яктан бер Тәлгат дөньяга китерсә, белем, рухи-әхлакый тарафлардан икенче Тәлгат үстерде.

Сизенгән Рәһбәр апаның күңеле, һай сизенгән. Белемле, яшь, чибәр кызга Карасу егетләре кәттәләнеп, рәвешен китереп, ирекгә озак йөрергә бирмиләр. Артыннан кара болыт кебек ябырылып йөргән "ухажерлар" арасында иң әрсезе, иң булганы, әйтер идем, иң чибәре Тәлгат исемлесе булып чыга.

Яшь укытучы, зурлап жыенып эшкә китүгә, берничә айлап узуга, безнең өй янына пыр-пыр килеп, матай килеп туктады. Парланган тәрәзәләргә ябырылдык. Озын буйлы, тартык яңаклы егет үзе генә түгел, артында кыска, ак сакаллы бер карт утыра. Күргән-белгән кешеләребез түгел. Мин, беренчеме-икенчеме сыйныф укучысы, әлеге бабайның бер чалбарын өскәрәк кайтарып куйганын күреп, гажәпләнмәдем, мотоцикл чылбыры балагын азгын бозау кебек эләктереп алмасынга шулай иткәндер, дип юрадым. Ә ул, ходаның рәхмәте белән, яучы булып чыкты. Әти, әни өйдә, исәнлек, саулык сорашып, дога кылганнан соң, "сакал" сүзен үзенә кирәк сукмакка төшерде.

— Карасуда, Нәбиулла туган, сине беләләр, хөрмәт итәләр. Ул бик жакшы кеше, бар да үзе белән сүләш, гозереңне аяк астына салып таптамас. Тастымал сорап бармыйсың, диделәр.

Әти нисби сөйләшүне кабул итми, ачыклыкны ярата. Карасу "десантының" ни өчен Кычыткалыга килеп төшүен чамаласа да, аңламаган булып кылана, башын жүләргә сала.

— Сөлге, тастымал ише әйбер күп бездә. Кызлар чигеп, без битне сөртеп торабыз. Шул гына кирәк булса...

"Сакал" үзенекен тукылый:

— Хатын-кыз кош баласы кебек инде ул. Очарга өйрәнгәнче генә аңа ата-ана кирәк. Шуннан инде ул тю-тю... Кире өлкәннәр канаты астына кайтып керми, үзенә оя кора. Ата-ана йорты аңа жакын, газиз, ну үзенеке тегел.

Сүзнең, ни нәрсә хакында баруын төшенгән әти агарынып китте. Һәр елны бер туй — күбрәккә китә.

— Рәһбәрне сорап килгәнегезне аңладым инде. Без аны шундый нужа белән укытып чыгардык. Семьяга ярдәме тияр дигәниек. Миңа аңардан берни кирәкми. Әтиләре — вафат. Сеңелләрен аякка бастырасы бар.

Галинең үз юлы, Вәлинең үз Мәккәсе. Башкода әтинең ихластан моң-зарын йонлы колагы аша үткәреп, зиһененә алып тормыйча, тәртәне үз ягына каера.

— Нәбиулла энем, янында әле сеңелләре кала. Малаең кул астына кереп бара, — дип, минем якка ишарә ясап, алып килгән "товарын", минем булачак жизнине, мактарга керешә. Әтисен гражданнар сугышындамы, басмачылар белән көрәшкәндәме үтергәннәр икән, әнисенең бердәнбер малае, иллә уңган механизатор икән Тәлгат Шәрәфетдинов.

Булачак жизнигә текәлебрәк карап, Шәкерт апаның хәлен аңладым. Җинел хәрәкәтле, зыялы йөзле, бик чибәр иде егет. Дәрте гәүдәсенә сыймый. Матур. Коңгырт күзләренә зәңгәрсу дулкын йөгергән, чәчләре кабарып тора. Нечкә иреннәрендә хәйләкәр елмаю бии. Йөзенә эчке шатлыгы жәелгән. Аңа ни: өлкәннәр бәхәсләшсен, туарылсын, кызның ризалыгы алынган. "Әзидән рөхсәт алып кайтуга, мин синеке", — дигән сүзләре жанын бәлзәмдәй жылытып тора. Ул да нәрсәдер әйтергә тиештер.

— Нәбиулла абый, сеңелләргә ярдәм итәрбез, укытырбыз.Рәһбәр белән без ни...

Яратыштык, вәгъдәләр бирештек, дип әйтәсе килгәндер инде. Җир кешесенең теле купшы сүзләргә өйрәнмәгән шул. Рәһбәр апага сандугачыннан ким сайрамагандыр әле. Ә биредә чит-ят кешеләр, һәр сүзне хәтерләп, йотып барган бала-чага... Ул тукталып, төртелеп калды.

Әби, кызның әнисе, ирләр эшенә катышмаган булып, яхшатланып утырса да, йөрәк парәсенең язмышына битараф кала алмады. Кызларны вакытында тапшыруның олы бер гамәл, изге бурыч икәнне ул яхшы үзләштергән. Билгеле бер яшькә житкәч, базарда алучысын таба алмыйча эленеп торып, уңа, төсен, ямен җуя барган кызыл малныкыдай һәр узган көн кызның бәясен төшерә.

— Нәбиулла улым, — ди әби ишетелер-ишетелмәс кенә, — ирләр сүзенә кысыласым килми. Шулай да әйтим инде: үзләре табышкач, ярашкач, әллә фатиханы бирәсеңме? Ятим үскән бала ди, кызыбызны рәнҗетмәс, иншалла.

Рәһбәр апа белән адаш жизни бик яратышып, тату, үрнәк гаилә булып яшәделәр. Хуҗа ташып торган кызу канлы, жинел холыклы. Чи борчак биетерлек кызган таба инде. Шәкерт апа тыныч, сабыр. Ир белән идарә итүнең юлларын чамалый. Шулай алар тормыш йөген бергә тартып, өч малай, ике кыз үстерделәр, хәлләреннән килгәнчә, барыбызга да ярдәм иттеләр.

Хәзер Рәһбәр апа лаеклы ялда. Буш вакытын оныкларына, дингә, мәрхәмәткә багышлый. Һәркемнен үз язмышы, үз йолдызы.

* * *

Кешенең галәм тормышы белән чагыштырганда бик кыска гомере бернична чорга бүленә икән. Ун-уникe яшькә чаклы әле синең сөекле бала булып, иркәләнеп яшәргә хакың бар. Егермегә кадәр үзеңне ихластан егет кеше, бәйсез инсан дип йөртә аласың. Бераздан үзеңнең өлгереп житеп, гаилә корып җибәрергә, кемнәр өчендер җаваплы булып яши башларга тиешлегеңне сизәсең. Бу инде дуамал яшьлек яшьнәп узып киткән дигән сүз. Утызның аргы ягына чыккач, кырык, илле, алтмыш... кебек саннар, безнең илдә акча алышынган тизлек белән килеп җитәләр, узып китәләр икән.

Якынnарын, бу карт кеше белән нишләргә инде дигән сорау алдында калганчы, күпме вакыт узасын бер ходай үзе генә белә. Бәлки, әлеге сөаль туганчы ук аның бу гөнаһлы дөньяны ташлап китәргә акылы житәр?

Хатирә-истәлекләр кешедән тизрәк картая, әмма кәгазьгә төшерсәң, ул вакыт белән санашмый, аның өчен яшьнең әһәмияте юк. Менә шуңар да шәҗәрәмнең, тәрҗемәи хәлемнең бер өлешен, хәтта кыйпылчыгын эченә алган язмаларымны кәгазьгә төшерергә жөрьәт иттем. Истәлекләремнең бу кисәген шагыйребез Роберт Әхмәтҗанов каләменнән төшкән юллар белән төгәллисем килә:

Яланаяк
Барам дөнья буйлап,
Барасы юл, шөкер,
Бетмәгән.

*1997-1998.*

# ШИГЪРИЯТ



## Зөлфәт

### АУЛАК СУКМАК

### Шигырем — гомерем

Китсәм дә төп йортыма мин
Үкенмәм бер дә
Гашыйклар, качып, үбешсә —
Минем шигырьдә.

Дошманга тик калкан булма,
Шигырем минем,
Шигырем генә түгел син —
Гомерем минем!

Ышыклама явызларны,
Шигырь дигәнем —
Яктырт күңеле сафларның
Яшәр көннәрен!

Тере утым, и гашыйклар,
Сездә кабынсын —
Шигырем
Былбыл сайраган
Талтирәк булсын...

Яшәмәдем юкка, диеп —
Мин үләр идем —
Гашыйклар бер ышык тапса
Шигырьдә минем!..

### Яшен тулган килеш

Яшен тулышкан бер күк шикелле
Йөри идем хәтәр дөньяда
Һәм уйлана идем:

— Бу дөньяда
Бәхет тиештер бит миңа да?

...И бәхетле, юләр яшь гомерләр!
Үзең дә бит, Ходай, әйтмәдең —
Яшьлегемә яшен оялагач
Яшьнәешләр алда икәнен!..

* * *

Сердәш булды авыл йолдызлары —
Шат чагымны, авыр чагымны —
Керфектәге күз яшендә хәтта
Йолдызлы күк тетрәп чагылды!

Нишлисең бит... Китәселәр бар шул —
Бу гомерне артык сузалмам —
Минем кадәр сокланучы булмас! —
Күк гөмбәзен шуңа кызганам.

## Юрап булмас төш

Балачагым узган йорт төшемә керде...
Нинди генә моңлы истәлекләр сөйләр
Түбә саламнарын кыштырдаткан җилләр?
Шул саламда шыткан сарут хәтта тере —
Балачагым узган йорт төшемә керде...

Һаман җылы килеш болдыр сайгаклары!
Кем мөлдерәп шулай карый икән, дисәм —
"Ботак күзләре"нең карашлары исән...
Әнкәй кырып юган идәннәр сап-сары.
Һаман җылы килеш болдыр сайгаклары...

Тәңре үзе шулай искәртәме әллә:
"Төп йортыңда, бәндәм, бер төш булып керер
Фани дөньядагы синең фани гомер!
Янган еллар синең калмас кара көлгә!" —
Тәңре үзе шулай искәртәме әллә?

Юрап булмас төшне кемнән юратырга?
Кояш төшкелектән ашкан көннәремдә
Уйный сабый җаным болыт мендәрендә,
Йөгән тимерләрен шыңдырата юрга...
Юрап булмас төшне кемгә юратырга?

## Әйтми калганы...

Моң дигәнең серләр середер...
Әллә әйтми калган сүз микән?
Күңелеңә төнме, көн үткән?
Тик бер генә кара — боз эрер!
Моң дигәнең — серләр середер...

Әллә әйтми калган сүз микән —
Килә дә бит җанга тия гел!
...Юкка, ахры, моны сөйләдем...
Газап иңә чиксез киңлектән —
Әллә әйтми калган сүз микән?

Күңеленә төнме, көн үткән —
Шул микәнни нуры гомернең?
Бәндәм, ни кордың, ни җимердең?
Галәм дигән биек киңлектән
Күңеленә төнме, көн үткән?

Тик бер генә кара! Боз эрер!
Уты кабар хәтта керфеккә! —
Ялкын шавын ишет-ишетмә —
Җаннарыңа ялкын йөгерер —
Тик бер генә кара — боз эрер...

Моң дигәнең — серләр середер!
Ниләр генә әйтим мин тагын?
Янсын әле дөрләп учагым...
Сөю һәрчак күккә үрелер!
Моң дигәнең — серләр середер.

## Караш

Шәфәкъ капты Ослан тауларына
Син борынгы чорга бакканда,
Борын-борын заманнардан ташып
Ак болытлар тауга ятканда.

Без икебез идек...
Борынгы да,
Бүгенге дә сыман гүяки...
Сәер милләттәге пар кошлар без,
Безнең милләт —
Сөю милләте...

Кил, шәфәкъкә башың терә, җаным!
Тик бер төнлек синең назыңнан
Мәңгелек чор шагыйрьләре янган,
Яздай мең дастаннар язылган!

Күрәсеңме? —
Бу шәфәкъләр синең
Карашыңнан ярсу ут алган!
...Янгын капты Ослан тауларына
Син ханбикә сыман бакканнан...

## Җавапсыз килеш

Авыр чакларда йомылып һаман
Яман дөньядан
шигырьгә качтым...

Дөнья айкаган сәйях шикелле
Бу җаным сәер дөньялар ачты.

Аңламадым ла тик бер сорауны —
Җавапсыз килеш кала җиһанда...
Аңлату мөмкин түгелдер аны
Мең җавап табар даһи булсаң да!

Мәңгелек сорау мәңгегә калыр,
Җавапсыз килдем, җавапсыз китәм:
Табигать көче
нәкъ минем өчен,
Нигә нәкъ сине сайлады икән?

Болгавыр дөнья түрләрен айкап
Нигә нәкъ сине тапкан бу күңел? —
... Табышмак булып
кала бер сорау:
— Нигә нәкъ сине?
Бүтәнне түгел?..

## Иярде дә китте

Актарды җил каен ябалдашын!
Яшел шавы шушы каенның
Иярде дә китте таң җиленә —
Җил зәхмәте аңа кагылды.

Һәм туй итте дөнья киңлегендә
Каен шавы белән таң җиле —
Шул зәхмәтле туйның гайрәтеннән
Шау өермә купты, билгеле...

Бу өермә, Тәңре үзе кушкач,
Әверелде кинәт адәмгә.
Ак кәгазьгә иелде ул адәм
Һәм үрелде кулы каләмгә...

Каләменнән төшкән хәрефләргә
Сыйды аһлы һәм шат гомерләр!..
... Әнә шулай пәйда була тора
Сәер затлар — әһле шагыйрьләр...

## Кемем син?..

Сызылып яна алсу таң
Янәшә офыкларда,
Тидерә җылы канатын
Гыйшыклы ышыкларга.

Шундый чакта уян әле! —
Таң-чулпан сүнеп бара —
Синең белән без икебез
Бар бит әле дөньяда!

Бар бит, бар таң сәгатенең
Дөрләткеч бер минуты!
... Борчымагыз...
Бу тик безгә
Кабынган таң вакыты...

Әллә кем әллә кайлардан
Гүяки сүзен әйтте:
— Җиргә мәхәббәт иңдерәм!
Сукты сөю сәгате!

Вәхи иңәдер күрәсең
Сөя белгән җаннарга
Бүтәннәр һич аңламастай
Сызылган ал таңнарда...

Хәләлемме, хәрамыммы? —
Аңламыйм шуны, иркәм!
Кем безне яратыштырды? —
Алламы? Иблис микән?..

## Якты!

Күрер көннәребез
ал таңнарның
Яктылары белән яктырды —
Ул таңнар гел атмас иде бәлки,
Аларны без
Икәү аттырдык...

Таң үзенә тарта ике җанны...
Моның
Гаҗәп сере бар икән —
Таң аттырмый гына кавышканнар
Гел яктыга интизар икән...

— Нишләдегез фани дөньяда? — дип
Сорасалар бакый дөньяда,
Тик бер генә булыр безнең җавап:
— Таң аттырдык икәү без анда!

Таң аттыру —
шашып яраттыру,
Сихерләнү
таңгы чыклардан...
Таң күзенә күренмичә калсак
Нишләр идек? —
Ходай саклаган!..

Уртак булды бугай
Хәтта безнең
Маңгайдагы "Ләүхелмәхфүз"ләр! —
Язмыш тактасына
Ходай үзе
Алдан язып куйган ул сүзләр

Шигырь белән ахры язылгандыр...
Таң каурыеннан хәреф тамгандыр...
Бөек Каләм Иясенең ул чак
Илһам ташкан чагы булгандыр!

Шуңа күрә насыйп булды сөю,
Газиз таңда икәү яктырдык...
Без бәхетле булдык бу җиһанда —
Яшәмәдек... без таң аттырдык!

## Аулак сукмак

Гомер буе кабалана торгач
Гади бер нәрсәгә төшенәм:
Олы юллар түгел, аулак сукмак
Кирәк икән уйлы кешегә.

Кошлар төшеп кунар өчен мәллә
Әйтик, гайяр супер-автобан?
Ә тын сукмак исә
Аулактагы
Кошлы таңнар моңын ятлаган.

Туң тимердән салган күңелләрне
Узгынчылар бары таптады,
Ә хыялый гашыйкларны көтте
Айның
Тын судагы сукмагы.

Салмак карлар төшкән тын сукмакка,
Яфрак очышлары төшәлгән;
Аста тирән сулар чылтыраган,
Өстә ялтыр яшен яшьнәгән.

... Биек яшен исе сеңгән килеш,
Чылтырый ла чишмә тавышы —
Табигатьтән килеп
Табигатькә
Тын сукмактан узып барышым...

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Суфиян Поварисов**

# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

РОМАН

***

Ике атна утыра инде Галимҗан бер үзе бер таш капчыкта. Сөйләшүгә көн дә диярлек чакыралар. Тегеләр үз төнлегеннән, Галимҗан үз төнлегеннән карап сөйли. Кичә аерым жандарм корпусы полковнигы чакырткан иде. Пеләш башлы, җирән сакал-мыеклы, кызыл чырайлы, калын, нык гәүдәле полковник, башта үзен бик нәзакәтле тотарга тырышып, сорауларны ягымлылык саклаган хәлдә биреп утырды. Галимҗанның язучы, галим, мөгаллим булуын, университетта тиз арада сәләт күрсәтүен, бөтен Киев җәмәгатьчелегендә абруй казануын, киләчәктә бик зур, мәртәбәле шәхес булачагын әйтеп, ике арада дуслык җепләре сузарга кирәклекне әйтте хәтта. "Ишәк мондаш булмас, алабута аш булмас", — дип уйлады Галимҗан. Әмма полковникның "дуслык җебе"н өзмәү, аны ныграк төенләү хәстәрлеген күрде:

— Рәхмәт, полковник галиҗәнаблары, яхшы сүзегезгә. Без, сез уйлаганча, кешеләр арасында яхшы мөнәсәбәт, дуслык-туганлык булдыру, аларны бәхетле итү өчен көрәшәбез дә, — диде. Ә инде сүзнең очы революцион эшкә барып төртелгәч, әлеге җеп өзелеп, ике арага тешләрен ыржайтып, иблис килеп басты. Иблис полковник яклы иде. Ул полковникны Галимҗанга карата рәхимсез булырга котыртты. "Алар бит, әфәндем, патшаны таҗ-тәхетеннән бәреп төшерергә ант иткән селәгәйләр. Әгәр шуларга кабер казый алмасаң, үзеңнең дә элмәккә эләгүеңне көт тә тор", — диде. Котырынды да китте шуннан полковник. Галимҗан ул теләгәнчә җавап бирмәгәч, йә үлем, йә гомерлек каторга белән куркытты. Уйланырга бер тәүлек вакыт бирде.

Менә ул тагын да шул ук полковник алдында. Ул килеп кергәндә, полковник өстәл артында ишелеп утыра иде. Башта ул, кичәге кебек, чыгырдан чыкмый сөйләшергә тырышты. Бакырдан көмеш чыкмас, бакырудан эш чыкмас, дип уйлагандыр, бәлки. Галимҗан да үзен тыныч тотты.

— Йә, уйландыңмы, нинди фикергә килдең, инде барын да ачыктан-ачык сөйләп бирәсеңме? — диде полковник.

Ризалашты Галимҗан:

---

*Ахыры. Башы 5, 6 саннарда.

— Мин сезгә бүген барын да түкми-чәчми сөйләп бирәм, полковник галиҗәнаблары, — диде.

## VI

Революцион көрәш — шамбы шулпасы эчү түгел ул. Бу кадәресен аңлый Галимҗан. Аның өчен уйларыңны үз кендегең тирәсендә чуалту гына житми, ә бәлки ил, халык, Ватан мәнфәгате белән яшәү таләп ителә.

Оренбургта 1905 елгы канлы вакыйгаларга катнашу, Уфа вокзалында полиция белән якалашу, ел буе Миас эшчеләре арасында кайнашу, Казанда мәгълүматлы кешеләр белән даими очрашу... — болар барысы да хакыйкатькә акыллы күз белән карарга теге яки бу дәрәҗәдә өйрәткән иде инде Галимҗанны. Ул мөселман студентларының күтәрелеше генә берни дә бирмәячәкне аңлатты. “Якташлар җәмгыяте”ндә житмешләп әгъза булса да, алар арасыннан берәү дә программа төзү кебек четерекле мәсьәләгә кул тыгарга җөрьәт итмәде. Бу житди эш Галимҗан Ибраһимовка йөкләтелде. Иң әүвәл университеты булган башка шәһәр студентлары белән бәйләнешкә керүне тәкъдим итте ул. Киевта бер очрашып мәслихәтләшү, фикер алышу, киңәшләшү мотлак. Аны башта ни дип атарга да белми гаҗиз булдылар: Съезд, Корылтай, Җыен... 1913 елның 17 апрель көненә билгеләнде ул. Казандагы дусты Хәнәфи Кайбышевка үзе хат язарга булды Галимҗан. Ләкин боларның барачак ак юлына агулы кара елан сузылып ятты. Җыен мәсьәләсе Киев жандармериясенә барып ишетелә. “Якташлар җәмгыяте” әгъзалары кулга алына. Башкаларын бергә-бергә утырталар. Галимҗанның бер үзенә бер караңгы тар камера. Фатирын тикшергәндә аның барлык кәгазь-китапларыннан әллә ничә төенчек хасил булды. Алар арасында әлеге “бәхетсез” “Казакъ кызы” романы да бар иде.

Галимҗанны көн дә диярлек алып киләләр сорау алучы каршына. Кичә уйлану өчен бер тәүлек вакыт бирелгән иде. Димәк, бүген аларның соңгы мәртәбә төпченүләре.

Һәр сөйләшүдә нык, тыныч тотарга тырышты ул үзен. Бүген дә югалтмады шул сыйфатын. “Якташлар җәмгыяте”нең төп максатын сорасалар, алдан уйлап куйган бер үк сүзләрне кабатлады. Алар, имеш, төрле әдәби кичәләр үткәрү, концертлар күрсәтү, фәнни түгәрәкләр оештыру, рухи байлыкны арттыру, эстетик зәвык мәсьәләләре белән шөгыльләнү өчен төзегәннәр бу җәмгыятьне. Башка калалардагы студентлар белән бәйләнешкә керү дә шуның өчен. Дуслык җепләрен ныгыту, фикерләшеп эшләү, бер-береңнең уңай сыйфатларын өйрәнү аларның аң-даирәләрен күтәрәчәк, уйлау офыкларын киңәйтәчәк. Икътисади мәсьәләләр белән дә шөгыльләнү булачакны әйтте Галимҗан. Монысы коргаксыган мичкә урынына калган Русияне аякка бастыру өчен кирәк. Әмма сәяси эшләр белән баш ватудан алар ерак тора...

Полковник ярсып, симез йодрыгы белән өстәлгә сукты:

— Алдашасың. Син — студентларны сәяси көрәшкә чакыручы. Менә бу хат синекеме?

Галимҗан хатны кулына алса, чыннан да үзенеке икәнлеген аңлады. Казанга Хәнәфи Кайбышевка язган хаты. Ничек соң бу? Нишләп Казанга җибәрелгән хат Киев жандармериясенә килеп эләккән? “Дустың күбәйсә белеп тор, арадан берсе дошман булыр”, — дигәнне белми иде Галимҗан. Бигрәк тә сәяси эшләр вакытында. Казандагы дусты Хәнәфи Кайбышев Галимҗан хатын охранкага алып барып тапшыра. Анда Киевтагы җыен булу көне дә, сәяси эшләр хакында да язылган иде. Димәк, провокатор булып чыкты Хәнәфи Кайбышев.

Хәзер инде Галимҗанның чәбәләнер рәте калмады.

Полковник аңа хәзер җиңүче күзе белән карый. Койрыгы бозга катырылган бүре хәлендә калдыңмы, янәсе. Шуннан ул Галимҗанга кәгазь, каләм бирде дә, башка боргаланыр хәлең калмады дигәнне аңлатып, барлык булган хәлләр турында язып бирергә кушты. Ул язган арада үзе,

урыныннан торып китеп, арлы-бирле йөрештереп торды, тәмәке тартып алды, әледән-әле чәнечкеле караш ташларга да онытмады.

Укып чыккач, полковник, бер агарып, бер күгәреп, тегермән ташы урынына дырылдарга кереште.

— Их, вы татары, злой народ, история не простит вас... — диде. Шул бер кызган килеш татар-монголлар һөҗүме тарихы дөньясына кереп китте. Татарларның унөченче йөздә хәзерге Монголиядән алып менә шушы урыннарны басып алуын, аларның исеме хәзер бөтен илләр тарихы сәхифәсендә "кара" сүзләр белән язылуы турында әйтеп шашынды.

Мондый сүзләрне Галимҗан университетта да ишеткән иде. Тарих укытучысы Степан Иванович татарларның куркыныч, кыргый булуы, даими рәвештә басып алучанлык сәясәте белән шөгыльләнүе хакында сөйләгән иде. Ул сүзләрне ишеткәч, Галимҗанның "Без бит ул татарлар түгел, бозмагыз тарихны", — дип кычкырасы килде. Шулай да тыелды. Чөнки вакыты ул түгел. Әмма берничә көннән соң практик дәрес вакытында хәзерге татарларның ата-бабалары болгарлар булу турында чатнатып сөйләде дә бирде. Болгарлар исә алан-сармат кабиләсе белән арадаш яшәгәннәр. Бу кавемнәрнең елга башы борынгы һуннар, шумерлар, скифлар дәверенә барып тоташа. Профессор аны әллә ничә мәртәбә туктатырга тырышты. Ләкин Галимҗан сөйләп бетермичә туктамады.

Шул дәрестән соң Ырымбурның Вәли мулла мәдрәсәендә бергә укыган Йосыф мәхдүмне очратты Галимҗан.

Алар анда бер ел бер бүлмәдә яшәделәр, Йосыф Галимҗаннан биш-алты яшькә өлкәнрәк иде. Әмма алар нык дуслашты. Йосыф Бөре өязенә кергән Илеш авылыннан иде. Галимҗанны кунакка алып барды Йосыф шәкерт. Ул үзе дә килде Солтанморатка. Бервакыт аерды аларны язмыш җилләре. Йосыф Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә күчте. Галимҗанны исә Вәли мулланың кадим мәдрәсәсеннән кудылар.

Йосыф Казанда өлгергәнлек шаһәдәтнамәсенә имтихан тоткан икән. Киевтагы бер туганы аңа университетка укырга керергә ярдәм иткән. Сөйләгәндә күзе төшкән иде аңа Галимҗанның. Нишләп ул монда? Улмы соң әле бу? Әллә охшаган гынамы? Әллә бер-бер туганымы?

Шулай уйлаган иде ул. Ә инде дәрестән соң Йосыф үзе килде аның янына. Соңгы вакытта авырып яткан икән. Лекцияләргә килә алмаган. Шуңа күрә очрашмаганнар.

Йосыф Галимҗанның танылган язучы, галим, укытучы, тарихчы, тәнкыйтьче булуын, бүгенге чыгышында үзен искиткеч итеп күрсәтүен искә алды. Тик зур кисәтү ясады:

— Син Ырымбурда да каты телле идең, "Галия" мәдрәсәсендәге "Гөнаһларыңны" да ишетеп беләм, бүген дә чыгышың белән шаккатырдың безне, тик, Галимҗан туган, профессорлар белән бәхәскә кермәвең яхшы булыр, — диде.

Галимҗан күп сөйләшмәде:

— Дөреслекне әйтүдән берәү дә тыя алмаячак мине, — диде дә китеп барды.

Ни өчен татарны куралмыйлар? Егерменче гасыр башында зур милләт киң һәм тирән, энҗе-мәрҗәндәй матур, сәнгать чаралары мул булган әдәби теле бар. Ә нигә җирәнеп карыйлар татарларга? Нигә куркалар алардан? Кайда соң үз гайрәтләрен күрсәтердәй татар пәһлеваннары?

Менә бу кызыл битле полковник та татарлар тарихын пычратмакчы. Галимҗан аңа күп сүз әйтмәде. Козгынны кырык ел сабынлап юсаң да, агартып булмаган кебек, надан башына дөреслек орлыгын барыбер сала алмыйсың. Тик шуны гына әйтте ул:

— Полковник галиҗәнаблары! Без бит ул татарлар түгел. Без — бөтенләй башка кавемнән...

Язуында да ул бу полковник алдында үзенең шактый эре бәрәнге икәнлеген күрсәтергә тырышты. Русиянең хәле таралып төшәргә торган арба кебек булу турында әйтте. Ник арбаны бу илгә яшь көчләр ясаячак.

Бу утлы фикернең ялкыны барыбер патша тәхетенә төбәлгәнлекне аңлау кыен түгел. Шуннан полковник аның нинди фиркадә торуын сорады. Галимҗан әле рәсми рәвештә берсендә дә тормый иде. Шулай да бу мәсьәләдә битарафлык күрсәтүне дә килештермәде:

— Мин, полковник галиҗәнаблары, Кешелеклелек партиясендә торам, — диде.

Полковник янә уттай кызып китте:

— Юк андый партия.

— Бар, полковник әфәнде! Булачак ул кешелеклелек бәхете өчен көрәшә торган изге Партия!

Полковник чыгырыннан чыкты.

— Мулла баласы, укымышлы кеше икәнлегеңне искә алып, мин әле сине ялгыз камерадан коткару уенда идем. Ә хәзер округ судын көт. Һм... "Татар җәмгыяте" төзи, имеш. Бу җирләрне яңадан басып алмакчысызмы? Не позволим!

Галимҗан һаман чигенмәде:

— Бу урыннарда, полковник әфәнде, борын-борыннан төрки халыклар яшәгән. Киевта дәүләт эшләре дә элек төрки телдә алып барылган. Димәк, төрки теле дәүләт теле булып исәпләнгән. Ә инде славяннар аларны басып алгач...

— Молчать! Сакчы!.. Алып китегез үзен!...

## VII

1913 елның июнь урталары иде бу. Украинаның җылы җәе кешеләр күңелендә шигъри тойгылар, ләтыйф хисләр уята. Төшкелектәге урыннан Кояш Җир балаларына галибанә сокланып карап тора. Ул бөтен җиһанга бәхет-сәгадәт тели кебек. Яшел күлмәкле Җир белән зәңгәр яулыклы Күк, гүя, бер-берсенә ниндидер яшерен серләр сөйләп әсәрләнә. Артык эссе түгел әле. Кешеләрнең йомшак җәй һавасы белән мөкиббән рәхәтләнә, ләззәтләнә, хозурлана торган мәле.

Бу — "Якташлар җәмгыят"е әгъзаларыннан кулга алынган егермеләп кешенең төрмәдән ирекkә чыгарылган көн. Башта алар төрмәнең биек таш койма белән әйләндереп алынган ишек алдында очрашты. Шатлыкның монда иге-чиге юк. Кочаклашу. Кул кысышу. Һәркемнең йөрәге азатлык бәхете татудан иләсләнә. Тик Галимҗан Ибраһимовның юклыгы гына аларның күңелен тетрәтте. Округ судына бирергә теләүләре чынмы әллә? Аларның "генералын" (алар Галимҗанны шулай дип тә атаганнар иде инде) алып калалармы? Себер җибәрәләрме? Бу беренче зиндан чиркәнчеге аларның рухын сындырырга тиеш түгел бит. Дөрес, ни өчен имәннең — төптән, наратның баштан корыганын белмәгән кебек, алар инкыйлабый көрәшнең мәсләген һаман аңлап бетерә алмыйлар әле.

Алар арасында ярсый-ярсый, кабалана-кабалана, биниһая борчылып, үзара сорашулар башланды:

— Кайда икән Галимҗан Ибраһимов?

— Нигә һаман чыгармыйлар?

— И, Ходаем! Округ судына бирүләре әллә чынмы?

— Авызындагы сүзне җил алсын!

Шулай кайгырышып сөйләшеп торганда, ниһаять, Галимҗан Ибраһимов күренде. Ләкин сакчы-конвой белән килә. Барысы да аңа таба ябырылды.

— Коткармадыларммыни?

— Күпмегә тагы да?

— Суд булачакмы?

Ибраһимов елмаеп куйды:

— Нинди суд? Нинди коткармау? Мин ирекtә.

— Ә нишләп конвой белән?

Галимҗан "Чепи"нең кем икәнлеген берничә сүз белән генә аңлатып бирде. Әле аның якташлык тойгыларыннан аерыла алмый йөрүен әйтте.

Галимҗан һәрберсе белән ике куллап күрешеп чыкты. Аннан берберсенә карашып калдылар. Менә ярсу йөрәкле, сәяси-иҗтимагый хәлләр белән мөкиббән шөгыльләнүче Хәллә Еникеев. Төрмә аның рухын сындыра алмаганлык көләч йөзеннән сизелеп тора. Әнә Уфа бае Абдусәгать кызы чибәр Гөлсем Әхмәтова. Ул да кайгыларга нык бирешмәгән кебек. Араларында төрлесе бар. Аның янында басып торган казанлы Хәким Сабировның хәле шактый мөшкел күренә. Җыелышларда, ай-һай, үзен чын инкыйлабчы, Мәмәт патшадан да өстен итеп күрсәтергә, йодрыкларын болгый-болгый сөйләргә, авызыннан, кем әйтмешли, саескан очырырга ярата иде ул. Ә хәзер карасаң, исең китәрлек. Уртача буй янә бераз чүккән кебек.

Секунд-минутлар эчендә кичерде Галимҗан мондый уйны. Һәрберсенең әйтер сүзе күп. Ләкин телләре бәйләнгән. Бер-берсенә ни дип сүз кушарга белми аптырыйлар. Тоткынлыктан соң янә бер авыр мәл булды бу. Галимҗан да сөйләргә ашыкмады. Чөнки аның өчен киләчәк бар. Ә хәзергесе урынсыз булыр кебек. Ә үзенә әллә күпме күзләр төбәлгән. Кыш буе "Казакъ кызы" романын яңадан язып бетерү, дарелфөнүнгә лекцияләр тыңларга йөрү, зурларны, балаларны укыту, башка мәшәкатьләр, тынгысыз эш, йокысыз төннәр аны болай да нык ябыктырган иде. Төрмә җилек маен янә шактый нык суырды. Шулай да ул рухи көчне иң туклыклы ашамлык итеп тотарга тырышты. Мәсләксез максат — мәңге йөрер аксап, ди. Максаты мәсләкле булды шикелле. Аксамады. Вакыт-вакыт шактый нык ютәлләп, хәтта кан төкергән чагы булса да, сабый чакта ук алган үпкә чире барыбер шашынып китә алмады. Мондый чакта Галимҗан бер хакыйкый фактны искә алды. Миас җиз эретү заводында- эшләгән Гариф исемле бабай сөйләгән иде аңа. Имештер, чирне иркәләргә ярамый. Иркәләсәң: "Бәй, бу бик һәйбәт, шәфкатьле кеше икән ләбаса", — дип, синең тәнеңә нарат сагызыдай сыланып ята бирә икән. Әгәр сүгенсәң, тиргәсәң: "Соң, мин җүләр, нишләп әле бу юньсез, әшәке бәндә бәдәнендә яшәп ятам. Беткәнмени өф-өф итеп тотучы йомшак затлар", — дип, ташлап китә икән моны.

Менә алар өчен зиндан сәгатенең соңгы минуты сукты. Шыгырдап зур, тимер капка ачылгач:

— Китәргә мөмкин, тик карагыз аны: монда кабат эләкмәскә тырышыгыз! — диде төрмә назиры.

* * *

Капка төбендә халык умарта күче урынына гөжли иде. Монда тоткында булганнарның ата-анасы, туган-тумача, дус-иш, кардәш-ырулары, кызыксынучы башка кешеләр, университет студентлары, бала-чага җыелган булып чыкты. Тик Галимҗанның кочагына берәү дә атылырга ашыкмады. Әмма аны да каршыларга килгәннәр икән. Каюм Мостакаев белән Габдулла Мостафин, халык дулкыны бераз басылсын дип, бер як кырыйда көтеп торганнар. Дулкын саега башлагач очраштылар. Кул кысышу, кочаклашу, якынлык хисләре бүләк итешү... — барысы да булды. Шулай да аларның карашында үпкә, гаепләү, борчылу чаткылары да бар иде. Теләсә кая тыгылган борынны әнә шулай җимерәләр, янәсе.

Юлда кайтканда да сүз шул тирәдәрәк барды. Бу котылу мең төрле газаплар аша булган икән. Утыручыларның ата-аналары барысы да кәттәкәннәр яки түрә балалары икән. Түрәләр, гәрчә Киев губернаторы, жандармерия башлыгы тупсасын даими таптап торсалар да, озак вакыт максатка ирешә алмый. Бу эшкә Петербургта яшәгән дәүләт думасы депутаты адвокат Ибнеәмин Әхмәтов ныклап керешә. Ул утыртылган сеңлесе Гөлсем Әхмәтованы коткарырга йөри. Жандармерия башлыгы

полковник Шпель адвокатның сенлесен коткара алмавы турында әйтә. Чөнки бергә хөкем ителеп каралганнардан аны гына аклау алар өчен яңа җинаять эзләре ача. Көчле адвокат була Әхмәтов. Тыштан балкып торган данлыклы Киев каласы җәмәгатьчелеге даирәсендәге күп кенә пычрак нәрсәләрне чокып чыгара. Алар, идән астындагы караңгылыкта мыжылдашып торган комаклардай, кешеләргә яшәргә ирек бирми. Нигә карамый моны губернатор? Ник йокымсырый жандармерия башлыгы? Шулар хакындагы язмаларын эчке эшләр министрына, дәхи дә полиция департаментына житкерәчәген әйтә. Шүрли полковник. Нигә әле ниндидер селәгәйләр аркасында пычракка буялырга? Бер сылашса, аны бит үткер пычак белән дә кырып ташлап булмый.

Әхмәтов янә бер нәрсә белән куркыта. Мөселманнардан әллә ни зыян юк. Ә менә поляклардан, яһүдләрдән, урыс революционерларыннан сакланырга кирәк. Кеше йота торган акула балыгыннан качмыйча, нигә әле чуртаннан шүрләп яшәргә?

Адвокат тагын бер житди мәсьәлә кузгата. Алар бит студент-яшьләр генә. Бер кала университетында укыган студентларның башка шәһәрләрдәге студентлар белән дуслык мөнәсәбәтенә керү, фикер алышу, агарту, мәгариф, мәдәният мәсьәләләре буенча мәслихәтләшү начар эшмени? Моның өчен аларны хөкемгә тарттырган кешеләрдән көләчәкләр генә. Ә инде студентларның бу дуслыгын революцион көрәш белән бәйләп күрсәтү булдыксыз бер көнчел провакатор эше генә.

Дәүләт думасы депутаты үзенең шактый мәгълүматлы, фикерле, полковниктан күп яклары белән өстен торуын күрсәтә. Депутат буларак та аларның бүлтәеп торган чирле якларын игәүләргә хакы барлыгын әйтә.

Җиңелә полковник! Шулай да Галимҗан Ибраһимовны чыгармаячагын, округ судына бирәчәген, утыртып куярга кирәклеген әйтә. Галимҗанны күргәне бумаса да, Әхмәтов аның мәшһүр татар язучысы, телче галим, тәнкыйтьче, педагог икәнлеген, фәннең төрле тармаклары белән шөгыльләнүен белә иде инде. Аның берүзен генә утыртуның бер файдасы да булмаячакны әйтте. Мисалга Тарас Шевченконы китерде. Нинди генә михнәтләр күрмәгән. Әмма бөек шагыйрь булып калган бит. Галимҗан Ибраһимов та казаначак андый шөһрәтне. Украин халкы белән татар халкы язмышындагы уртак якларны да әйтә адвокат. Урыс халкы алдында алар барыбер кимсетелгән булып исәпләнә...

Адвокат шулай җиңә губернаторны. Аң-белеме белән. Аңлатып. Чын кешеләрчә.

Әхтәмов Гадулла әфәнде белән таныш икән. Бу хәлләрне Габдулла Максутовка әле кичәгенәк кенә ул сөйләп биргән. Галимҗанның да котылачагын әйткән.

Юлда шул хакта сөйләде Габдулла бай. Кисәтү ясарга да онытмады:

— Бик нык ялгыштың, Галимҗан улым! — диде ул, артык кайгырган, борчулы йөз күрсәтеп.

Аның сүзләрен Каюм куәтләде:

— Әйе, мин дә шуны уйлап атлыйм. Кырга чүп-чарны начар орлык тутырыр, диер иде әти мәрхүм; яшьләрнен бу эш —орлыгыннан мин бер нәрсә дә өмет итә алмыйм.

## VIII

Галимҗан эндәшмәде. Сүзсез генә атлады.

Аңлады Галимҗан Габдулла бай белән Каюм әфәндене кичерешен. Аларга карата тамчы да үпкә-сапка юк. Синең язмышың өчен берәү өзгәләнә-өзгәләнә сыкрана икән, аңа карата битараф калу ахмаклыктан башта бернәрсә дә түгел. Шулай да аларның кызгану хисен, бу эшне начар орлыктан үскән чүп итеп күрсәтергә тырышуларын, андый мәшәкать-

ләрдән ерак торырга кирәклекне әйтүләрен һич тә кабул итә алмый Галимҗанның йөрәге. Алар икесе дә яхшы кеше. Габдулла әфәнде, гәрчә татар теленең гәүһәрләре тупланган Казан шәһәре тирәсеннән шактый еракта яшәсә дә, балаларын һәм якыннарын туган телнең сафлыгы, шифалы көче, шигъри зәвыгы белән тәрбияләмәктә. Шуның өчен Казаннан махсус чакыртып китерде дә бит инде. Туган телне сакларга тырышу — милләтеңнең кадерен белү, аны данлау, бөек тоту дигән сүз ул. Каюм әфәнде дә тора шул югарылыкта. Әмма ике ай ялгыз камерада утыру, алар уйлаганча зур газап булса да, бу һич тә кимсетми Галимҗанны. Бу зиндан аның зиһенен кузгатты, дөньяга маңгай күзе белән генә түгел, күңел күзе белән карарга, кешеләрне аера белергә өйрәтте. Кем уйлаган Кайбышевны сатлык җан булып чыгар дип. Кеше авырлыкта сынала, дип, халык бик гади һәм мәгънәле әйткән. Әле бу ул тиклем авырлык та түгел ич. Ә кайберләүләр уттан курыккан Шүрәле урынына калтыранып калды. Янә шуны әйтте Габдулла бай:

— Инкыйлаб эше кан кою белән бәйле, ул халыкны, илне бәхетле итми, хәерчегә калдыра, — диде.

Бу сүзләрне Каюм Мостакаев та җөпләде.

* * *

Кат-кат барды Галимҗан тентү вакытында алып киткән берничә төргәкне кире кайтару өчен. Ләкин әллә ничә зур төргәктән нибары берсен генә бирделәр. Анда “Казакъ кызы” романы юк иде.

Үтенеп-ялынып сораса да, анысын бирмәделәр аңа. Вакыты җиткәч, почта аша үзләре җибәрәчәкне әйттеләр. Галимҗан Солтанморат адресын бирде. Чөнки Казанда кайда тукталачагын тәгаен генә белми иде әле ул.

Өч көн вакыт бирделәр Галимҗанга Киев белән хушлашу өчен. Габдулла бай һәм Каюм дусты белән исәп-хисапны өзеп, Казанга юл тотты ул. Казакъ кызы Карлыгач-Сылу аны моңаеп озатып калды. Романны янадан кулга төшерү өмете хәзер тәмам өзелде инде. Эт авызындагы сөякне тартып алып буламыни?..

## IX

Быел кыш кар күп булды. Вакыт-вакыт ул талгын гына ява. Мондый чакта күктән ап-ак чәчәкләр коелгандай тоела. Бәгъзе бер чак, үзләренчә кыш бәйрәме ясагандай, уйнаклап-уйнаклап ява кар. Аларга карап тору күңелле. Шул уйнак карлар эчендә ап-ак туй күлмәге кигән дәртле кызлар шаярыша кебек. Аннан Табигать бабай бу нәфис кызларны әллә кая куя. Гүзәллекләренә сокланып, урлыйммы әллә? Җәннәткә җыя барамы? Хур егетләре өчен? Менә бервакыт салкын буран куба. Хәзер инде кар чәчәгенә төренгән ак кызлар юк. Алар — җәннәттә. Хәзер өшетә, тундыра торган коточкыч буран эчендә зәһәр шайтаннар бәйрәм итә. Аларга ирек кенә бир. Ярлыларның бөкрәйгән карчыктай хәлсезләнгән балчык өйләрен кар белән күмеп-күмеп ташлыйлар да, ертыктан мәзәк табып ихахайлаган Иблистәй шаркылдап көлә-көлә, каядыр китеп югалалар. Кар да җиргә мәшәкатьсез генә төшми, күрәсең. Ничек кенә булмасын, ап-ак кар өемнәре ап-ак икмәкне хәтерләтеп тора. Күп карда бәрәкәт бар, дип сөйли авыл халкы. Димәк ки, быел икмәк мул булачак. Чөнки мул кар суы белән сугарылган җир сөтле ана белән бер ул.

Әмма ләкин җылы җир куенынннан шытып чыккан уҗымнарга Күк бабай рәхимсез булса, эче тулы шифалы яңгыр бөртекләрен кызганса, игенкәйләр сагышлы кеше йөзедәй саргая, көя, авыр хәл кичерә.

Быел нәкъ шулай булды да. Чатнап ярыла җирләр. Комга күкәй күмсәң, “ә” дигәнче пешеп чыгар. Яланаяк туфракка басып булмый.

Көйдерә. Бөтен ышаныч малларда. Ләкин аларга азык булган үлән-печәннәрне дә эсселек көйдерә. Бер ярма бөртеге табу өчен бер өем чүп актарган тавык кебек, бер саф үлән эзләп, хайваннарга әллә күпме мәшәкать чигәргә кирәк. Эсселектән Солтанморатның диңгезне хәтерләтеп торган Кондызлы күле тараеп, кысылып, боегып калгандай булды. Зәңгәр чишмәнең дә төсе үзгәрде: зәңгәрсу, зәңгәр-сары, зәңгәр-кызыл, зәңгәр-көрән... — тагы да әллә нинди төсләргә керә.

Ярлыларның йөзе дә ачлыктан саргая. Яз көне аларның жанын черегән бәрәңгедән пешергән кәлҗемә саклады. Аннан кычыткан, какы, кузгалак, балтырган, бәбәк, көпшә ашап юандылар. Хәзер инде, июль башларында, аларның берсе дә калмады. Ходай җан биргәнгә юнь биргән, диләр лә ул, мондый чакта юнәтүкәйләр дә бик читен шул. Шулай да ачтан үлми әле халык. Бәгъзе берсе әвеш-тәвеш белән шөгыльләнә. Алып-сатарлар да күзгә ташлана. Читкә чыгып китүчеләр дә бар. Ашланган җир аш бирә дигәндәй, булдыклы хуҗаларның яхшы эшкәртелгән, дөрес сөреп чәчелгән, ашланган җирләрендәге куе булып чыккан уҗымнар, төпләрендәге күләгәләрен берникадәр кояшның эссе нурларыннан саклаган хәлдә, тырышып-тырмашып булса да үсеп ятмакталар.

Гыйрфан мулланың җире яхшы эшкәртелгән. Хәзерге эсселеккә артык бирешми. Авырлыкка үч итеп үскән җылгыр малайдай, яшәү өмете белән башларын югары күтәрәләр. Бирер Ходай яңгырны. Бирми калмас. Аңлар халыкның аһ-зарын. Кайгы-хәсрәтен аңлар!

Шундый теләк Гыйрфан мулланың күңелен бераз күтәргәндәй итә. Мәгәр хәле нык авыр. Газраил аның бугазыннан әнә шул ишелеп-ишелеп кар яуган вакытта ук алган иде инде. Әмма ул баш бирмәде. Ник шул тиклем ашыгасың, һич югында язгы чәчүне көт, диде ул. Көтте Газраил. Тик кырлар йөзен янә бер күрергә насыйп булмады. Уллары Шакирҗан белән Габделхәким башкарды язгы чәчү эшен. Хәзер инде, эсселектән аюдай гайрәтле ирләр әлсерәгәндә, түшәк хастасы Гыйрфан мулла кая бара алсын. Шулай да, гәрбиянлык күрсәтеп булса да, көрәшә әле ул Газраил белән. Килгән саен куып җибәрерлек көч таба. Шайтан гына өметсез була бит. Ә ул — кеше! Өмет итә белә.

Авыл халкы аның янына килеп тора. Хәл белергә. Гыйрфан мулланың табигать серләрен гамәл дәфтәренә язып бара торган гадәте бар иде. Төрле сынамышларның да мәгънәсен күп вакыт аннан сорыйлар. Ни өчен быел яңгыр яумый? Нигә рәнҗетә Ходай халыкны? Ни гөнаһлары бар икән? Шуның да сәбәбен сорыйлар Гыйрфан мулладан. Көннәрдән бер көнне Хәйретдин хәзрәт килде аның янына. Аны авылда "Ак хәзрәт" дип йөртәләр. Яшь чакта ул ак йөзле, зәңгәр күзле, бик чибәр булган. Болары — тышкы матурлык. Илтифатлылык, шәфкатьлелек, кешелеклелек — аның эчке сыйфатындагы асыл таш. Картайган көнендә ул ак ефәктәй йоп-йомшак ак сакал җибәрде. Ак йөзендәге бит очлары бераз кызарып тора. Зәңгәр күзләр һаман әле яшь чагындагыдай нурлы. Уртача буй. Кешеләрне яратып, сөеп карый торган мөлаем караш. Тәмле тел. Җитез хәрәкәт. Җәй көне ул гел актан киенеп йөри. Шуңа күрә аны Хозыр-Ильяска да охшаталар. Һич картаймый, үзен һаман яшьләрчә тота: йөргәндә дә, сөйләшкәндә дә. Битендә җыерчыкның әсәре дә юк әле. Картаймавын эчкерсез, гөнаһсыз, матур күңелле булуыннан, кешеләргә начарлык теләмәвеннән күрәләр. Ул килгәч, Гыйрфан мулла торып утырды. Үткән хатирәләр, яшәеш, пәйгамбәрләр тормышы, дин, әхлак турында сөйләшә-сөйләшә чәй эчкәч, Гыйрфан мулланың күңеле күтәрелеп китте, йөрәге тынычланып калды, яшәүгә өмете артты. Яңгыр яумау сәбәбе, халыкны ачлыктан саклап алып калу, ярлыларга иганә бирү турында да алар озак кына сөйләштеләр. Алар фикерләвенчә, быелгы корылык — Аллаһу Тәгаләнең халыкка булган рәнҗеш нәтиҗәсе. Ил шаша. Халык бозыла. Бәндә күңеле керләнә бара. Солдатлар кайтса да эчү. Зимагурларны әйтәсе дә юк. Чөмерәләр генә хәмерне. Һич уйламаган кеше дә дуслашып алды яшел елан белән. Нәҗметдин бай сәүдәдән килгән бөтен акчасын

аракыга тота икән. Хәзер кешеләрне алдау юлына баскан. Төрмәдән кайткан улы Илһаметдин беркөн исерек килеш канауда аунап яткан. Дөнья башка бозыклыклар белән дә тула. Ирләр хатыннарын тукмый. Астыртын гына гөнаһ кылалар. Намәхрәм эш белән мәшгульләр. Авыл читендә яшәүче Гайшә, ире зимагурлыкка чыгып киткәч, бер егеткә гыйшык-мыйшык тота башлаган. Аннан авырга калган. Тапкан нарасыен елгага ташлаган. Ничек Ходай рәнжемәсен моңа? Ничекләр генә итеп түзсен ул? Шулай да жирне шартлатмый әле. Түзә. Сабыр итә. Хәер, Ходай түземле шул ул.

Болары бер хәл. Мөбахис мәзин нигә шашына? Ул бит читтән килгән диндар. Төче теленә, бөгелеп-сыгылып сөйләшүенә, моңлы итеп азан әйтүенә караганда, ул бит менә дигән шәфкатьле, илтифатлы, гөнаһсыз булырга тиеш кебек. Иллә-мәгәр итәк астыннан ут йөртә. Гыйрфан мулла өстеннән Уфа диния нәзарәтенә шикаять язган. Муллалыгын ташлау житмәгән, хәзер инде халыкны дингә каршы котырта, имеш. Ул гына да түгел, Хәйретдин хәзрәткә дә өлеш чыгарган. Имештер, хәзрәт, дәһри, ягъни дин азгыны Гыйрфан картның тузган тегерменәнә су коя. Шулай итеп, Мөбахис мәзиннең тел тегермәне жилсез көндә дә әйләнеп тора. Моны халык та белә. Халыктан бернәрсәне дә яшереп булмый. Аның күзе — очлы. Зиһене — үткер. Колагы — сак. Гыйрфан карт муллалыгын ташласа да, аңа гавам халкы барыбер ихлас күңелдән, мөкиббән якын күреп, мөкатдәс бер кайнар хис-тойгы илә "Мулла абзый", "Мулла бабай!" дип эндәшә. Муллалыгын авырып киту аркасында башка бирәүгә бирсә дә, эчендәге иман гәүһәре әле һаман мөлдерәмә икәнлекне халык белмиме әллә?!

Әлбәттә, авыру чакта болар хакында сөйләшү урынсыз да кебек. Ләкин сүзне Гыйрфан мулла үзе башлады. Берәүнең дә акылы мөкәммәл түгел. Мөхтәрәм Хәйретдин хәзрәт тә пәйгамбәр хәлифәсе булуга дәгъва итә алмый. Ә шулай да эчтә кайнаган шик-шөбһәләрне кемгәдер сөйлисе килә. Гомер кояшы баеп барган мәлдә адәм баласы үзен төрле кыяфәттә күрә икән. Менә ул кылычтан үткер, кылдан нечкә сират күперен үтә. Үтә икән, жимешле жәннәткә эләгә. Үтәлмәсә, аягы таеп китсә, яки үткер кылычта киселсә, мәңгелек тәмуг утына тәгәри. Бусы — бер. Икенчесе шул: син китсәң әгәр мәңгелеккә, фани дөньяның әйтерсең, асты өскә килә, мәгыйшәтлелек какшый, инсаниятлелек югала. Акыл мөлкәте, гүя, синең башта гына.

Гыйрфан мулла да шулай уйлый. Шуңа күрә үз уеның мөлкәтен Хәйретдин хәзрәткә күчермәк була. Уратып-чуратып булса да, үз шәме яктысының зәгыйфьләнеп баруы, хәдис өйрәткәнчә яшәү өчен яңа шәм кабызырга кирәклек турында аңлата. Авыл халкы иманыннан язмасын, яшәү кадерен белсен, киләчәк буыннар ата-бабаларына рәхмәт әйтерлек булсын!

Барын да аңлады иманга ихлас күңелдән табынган, Коръән аятьләре энжеләрен кадерле белгән, зирәк күңелле Хәйретдин хәзрәт. Ә инде корылык турында ул болай диде:

— Сабыр итик, Гыйрфан кордаш, Алла сабыр итәргә кушкан, үзебез дә: "Сабыр иткән — морадына житкән", — дип сөйләшәбез ләбаса, яңгыр яумый калмас, явар; әгәр яумый икән, гөнаһсыз авыл картлары жыйнаулашып зират янына барып, анда дога укый-укый, Аллаһу Тәгаләдән рәхим вә шәфкатьлелек сорарбыз, гөнаһ кылмаска сүз бирербез.

— Ә нигә соң, Хәзрәт, аны бик озакка сузасыз?

— Бу хакта үзем дә уйланам. Аллаһу Тәгалә ашыгып эш итүне дә яратып бетерми. Күңелем сизә: әле вакыты житмәгән, урынсыз теләк кабул булмый ул.

Шуның белән аларның сүз чылбыры өзелде. Хәзрәт киткәч, Гыйрфан мулланың тыны иркенәеп киткәндәй тоелды. Ул аягына басты хәтта. Ләкин Мөбахис мәзин аны кабат аяктан екты. Бөтенләйгә, мәңгелеккә екты.

Ул — Мөбахис мәзин — аяк очларына гына басып, йомшак нәзакәтлелек күрсәтергә теләгән хәлдә, монлы тавышы белән "әссәләмегаләйкүм"не бөгелә-сыгыла әйтеп, ун кулын йөрәгенә куеп килеп керде. Ул матур киенгән. Аягында — сафьян читек. Өстендә — ефәк җилән. Ун кулында — әллә нинди нәфислекләр белән сырланып эшләнгән тәти таяк. Сул кулында — нниндидер гәзит. Нәзафәтлелек вә ыспайлык җәһәтеннән ул — авылда матурлык таҗы. Гыйрфан мулла исә — аның киресе. Дөрес, ул да мәчеткә, ашка, туйга барганда, сабантуйларда үзенең зыялы зат, диндар кеше икәнлеген онытмый — зәвыклы киенергә тырыша. Ә инде иген эше дулкынына кереп чумса, маллар арасында кайнашса, ишек алларын чистарту мәшәкатенә керешсә, аны теләсә нинди гади крәстиәннән һич тә аерып булмый. Күрше-күләнгә, туган-тумачага, дусишкә болай гына кергәндә дә киндер күлмәген, кижеле ыштанын салып ыргытып, һич тә ефәккә уралырга тырышмый. Мөбахис мәзин исә алай түгел. Үз ишек алдында да балкып йөрергә ярата. Кара эшкә ул җирәнеп карый. Аның хезмәтчеләре күп шул. Аларның җанын алып эшләтә. Гыйрфан мулла "кара" эшнең сәнгатен аңлый. Мөбахис мәзин исә "ак хыяллар" белән яши. Кеше дөньясына тыкшынуның кырмыска оясына таяк тыгу белән бер икәнлекне аңлый Гыйрфан мулла. Шулай да Мөбахис мәзингә тыкшынырга аның хакы бар. Чөнки Троицк мәдрәсәсендә мөдәррислек вазифасы башкарган чагыннан бирле белә ич ул Мөбахисны. Белем дәрәҗәсе сай булса да, шәкертлеккә кабул иткәндә, Мөбахис үзен шаян табигатьле, сүзчән, шат күңелле итеп күрсәтә белде. Укуда артык алдыра алмаса да, хәлфәләрнең, мөдәррисләрнең кикергәненә "әлхәмде лилля", "Аллага шөкер" кебек сүзләр әйтеп, аларның табан асларын яларга, төчкергәндә танау асларына кульяулык куярга, бер алларына, бер артларына төшеп маймылланырга ярата иде. Бу сыйфатлары күпләрнең саруын кайнатты шикелле. Аны нниндидер дәрәҗәле урынга кунаклатмадылар. Тегендә-монда төртелеп йөри торгач, Гыйрфан остазының кешелеклелек сыйфатларын искә алып, аның мәчетенә мәзин булып килде. Авыл халкы тиз сыный кешене. Бигрәк тә иман нуры чәчеп яшәргә тиешлеләрне. Чәчәлмәде Мөбахис мәзин иман нурын. Нәкәслек белән шөгыльләнде. Терелә́й кабергә күмдерде бит Хөрмәтулланы. Хәзер инде, үзен ал да гөл күрсәтергә теләп, куылып китүдән куркып, Уфа Диния нәзарәтләренә хак күңелле диндарлар өстеннән шикаять яза. Балаларын да шул рухта тәрбияли. Бер улы аларның сыерчыгын таш белән бәреп үтерде. Бәкерҗаны "Галия" мәдрәсәсендә яман эш белән шөгельләнә икән. Эчә, тарта, мәрүскәләр янына бара, ди. Бу пычраклыкларны башындагы ак чалмасы белән капларга йөри хәзер Мөбахис мәзин. Еланның агына да ләгънәт, карасына да ләгънәт, дигәнне аңламый, күрәсең.

Ник килгән ул монда тагы да? Хәл белергәме? Бәхилләшергәме? Ачуың килеп, әллә ни әйтеп ташлавың, ахыр чиктә теге дөньяга иман белән түгел, авызыңа алама сүз тутырып китеп баруың бар.

Шакирҗан белән Габделхәким игеннәрне карап кайту өчен кырга киткән иделәр. Хәсәнә абыстай аш-су бүлмәсендә. Дөрес, төшкелек ашалып, өйлә намазы укылып куелган инде. Икендегә, ахшамга шактый вакыт бар әле. Кичке чәйгә коймак туглап куйды ул. Эш белән шулай әвәрә булганда руханиларның сүзләре дә килеп бәрелә колак барабанына. Сүзнең матуры да, ямьсезе дә колак барабаныннан йөрәккә үтә. Матуры назлый йөрәгеңне. Аламасы чеметә. Ак хәзрәт шәфкатьле йөзе, мәгънәле сүзе белән рух рәхәте калдырып чыгып китте өй эчендә. Аңа рәхмәт әйтеп кычкырасы килде Хәсәнә абыстайның. Ләкин ярамый. Мөселман хатыны ирләрдән, бигерәк тә Ак хәзрәт кебек руханилардан, тел вә йөз яшерә. Чөнки шәригать шулай куша.

Хәзер менә икенчесе килеп керде. Аннан да тел һәм йөз яшерергә кирәк. Бусына әллә нниләр әйтәсе килә Хәсәнә абыстайның. Теләсә ни такылдап, мулласын мазасызламаса, йончытмаса ярый ла ул. Әмма аңа ышаныч бик аз. Ач әрвах белән бер бит ул.

— Ху-у-у-ш, Гыйрфан әфәнде... хәлеңне белеп чыгыйм әле... дип кергән идем... — дип сүз башлады ул.

Сүз башлавын ук ошатмады аның Гыйрфан мулла. Элек, йомакайланып булса да, "Мулла абый", дип, матур итеп әйтә иде. Хәзер "әфәндегә" күчкән. Димәк, аның өчен "Мулла абзый" түгел инде.

— Мин, Гыйрфан әфәнде, сез күрсәткән изгелекне һич онытмыйм. Моңа бер Ходай үзе шаһит булсын. Әле дә менә кайгыгызны утраклашырга килдем. Бу гәжитне әле укымагансыздыр. Безнең авылга килеп җитмәгәндер. Аны бүген Уфадан Бәкерҗан алып кайтты. Монда ул тиклем баш ярылып күз чыгарлык нәстәкәй дә юк сыман үзе. Аллаһу Тәгалә олы кайгыларны җиңел кичерергә куша. Бәс, шулай булгач, сез дә бөгелеп төшмәссез дип уйлыйм. Бер дуңгызы китереп бу хәбәрне, әллә ниләр такылдап, нахак бәлаләр тага-тага, болай да авыр хәлегезне кыл өстенә куеп чыгып китмәсен дип, үзем килергә мәҗбүр булдым.

Аның шулай кыланып, куштанланып сөйләвенә Гыйрфан мулланың саруы кайный башлады:

— Нинди кара кайгы бар соң ул гәзиттә минем өчен? — дип сорады ул, артык ачуы килеп.

— Киевтан Галимҗанны төрмәгә утыртып куйганнар лабаса. Шул хакта менә "Вакыт" гәзитенә язганнар. Мә, укы!

Гыйрфан мулла, газетаны тартып алып, аның йөзенә бәрде:

— Имансыз! Тапкансың начар хәбәр таратып йөрер вакыт. Синең өчен шатлык ул хәзер. Әллә белмимме? Гыйрфанны алдый алмассың.

Чыгып китәргә ашыкмады Мөбахис мәзин:

— Минем Өфедә таныш адвокатым бар, остазым, шунын аша Галимҗанны коткарып...

Гыйрфан мулла аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Мөбахис... оял азрак... Алладан курык... Кит!.. — дип өзек-өзек сүзләр әйтте дә бөгелеп төште.

Атылып килеп чыкты Хәсәнә абыстай аш-су бүлмәсеннән. Гыйрфан мулланы, җайлап кына, урынына утыртты. Ә Мөбахис мәзин, күзләрен чекерәйтеп, һаман карап тора иде әле. Инде хәзер тел вә йөз яшерү дигән шәригать кануны турында уйланмады абыстай:

— Әллә ясин чыгыйммы? — дигән иде мәзин, абыстай аңа ачыргаланып җавап бирде:

— Алла хакы өчен... үтенепләр сорыйм... чыгып китегез... зинһар!.. Ясин чыгарга сезнең хакыгыз юк...

Бу кадәресен абыстай артык тупаслык дип исәпләде. Ярыймы соң инде ир кешегә шулай кычкырынырга? Моны шәригать тә, бәндәчелек тә кушмый. Нигә шулкадәр икейөзлеләнә ул? Ир кешегә һич кенә дә килешми ләбаса. Аңламыймы шуны?

Мондый уйлар яшен тизлегендә үтте аның башыннан. Ярый әле Габделхәким давылланып кайтып керде. Керә керешкә ул, кулларын болгый-болгый:

— Әткәй, әткәй, безнең игеннәр шаулап үсеп утыра, — дип, нидер сөйләмәкче иде, абыстай бармак какты:

— Улым!.. Тиз генә йөгер... Ак хәзрәтне алып кил... Әтиең авыраеп китте...

Мулла абзыйның абыстайны җибәрәсе килми иде. Ул, гүя, мине газраилгә бирмә-бирмә, дип әйтә. Аларның тынлыгы озакка бармады.

— Хәсәнә җаным! — диде Гыйрфан мулла ыңгырашып, — мин шактый кырыс... усал да булдым шикелле... Сине артык нык рәнҗетмәдемме?.. Әгәр шулай икән, кичер, зинһар!.. Ходай шаһит... синең алда тузан бөртеге кадәр дә гөнаһам юк... Мин бит инде әллә кайчан җан тәслим кыла идем... Син коткарып киләсең... Соңгы вакытта үзең дә бик алҗыдың бит инде... йокысыз төннәрең... күпме борчу... Барысы да минем аркада... Сиңа бер рәхәт тә күрсәтмәдем бугай...

Ул сүзләрне шактый авыр әйтте. Өзеп-өзеп. Сизә абыстай: соңгы

ясин вакыты якынлашып килә. Әмма абыстайның үз хәле дә бик мөшкел шул әле. Өч-дүрт ай инде юньләп йоклаганы юк. Хәле бетә. Акрынлап сыза ул. Соңгы вакытта тамагыннан аш үтми башлады. Үз хәле авырая барганны абыстай мулласына сиздермәскә, аны янә озаграк яшәтергә, мөселман хатын-кызларына хас булганча, ир хакының тәңре хакы икәнлекне исбат итәргә тырышты. Әлбәттә, башка әллә нинди иләс-миләс, күңелсез, зәгыйфь уйлар да килә: кем белә — үзенең әле алдан аяк сузуы бар. Башка төрле дә уйлый: әллә Ходай аларның икесен бер көнне үк үз катына алмак буламы? Ирдән калу — бәхетеңнән калу, диләр бит. Яман шеш дигәне чын булса, аның да гомере өзелеп бара лабаса инде. Тик... Галимҗан кайтсын иде тизрәк. Аңа ата-ана фатихасы кирәк. Ә инде мулласының борчылуын, һәрвакыттагыча, мәгънәле һәм матур сүзләр белән җуярга тырышты ул:

— Син алай уйлама әле, әйкәем, тормыш ләззәт вә рәхәтлек бакчасы түгел бит ул, аның җиле дә, давылы да була, әмма без, Аллаһу Тәгалә үзе шаһит, иманнәрне аударырдай гарасатта да сынмадык. "Бер рәхәт тә күрсәтмәдем", дисең. Яшәү үзе рәхәт! Хәят үзе матурлык! Дөнья көтү — авырлыклары белән гүзәл! Мин синнән бик канәгатьмен! Кырысрак чакта да гадел булдың. Дөрес яшәдең!..

Боларны ишеткәч, Гыйрфан мулланың остазбикәсенә бик җылы, ягымлы, кадерле сүзләр әйтәсе килде. Ләкин теле тибрәнсә дә, сүзе чыкмады. Әмма үзе остазбикәсен, хәлсез кулларының карышуына карамастан, һаман ныклап кочакларга тырышты. Тик ул инде аны булдыра алмады. Бөгелеп төште дә:

— Ху-у-у-ш... Хә-сә-нә... бә-бә-бәхил бул... фа-фа-фа-тиханда бул... — диде.

Хәсәнә абыстай, бөтен көчен туплап, аны мамык түшәккә сузып салды. Хәзер инде хушлашу минутлары җиткәнлекне аңлау кыен түгел иде. Шуңа күрә аңа да фатиха алып калырга кирәк иң:

— Мин бик бәхилмен, муллакаем, кадерлекәем, синең бер гөнаһың да юк, оҗмахның түрендә булырсың, кавемегезнең башы Ибраһим пәйгамбәр әрвахы янында. Син үзең соң... миңа бәхиллегеңне бирәсеңме?

— Бә... бә... бә... — диде мулла абзый. Әмма сүзне ахырынача әйтеп бетерә алмады. Ул телдән калган иде.

Шулай да Галимҗан турында аның фикере кирәк иде әле.

— Атасы!.. Атасы!... Әйткәем!.. Муллакаем!... Галимҗанга фатиханы бирәсеңме?..

Ләкин җавап булмады. Күзләре мәзәкләнде Гыйрфан мулланың. Шулай да нидер белдерергә теләде ул:

— Га... га... га... — диде дә, калган иҗекләрне әйтә алмагач, уң кулын көч-хәл белән күтәреп, иман бармагын әйләндереп торды. Бераздан "лим-җан"ны әйтте. Шуннан әлеге иман бармакны бөгеп куйды. Моның мәгънәсен шулай фараз итте Хәсәнә абыстай: Галимҗан бик югары үрләргә тиеш иде, ләкин киреләге аны түбән төшерде.

Нәкъ шул вакыт Хәйретдин хәзрәт тә килеп җитте. Хәсәнә абыстай, алдан бәйләгән ак яулыгының бер як чите белән битен каплады да, ясин укырга кирәклекне аңлатып, эчке бүлмәгә кереп китте. Хәзрәт авыру янына килде. Башта эндәшеп карады ул. Гыйрфан мулланың телдән калганлыгын, соңгы сулышы җиткәнлеген аңлагач, кычкырып вә моңлы итеп укый башлады ул ясинны.

Нәкъ ясин укып бетергән мәлдә бирде Гыйрфан мулла җанын Ходайга.

# Дүртенче бүлек

## I

"Галия" мәдрәсәсенә Галимҗан янә әйләнеп кайтты.

Нәрсә тартты аны монда? Нинди язмыш? Шашкын уй-хисе, кайнар дәрте, илаһи күңеле ашкынамы туган ягына? Туган җиренең кымызга биргесез шифалы саф һавасы бар. Йөрәгендә тирән сер саклаган солтанат кыяфәтле Урал таулары горурлык нуры чәчеп тора. Оһ, ул калын, борынгы кара урманнар! Аларның бит эче тулы моң. Илаһиятлелек. Садәлек.

Табигать ул адәм балаларының кәйфиятен искә алып яши сыман. Инсаният әнә шушы илаһи матурлыкның хозурлыгын тоеп, кадерен белеп кенә гомер кичерә икән, табигать күңеле һәрвакыт шат, мәрхәмәтле, илтифатлы була. Бу җәһәттән аны йә ата-анага, йә балага чагыштырырга мөмкин. Бала йөзендә кайгы күрсә, ата-ана хафалана башлый. Ата-ана кайгысы баланы елар чиккә җиткерә. Көтмәгәндә сугыш-дәһшәт башланды. Аяз күкне кара болыт каплады. Кешеләрнең бу юньсезлеген бик авыр кичерә табигать. Ул инде хәзер аларга кара йөз күрсәтә. Агыйдел дә нык кайгылы. Аның ак күңеленә кара шом төште. Димнең агышы да, элеккечә, көләч кыз елмаюын хәтерләтми инде. Караидел-егетнең кара чәченә дә кырау төште. Урман әрнү моңы белән шаулый. Урал таулары көчсезлектән сыкрана. Күлләр елый. Имәннәр баш ора. Әзмәвердәй егетләр сугыш кырында һәлак була лабаса! Ипи кибетләрендәге киштәләр бушап калды. Ачлыктан халык зар елый. Җилләр үкереп исә. Бөтен табигать өзгәләнә. Атлыгып, ярсый-ярсый, туган якларын сагынып кайткан Галимҗан түшәккә ятты. Бу да — сугыш тәэсире. Дөнья бозылудан килгән фаҗига. Аламалык хикмәте.

Галимҗанны алмадылар сугышка. Әлеге дә баягы, дигәндәй, балалык елларыннан ук килгән чир үпкәсен һаман телгәләп маташа икән әле. Абыйсы Шакирҗан, Ходайга шөкер, һәрвакыт сәламәт булып, иркен тын алып яшәде. Мактый-мактый алдылар аны патша хезмәтенә. Әнә шуны озатып йөргәндә аяктан егылды да инде Галимҗан. Гыйнвар, февраль айлары сыер мөгезен төшерердәй нык салкын булды. Шакирҗанны сугышка нигәдер тиз генә озатмадылар. Әллә ничә мәртәбә барырга туры килде Уфага. Янә өч-дүрт көн вакыт барлыгын белсә:

— Абзыкай! Җыясы ризыгың бетмәгән, әйдә бер тәүлек булса да җылы өйдә тор, — ди дә, инде шактый картаеп килгән алмачуарны җигеп, алып кайта да китә Галимҗан Шакирҗанны.

Шакирҗан, аны артык борчудан куркып:

— Булмаса, энем, син үзең генә кит, Уфада танышлар күп бит, берәрсендә баш төртерлек урын табармын әле, — дип әйтеп тә карый.

Ләкин үзсүзле Галимҗан уйларга да форсат бирми:

— Шәкерт абзыкай! Әйткән-беткән, — дип кенә куя.

Бәләкәй чакта да сүзен сүз итми калмый торган Галимҗанның холкын белә абыйсы. Шуңа күрә артык карышып маташмый. Ризалаша. Ә бу юлы ул Галимҗанны ныклап яратып та өлгерде. Шулай үзсүзле, нык, чигенмәс булу кирәктер. Бу табигате аңа зур эшләр башкаруда да ярдәм итәчәк әле. Галимҗанның бәгъзе бервакыт үзен артык эре, тәкәббер тотуы, әллә нинди тирән уйларга чумып гасабиләнүе аңа ошамый иде. Ә менә аның өчен авыр минутларда Галимҗан туганлык хисенең кадерле, зур, бөек икәнлеген исбат итә алды. Үзе дә бик авырлык күреп яши шул. Кайда гына булмады. Кемнәр белән генә аралашмый ул. Нинди генә авырлыклар күрми. Шуларның барысы да аның кешелеклелек дәрәҗәсенә яңа, уңай сыйфатлар өстидер, күрәсең.

Хәсәнә абыстай да шулайрак уйлады Галимҗан турында. "Кәгаздән башканы белмисең, балам!", "Дөнья китаптан гына тормый", "Кешеләрне ярата белергә кирәк", кебек сүзләрне еш әйтә иде. Шакирҗанны Уфадан кат-кат алып кайтуы, аны янә иренми илтеп куюы, һәр адымда илтифатлы

булырга тырышуы нык шатландырды ана кешене. Уфа белән Солтанморат арасы —җитмеш-сиксән чакрым чамасы. Галимҗан үзен дәртле ямчыкучер кебек тотты хәтта. Шаян сүзләр ычкындырырга да саранланмый. Ат җигү, ат карау мәшәкатьләрен дә үз өстенә алды.

Галимҗанның, гәрчә ул үзсүзле булса да, үзе хакында аз уйлаганлыгын, сакланмаганлыгын Хәсәнә абыстай да, Шакирҗан да яхшы белә. Шуның аркасында әллә кайларда, казакълар, нугайлар арасында йөрде, зимагурлар белән эшләп авырлык кичерде, төрмәдә утырып чыкты, әллә кемнәрнең эт бәйләсәң тормаслык почмакларында аунап интекте. Бу юлы да күңеленә шик килгән иде ана кешенең. Ай-һай ла, һич кенә дә саклана белми, юлда ул-буга очрап, бер-бер күңелсез хәлгә юлыкмаса ярар иде, дип борчылган иде. Ана йөрәге сизенми буламы? Соңгы мәртәбә киткәндә көнне бераз жылыткан иде. Галимҗан юка пальтосын гына кигән. Моңа Хәсәнә абыстай да игътибар итмәгән. Икенче көнне салкын буран куба. Өч тәүлеккә сузыла бу. Галимҗан юлга әнә шундый чакта чыга. Караңгы төшеп, тәрәзәләрдә утлар сүнгәч, туңып кайтып керә ул. Һәм... аяктан егыла.

## II

Башта Галимҗан авырып китүен әнисенә сиздермәскә тырышты. Аның кайгысы болай да җитәрлек ич инде. Ничә еллар буе сандугачтай сайрашып, күгәрчендәй гөрләшеп гомер иткән хәят юлдашын югалту җиңел булмагандыр. Шакирҗанның китүе — ана йөрәгенә янә бер җәрәхәт. Тиздән сугышка Габделхәкимне дә алачакларын аңлый ул. Галимҗанның, бәйләп куйсаң да, авылда тормаячагын яхшы белә. Шулай да кайгыларын ул һаман әле тышка чыгармаска тырыша. Кайчак "уф", дип куя. Бәгъзе бервакыт, эш арасында, үзе сизмәстән, "Гыйрфан" дигән сүзне әйтә. Әллә акылы җиңеләяме югыйсә? Ирсез калган хатынны канатсыз кошка тиңлиләр. Галимҗан үзе генә дә күпме кайгы китерде инде аңа. Кайда гына йөрмәсен, хәзер инде Галимҗанның полиция күзәтүендә яшәгәнлеген белә ул. Ләкин тузынмый. Кайгысын эченә йота. Түзә. Күпне күтәрә белә икән шул ана йөрәге! Әмма ул шулай эчтән генә яна-яна, әкренләп сүнеп бара шикелле. Авыр тын ала. Күкрәк гыжлавы сизелә. Яңаклар эчкә баткан. Гәүдә кечерәеп калган. Әлбәттә, күз карашы һаман ягымлы. Йөзендә әле мөлаемлек, кешеләрне җәлеп итә торган җылылык, шәфкатьлелек чаткылары сүнмәгән.

Икенче көнне Галимҗан, авырып китүен сиздермичә, һаман шулай шат булырга, урын өстенә ятмаска тырышты. Төшке аштан соң, икенче катка күтәрелеп, язу өстәле өстендәге китапларын караштыра башлады ул. Хәсәнә абыстайның бик тә сөйләшәсе килә иде. Аш бүлмәсендә эшен саектыргыч, өске катка ул да менде:

— Балакаем! Кәгазьдән һич күзеңне алмыйсың. Азрак ял итәр идең.

— Тик торудан да авыр хәл юк, әнкәй! Син үзең дә шулай бит инде.

— Әтиең дә бик тынгысыз кеше иде, мәрхүм.

— Син, әнкәй, бик кайгырма инде. Үзеңне сакла.

— Кем өчен?

— Безгә син иң кадерле кеше!

— Габделхәкимне дә алсалар, берүзем калам ич. Ялгызлык белән тик тору — игезләр.

— Ялгызлыкның да авырлыгын беләм, әнкәй!

— Ә нигә өйләнмисең соң, улым?

— Вакыт юк, әнкәй!

— Инде зур кеше булдың ич.

— Мин әле күкнең җиденче катында гына.

— Мин аларны аңламыйм.

— Алайса, санап күрсәтим. Язучымын — бер кат. Тәнкыйтьчемен — икенче кат. Галиммен — өченче кат. Мөгаллиммен — дүртенче кат. Тарихчымын — бишенче кат. Өслүбчемен — алтынчы кат. Телчемен — җиденче кат...

— Шулар җитмимени соң?

— Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләр бит. Мин хәзергә җидесен генә беләм.

Инде ошбу җиде һөнәрне әнисе санап китте:

— Тырма тырмау, сабан сөрү, ашлык чәчү, печән чабу, ат карау, урак уру, кибән кую, чүмәлә тарттыру, бәләкәй арба ясау, балык тоту, ат чаптыру һәм... шалкан урлау... Шулаймы?

Галимҗан көлеп җибәрде:

— Әнкәй! Анысын әйтмә инде. Без бит ул шалканны барыбер ашамадык.

— Кибән астына яшердегез.

— Без бит аны беркемгә дә әйтмәдек, ә син ничек белдең, әнкәй?

— Без капчыкта ятмый, балакаем!

Үзләре ясаган бәләкәй арба белән малайлар бервакыт печәнгә дип киткәннәр иде. Басуда алар шалкан җиренә тап булдылар. "Шалкан буры" дигән "һөнәр"не ишеткәннәре бар иде аларның. Нигә шул "һөнәр"гә ия булмаска? Әлбәттә, әллә ни күп тә алмадылар. Ләкин кайтканда:

— Мин моны барыбер ашамыйм, — диде Галимҗан. Башкалар да шул ук сүзне кабатлады. Шуннан шалканны бер кибән төбендә калдырдылар да киттеләр. Алар, әле дә очрашсалар, аны сабыйлык еллары истәлеге итеп сөйләп көлешәләр. Бу шуклык хакында әнисеннән ишетү балачак хәтирәләрен яңартты. Шул вакытларны искә алып көлешкәч, сүз янә күк дөньясына күчте:

— Галимҗан улым! Әтиең гел генә нәсел тамырыгызның Ибраһим пәйгамбәрдән килүе турында сөйләргә яратты. Шулай да мәгълүматы җитми иде шикелле аны аңлатып бирергә. Имештер, күкнең һәр катында бер пәйгамбәрнең җаны яши. Ә менә Ибраһим пәйгамбәрнең җаны күкнең ничәнче катында икән, балакаем?

— Ибраһим пәйгамбәр — күкнең җиденче катында. Мин үзем дә анда булдым, әнкәй! Ибраһим пәйгамбәр-бабакай белән чәй эчтем, оҗмах җимеше ашадым!

— Кит, юньсез, шаяртма, гөнаһлы булырсың.

— Мин бит аны төштә күрдем, әнкәй!

— Шулай дисәң генә инде.

— Хәзер аны өнгә күчерик, әнкәй! Мин белемем белән күкнең әнә шул җиденче катында гына әле. Минем өчен ул бик тәбәнәк. Белемем әле уртача гына дигән сүз. Тагын да югарырак күтәреләсем килә.

— Җиденче кат күкнең соңгы капусы түгелмени?

— Түгел, әнкәй! Җиде саны бик борынгы заманнарда күплекне белдерү өчен кулланылган. Күкнең чиге юк. Шуңа күрә ул җиде кат кына була алмый.

— Мин боларны аңлап бетермим, балакаем! Ят. Ял ит.

— Уф, әнкәй, мине син сабый балага әверелдердең.

— Ир-атның барысы да сабый. Холыклары кырыс булса да, алар наз ярата.

— Әнкәй! Әнкәй! Мин авырмыйм. Ул болай гына. Мин синең бишек җырларыңны тыңларга ярата идем. Бер җырлачы!

— Хәзер... Тик онытылган бит әле.

Күзләремнең нуры бетсә,
Алырмын алсу таңнан;
Кояштан эссе сорармын,
Җылылар китсә җаннан.

Күктә дисәләр бәхетне,
Анда да менәр идем;
Көчтән килсә, юлларыңа
Таҗгөлләр тезәр идем.
Йокла, улым! Йөрәк хисем
Мин юрган итеп ябам;
Төннәр буе керфек какмый
Наз белән сөяр анаң!

— Әнкәй! Әнкәй! Син — шагыйрә! Җаның тулы моң. Син мине дә шулай моңлы иттең. Язучы иттең мине!

— Әтиеңне дә онытма, балакаем!

— Әйе, ул да телгә оста иде. Икегез дә язучы иттегез мине.

— Ә табигать?

— Ул да минем йөрәгемдә яши, әнкәй!

— Ә Алла рухы?

— Минем өчен барысы да илаһи!

— Алайса, тыныч кына йокла инде! Арыгансың син. Үзеңне бер дә сакламыйсың шул, балакаем.

Хәсәнә абыстай Галимҗанның кайнар чәчләреннән сыйпап, аркасыннан сөйде дә аскы бүлмәгә төшеп китте. Галимҗанга рәхәт иде. Ана назы! Ул бәләкәй чакта гына түгел, утызга җитеп килгәндә, гомергә кирәк икән. Бу мизгелдә ул үзен бөтенләй сабый балага әверелгәндәй хис итте. Шул хисләр ләззәтендә балдай татлы йокыга талды.

## III

Галимҗан йоклаган арада, аңа сиздермәскә тырышып, Хәсәнә абыстай өстәл өстендәге кәгазьләрне җыештырып куймакчы булды. Шунда бер язуга күзе төште аның. Анда болай дип язылган иде:

*"Тормыш, яшәү өчен кирәк булган һәрнәрсә табигатьтә бар. Тик алардан файдалану юлын гына белергә кирәк. Авыру, ачлык, салкынлык кебек кешенең тормышына һөҗүм итә торган никадәр нәрсәләр булса, боларның һәммәсеннән дә котылу өчен табигать чараларын хәзерләгән... Тик файдалана гына бел! Табигать үзенең бу нәрсәләрен бик кыйммәт сата. Ул боларны яшергән. Һәркемгә биреп бетермидер. Табигатьтән файдалану һәр кешенең гыйльми тәҗрибәсе нисбәтендә буладыр. Аның яшергән хәзинәләре гыйлем аркасында гына чокып чыгарыла. Гыйлем, үзенең иң күп көчен табигатьнең яшерен хәзинәләрен чыгару юлына, аңардан күбрәк файдалану чарасына сарыф итә һәм ирешә дә аладыр. Гыйлем арткан саен табигатьнең яшерен серләре табыла бара, кешеләрнең файдалануы арта барадыр. Бу бабта бәян кылынырга теләнгән тыйб гыйлемнәре мәгълүм булсын ки: кешенең тормышына, сәгадәтенә иң зур дошман булган "чир-авыру"дан саклану өчен табигатьтән файдалану юлларын кешегә белдерә торган гыйлемдер. Бу гыйлем табигатьтән күп дәвалар чыгара, табигый матдәләргә үзенең махсус ысуллары белән хезмәт кушып саклау, котылу юлларын өйрәтәдер. Һәр гыйлем, башта бик зәгыйфь булып мәйданга чыкса да, бу көндә гакылларны хәйран кылачак дәрәҗәдә үсте. Кешеләрнең һәр гамәлләре — аларның гакылда, фикердә үсүләре белән тигез була".*

Боларны укып чыккач, озак кына уйланып утырды Хәсәнә абыстай. Әтисе дә гел генә шул хакта баш вата иде ләбаса. Үз йөрәген табигать йөрәге белән бәйләргә ятатты. Кыш, яз, җәй, көз көннәренең "холкын" язып бара иде. Үләннәр, чәчәкләр, игеннәр дөньясына кереп китә. Елгалар, күлләр, чишмәләр торышын тикшерә. Таулар, болыннар, тугайлар атамасын өйрәнә. Һәй, алма агачыннан ерак төшми инде ул. Шулай да бу ераграк киткән шикелле. Фәннең эченә кереп бара. Тик бу табиблар эше түгелме соң? Нигә кирәк булды икән ул аңа? Чү! Тукта, тукта! "Борынгы ислам

мәдәнияте", дигән бит бу. Янә "Голүм тыйббия, ягъни медицина гыйлемнәре", дигән ләбаса. Шуннан "Ислам табиблары", "Ислам дөньясында маристаннар, ягъни шифаханәләр" дигән баблар бар. Янә дә: "Гыйльме кимия, ягъни химия фәне", "Табигать фәннәре", "Җәгърәфия, ягъни география фәне", "Гомуми география китаплары..." — тагы да әллә ниләр. Үз һөнәрен җидегә генә чыгарган иде бит ул. Ә монда тагы да әллә ниндиләре бар. Ә монысы? Тукта! Тукта! "Гарәпләрнең уку вә белүләре", "Заман җаһилиятенең, ягъни наданлык, мәҗүсилек заманының ахыры", "Гарәпләрдә исламият..." Бә-ә-й, Ходайның рәхмәте! Әллә ниләр, әллә нәстәкәйләр бар бит монда! Борынгы гарәпләр дөньясына кереп киткән. Ислам динен шәрехләгән. Менә кемдә баш!

Язмаларны иплəп кенә җыештырып алды да аскы катка төште Хәсәнә абыстай. Әйдә, кырык эше кырык җирдә кырылып ятсын шунда. Алар белән көн-төн әвәрә булып, күзенне чекрәйтеп, колагыңны шәмрәйтеп, аһ-уһ килеп йөрисең дә йөрисең. Ә бу кәгазьләрдә бөтенләй башка дөнья! Кызык дөнья!! Мавыктыргыч дөнья!!!

Менә монысы нинди язу икән тагы да? Нигә дүрткә бөкләде икән аны? Бәй! Хат ич бу.

*"Шәһит дус! Мин әле ут эчендә ятам. Газраил бугаздан алып маташа. Төп йортта булгач, әллә ни бирешмим. Чөнки әнкәй нык тәрбияли. Аны борчымаска, чиремне әйтмәскә тырышкан идем. Ләкин булдыра алмадым. Әллә мин артык йомшакмы? Әллә әнкәйнең ләтыйф назы эретәме? Җитмәсә, әткәй мине үз янына чакыра. Барырга иртәрәк бит әле. Үзең беләсең: язасы әйберләр күп. Әткәйнең дә, әнкәйнең дә сүзен тыңламый харап булдым. Хәер, син дә: "Үкенерсең, Галимҗан, нигә үзең турында азрак уйламыйсың", — дип әйтә идең бит. Оренбургта җиде ел Вәли мулланың кара базында яшәү, Миаста ачлы-туклы интегү, көненә ундүртәр сәгать эшләнеп эшләү, анда да, Казанда да бөкре карчыкның сасы почмагында аунау, Киевтагы ялгыз камера, тагы да әллә нинди нәҗеслекләр үпкәне парә-парә телгәләп бетерде шикелле. Шакирҗан абыйны озаттым. Тиздән Габделхәкимне дә алырлар кебек. Димәк, әнкәй берүзе кала. Әгәр аякка басмасам, миңа әнкәйне ташлап киту һич килешмәячәк. Шушында калырмындыр. Әмма хат язуның төп максаты саулыктан зарлану гына түгел. "Казакъ кызы" романы югалды инде. Аны кире кайтарып булмаячак. Шуның артыннан "Безнең көннәр" романым да харап булса, күпме көч бушка китә бит, дускай! Син инде шунысын булса да саклау чарасын күрсәң иде. Үзеңә мәгълүм: Казанда дуслар күп, әмма иң ышанычлысы — син! Шуңа күрә сиңа язарга булдым. Бигәйбә!*

*Хөрмәт вә ихтирам илә — Галимҗан".*

... И Аллам! И Ходаем! Артык мавыгып кителгән ләбаса! Икенде намазы якынлаша икән бит. Кулындагы дәфтәр-кәгазьләрне кәнәфидә калдырып, тәһарәт алырга йөгерде Хәсәнә абыстай.

* * *

Озак йоклады Галимҗан. Әнисе аны ясту намазыннан соң гына уятты.

— Тор инде, улым, итле аш, коймак пешердем, ашагач ятып йокларсың, — диде Хәсәнә абыстай.

Әлеге кәгазь-дәфтәрләрне алып менеп, өстәл өстенә куйган иде инде ул. Галимҗан торып утыргач, сүзне шуннан башлады:

— Бу язмаларыңны, укыдым, балакаем... Син һөнәреңне бая җидегә генә чыгарган идең. Алар бик күп икән ләбаса. Син күргән ул — төш түгел. Хакыйкать. Күкнең җиденче катына Ходай сине дөрес мендереп утырткан.

— Күкнең җиденче катында, ягъни пәйгамбәр Ибраһим-бабай янында мин нык утырмыйм шул әле, әнкәй! Наданлык көчле. Күп нәрсәләрне аңлап бетереп булмый.

— Соң, балакаем, бөтен гыйлемне колачлый алалмассың бит инде.
— Колач таррак шул әле, әнкәй!
— И Аллам!.. Әйдә... ашарга...
— Хәзер...
Атлыйм дисә, башы әйләнеп китеп, караватына яңадан ауды Галимҗан. Эчен тотып бөгәрләнде дә, буылып, ютәлләргә кереште. Шуннан янә торып, янә ятты. Тагын торып, алпан-тилпән атлап, аскы катка төште. Һаман шулай буылып-буылып ютәлләгән хәлдә, эчке бүлмәгә кереп китте дә почмакта торган куесу чиләгенә иелде. Авызын җылытып, мөлдерәп кан килә башлады.

* * *

1915 елның гыйнвар урталары иде бу. Тышта салкын буран купты. Галимҗан, әнкәйнең күңеле булсын дип, аш ашарга, чәй эчәргә тырышты. Ләкин тамакка берни бармый: һаман ютәлләде дә ютәлләде ул. Ичмасам Габделхәким дә өйдә юк бит. Нәгыймә апасына йомыш белән киткән иде. Әллә куныш каламы, югыйсә. Аны кендекәй Хәмдия абыстайны алып килергә җибәрер иде. Ул әллә нинди им-томнар белә ич. Бәләкәй чакта да үлемнән ул алып калды Галимҗанны. Хәсәнә абыстайның үз дару үләннәре дә шактый күп. Ләкин алар кан косуны баса торган түгелләр. Шулай да вакытлыча салкын тигәнне ала торган төрле төстәге мәтрүшкәләрне кайнатып эчереп карады. Әмма аларның да файдасы тимәде шикелле. Бума ютәл тәмам йончытты Галимҗанны.
Хәсәнә абыстайның үз хәле дә шәптән түгел иде. Шулай да улы янынннан китмәде ул.
— Әнкәй! Бар, ят инде, хәлем җиңеләйде хәзер, — ди Галимҗан. Ә үзе, шундый сүзләр әйтү белән, янә ютәлләргә тотына. Бизгәк тоткандагы кебек калтырана-калтырана ютәлли. Шуннан, торып, авызындагы канны түкерү өчен, аскы катка төшмәк була. Ләкин башы әйләнә. Хәсәнә абыстай түбәнә көл салган бер керәч савыт китереп куярга мәҗбүр булды. Аңлады Галимҗан моның ни өчен икәнлеген. Теге вакытта, Йосыф мәхдүм белән баргач, шушы хәлне Хөрмәтулла өендә күргән иде ул. Хөрмәтулла абзыйсы ютәлли-ютәлли дә авызындагы канын янындагы савытка төкерә. Шушы искиткеч күңелсез хәл аның үз башына килер дип уйламаган да иде бит ул.
Ярты төн авышкач кына, бераз басылды Галимҗанның ютәле. Акрын гына күзләре йомылды. Имештер, ул әнисе белән Исәнбикән болынында җиләк җыеп йөри. Ә җиләк бик күп. Эре-чыпчык башы зурлык. Тирә-якта чәчәкләр. Гөлләр. Янә арырак дулкынлы үлән диңгезе арасыннан тар гына елга ага. Ул Зәңгәр чишмәдән килгән су, имеш. Эссе көн. Кояш. Бөтен дөнья матурлык эчендә җәйри. Җиләк бик тиз җыелды. Ике савыт "ә" дигәнче мөлдерәмә тулы булды. Инде кайтабыз дигәндә, кинәт давыл купты. Кара-кучкыл болыт белән капланды күк йөзе. Мең тегермән ташы дырылдаган тавышлар чыгарып, ажгырып күк күкрәде дә, ялт та йолт килеп, яшен яшьнәргә тотынды. Әллә нинди бер котырган өермә күтәреп алып менде дә китте аны күккә. Әллә кайларда йөртә-йөртә, күкнең җиденче катына менгезеп, аннан кире алып төште дә пычрак җиргә дынкытты. Әй, тотынды яңгыр яварга. Чиләкләп коя. Җиргә береккән килеш ятты да ятты ул. Аннан эре боз яварга кереште. Йодрык зурлык. Башы тишелеп бетте. Борыны җимерелде. Бөтен тәне теткәләнеп бетте. Торып китәр иде — хәле юк. Шуннан ул имәнеч куркыныч тавыш белән кычкырырга тотынды: "Әнкә-ә-й!", "Әнкә-ә-й!", "Әнкә-ә-й!", "Әнкәй!".
Әһә, тавыш! Ана тавышы! "Әү, балам!", "Бала-а-а-м!", "Галимҗаны-ы-ы-ым!", "Галимҗаным-ы-м!", "Галимҗаны-ы-м!. Әллә нинди кара-кучкыл давыллар, бозлар, гарасатлар арасыннан килеп чыкты әнисе. Килеп

тә чыкты, аны нәни баланы күтәргәндәй күтәреп алып, китеп тә барды. Аналарда икән илаһи бөек көч!! Ләкин бара-бара арыды ул. Тын алалмый башлады. Йөрәге кысыла. Үпкәсе кабара. "Әнкәй!", "Әнкәй!", "Әнкәй!". "Җитте инде, төшер, үзем атлыйм", — ди Галимҗан. Әмма ана ризалашмый: "Юк, юк, балам, кайгырма, аналар түзә ул, бала өчен алар бөтен михнәтне үз җилкәләренә алырга әзер", — ди ул. Шулай бара торгач, алар бер яр буена килеп җиттеләр. Кинәт кенә яр ишелеп, алар упкынга йотылдылар! Упкыннан да алып чыкты ана. Упкын алдында таш кыя пәйда булды. Шул таш кыя төбәсенә дә күтәреп алып менде ана. Тик чыпчык башы зурлыгы кып-кызыл җиләкләре генә юк. Алар инде каядыр чәчелгәннәр. Җиләкләр урынында боз тавы хасил булды. Боз тавы башына да алып менеп китте ана. Тик очлы боз тавы башында ананың аягы таеп китте. Инде түбәнгә тәгәри дигәндә, ниндидер көч-куәт кереп Галимҗанга, әнисен тотып кала алды ул. Үзе һаман кычкырды да кычкырды: "Әнк-ә-й!", "Әнкә-ә-й!", "Әнкә-ә-й!".

Хәсәнә абыстай эшен бетергәч, башын мендәргә терәп, аз гына черем итеп алмакчы булган иде. Шулай да кире кайтты бу уеннан. Ныклап йоклап китсә, Галимҗанга хәвеф килер кебек тойды. Өске катка менеп килгәндә, улының саташу сүзләрен ишетеп, борчылуының бер дә юкка булмаганлыгын аңлады ул. Тик караватына барып җиткәндә, башы әйләнеп, үзе дә егылып китте. Галимҗанның "Әнкәй!!, "Әнкәй!", "Әнкәй!" дигән сүзләре телгәләде ана йөрәген. Ә торырга хәле юк. Ни булды? Ходаем! Ул Алладан ялварып сорарга кереште: "И! Бер Аллам! Балам хакына!" "И! бер Аллам! Балам хакына!" "И! Бер Аллам! Балам хакына!" "Көч-куәт бир!", "Көч-куәт бир!", "Көч-куәт бит!", "И! Бер Аллам!, "И! Бер Аллам!"

Бераздан һушына килде Хәсәнә абыстай. Иплән кенә торып, улының башын тотып караса, Галимҗан һаман шулай ут кебек яна иде әле. Ул инде уянган булып чыкты. Әнисенең кулларын нык кысып:

— Әнкәй! Әнкәй! Үлемнән коткардың мине! — диде.

— Нинди үлем?

— Төштә күрдем. Рәхмәт, әнкәй! Рәхмәт сиңа!

Хәсәнә абыстайның йөрәген шом вә курку басты.

## IV

Галимҗанның хәлен белергә халык килеп торды. Кендек әбисе Хәмдия абыстай:

— И генәм лә, иң жараткан, иң жакын күргән улымны түшәктә жаткырамммы суң, хәзер аякка бастырам мин аны, Алла боерса, күз белән каш арасында, мына сизмәйенчә дә калырсыгыз, — дип сөйләнә-сөйләнә килеп керде дә, кулындагы төргәген чишеп, әллә нинди үләннәр чыгарды. Галимҗан янына күтәрелмәкче булган иде ул, ләкин Хәсәнә абыстай аның юлын бүлде:

— Әле ул йоклый, Актүти, син алып килгән үләннәреңнән шифасын беләм мин, кайнатып, суын эчерермен аңа; олы башыннны кече итеп йөрүеңә күптин күп рәхмәт инде. Ходай озын гомер бирсен үзеңә!

Актүти Хәсәнә абыстайның үз хәле мөшкел икәнлекне дә сизми калмады.

— И генәм лә, бигрәкләр дә бетерештең лә инде, артык кайгырмасаң икән, жаныкаем!..

— Йокламаганга шулай ул, Актүти; анысы үтәр лә ул, тик минә Галимҗаным гына... Бик яшь бит әле, утызга да җитмәгән...

— Һәй, һәй, шул белеме, шул чибәрлеге белән суң, мына дигән җиләктәй бер кыз алып, дөнья көтеп кенә ятасы да бит...

— Без шулай уйлыйбыз ла ул, Актүти, аларның бит тәртәсе үз якларына каерылган...

* * *

Өч тәүлек йокламады диярлек Хәсәнә абыстай. Галимҗанның хәле исә һаман авырая барды. Ә күңелдә әллә нинди шомлы уйлар кайнаша. Авыру потлап килә, мыскаллап китә, диләр лә ул. Мыскаллап китсә дә, бик шөкер анысы. Кышкы салкыннар, язгы пычраклар үтеп, җәйге матур көннәрдә аякка ныклап басса, мең-мең шат булыр иде. Үпкә чире сәкегә сузып салдымы, ул инде кабат баш калкытырга ирек бирми. Беркетә шунда. Киптерә кешене. Бик күпләрне харап итеп тора бит бу чир. Бик күпләрне. И Ходаем! Үзең сакла инде! Үзең сакла!

Сыкрану, яну-көю, өзгәләнүнең берни бирмәгәнлеген аңлый Хәсәнә абыстай. Кайгыдан каймак чыкмаганлыкны да белә. Ә нишләргә хәзер? Уфа шифаханәсенә җибәрергәме? Кем белән? Габделхәкимнең алып барырлык чамасы юк. Урыс телен белми. Анда бит сөйләшергә, аңлатырга да кирәк әле. Әгәр кабул итмәсәләр, алып кайтып китәргә туры киләчәк. Юл газабы кайчак сәламәт кеше өчен дә гүр газабына әверелә. Бик суык бит. Каты бураннарда адашып үлүчеләр дә була. Мондыйны Ходай күрсәтмәсен берүк! Андый эш була калса, болай да көрчеккә терәлгән җаны аны тиз ташлап китәчәк.

Галимҗанның хәлен белергә мөгаллим Сәетгали Сәлимов килеп керде. Хәсәнә абыстай, түкми-чәчми, аңа барын да ачыктан-ачык сөйләп биргәч:

— Уфа шифаханәсенә озатырга кирәк, — диде мөгаллим.

— Бик салкын бит. Габделхәкимгә ышанып чыгарып җибәрү дә әллә ничек бит әле, Сәетгали улым, йә Шакирҗан, йә атасы булса бер хәл иде...

— Үзем алып китәм!

— Болай килешерме соң?

— Галимҗан зур кеше хәзер, Хәсәнә абыстай, андый талантлар сирәк була, аны саклап калу безнең бурычыбыз.

— И балакаем! Һәр намаздан соң бәхет теләп дога кылырмын үзеңә!

Мөгаллим коры тотты. Габделхәкимгә ат җигәргә кушып, бик тиз әйләнеп киләчәген әйтеп, чыгып китте.

Озак тормады ул. Кире борылып килде дә, киендереп, Галимҗанны беренче катка алып төшәргә, аннан тышка алып чыгарга ярдәм итте. Артсыз чанага Габделхәким шактый күп печән түшәгән иде. Галимҗанны әтисеннән калган толыпка урап салдылар чанага. Габделхәким капканы ачкач:

— Күрәм: бик нык борчыласыз, Хәсәнә абыстай! Кайгырмагыз, Галимҗанның язмышы ышанычлы кулда, аның өчен көрәшәчәкмен, тыныч булыгыз, — диде дә, чанага менеп утырып, дилбегәне кулына алды: — һәй, малкай, әйдә, хәерле юлга!..

## V

Галимҗан шифаханәдә март башына чаклы ятты.

Хәсәнә абыстай үтә авыр кичерде бу чорны. Их, нигә шулай ул: Ходай Тәгалә кошларга канат биргән, ә миңа кешедән җәлләгән. Канаты булса, очып кына барып кайтыр иде Галимҗаны янына. Шулай да улының хәлен белү әмәлен гел чамалап кына тора ул. Берәрсенең Уфага барасын белсә, мөгаллим Сәетгали биргән адресны әйтеп, Галимҗанны күреп кайтырга куша. Тик моны берәү дә эшли алмый. "Бер дә вакытым булмады шул, абыстай"; "Эзләдем-эзләдем, һич таба алмадым", кебегрәк җавап бирәләр. Шуннан абыстай мөгаллимне күрергә мәҗбүр була.

— Сәетгали балакаем! Алай-болай Уфага барасың юкмы? — дип сорый.

Аңлый мөгаллим: абыстайның Галимҗан янына җибәрәсе килә. Тик турыдан-туры әйтергә кыймый гына.

Мөгаллим үкенеч белдереп җавап бирә:

— Уфа ерак җир түгел, абыстай, бер көнлек юл, ләкин ат юк бит минем.

Шуны гына көткән абыстай бик тиз ачылып китә:

— Соң, балакаем, Галимҗанны илтеп куйган шул туры бия ярый торгандыр бит?

— Минем өчен барыбер.

— Теге вакытта аны син генә коткардың үлемнән. Яхшылыгыңны мәңге онытасым юк. Инде, балакаем, Галимҗанны сәламәтләндерү дә синең кулда.

Сәетгали белән аларның якынлыгы элек тә нык иде. Гыйрфан мулла унтугызынчы йөз азакларында Солтанморатта янача мәктәп ачу турында хыялланган иде бит. Үзе мөгаллим, остазбикәсе Хәсәнә мөгаллимә була, янәсе. Ләкин хыял агачы җимеш бирә алмады. Үзе, башы-аягы белән дигәндәй, җир эшенә чумды, Хәсәнә абыстай хуҗабикәләр җилкәсенә төшә торган мең төрле мәшәкатьне үз җилкәсенә алды. Ә гомер дигәнең, җитез тулпардай, алга таба тиз җилә. Хәятнең гәүһәре дә, чүп-чары да бар. Тулпарга атланып җилдерсәң, гәүһәрен тотарга мөмкиндер. Аның аяк астында калсаң, зурга өмет итеп булмый. Үз давылы, үз каршылыклары, үз яңалыгы белән килгән егерменче гасыр зиһенле, мәгълүматлы, аң даирәсе киң булган мөгаллимнәр таләп итә. Сәетгали Сәлимов шундыйларның берсе булса кирәк. Авыл халкы аны инсафлылыгы, тәртибе, балаларны яхшы укытуы өчен яратты. Ул хәтта зурларга да кулыннан килгән кадәр белем бирергә тырыша. Гыйрфан мулла үзе дә шулай иде бит. Гәрчә мәктәп ачып укытмаса да, күпме авыл кешесен хәреф танырга, аны кәгазьгә төшерергә өйрәтте. Агыйдел бер атлам киңлектәге инештән зураеп киткән шикелле, адәм баласы бер аваз-хәрефне кәгазьгә төшерүдән барып чыга фән дәрьясына. Шундый ук белем башлангычын Хәсәнә абыстай йомык чәчәктән ачылырга ярсыган кызларга бирде. Шушы сыйфатлар якынайтты бу гаиләнең Сәлимов мөгаллим белән булган мөнәсәбәтен. Ул еш килә торган булып китте бу гаиләгә. Килгән саен, телиләрме алар моны, юкмы, сүз гел генә уку-укыту мәсьәләләре турында бара. Сәлимов шактый белемле, зыялы булса да, үзен һәрвакыт гади тота.

Ике мәртәбә барып кайтты мөгаллим Уфага. Берсендә Хәсәнә абыстай соңгы казын биреп җибәрде хәтта. Аны алмаска, кем әйтмешли, теше-тырнагы белән каршы торды мөгаллим:

— Соң, абыстай, әллә белмисеңме бу казның хәзер күпме торганлыгын, калада халык бер сынык икмәккә тилмереп яши ләбаса, — диде ул.

Абыстай чарага куймады:

— Беләм, балакаем, беләм, барын да аңлап торам, Галимҗаным өчен җаным да җәл түгел, аны дәвалаган духтырга бирерсең. Тик әйт, нык карасын, савыктырмый калмасын. Кирәк икән, соңгы сыерымны да кызганмам...

Галимҗанны март башында барып алып кайта мөгаллим. Аларның дуслык җебе яңадан нык төйнәлеп китте. Элеккечә, ягъни Гыйрфан карт бар чагындагыча, Сәетгали, һәр буш вакыттан файдаланып, аларга килеп чыгарга тырышты. Уку-укыту, мөгаллимлек итү мәсьәләсендә, әлбәттә, Галимҗан әтисеннән күп өстен тора. Ул Сәетгали мөгаллимгә нугай һәм казакъ балаларын, Киевта татар улларын, кызларын ничек укытуы, нинди авырлыклар кичерүе, бу эшкә мөкиббән бирелеп килүе турында сөйли.

Сәетгали мөгаллим колак салып тыңлый. Аның игътибарлы булуы, үз эшенә җитди каравы, мәгърифәт нуры белән кешеләр күңелен яктырту нияте белән яшәве, гадилеге, кешелеклелеге нык ошый Галимҗанга. Чибәрлекне Ходай берникадәр кызганган аннан. Бәләкәй бакыр йөзен тукмак танавы ямсезләп тора кебек. Кыска буй да ирлек гаярьлеген бернитиклем киметә шикелле. Әмма фикерне мәсьәләнең мөгезенә карап йөртергә кирәктер. "Кыска буйлының акылы озын булыр", — ди халык.

Акылы бар моның. Төпле фикер йөртә белә. Мәгәр эчке дөньясы матур мөгаллимнең. Рухы нык. Кешелеклелек сыйфатларын югары тота белә. Алаптай авызын колагынача ерып, көлеп җибәрсә, бөтен кайгыларың таралып киткәндәй була. Анынча ихлас, чын йөрәктән, матур итеп теләсә кем көлә белмидер әле ул. Уфа шифаханәсенә илтеп куйды. Кайтырга кирәк булганда килеп алды. Шул арада ике мәртәбә хәлен белер өчен генә махсус килеп китте бит әле ул. Солтанмораттан Уфага бер килеп әйләнүгә ике көн кирәк. Димәк, сигез тәүлек вакытын әрәм иткән аның өчен. Моны теләсә кем эшли алмый. Аңа олы йөрәкле була белергә кирәк.

Галимҗанның бүгенге язмышын хәл иткәндә дә мөгаллимлекнең чын йөзен күрсәтә белде ул. Шифаханәдән кайтып бераз торгач, Габделхәкимне дә алдылар сугышка. Галимҗанның ике аягы туган авылында булса да, һаман әле бер күзе Казанга, икенчесе Уфага карап тора. “Казакъ кызы” романы югалды инде. Киев каласы жандармериясе кәгазьләре астында исраф булып ятадыр ул хәзер. Утта яндырып, көлен күккә очырмаган булсалар. Ә менә Казандагы “Гасыр” басмаханәсендәге “Безнең көннәр” романы ни хәлдә икән? Хат язып салу да, барып кайту да әллә ни файда бирмәячәк. Әсәрне язу бер авырлык булса, аны бастырып чыгару тагын да кыенрак. Шуңа күрә Казанның үзенә барып яшәү хәерлерәк булыр. Бу фараз итүләр дә нәтиҗәле түгел. Чөнки дөньяны хәзер карт әнисе берүзе көтә...

Киту-китмәү фикере уртасына Сәетгали мөгаллим килеп керде. Ул болай диде:

— Галимҗан абый! Дөньялар бик авырайды. Сугыш пыран-заран китерде барысын да. Хәсәнә абыстай бик йөнчү. Ул аны кешеләргә дә, сиңа да сиздермәскә генә тырыша. Бу инде аның сабырлыгына бәйләнгән. Син хәзер бөек кеше. Акыл өйрәтеп маташу бер ахмаклык кынадыр. Ә шулай да бер олыныкын, бер кеченекен тыңларга кушалар бит...

— Тыңладык. Калырга өндисең.

— Әйе. Үзең дә бик хәлсез бит әле. Көчкә тын аласың. Ютәллисең. Бу җәйне авылда үткәрү файдалы булыр сиңа. Соңыннан үзең үк миңа рәхмәт әйтерсең.

Галимҗан аның кулын кысты!

— Җиндең, мөгаллим! Рәхмәтне хәзер үк әйтәм сиңа! Кылган игелекләрең, акыллы киңәшең өчен рәхмәт.

## VI

Язгы чәчүгә чаклы аякка ныклап басты Галимҗан. Әнисенең әле оны да, ите дә, бәрәңгесе дә бар иде. Галимҗанны нык тәрбияләде ул. Яшь баладай күреп тәрбияләде. Авылның саф һавасы, кыр эше, су коену, балык тоту, урманнарда, болыннарда йөрү, кыскасы, табигать-бабайның һәр ягымлы карашы аның йөрәгенә шифа булып ятты. Әнисе дә берникадәр җинел сулыш ала башлады.

Күзен Галимҗанның бер күзе янә Уфага, икенчесе Казанга карый башлады. Казанга барырга, шунда яшәргә кирәк, билгеле. “Безнең көннәр” романын ничек тә чыгару ягын карау котылгысыз. Шулай да әнисен ташлап китүне килештермәде ул. Уфа ерак ара түгел. Кайтыр да килер.

Менә октябрь башланды. Яшел киемен сала табигать. Хәзер ул чуар бишмәт кия. Яшеллек күңелгә яшьлек дәрте бирә иде. Чуары сине әллә нинди моңсу тойгыларга сала.

Уфага килгәч, Галимҗан, гадәттәгечә, фатир өчен чибәр йорт эзләмәде. Шулай да Казандагы “йомран оясы”ннан яхшыраκны тапты ул.

Галимҗан Ибраһимовны теге вакытта үзе укыган “Галия” мәдрәсәсенә мөгаллимлеккә чакырдылар. Зыяэддин әл-Камали әфәнде ишеткән дә аның килүен, ике шәкертен җибәргән.

Ләкин алар бик күңелсез вакытта очрашты. Галимҗан аның бүлмәсенә килеп кергәндә, Зыя Камали җәнаблары бер шәкертне шелтәле сүзләр белән "сыйлый" иде. Зыя әфәнде өстәл артындагы утыргычта утыра. Шәкерт исә аның алдында басып тора. Ул килеп керү белән, урыныннан кузгалып, аңа таба атламакчы булган иде Зыя Камали, ләкин күз карашлары, куллары белән ым кагып, көтеп торачагын аңлатты Галимҗан: шәкерт кешене кимсетергә ярамый, янәсе. Аңлады Зыя Камали Галимҗанның "ым"ын. Хәзер инде ул шәкерткә соңгы сүзен әйтергә ашыкты:

— Олы яшьтә булуыңа карамастан, гәрчә белем дәрәҗәң бик сай икәнлек безне борчыса да, укуга зур теләгең барлыкны искә алып, бик икеләнеп кабул иткән идек үзеңне мәдрәсәгә, әмма ләкин ашаган табагыңа төкерә торган кеше булып чыктың. Инде мәдрәсә хакимиятенең карары бер генә, бүген "Галия"дә соңгы көнең...

Зыя Камали, элеккечә, һаман йомшак, ашыкмый, нәзакәт белән сөйләшә икән. Бер шәкертне мәдрәсәдән куа. Димәк, ул низам яки тәртип кагыйдәләрен бозган. Шулай да, Оренбурдагы кадим мәдрәсә башлыгы Вәли мулла кебек, ертылыр чиккә җитеп акырынмый-бакырынмый, китәсе кешенең күңелен китеп җибәрмим дигәндәй, бик сак кылана, сүзләрен чамалап әйтә. Ә инде шәкерт мәдрәсә белән хушлашуны бик авыр кичерә, күрәсең. Һаман чыгып китми. Остазы алдында каккан казыктай селкенмичә басып тик тора. Бераздан ул сүз сорады:

— Мөхтәрәм Зыя әл-Камали җәнаблары! Бер сөаль бирергә мөмкинме?

— Тик ул соңгысы булсын.

— Җарай. Суңгысы. Сез мине мәдрәсәдән шул иблис тукымы Бәкерйән әләкләгәнне чынга алып куасыгызмы?

— Мондый сорау бирергә хакың юк.

— Бар, Зыя әфәнде! Ике җаклы пычак мине генә төгел, кирәк икән, атасын, анасын, сезне дә сатарга мужыт. Паразит!.. Ух, мин аны! Иманы бугазына сөяк булып кадалгыры...

Аның әдәби телдә сөйләшмәве, авазларны дөрес әйтмәве, җитмәсә, урыс телендә сүгенүе Галимҗанның исен китәрде. Моның өчен Зыя әфәнде дә бик нык уңайсызланды:

— Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел дигәнне ишеткәнең бардыр, Сәрвәретдин, син бит әле минем күз алдымда әллә нинди биздергеч сүзләр әйтәсең, сүгенәсең, мәдрәсә ямен җибәрү була бит бу...

— Сез ул Султанмурат хәшәрәте Бәкерйән дигән мәкерле җөрәкнең кем икәнлеген белмисез шул... Сволочь ул... Козел... Ух!.. Иманы тутыккан нәмәкәй...

"Солтанморат" сүзен ишеткәч, Галимҗан аптырап калды. Монда бит Мөбахис мәзин малае Бәкерҗан турында бара гәп. Куылырга тиешле шәкертнең дә тавышыннан кем икәнлеген чамалап алды ул. Бу — Миасның җиз эретү заводында бергә эшләгән "Зобани" кушаматы белән йөртелгән Сәрвәретдин лабаса! Нишләп килеп эләккән ул монда? Һаман элеккечә сүгенә икән әле үзе. Зыя Камали:

— Бушатыгыз бүлмәне, күрмисеңмени кунакны, кеше алдында легатькә килмәгән сүзләр әйтәсең, — дигәч, Сәрвәретдин Галимҗанга таба борылды. Һәм:

— Галимҗан... Ибраһимов... дип, үз туганына ташлангандай, аны кочаклап ук алды.

Бу күренешкә ни дип бәһа бирергә дә белмәгән Зыя Камали.

— Сез туганнар түгелдер бит? — дип сорарга мәҗбүр булды.

— Шулайрак, — диде дә Галимҗан, сүзне икенчегә борды:

— Сәрвәретдин хәзергә чыгып торсын, Зыя әфәнде, әмма аны куарга ашыкмаска кирәк.

Икесе генә калгач, ниһаять, алар кочаклашып күрештеләр. Шулай да кочакларда бер-берсенә булган тойгы кайнарлыгы әллә ни нык сизелмәде. Аның нигә шулай икәнлеген аңлау да кыен. Теге вакытта

Галимҗан мәдрәсәдән куылганда Зыя әфәнденең йомшаклык күрсәтү галәмәте сәбәбеме бу? Әллә әле генә менә Галимҗанның: "Аны куарга ашыкмаска кирәк", — дип әйтү кәсафәтеме? Болай дияргә аның ни хакы бар? Әле бит аның, кем әйтмешли, башы — тышта, аягы эчтә чагы гына. Ә инде үзен хуҗа дәрәҗәсенә куярга маташа түгелме соң?

Акыллы кешенең кочагын мондый вак-төяк имеш-мимеш уйлар гына суыта алмый, әлбәттә. Алар икесе дә сүзгә саран кеше. Шулай да, очрашкач, бер-беренә илтифатлы булу мотлак. Илтифатлылык әүвәл күз карашлары белән алышынды. Зыя әфәнденең йөзендә әллә ни үзгәреш юк кебек. Шул ук бөтерелгән очлары өскә таба күтәрелеп торган карлыгач канатыдай кара мыек. Сабыр йөз. Сөйкемле караш. Әмма тормыш ул сабырлыкка берникадәр кырыслык чаткылары да сипкән төсле. Сөйкемле карашларда хәзер нык җитдилек сизелә. Аларга олыгаю шәүләсе дә сенә башлаган. Ә инде уптым-илаһи алганда, аның кабилиятле шәхес икәнлеген бөтен кыяфәте күрсәтеп тора.

Зыя әл-Камали галиҗәнаблары да Галимҗанда шактый үзгәреш барлыкны анлады. Теге вакытта, 1908 елда мәдрәсдән киткәндә, егетҗилән чагы икәнлек бөтен гәүдәсендә, йөзендә, елмаюында сизелеп тора иде... Аннан соң җиде ел үтеп киткән икән шул инде. Күпме җилләр исеп, күпме сулар аккан.

— Без болай итик, Галимҗан әфәнде, чәйләп алыйк, сез дә сусагансыздыр, мин хәзер әйләнеп килермен, — диде дә Зыя Камали, җәһәт кенә чыгып китте.

Зыя әл-Камали галиҗәнабларының чыгып китүе булды, Сәрвәретдин кире атылып килеп керде. Сизә Галимҗан: аның сөйләр сүзе күп. Ләкин ашыга — аңлашыла: ул Зыя әфәнденең күзенә янадан күренергә курка. Чөнки аңа хәзер монда керергә ярамый.

— Менә нәрсә, Сәрвәретдин дус, күреп торам, сөйләшәсең килә. Әйдә моны, булмаса, башка вакытка калдырмыйк, — диде Галимҗан.

Сәрвәретдин җанланып китте:

— И-и-х, Галимҗан агай, әллә әүлияме син? Сөйләшәсе килү генә дисең... Эчем тулы ут минем... Менә... чукынып китим... "Ор, ор да койрыгын бур", ди турганыйы атай карт... Мин ул авылдашың мәкерле йән Бәкерйәннең койрыгын бурып... ишәк итеп бакыртам әле!

— Тукта әле, Сәрвәретдин, нигә болай кызасың әле?

— Мине алып кал, Галимҗан агай... әй лә, әфәнде... әй лә гали... гали... җәнәп...

— Мин сине алып калалмыйм, Сәрвәретдин. Беренчедән, сүзләрне әдәби телдәгечә әйтергә дә өйрәнмәгәнсең —"турганыйы" түгел, "торган иде", "бурып" түгел, "борып". Әйт шулай дип.

— "Бырып", "тырганыйы"...

Галимҗан көлеп җибәрде:

— Теленне чукисе бар.

— Чүке. Игәүлә. Чарла. Тик алып кал мине...

— Мин сүгенгән кешене яратмыйм.

— Моннан соң алама сүз әйтсәм... Сабакы булыйм... богазыма пычак керсен... Галимҗан... әфәнде... Тик алып кына кал...

— "Ачкорсак" "Зобанига" ярдәм итә алырмы?

Сәрвәретдин кычкырып көлеп җибәрде:

— Онытмагансың, әй! Миасны искә төшердең.

— Ярый, алып калырмын. Тик ике шарт белән: сүгенүеңне ташлыйсың, әдәби телдә сөйләшергә өйрәнәсең. Аллага тапшырдык!

— Аллага ышан, дилбегәнне үзең тот...

Тышта аяк тавышы ишетелде. Сәрвәретдин, селәүсендәй җиңел сикереп, ишекне ачып чыгып китте дә зымзыя юк булды.

* * *

Бүлмәгә Зыя Камали түгел, ашамлыклар тулы поднос күтәргән унбиш яшьләр чамалы бер чибәр кыз килеп керде. Кулындагысын өстәлгә куйгач, Галимҗанга өздереп бер карап алды да, нәзакәтле генә елмаеп, чыгып та китте. Бусы янә бер яңалык. Татар кызлары йөз яшерми башлаган. Елмаеп карау гына түгел, күзен берникадәр уйнатты да шикелле әле. Анда бер гөнаһ та юк, әлбәттә. Күзләре зәңгәр иде бугай. Ул зәңгәрлектә наз, моң, хис... — тагы да әллә ниләр сирпелгәне сизелде. Аның ак йөзендә йөрәк төпкеленнән үк бәреп чыккан гыйффәтлелек гәүһәреннән башка бернәрсә дә юк кебек. Ак калфагы нинди килешә үзенә! Зәңгәрсу күлмәк өстеннән бәйләгән ак алъяпкыч! Ә йөреше?! Аккошмыни! Биле тагын! Өзелеп китәргә torгандай. Буй — уртача. Озын да, кыска да түгел. Гәүдәсен ул уйнатмый. Шулай да сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә генә дулкынландырып ала. Бусы әллә табигый халәте, әллә янә дә матуррак күренергә тырышу галәмәте? Анысы инде аның үзенә, дәхи дә бер Ходайга гына мәгълүм. Әмма ул сылу гәүдәдә барыбер мөселман кызларына хас иплелек, әдәплелек, илтифатлылык сыйфаты күзгә бәрелеп тора әле.

Бераздан кыз янә әйләнеп керде. Бу юлы аның кулында бик матур ак чәйнек иде. Аны өстәлдә калдырып, чигүле чүәк кигән нәфис аяклары белән һаман шулай аккоштай йомшак кына басып, иплe генә адымнар белән чыгып китте. Галимҗан аның тагын бер мәртәбә көйдереп каравын теләгән иде. Ләкин кыз, бу юлы нигәдер зәңгәр күзләренең нурын аңа бүләк итмәде.

* * *

— Озак көттердемме? Эш, эш, эш... — дип, килеп керде Зыя әфәнде. Галимҗан шаярыбрак сөйләшергә тырышты:

— Зарар юк, Зыя әфәнде! Мин әле монда сез юкта рухымны туйдырдым. Матурлык белән очраштым. Минем чибәр кызлар яратканны белдегезме? Шуңа күрә күрсәттегезме бу асыл затны?

Зыя әфәнде елмаеп куйды:

— Аның акылы да матур!.. Йә, утырышыйк әле... Әйдә... Менә кайнар вак бәлеш... Суынганчы рәхим итегез... Чәкчәк... Бу әле болай гына... Кичен безгә ашка барырбыз, Алла боерса!

## VII

Чәй эчкәндә сүз күбрәк Галимҗан Ибраһимовның 1908 елда "Галия" мәдрәсәсеннән киткәннән соң булган "маҗаралары" турында барды.

"Галия"дә хәзер тел, әдәбият, тарих, җәгърәфия, мантыйк, хисап, һәндәсә, фәлсәфә, сарыф, нәхү, лөгат, ысулы тәгълим, рәсем һәм җыр сәнгате кебек фәннәр укытыла. Ул инде хәзер милли институт дәрәҗәсенә күтәрелеп килә. Тик "Мәдрәсәи галия диния" дип йөртү мәгъкуль күрелә. Чөнки мәдрәсә шәһәрнең дин әһелләре, байлар иганәсенә төзелде. Бу иганәлек әле һаман дәвам итә. Иганәчеләр һаман әле шәкертләрнең аң даирәсен дин тәгълиматлары белән генә "агартмакчы". Алар инсаниятә ак нур бирүче, дөньяны җаһиллектән коткарырга тиешле, матур хәят төзүгә ярдәм итүче фәннәрне укытуга, кем әйтмешли, теш-тырнаклары белән каршы. Байның колы булганчы, этнең улы бул, дисәләр дә, вакытлыча шәһәрнең черегән байларына кол булырга да туры килә шул. Шунсыз мәдрәсәне тотып булмый. Тик

мөгаллимнәр дә, ысулы тәгълимнәр дә житешми. Шул җәһәттән Галимҗанның "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре", "Мәктәптә әдәбият", "Яңа әдәбият", "Татар сарыфы", "Татар нәхүе" кебек хезмәтләре шәкертләр кулыннан төшми диярлек. 1911 елда иҗат ителгән "Татар сарыфы", "Татар нәхүе" кебек грамматика китаплары исә ел саен диярлек кат-кат басылып тора. Әмма аларны ныклап укыта белүче генә юк. Әгәр Галимҗан үз кулы, үз акылы, үз белеме белән язган китаплары буенча дәрес үткәрсә, бәһаләп бетергесез хәл булачак бит бу.

Бизмәнгә салып карасаң, Галимҗан өчен күңелсез яклар күбрәк икән шул. "Казакъ кызы" романын Киевтан аңа җибәрмәделәр. Махсус барып сораса да бирмәделәр. Аннан Казанда чыга торган "Аң" журналының сәркәтибе булып эшли башлый. Шулай да бу хезмәткә күңелен нык беркетә алмый ул. Беренчедән, әдәбият-сәнгатьне яктырту белән генә чикләнмәскә, "Аң"ны тамырыннан үзгәртеп, сәяси, фәлсәфи, иҗтимагый хәлләр турында да язу мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Ләкин патша хөкүмәте андый нәрсәләргә рөхсәт бирәме соң. "Мин Казанда шул мәгълүм мохитта тора алмыйм. Казан үзенең Печән базары, Болагы, Балык базары белән, аннан бигрәк тә эшсез, имансыз, фасикъ яшьләре, баштанаяк мәгънәсез интригалар эчендә чорналып беткән "Хадиме милләт"ләре белән мине гаҗәп туйдырды. Теге елны, гаҗиз булгач, Киевка киткән идем. Бер ел үтте, Казанның биргән начар тәэсире йөрәктән чыкты — Гәрәйнең* яңа чакыруын кабул итә бирдем. Ләкин Казан һаман шул Казан, яше, хадимнәр һаман шул иде. "Аң"ны ташлауны мин кызгандым, ләкин Казанда торуның имкяны калмагач, һәр кеше чишә алмас хисне өздем дә — вәссәлам", — дип язган иде бер хатында Галимҗан Ибраһимов Хөсни Кәримгә.

Икенчедән, Галимҗан тулысы белән иҗат дәрьясына чумарга була. Шул ният белән ул Сухумига "Безнең көннәр" романын язарга китә. Ләкин әлеге Киев вакыйгасыннан соң аны жандармерия һәрвакыт күзәтеп тора. Бу хакта туган авылы Солтанморатка да хәбәр ителә. Сухумида чакта да Киев губерна жандарм идарәсе начальнигы Казанга болай дип яза: "Сезгә билгеле булган Галимжан Гыйрфанович Ибраһимов, күзәтү буенча "Интеллигентный" кушаматлы, мартның 11 ендә Киевтан Одессага күзәтүсез китте. Аның өстеннән тышкы күзәтү оештыру өчен шул ук числода бу хакта Одесса шәһәре жандарм идарәсе начальнигына хәбәр ителде"**

"Безнең көннәр" романы дүрт ай эчендә языла. Көн-төн эшли әдип. Шулай да ул арымый. Матур табигать, яшеллеккә күмелгән биек-биек мәһабәт таулар, дингез һавасы аның күңеленә хуш килә. Казанга кайту белән ул "Безнең көннәр"не "Гасыр" нәшриятына тапшыра. Роман шундук басыла да башлый. Ләкин 1905 елгы революция давылларын чагылдырган әсәр озак та үтми тыела.

Галимҗан шулар хакында хәбәр кылгач, Зыя әфәнде Камали, бик үкенечле йөз күрсәтеп:

— Димәк, "Казакъ кызы" да, "Безнең көннәр" дә бәхетсезлеккә очрады? — дип сорады.

Галимҗан мондый сорауга Галиәсгар Камалга: "Бәхет бит ул зимагур акчасы белән бер — табыла да, бетә дә" кебегрәк сүзләр белән җавап биргәнлеген хәтерләде. Ә менә Зыя әфәндегә ничегрәк килештереп әйтергә кирәк? Шуны уйлап, сүз энәсен шаянлыкка борырга булды ул:

— Бәхет, Зыя әл-Камали галиҗәнаплары, менә бу безгә чәй

*Гәрәй — "Аң" журналы мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни.
**Болар Мансур Хәсәновның "Галимҗан Ибраһимов" исемле әсәреннән алынды (Казан, 1964, 85 бит).

табыны әзерләгән кыз кебек бит ул: табыла да, югала да.

Зыя әфәнде елмаеп куйды:

— Сиңа кызлар җене кагылган. Утызга җитеп киләсең түгелме? Өйләнергә вакыттыр, шәт? Ә?!

Галимҗан һаман шаяртырга тырышты:

— Сез бу хосуста әмернамә язарсыз, бәлки, Зыя әфәнде?

Зыя Камали да шаярыбрак сөйләште:

— Мотлакан, язачакмын. Тик тәртибең ничек булыр бит?

— Тәртип тәртә кебегрәк бит ул, Зыя әфәнде, кая борсаң, шунда бара.

— Син һаман шулай элеккечә усал сөйләшәсең.

— Килешеп эшли алмаудан шүрләмисездер бит?

— Мине тормыш күп куркытты инде, туганкай!

— Бу яктан икебез дә "бәхетле".

— Иштә, авырлыкны җинә белү дә бәхет!

— Шан-шәрәфләр булсын, Зыя әфәнде! Мин сезнең ихтыярыгызда. Тик...

— Нәрсә: "Тик?"

— Менә бу Сәрвәретдин "әфәнде"не кумаска кирәк.

— "Әфәнде" түгел ул, "әтрәк әләм".

— Ул, барыннан да бигрәк, Кеше!

— Мөгаллим һәм язучының кеше язмышы өчен көрәшүен аңлыйм мин, ләкин...

— "Ләкин" — каршылык тудыручы ярдәмлек ул.

— Без читләшәбез шикелле.

Шуннан Галимҗан "Зобани" кушаматлы бу Сәрвәретдин белән Миас җиз өретү заводында бергә эшләве, башта үзеннән нык көлүе, хәтта мыскыл итүе, соңыннан дуслашып китүе, аларны укырга-язарга өйрәтүе турында кыскача гына сөйләп бирде дә аны бирегә нинди язмыш-лар китереп ташлау, мәдрәсәгә ничек кабул ителү сәбәбен сорашты.

Мәсьәлә болай тора икән. Сәрвәретдин мәдрәсәгә укырга дип килгән. Ләкин ул берәр эш сорый. Монысына каршы килми Зыя Камали. Аны хуҗалык эшләре җитәкчесе итеп куя. Нык эшли. Рыясыз. Көн-төн дип тормый. Бер үк вакытта уку белән дә шөгыльләнә. Белемгә булган ихлас теләген искә алып, аңа "ирекле тыңлаучы" сыйфатында укырга рөхсәт ителә. Аннан, бик тә инде үтенеп сорагач, чын шәкерт чапаны кидереп куялар үзенә. Ләкин кәҗәне кәүсәр күлендә юындырып тәхеткә мендереп куйсаң да, кәҗә булып калган кебек, аннан әдәпле шәкерт чыкмаган. Сүгенүе, сөйләшә белмәве генә җитмәгән, мәрүскәләр янында иснәнеп йөри, тарта, эчә башлаган.

Зыя Камалиның туры сүзле, алдашмый торган зат, ихлас күңелле, уйлап сөйләүче булуын белә Галимҗан. Сәрвәретдин турында әйткәннәрнең һәммәсенә дә ышанды ул. Зимагурлар арасында канга сеңгән алама гадәтләрне кырып ташлау өчен үткер пычак кына түгел, көчле ихтыяр да кирәк шул. Бармы алар "Зобани"да? Бусын тәгаен генә әйтә алмый әле. "Теле пычракның күңеле пычрак", — дигәнне ишеткәне бар Галимҗанның. Андый пычрак юшкыны да кайнап утырган "Зобани" күңеленә. Моны кырып ташлау өчен чәч ала торган үткер пычак кына җитмидер әле. Акыллы башларның кылычтан үткер теле кирәктер. Бөтен Русия наданлык-ның кара чапанына төренгән. Һаман шулай: "Аш дигәндә — җан-фәрман, эш дигәндә — юк дәрман", — дип яшәргә тиешбезме? Нигә бай балаларын гына укытырга? Бөтен Русия халкына кирәк мәгърифәт. Егерменче гасыр лабаса. Мондый кап-караңгы илдә башкача яшәү мөмкин түгел бит. Агарырга кирәк! Агарырга!! Агарырга!!! "Зобани" кебекләрдән куркырга ярамый. Бөтен кеше дә коеп куйган коймак булалмый ич. Төерле коймак — камырны иренеп туглаудан ул. Шәкерт эчендәге кара төерне кем туглап бетерергә

тиеш? Мөдәррис, әлбәттә. Мөгаллим. Укытучы. Хәлфә. Укытучының бөтен мөмтазлыгы шунда лабаса. "Һайт" дигәндә "тайт" итеп торучы, тәрбияле вә сәләтле шәкертләр белән эш итү җиңел ул. Ә менә "Зобани" кебекләрнең күңел кылына чиртә белү өчен икеләтә осталык, маһирлык, сабырлык кирәк.

— Минем сүзләр йомырканың тавыкны өйрәткәне кебек булмасын, Зыя әфәнде! Сәрвәретдин шәкертне кумасагыз иде, аны үз тәрбиямә алырга сүз бирәм, — диде Галимҗан.

Бу сүзләрне йомшак кына әйтсә дә, Галимҗанның катылыгын белә Зыя Камали. Ничек кенә булмасын, Галимҗанны ул хөрмәт итә. Дөресен генә әйткәндә, теге вакытта куылмады ул "Галия" мәдрәсәсеннән. Әгәр аны кусаң, күп шәкертләр ияреп китә иде аның артыннан. Зыя Камали аңа киләсе уку елында "Галия"гә аяк басмаска тиешлек турында гына әйтте. Аңлады Галимҗан мәсьәләне. Һич тә ачу-кочу белдермичә китте. Ә менә хәзер нишләргә? Галимҗан, билгеле, тагы да әллә нинди мөгезләр чыгара башлаячак. Түз генә.

— Ярый, тап алайса ул "дустыңның" кара төерендәге гәүһәрне...

Моның өчен Галимҗан Зыя әфәндегә рәхмәт әйтте. Әмма бер кисәтү ясарга да онытмады:

— Мин бит, Зыя әфәнде, һаман әле жандармерия күзәтүендә яшим. Берәр вакыт тагын да авырлык китермәммме сезгә?

Зыя Камали бу юлы коры гына әйтте:

— Мин тормыштан җиңеллек эзләмим, Галимҗан әфәнде! Алла ярдәм итсен! Иртәгә үк эшкә!..

Шуның белән аларның сүзләре өзелде.

* * *

Икенче көнне үк эшкә чумды Галимҗан. Мөгаллимлек аңа ошый. Моның өчен иң әүвәл шәһадәтнамә алып, аннан соң дарелфөнүн тәмамлау иде бит теләге. Бу максатлар хәзер кояшка йотылган томан кебек кенә булып калды. Киев университетында ул профессорлар алдында фән буенча ничегрәк "сайрарга" кирәклекне өйрәнгән иде инде. "Галия" югары уку йортларыннан һич тә ким түгел. Барлык фәннәр диярлек укытыла. Монда инде, туганкай, син лекцияне профессор дәрәҗәсендә укырга тиешсең. Зур шатлык шул: тел-әдәбият буенча язган хезмәтләренең ни дәрәҗәдә үтемле икәнлеген ул үзе сынап караячак.

Менә тагын бер каршылык. "Зобани", түшен алагаем киереп, мактанып йөри икән. Чирттеме ул Зыя Камали борынына, янәсе. Төкердеме әрем телле әләкче Бәкерҗаннар йөзенә! Галимҗан Ибраһимов ише бөек кеше бар хәзер аны яклаучы.

Бу "аяклы" хәбәр Зыя Камалига барып ишетелә. Зыя әфәнде аны Галимҗанга җиткерә. Галимҗан "Зобани"нең авызын йозакларга сүз бирә. Чакырып ала да бер кешесез бүлмәгә, суга җибәрә, суга җибәрә. Бу кадәресен эшләрмен дигән уй аның башында бөтенләй юк иде. Яхшылыкка яманлык чәчү нәфрәте шулай ярсытты аны. Сугуның сәбәбен әйткәч, "Зобани"нең үзеннән дә "сдача" көткән иде ул. Ләкин тегесе кул күтәрергә җөрьәт итмәде.

— Ярай, куыгыз алайса, байгышның оясын ходай кора, ди, табылыр әле берәр оя, — диде ул боек кына.

Галимҗан эндәшмәгәч, янә шуны әйтте:

— Атай мәрхүм әйтер иде: "Аягы пычрак — өй пычратыр, теле пычрак — кеше пычратыр", — диер иде. — Китәм моннан. Башым — кайда, сараем — шунда. Вәссәлам!

Галимҗанга ул кызганыч булып та тоелды. Шулай да юатып маташмады:

— Бар! Кит! Башың эзләгән сарайны тап! — диде дә, тып-тып басып, китеп барды. "Зобани"ның да жене кузгалды:

— Китәм! Китәм! Мине "Зобани", дисез. Ник күрмисез мәдрәсә эчендәге чын "зобаниларны?"

Аны җибәрәсе килми иде Галимҗанның. Кемдә юк китек-митек яклар? Галимҗанның үзендә юкмы? Үз шәкертенә кул күтәрче? Бу гөнаһ түгелме? Шулмы укытучы һөнәре? Монысы инде китек-митеклек кенә түгел. Нерв кылларының челпәрәмә килүе бу.

Кичен Галимҗан "Зобани" янына барды. Ул караватында бөгәрләнеп ята иде. Башкалар уку залына киткән, күрәсең.

Галимҗан сүзне сораудан башлады.

— Әллә авырыйсыңмы, Сәрвәретдин?

— Юк.

— Эченне тотып үрсәләнәсең түгелме?

— Болай гына.

— Яшермә.

Шуның белән аларның сүзләре өзелде. Аны Галимҗан үзе ялгап җибәрде: — Мин бая кызып киттем, Сәрвәретдин. Гафу ит.

— Үпкәм юк, Галимҗан абый... әфәнде... әй... мөгаллим... Шулай кирәк мин юньсезгә.

— Син китмә!.. Укырга теләгең зур ич...

Бу сүзләрне ишеткәч, торып ук утырды Сәрвәретдин. Арада бернинди дә кара күләгә булмагандай, алар янә сөйләшеп киттеләр. Галимҗан күңелсез хәлләрне оныттырырга теләп, Миас җиз эретү заводында бергә эшләгәннәр турында сорашуга күчте. Ләкин Галимҗан өчен шатланырдай бер генә хәбәр дә булмады. Теге урыслар тарафыннан тукмалган Нәҗип мантый алмаган, мәңгелек дөньяга күчкән. Моннан тыш янә әллә нинди фаҗигале хәлләр булган. Бер кышкы давыллы төндә әлеге иске барак җимерелеп, Нурислам абзыйның хәләл җефете Сабира җиңги ике баласы белән бергә һәлак булган. Күпләрне хастаханәгә тирән яра белән озатканнар. Үзе дә бер авыр бүрәнә астында сытылып калган Сәрвәретдин. Шуннан бирле авырудан башы чыкмый икән...

## VIII

"Галия" мәдрәсәсе төрки халыклар дөньясында мәгърифәт учагына әверелде. Бик күп милләт вәкилләре күңелен җылыта бу учак. Бер уйласаң, ифрат күңелле хәл. Шәехзадә Бабич анда 1913 елдан бирле инде "Парлак" дигән журнал чыгарып килә. Чиркәс шәкертләре исә "Ләгу", казакълар "Садак" исемле журнал чыгаралар. Башка милләт шәкертләре дә алардан өлге-үрнәк ала башлады. Милли хис ул адәм баласының күңеленә, йөрәгенә, бөтен тән күзәнәкләренә кērәзләнгән. Бу хис аны зурайта, олы итә, күккә күтәрә. Ә ул бик күп төрле хисләр уптым-илаһи бергә кушылса, ни нәрсә булыр икән? Аралашып, бербeрсенә сеңешеп, нәкышләнеп китә алырлармы? Менә шушы өстән караганда ифрат гади, ә чынында исә гаҗәп катлаулы, четерекле мәсьәләне аңламау нәтиҗәсендә купты бервакыт давыл. Һәр сандугач үз оясын мактап сайраган кебек, һәр шәкерт үз милләтен зурлап сөйли. Бу үзенчәлек шәкертләрнең телендә генә түгел, кульязма рәвешендә чыгарыла торган журналларында да чагыла башлады. Бер татар шәкерте казакъларның "Садак"ын ертып ыргыткан. Журналлар бер телдә генә чыгарылырга тиеш, янәсе. Шуннан "Галия" шәкертләре умарта күче урынына кайнаша башлый. Эш якалашуга барып җитә. Ходай сакласын, аннан да яманрагы булырга мөмкин.

Зыя Камали ашыгыч рәвештә җыелыш җыярга мәҗбүр була. Бу авыр мәсьәләне җиңеләйтеп аңлату кадәресен ул Галимҗан Ибраһимовка тапшыра. Чөнки бу өлкәдә ул махсус шөгыльләнә. Әледән-әле мәкаләләр

бастырып тора. Милли мәсьәлә ул — зур сәясәт. Шуна күрә сәясәттә аксарга ярамый.

Бу хакта шәкертләрне гаепләп тә булмый. Чөнки милли телгә, милли мәсьәләгә егерменче гасыр башында сыйнфыйлык күләгәсе төшә башлады. Кискен бәхәс купты. Әллә күпме ялгыш карашлар һаман әле яшәп килә. Телнең сафлыгы, төзеклеге, матурлыгы өчен ата-бабаларыбыз бик борынгы заманнарда ук көрәшкән. Бичара татар теленең тамырына балта белән гел чабып торалар. Әмма ул, бөтен дөнья авырлыгына үч итеп яшәгән үҗәт адәмдәй, башын һәрвакыт югары тотты. Бервакыт аны гарәп-фарсы сүзләре күмеп китә язды. Егерменче гасыр башында инде аларның аңлашылмаганы, көрәш мәйданында җинелгән солдат кебек, читкә тибәрелә башлады. Борынгы төрки телдән үк килгән сүзләр дә шулай. Хәзер инде телебезне урыс сүзләре дулкыны баса. Бәгъзе берәүләр барлык урыс сүзләрен алып ташлау ягында. Бу да дөрес түгел. Чама кирәк. Аннан соң телләрне берләштерергә кирәклек сәясәте калкып чыкты. Ислам динен тотучылар бер милләт булып оешырга тиеш, янәсе. Кайбер шәкертләр шушы фикер чапаны итәгенә нык тотына. Моның дөрес түгеллеген Галимҗан күңелен бик ерак тарихка ташлап аңлатты. Әйе, кардәш телләр бер чыганактан булган. Моның шулай икәнлеген ул тау сүзенә бәйләп аңлатты: татарча — тау, башкортча — тау, казакъча — тоу, үзбәкчә — то, кыргызча — тоо, уйгурча — та, чувашча — ту, якутча — тыа, төрекчә — тог, алтайча — тог. Димәк, бик борынгы тамырларда да фонетик төрлелекләр бар. Аннан төрки телләр (алар егермеләп) бер-берсеннән ераклаша-ераклаша бара. Кыпчак кабиләсеннән, әйтик, татар, башкорт, казакъ, кыргыз, каракалпак, кумык, нугай телләре үсеп чыга. Ә инде төрек, әзербайҗан, төрекмән, кырым татарлары теле угыз төркемен тәшкил итә. Менә кушып кара инде аларны хәзер. Ә бит кыпчак-болгарларга чаклы аланнар, сарматлар, хазарлар, шуннан, скифлар булган. Кайда алар? Юк инде. Комга сеңгән су кебек юк булганнар. Телнең кануны бар. Ул аерым шәхесләр акылына бирелми. Әгәр бүген җир йөзендә өч меннән артык тел бар икән, шуларны бер-берсенә һичкем куша алмый. Ә бит: "Татар теле — казакъ теле", "Казакъ теле — татар теле", "Үзбәк теле — уйгур теле", "Уйгур теле — үзбәк теле" дип тә язып чыктылар. Шул егермеләп төрки телне берләштереп, алардан бер тел ясау һәм шуны мәктәптә укыту кирәклек турында Галимҗан чыгышы-нын фәннилеген берникадәр йомшарту, тагы да ныграк гадиләштерү, хәтта җинелчә генә көлдереп алу өчен: "Тел ул беркемгә дә баш бирмәгән горур-чибәр кыз кебек", — дип куйды.

Ә инде тел төрлелеге укыту өчен шактый авырга туры килә. Хәтта бер милләт кешеләре телендә дә төрлелекләр күп. Хәсән Туфан, мәсәлән, "къ" авазын әйтә алмый. Аның гел йомшак "к" килеп чыга. Шәехзадә Бабич "ай", "әй" дифтонгларына бик юмарт. Сүз азагындагы "з" авазын да дөрес әйтми ул. Мишәр егете Шәйхелислам "хәл"не "халь" дип әйтә. Чиркәс Хаҗиморат, Хәсән Туфанның киресе буларак, йомшак "г" авазын каты "гъ" итеп әйтүчән. Себер татарлары арасыннан килгән Фатих Зәйни "з" урынына "с" авазы куллана: сүзем — сүсем. Казакъ Бәембәт Майлин телѐндә "ч" урынына "ш" өстенлек ала: очкын — ошкын.

Уртак грамматика булдыру да кыен, билгеле. Һәр милләт шәкерте өчен аерым грамматик кагыйдәләр дә чыгарып булмый. Җөмлә төзү, сүзләр куллану, тел төзеклеге үзенчәлегендә гомумирәк хосусият белән дә эш итәргә туры килә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген, сәнгатьчә эшләнешен, зәвыклылык дәрәҗәсен, эстетик сыйфатын аңлау өчен дә һәр шәкертнең күңел даирәсен бер офыккарак юнәлтергә кирәк була. Бер кәүсә әллә никадәр ботакларны тотып тора ич. Ботакларны — тел төрлелеге, кәүсәне аларның күңеле дип хис итик. Шуннан Галимҗан:

“Телләре башка булса да, күңелләре бер”, — дигән мәкалә язарга мәҗбүр булды. “Телләр, әдәбиятлар үзең теләгәнчә ясалмый. Алар хәят рухыннан ихтыярсыз килеп туа. Кемнәрнеңдер фикере, хезмәте бу мәсьәләгә диңгез дулкынында өскә күтәрелгән күбекләр генәдер”, — диде ул.

Телләр төрлелегә акыл, күңел, йөрәк берлегенә һич тә комачауламау турында әйтте Галимҗан. Моны ул ил эчендә канат җәйгән сәяси хәлләргә бәйләп аңлатты. Каюм Насыйри бабабыз унтугызынчы гасыр азакларында татар телендә “Таң йолдызы” дигән гәзитә чыгарырга җан атып йөри. Ләкин патша хөкүмәте рөхсәт итми. Ярый, 1905 елгы инкыйлаб давылы ил тәхетендә утыручы түрәләргә милли тойгылар белән шаярырга ярамаганлыкны шактый нык искәртте. Фатих Әмирхан әфәнде, җиң сызганып дигәндәй, “Әльислах”ны чыгара башлады. Әмма халык йөрәгендә кайнаганнарны рәхәтләнеп язарга рөхсәт юк. Фатих әфәнде демократия турында йөрәк кага башлагач, яптылар да куйдылар “Әльислах”ны. Шулар хакында җайлап-җайлап сөйләгәч, сүзенең тәртә очын пайтәхет оясындагы түрәләргә китереп терәде ул. Илнең кара пәрдә, наданлык сөреме белән каплануы, милли телләр үсешенә ирек бирелмәү турында әрнеп сөйләде. Ак хакыйкатьнең әлеге кара пәрдә ертылгач кына табылуы, моның өчен инкыйлаб кирәк булу хакында әйтте.

Зыя Камали башта Галимҗан Ибраһимовның җай, белеп, тотанаклы сөйләвенә, мантыйк дилбегәсен кулында нык тота алуына, һәр нәрсәне тамырыннан башлап очынача житди алып чыгу осталыгына ихлас шатланып утырган иде. Ә инде тел төбе революция мәсьәләсенә килеп терәлгәч, аның йөзенә кара коелды. Галимҗан моны шәйләп алды. Чөнки ул авыр, шиклерәк сүз әйтсә, Зыя әфәндегә күз сирпеп алырга һич онытмый. Ул моңа нинди бәя бирә, янәсе... “Галия” хакимияте башлыгы йөзендәге кара күләгә залда утырган башка бәгъзе бер шәкертләргә дә тәэсир иткәнлекне сизми калмады Галимҗан. Чөнки аларның да йөзе ачы торма капкан кешенекедәй чытылды. Шулай да андыйлар азчылыкны тәшкил итә. Күпләрнең чыраенда: “Дөрес, без дә шулай уйлыйбыз, һәр караңгы төннең бер якты көне буларга тиеш”, “— дигән тойгылар чаткысын күрү һич тә кыен түгел иде.

Җыелыштан соң Зыя Камали Галимҗан белән махсус сөйләшергә булды. Болай иплэп кенә әйтте ул:

— Сине өйрәтәсе юк инде, Галимҗан әфәнде, артык сүзнең аркага таяк булып төшкәнлеген беләсең.

— Әмма ул таяк арканы гына түгел, башыбызны, аягыбызны дөмбәсләп бара лабаса инде.

— Курыкма, башсыз да калмабыз, аяктан да егылмабыз.

— Минем куркак түгеллек сезгә күптән мәгълүм бит инде, Зыя әфәнде.

— Урынсыз батырлыкның ахмаклык икәнлеген дә аңларга кирәк.

— Мин коры батырлык күрсәтергә маташучымы?

— Син әллә кая борма әле.

— Димәк, сабыр төбеннән сары алтын көтеп ятыйк. Тукай әйтмешли, сабыр төбеннән сары алтын түгел, сары бәрәңге дә чыкмый ич.

— Аңлыйм сине, инкыйлаб кирәк. Әгәр була калса, үзең үк аның утына сикерергә торасың.

— Башкача болай яшәү мөмкин түгел бит инде.

— Мин нәкъ синеңчә уйлыйм, Галимҗан әфәнде! Шәкертләр арасында шымчылар да бар. Алар ялланып куелган. Бернәрсә булса, тышкы дөньяга чәчәләр. Аннан соң иганә бирүчеләр якадан ала. Мин дә: “Ил көенгәнгә көен, ил сөенгәнгә сөен”, — дип яшәүче. Әшебез ил, халык өчен! Мәдрәсәне нинди авырлыклар белән ачканны беләсез. Аны яшәтергә кирәк...

— Без һаман шулай тынышып эшли алмабыз кебек, Зыя әфәнде! Миңа моннан тагын да китәргә кирәктер.

Зыя Камали эндәшмәде.

## IX

Әмма китмәде Галимҗан "Галия"дән. Биредә шәхси фикерләрне өскә кую, ык-мык килеп яшәү, бер дә юкка сырт кабарту, җинел акыл белән эш итү мөмкин түгел. Мөгаллим-мөдәррисләрнең дә йөзек кашы кебекләре килеп кенә тора. Фатих Сәйфи-Казанлы тарихтан укыта. Ул — "Мөкатдәс хезмәт", "Безнең заман", "Ямьсез тормыш" исемле китаплар да чыгарып өлгергән инде. "Ялт-йолт", "Мәктәп", "Ак юл", "Ан" журналларында, "Йолдыз", "Тормыш" газеталарында әллә никадәр публицистик мәкаләләр, рецензияләр бастырган кеше. Куе чәчле, тулы йөзле, үткен карашлы бу тәнкыйтьче, мөгаллим, галим буларак, шәкертләр арасында шактый абруйлы зат-шәхес булып исәпләнә. Галимҗанның "Яшь йөрәкләр" романына да рецензия язган иде ул. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Җиһанша Абдюшев белән дә фикердәш булып кит-те Галимҗан. Хәзер инде аңа рус телен дарелфөнүнгә керү өчен өйрәнергә кирәкми. Ул еллар шаулап артта калды инде. Ә шулай да, җае туры килгән саен, һәр форсаттан файдаланып, алар Пушкин, Толстой, Лермонтов, Тургенев әсәрләре дөньясына кереп чумалар да, алардагы сәнгатьлелек энҗеләрен сайлап алып, шулар турында фикер алышалар. Бәхәскә Истанбул университетын тәмамлап кайткан Мәхмүт Сатай да катнашырга ярата.

Мәдрәсәгә Мәҗит Гафури дә килеп киткәли. Ул инде хәзер дистәләгән китап чыгарып өлгергән зур әдип, сүз сәнгате остасы. Мәгәр тәкәбберлек, мактану, кирәкмәгәнгә үзен зур куюның ни икәнлеген белми. Кешелеклелек, шәфкатьлелек, гадилек, яхшы күңеллелек... — тагын да әллә күпме матур сыйфатлар зурлый аны. Галимҗанны ул фатирына да еш чакыра. Хәләл җефете Зөһрә апа исә ачык йөз, мөлаем караш, җылы-матур сүзләр әйтә-әйтә каршы ала.

Галимҗан Ибраһимов "Галия" мәдрәсәсендәге Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфан кебек шәкертләрнең йөрәгендә шигъри очкын барлыкны ныклап аңлады хәзер. Ул очкыннарның киләчәктә зур поэтик ялкынга әверелүендә һич шик юк. Казакъ егете Бәембәт Майлин һәм башка бик күпләрнең күңелендә — шигърият бакчасы. Ул бакча, шөбһәсез, поэтик гөлләр үстерәчәк. Бусы — бер. Икенчедән, ул шигъри ялкыннар арасында үзеңнең ялкының тагын да көчлерәк булырга тиеш. Аларныкыннан ким икән, сине инде яндырачаклар. Шуңа күрә "Галия"гә укытучы-мөгаллим табу да шактый авырлашты. Йомшак ягын кычытса, усал шәкертләр кашый белә. Тирән белемле, зирәк акыллы, таләпчән Зыя Камали әфәнде эшкә алганда ук нык чамалый булачак мөгаллимнең башында нинди җилләр уйнаганын. Карап торуга йомшак табигатьле, артык рәхимле, сабыр холыклы, хәтта берникадәр юаш тоелса да, эшкә алганда икеләнү, ык-мык итү, артка чигенүнең ни икәнлеген белми. Булмаслык икән — күзенә бәрә дә әйтә: "Юк. Сез "Галия"дә эшли алырлык түгелсез!" — ди.

Янә шунысы бар: "Галия" шәкертләренең шигъри йөрәге бик күпне таләп итә бит — җыр, музыка, сәнгать... Театрларга йөрү, үзләре спектакль кую, төрле кызыклы кичәләр үткәрү... — тагы да әллә ниләр, әллә нәрсәләр. Империалистик сугыш башлангач, Варшава консерваториясеннән бер профессор килгән икән Уфага. Галимҗан тәкъдиме белән аны да чакырдылар. Әлбәттә, иң әүвәл Зыя әфәнде Камали белән мәслихәтләшергә кирәк була. Ул башта сабыр гына, зур дикъкать илә тыңлап тора. Мәсьәләнең авыр икәнлеген белсә, бераз уйланып, мыек очларын бөтереп тора. Аңлый, кирәк — барысы да кирәк. Тик тышкы дөнья, иганәчеләр ни әйтер? Шулай да икеләнүләрне җиңми калмый аның яктылыкка омтылган киң күңеле.

Галимҗан, тел-әдәбият укытучысы, җыр-моң, сәнгать яратучы була-рак, аларның эчендә кайный. Тик ул "шулай итегез", "болай итегез", "тегеләй итегез", дип, һәрдаим өйрәтеп кенә тормый, үзләренә ирек бирә. Иҗади эш итсеннәр. Мөстәкыйльлек кирәк...

## X

“Акылны акыл биргән кешеңнән дә алырга тырыш”, — дигән кемдер. Көннәрдән бер көнне шәкертләр “Нәрсә ул шигърият?” дигән сөйләшү оештырмакчы булганнар. Әлбәттә, Зыя Камали белән Галимҗан Ибраһимовны да зурлап, хөрмәт итеп чакырды алар. Галимҗан Ибраһимов катнашмаска да уйлаган иде.

— Сез, шәкертләр, үзегез мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнегез, чәйнәп биргәнне генә йотарга гадәтләнмәгез, — дигән иде Галимҗан, ләкин алар ризалашмады.

— Йота белергә дә өйрәнсәгез иде! — диде сүз өчен кеше кесәсенә керергә гадәтләнмәгән Шәехзадә.

Бабич башта шигырьләрен мәдрәсәдә чыга торган “Эләктергеч”, “Парлакъ” дигән кулъязма журналында бастыра иде. Аннан әсәрләре “Акмулла”, “Шура” журналларында дөнья күрә башлый. Сәйфи Кудаш исә Уфадагы “Тормыш” газетасында, Оренбургтагы “Кармак” журналында да бастырып чыгара шигырьләрен. Боларда “талант” дигән илаһилыкка шагыйрь өчен су һәм һава дәрәҗәсендә кирәк булган кыюлык, үҗәтлек килеп керергә әзер тора. Вакыт-вакыт бигүк шомарып бетмәгән шигырьләрен дә чатнатып укып бирәләр. Ин кыены үзеңне аңлау булган кебек, бәгъзе берчак үз әсәреңнең дәрәҗәсен белеп бетермисең. Аларның янә бер шәп ягы бар: тәнкыйть утында янудан һич курыкмыйлар. Хәсән Туфан алардан биш-алты яшькә кечерәк. Бәлки, шуңадыр: бик аралашып бармый. Шигырьләрен бастырырга да ашыкмый. Сабырлык, оялучанлык, әдәплелекне ходай аннан җәлләмәгән. Мәгәр — өметле. Шигырьләрен кат-кат эшләргә ярата.

Баксаң, шигърият турында аларның ныклап, ихлас, җентекле сөйлә-шәсе килә икән. Шуңа күрә Галимҗан Зыя Камалины да чакыра. Мәҗит Гафурине дә барып алып килделәр. Сәгыйть Рәмиев бу вакытта Уфада яши иде. Ул да бик теләп килде шигърият мәҗлесенә.

Галимҗан Ибраһимов башта сүзнеңниндирәк юнәлештә барачагын белмәгән иде. Фикер алышу аның “Татар шагыйрьләре” исемле мәкаләсе буенча булачак икән. Анда Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдмәнд, Тукай поэзиясе турында яза.

Башта Шәехзадә Бабич ясады чыгышны.

— Мөхтәрәм Зыя әл-Камали җәнаблары! Мөхтәрәм әфәнделәр! Мөхтәрәм шәкертләр! Бүген без зур шигърият турында моназарә кылырга, фикер алышырга җыелдык, — дип башлады ул сүзен. — Без хөрмәтле мөгаллимебез Галимҗан әфәнде Ибраһимовның “Татар шагыйрьләре” исемле мәкаләсен бик җентекләп, яратып, укып чыктык. Анда Сәгыйть Рәмиев турында сүз бара. Мәкаләнең авторы, аннан олуг бәһа алган шагыйрь Сәгыйть әфәнде Рәмиевнең, шулай ук талант йолдызы Мәҗит ага Гафуриның монда булуы безнең өчен бәхет өстенә бәхет, нур өстенә нур ул! Сезгә мәгълүм булганча, мәкалә Сәгыйть әфәнде Рәмиев шигыре белән башлана:

Күңелле булмадым, булмам гомергә, —
Туганмындыр тугандук кайгы берлә;
Аяз кичләр булып, күктән карансам,
Карыйм үз йолдызымны, тик табалсам,
Табам нурсыз — сүнәр төсле тора ул,
Җиһанга бер бикяр* ләгънәт ора ул...

Шуннан докладчы мәкаләдән аерым-аерым өзекләр китерде: “Татар шагыйрьләре” дигәч үк, хәтеремә Сәгыйть Рәмиев килә. Һәм табигый дә.

---

*Бикяр — файдасыз.

Шуңа күрә сүзне анардан башлыйм". "С. Рәмиев — чын шагыйрь, аның яздыклары — куәтле шигырьләрдән, димез". "Кеше үзе теләп шагыйрь була алмый, аны табигать ясый". "Шагыйрь, әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрьлеге ягыннан караганда, салкын гакыл, коры мантыйк белән күп эше булмый. Ул һәрбер матурлыкка мәфтүн булган кеби, һәрбер матурлык каршысында тез чүгәргә, аның тудырган хиссиятен зур сәгадәт итеп алырга һәрвакыт хәзердер. Һәрбер хис йә ачы, йә татлы булып, шагыйрьнең йә нәфрәтен, йә шатлыгын тудыра".

Шушы өзекләрне әйткәч, үзенчә бер проблемалы сорау куйды Бабич: "Коры хискә генә корылган мәгънәсез шигырь буламы?, "Ник кеше үзе теләп шагыйрь була алмый?", "Әгәр шагыйрьне табигать ясый икән, аңа тырышып маташырга кирәкмиме?".

Сәгыйть Рәмиев шигырьләре турындагы фикерләрне әйткәч, мәкаләнең соңында язылган шигырьне укыды Шәехзадә:

Тугъ янадан мәгърифәтле анадан!
Югыйсә син, әй татар,
Бел, бетәсең, — ди, — надан!
Бетмә надан, тугъ янадан —
Мәгърифәтле анадан.
Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,
Хата ул коры өмид Алладан!

Аннан Дәрдмәндкә күчте Бабич. Ул да шигырь белән башлана:

Исә җилләр... күчә комнар... бетә эз...
Дәригъ,* мәхзүн** күңел, без дә бетәбез.

Бабич, тыңлаучыларга шактый четерекле сорау куйды: "Башта шагыйрьнең хис колы булуы турында әйтелгән иде, ә хәзер тирән уй турында сүз бара; боларның кайсы кыйммәтлерәк: хисме, уймы?".

Сораудан соң Тукайга күчте Шәехзадә: "Бездә һичбер шагыйрь Тукай чаклы корама тел белән яза башламады, — дип, тыңлаучыларның колагын торгызды да, шагыйрьнең халыкчанлыгы турында әйткән сүзләренә күчте. — Халык йөрәгендә булып та, теленә килә алмый торган тойгыларын әйтеп бирү һәм укучыны үзе теләгән рәвештә уйландыру, тәэсирләндерү — язучының үз вакытында күтәрелүнең бердәнбер ачкычы! — диләр.

Тукаевта шул сүзнең асылын күрү мөмкин.

Халык бөтен дөнья мөселманы өчен кайгырганда Тукаев шуны җырлады; миллияткә күчкәч, аның теленнән татарлык аһлары коелды, әле анда яхшы фикергә гашыйк заманы иде. Тукаев моны бер дә кызганмады. Шулай итеп, халык Тукаевта үз саны, үз күңеле эзләгәнен беркадәр таба килде. Вакыты белән Гафурине дә күтәргән нәрсә шул — халыкчанлык иде".

Шәехзадә Бабичтан соң Сәйфи Кудаш чыгыш ясады. Аны да шул бер үк нәрсә борчый икән: шигырь өчен кайсы мөһимрәк: хисме, акылмы?

Галимҗан Ибраһимов сорауларның барын да яза барды. Соңыннан аларга җавап бирде. "Шагыйрьне табигать тудыра" дигән сүзләренә төзәтмә дә кертте ул. Талантны үстерү өчен күп хезмәт кирәклек турында әйтте. Сәгыйть Рәмиев тә, Мәҗит Гафури да, Зыя Камали да куәтләде аның фикерен. Зыя әфәнде Галимҗан Ибарһимовның үзен берникадәр тәнкыйть итеп тә алды. Фикерен ул чагыштырулар ярдәмендә аңлатты:

— Мин болай уйлыйм, Галимҗан әфәнде: менә, фаразан әйтик, Ходай Тәгалә безгә ифрат зәвыклы гөл бакчасы бүләк итте. Һәр гөл-

*Дәригъ — аяныч.
**Мәхзүн — кайгылы.

чәчәк, минемчә, үзе бер шигърият ул. Бу шигърият — җирнең үзендә. Сезнеңчә әйтсәк, аны табигать тудырган. Әмма, шул матур гөлләргә хисләнеп карап тору гына җитми әле. Аларны бәяли, тәрбияли торган акыл да кирәк. Хис вә акыл бердәмлегендә туа мәгънәле, зәвыклы шигырьләр. Яшьләргә моны ныклап аңлатырга кирәк. "Галия"дә генә күпме шигырь язучылар бар. Шулаймы, Шәехзадә?

Бабич тиз генә җавап бирмәде. Шәкертләр аның ниндидер шаян сүз әйтүен көтте. Һәм ул әйтте дә.

— Шулай. Безнең Сәрвәретдин дә, әнә, сатирик шигырьләр яза, — дигәч, барысы да көлеп җибәрде. Галимҗан Ибраһимов аптырап калды: әллә шигырь җене "Зобани"га да кагылганмы?

— Йә, Сәрвәретдин, ялындырма, теге беркөн безгә әйткән шигыреңне башкаларга да ишеттер әле, — диде Бабич.

Сәрвәретдин, шәкертләр арасыннан күтәрелеп, артистларча кулларын болгый-болгый сөйләп тә китте:

Телем озын, телем озын,
Телем озын — нишләтим;
Әллә инде кисеп алып,
Кәтлит кенә эшләтим?

Янә рәхәтләнеп бер көлешеп алдылар. Аннан, Зыя Камали әфәндедән рөхсәт сорап, музыка уйната башладылар.

## XI

Көннәрдән бер көнне Галимҗан янына казакъ егете Бәембәт Майлин килде. Казакъ халкының күңеле — очсыз-кырыйсыз үз даласы кебек киң. Дала тавышы белән бер җырлап җибәрсә казакъ, аның күкрәгеннән кайнап чыккан тирән, сихри, давыллы моң Җир белән Күкне кочаклашты-рып кавыштыра ала. Бәембәт Майлинны Уфага дала моңы, дала тыны, казакъ халкының рухи бөеклеген алып килгәне, думбрада шул илаһилыкларның һәммәсен чыңлата белгәне өчен генә түгел, ә бәлки аның олы җанлы, акыллы, хис-тойгыларга бай, талантлы булганы өчен дә яратты Галимҗан. Түгәрәк йөз, шомырт кара күз, кыю караш, эчкерсез елмаю, кешегә изгелек кылырга әзер тору, дуслык тойгыларын югары тота белү кебек сыйфатлар күркәм итә аны. Ул шигырьләр дә, хикәяләр дә яза. Җанлы, сәнгатьле, аһәнле тел белән яза. Тик... фикер колачы җитмәү, белем азлыгы сизелә. Аның шулай икәнлеген үзе дә аңлый шикелле. Надан булу бер яман, наданлыгыңны аңламау бишләтә яман, ди. Ә ул аңлаган үзенә белем җитмәүне. Шагыйрьнең анадан шагыйрь булып тууы гына җитми, шул әле, аңа зур шагыйрь, зур әдип булу өчен күп белем дә кирәк. Галимҗан дарелфөнүндә уку турында хыялланды. Бу хыял җене Бәембәткә дә тынгы бирми икән. Ул укырга кая китәр өчен киңәш сорарга килгән. Майлин — әле яшь. Югары уку йортына керү өчен шәһадәтнамә алырга кирәк. Рус телен яхшы белмәсәң, бу максатка талпыну канаты каерылган кошның очарга маташуы кебек кенә. Шулар хакында сөйләп биргәч:

— Талант бөреңне ныклап ачу өчен сиңа укырга кирәк, Бәембәт туган, — дип, аның аркасыннан кагып куйды Галимҗан.

Боларның — Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфан, Бәембәт Майлин кебекләрнең — Мәккә-кыйбласы билгеле инде: шагыйрь, әдип булачаклар. Ә менә "Зобани"ны кая куярга? Кем чыгар аннан? Хәлфә? Мөдәррис? Мулла? Мәзин? Юк — алар чанасына утырмаячак ул. Аслан. Авыл мөгаллиме булырмы? Бәлки. Әмма һаман әле пырдымсыз ат белән бер. Һич кертеп булмый тәртә арасына. Дөрес, соңгы вакытта әдәплелек әрҗәсенә әзрәк утыра башлады шикелле. Җаны-тыны белән укуга бирелде. Монысы — шәп! Әмма — теле озын. Үзе әйтмешли, кисеп алып, кәтлит кенә итәрлек...

* * *

Беренче көнне чәй табыны әзерләгән чибәр кыз Хәдичә исемле икән. Ятимә. Казакъ далаларыннан аны Бәембәт алып килгән. Нинди дә булса берәр эшкә урнаштырырга нияте. Бу хакта Бәембәт Зыя Камали әфәндегә сөйләп бирә. "Галия"дә кызлар өчен бер бүлек ачмакчылар икән. Дөрес, аның кайчан булачагын тәгаен генә әйтмиләр. Булыр ул бервакыт. Хәдичәнең бик әдәпле, җыйнак, сөйкемле икәнлеген искә алып, Зыя әфәнде аны эшкә урнаштыра. Аның урыны хәзергә ашханәдә. Галимҗаннан ул дәресләр дә ала. Үзлегеннән укый. Кем белә, бик тырышса, мөгаллимә булып китәр, бәлки. Казакъ далаларыннан килгән кызга хөрмәте зур Галимҗанның. Кыз язмышы — кыл өстендә, диләр. Кыл бер өзелсә, аны ялгау бик кыен. Моны әйтеп булмый Хәдичәгә. Ярамый. Нотык уку була.

— Синең сәләтең бар, Хәдичә, укы, иренмә, мөгаллимә булырсың бервакыт, — дигән сүзләрне кызганмый мәгәр.

Ә менә алмадай матур Алмабикәнең язмыш кылы өзелгән. Теге вакытта да ул Галимҗанның фатирына үзе килгән иде. Бу юлы да шулай итте. Галимҗан Ибраһимовның "Галия" мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты укытканын белгәч, бу эше бөтен Уфа зыялылары теленә күчте. Алмабикә аның "Яшь йөрәкләр" романын кат-кат укыган иде инде. Әсәрнең аһәнле, садә, җанлы теле, андагы каһарманнар язмышы, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәтләр, татар дөньясы чагылышы нык әсир иткән иде аны. Галимҗан абый язганмы соң моны? Шул Гыйрфан мулла улы Галимҗанмы? Кайчандыр аларда торган Галимҗанмы? Ничек анларга моны? Кайдан ала ул мондый көчне? Шулкадәр килешле сүзләрне ничек таба икән? Әллә бер-бер фәрештә әйтеп торамы колагына? Татар теле шулкадәр бай икән ләбаса! Аны бик ярлы, диләр иде бит. Әтисе дә шулай әйтә иде хәтта. Димәк, аңлап бетермәгәннәр.

Шуларның барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде Алмабикә Галим-җанга. Дулкынланып сөйләде. Озак. Мактап. Гаҗизанә йөрәк белән.

Галимҗан Ибраһимовның язу өстәлендә китап-дәфтәр-кәгазь һәрвакыт таралып яткан була. Бу юлы да шулай иде. Зыяэддин әл-Камалиның бу хезмәтен янә бер кат укып утыра иде ул Алмабикә килеп кергәндә. Алар кочаклашып күреште. Башта сүзләр әллә ни ялганмады. Араларындагы мөнәсәбәтне тикшерә башласаң, әлеге дуслыкка кагылышлысы өстенлек аладыр, бәлки. Ә инде 1906 елда, Галимҗан аларда торганда, дуслык хисенә туганлык тойгысы чаткысы килеп кушылды кебек. Мондый тойгы әтиләре дуслыгының туганлыкка әверелү сөземтәседер, мөгаен. Шулардан мәхәббәт очкыны чәчрәде шикелле. Әмма ялкын булып дөрли алмады ул. Шушы хакта да алар, ялкынга ялкын килергә курыккан күбәләктәй генә булса да, гәпләшеп алдылар. Алмабикә, хатын-кызларга хас төпченү гадәтен һаман куерта төшеп, Галимҗанның күңел кылларына төрлечә чиерткән халдә йөрәгенең тирән төпкеленә төшәргә тырышып утырды: нигә һаман өйләнми, гомер дигән кадерле нәрсә бер генә бирелә адәм баласына, ялгызлыктан да авыр хәл юк бит дөньяда — шуларны белергә тырышты.

Алмабикә, шөбһәсез, Галимҗанның нигә һаман тормыш кормаганлыгын белә: тегендә ташлана, монда, ни арада өч роман, хикәя, повесть, фәнни хезмәт, мәкаләләр язып ташлады. Алып батыр көче бар анда, дип уйлый. Ә Галимҗан үзе бу мәсьәләне күңел төшкән кыз булмауга китереп бәйли. Алмабикәгә "яратам" дигән сүзне ычкындырмый. Шулай да берәрә, Алмабикә бик төпченгәч:

— Ә менә үзең килер идеңме миңа? — дип куйды.

Алмабикәнең бит очларына алсулык йөгерде. Сорау аны дулкынландырды шикелле. Кыз бер җавап та бирмәгәч, ике арада тынлык тавы хасил булды.

Бераздан кыз акрын тавыш белән:

— Мин сезне кунакка чакырам. Шунда сөйләшербез, — дип куйды.

— Әтиеңне, әниеңне дә бер күрәсе килә иде.

— Алар юклар шул инде.

— Ничек алай?

— Мәрхүмнәр...

Алмабикәнең әтисе, әнисе үткән ел бер-бер артлы вафат булганнар икән. Аларны татар зиратына җирләгәннәр. Абыйсы Имаметдин Каһирәдә укый иде. Хәзер шунда укыта башлап, ике энесен дә үз янына алдырган. Ху-у-ш! Чәчелә татар. Әллә кайларга алып китә газиз башын. Хәзер Алмабикә егерме ике яшьлек өйләнмәгән Кадермөхәммәт исемле энесе белән яши икән. Кияүгә чыкмаган әле. Моның сәбәбен сорагач, сүзне артык озынга сузмыйча, берникадәр уңайсызланып, сөйләп бирергә мәҗбүр булды кыз. Әтисе, әнисенә аның үпкә-сапкасы юк. Мөселман халкына хас булганча, мәрхүмнәрне яман як белән искә алу ягында түгел. Аларның авыр туфрагына җиңеллек тели. Җаннары оҗмахта булсын! Ләкин тормышка чыга алмый калуында әтисе, әнисе гаепле икән. Бигрәк тә әтисе Габдрахман хаҗи. Аны хатыны үлеп, ике бала белән калган Насретдин исемле байга бирмәкче булганнар. Ризалашмаган. Аннан Миргали исемле бер мулла малаена димләгәннәр. Яратмаган. Ул Гутман заводында эшләгән Мөхәммәтшәрип исемле егеткә гашыйк була. Ләкин Габдрахман хаҗи ярлы егетне якын да китерми. Шуннан башлана мәхәббәт трагедиясе. Ни акыллы, ни дурак чаклар, энә очында биегән дәртле еллар акрынлап үтә тора, үтә тора. Аннан сайлау-сайлану, тиңне эзләү башлана. Тик табылмый йөрәккә якын кеше, табылмый...

Алмабикә элек тә күңелендә барын яшерми иде. Шул сыйфаты һаман сакланган икән. Элеккечә табигый матурлыгын ясалма матурлык белән күмгән. Буялган иреннәр. Уймак авыз. Каралтылган кыйгач кашлар. Кершән ягылган йөз. Нечкә бил... Ничек кенә булмасын, ул чибәрләр рәтенә керә. Мондый кызлар горур, көяз, хәтта холыксыз була. Алар үзләрен матурлык фәрештәсеннән өстен куеп яши. Тормыш өчен пәйгам-бәргә тиң егетләрне эзли. Теләгенә ирешә алмаса, чибәрлегенә ләгънәт укый. Шушы фаҗига сазлыгына якынлашып киләме бу туташ? Дөрес, яшьлеген ул саклаган әле. Чибәрләр яшьлек укасын коймаска тырышып яши. Әлбәттә, ныклап игътибар итсәң, әллә күпме үзгәреш күрәсең. Үзен күпме генә горур, тәкәббер тотмасын, элекке елмаюы аның шактый садә, самими була иде. Ул садәлекләрдә хәзер әллә нинди аңлаешсыз күләгә бар кебек. Элекке үткен, чая, каты күз карашлары да йомшак, юашланып калган төсле. Ул чая карашларга берникадәр хәяти хәсрәт өстәлгәне төсмерләнә. Көлгән чагында ике янагында тирән генә чокыр хасил була иде. Ул чокырлар да инде саеккан кебек. Сандугачныкыдай моңлы була торган иде тавышы. Ул монда да хәзер сүренкелек сизелә.

* * *

Алар шулай очрашып торды. Галимҗанга күңелле иде Алмабикә белән. Алмабикә әдәбият, моң, җыр, сәнгать ярата. Шулар хакында сүз чыкса, шактый озакка сузыла аларның сөйләшүе. Утызга җитеп килгән Галимҗан йөрәгендә, — бигрәк тә тик торган, иҗат итмәгән вакытларда, — әллә нинди галәмәт бушлык сизелә. Ул нәрсәдер тели. Аңа нидер кирәк. Сусыз корыган гөл хәленә кала ул бәгъзе бервакыт. Егерме бишнең өстенә чыккан Алмабикә йөрәге дә нидер

өмет итә. Кайчак ул үтереп сызлый. Әрни. Телгәләнә. Ә инде яшьлекнең яшел бакчасыннан һаман ераклаша барган бу икәү очрашсалар, күңелләре хушлана, кәефләре күтәрелеп китә шикелле. Ни бу? Бер-берсеннән алышкан сүз гәүһәренең җанны балкытуымы? Әлеге "дуслык", "туганлык" чаткысыннан мәхәббәт ялкыны кабынып китте. "Яшь мәхәббәт — узгынчы җил, карт мәхәббәт — таш яра", — дигәнне искә алсак, бик хикмәтле вә гаярь булачак бу ике йөрәк кушылуыннан оешкан зур мәхәббәт. Иншаллаһ! Бер Алланың үзенә тапшырдык!

Көннәрдән бер көнне Алмабикә Галимҗанны үз янына янә чакырды. Башка вакытта кавышу шатлыгы чәй эчү, укылган китаплар турында фикер алышу, тормыш-көнкүреш, яшәү рәвеше хакында бәхәсләшү белән тәмамлана иде. Бу юлы катлаулырак булды мәсьәлә. Галимҗан һәрвакыт тизрәк кайтып китәргә ашыга. Белә моның сәбәбен Алмабикә: аны эш көтә. Алмабикә куңып калырга кыстый. Ризалашмый Галимҗан. Төрле сәбәпләр таба. Ике катлы йорт. Биш-алты бүлмә. Бервакыт Алмабикә бөтенләй күчеп килергә тәкъдим итте. Тик тәгаен генә җавап бирмәде Галимҗан. Аның чире турында элек тә, ул шәкерт булып йөргән елларда, сораша торган гадәте бар иде. Хәзер, күрәсең, акыл белән эш итә ул. Төпченми. Шикләнүен яшерә. Әмма шикләнү безе беркөн күңел капчыгын тиште дә чыкты. Һич уйламаганда, көтмәгәндә сәламәтлеген сорашып алды. Бу инде Галимҗанның ярасына тоз сибү белән бер иде. Шулай да сер бирмәде ул:

— Сәламәтлегем бик шәп, Алмабикә, үземне унҗиде яшьлек егетләр кебек хис итәм, — диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, кызның йөзе яктырып китте. Бер-береннән исәнлек-саулык сораша торган гадәт бар анысы. Тик Алмабикәнең ни өчен сәламәтлек хакында борчылганын аңлый Галимҗан. Шулай да аңа игътибар итмәскә тырыша. Ә инде күчеп килү кадәресен нәкъ менә шушы сәбәп катлауландыра да. Тапты Алмабикә бу катлаулылыкны гадиләштерү ысулын. Бик бай нигъмәтле өстәл уртасына бер көн шапылдатып шәрап китереп куйды. Энесе әтисе белән бертуган Хәйретдин муллага киткән иде. Кайтмады нишләптер. Алар шактый озак утырды. Төн караңгы иде. Әллә нинди көчле буран купты. Җибәрмәде Галимҗанны Алмабикә. Җылы кочагына алды. Тышта буран котыра. Давыл шаша. Җил елый. Өй эчендә — кайнар мәхәббәт. Җан рәхәтлеге. Ләззәт!

... Ул дәвам итте. Көннәрдән бер көнне Алмабикә бик тә кәнфитләнеп, көязләнеп, уймактай авызын бишкә бөреп, аңа яңа хәбәр әйтте:

— Минем сиңа зур бүләгем бар, Галимҗан!

Галимҗан җавапны сүренке генә бирде:

— Минем өчен син үзең зур бүләк, Алмабикә!

— Алай гына түгел шул бу.

— Ә ничек?

— Мин бала көтәм!

## XII

1917 елның февраль ае иде бу. Галимҗан Солтанморатка кайтты. Ә илдә зур көрәш бара. Кан коеш. Ачлык. Ялангачлык. Солтанморатта да әллә нинди үзгәрешләр булып алган. Нәҗметдин бай малае, төрмәдән кайткач, яшел елан белән янә дуслашып киткән. Елан аның канын соңгы тамчысына кадәр эчкәч, муенына элмәк салырга мәҗбүр булган Илһаметдин. Кайчандыр Хөрмәтуллага нахак бәла яккан Хәмәтдин карт урамда җенләнеп йөреп үлгән. Ярты ел буе якалаша икән Мөбахис

мәзин газраил белән. Күзләре сукыраеп, авызы кыегайган хәлдә ята икән түшәктә. Мәдрәсәдән кайткач, улы Бәкерҗан әйткән аңа: "Әткәй, — дигән, — син гомер буе үзеңә күп яхшылык кылган Гыйрфан муллага дошманлык күрсәттең, безне дә аларга каршы котырттың, ә Галимҗан әфәнде мәдрәсәдә минем яманлыгымны кичерә белде. Кылган гөнаһларың өчен Хәсәнә абыстайдан булса да гафу үтен, — дигән, — шулай булмаса, дигән, мине улың дип исәпләмә", — дигән.

Бу хәбәрләрне, тагы да әллә күпме имеш-мимешләрне әнисе Хәсәнә абыстай сөйләде Галимҗанга. Ә икенче көнне мөгаллим Сәетгали атылып килеп керде:

— Галимҗан абый! Патшаны төшергәннәр! — дип кычкырып җибәрде ул. — Телеграмма бар...

Әнисе Хәсәнә абыстай белән кала, авыл, ил хәбәрләре, кардәш-ыру, күрше-күлән, дус-иш хакында аскы бүлмәдә сөйләшеп утыра иде Галимҗан. Тиз генә сикереп торып:

— Хәзер туры бияне җигәбез, — диде ул.

Хәсәнә абыстай каушап калды:

— Нигә? Ни өчен? Кая бармак буласыз?

— Корманайга.

— Ни калган анда сезгә?

— Вулыска. Урядник Кузьминны кулга алырга!

— Соң, синнән башка да кеше бардыр бит?

— Кайткач аңлатып бирермен, әнкәй!

— Галимҗан өстенә юка пальтосын киде дә, чыгып та китте. Мөгаллим аңа иярде.

Атны тиз җиктеләр. Дилбегәне үзе тотты Галимҗан. Сәетгали капканы ачты. Урамга чыккач:

— Әйдә, мөгаллим, утыр, син дә барасың, — диде Галимҗан, каршы килмәслек җитди тавыш белән.

Алар атка артлы чана җиккәннәр иде. Сәетгали чананың артына җайлашты. Галимҗан исә утыру турында уйламады да. Хуҗасының ярсу йөрәген туры бия дә аңлап торды шикелле. Дилбегәне кагу белән, дәррәү чаптырып алып китте.

— Һәй, җәмәгать, патшаны төшергәннәр, Корманайга ашыгыгыз, берегез дә калмагыз! — дип кычкыра Галимҗан. Нишләргә дә белми мөгаллим. Галимҗанның тавышы бик сәер, куркыныч, коточкыч чыга. Ни кылана ул? Ул хәзер зур язучы, тарихчы, педагог лабаса. Бу бит әдәпсезлек. "Әллә Галимҗан Ибраһимов акылыннан язганмы?" — дип уйлаулары бар. Хәсәнә абыстай дөрес әйтә: Корманайда алардан башка урядникны богаулардык кеше юкмы әллә? Әйт хәзер аңарга: "Салкын тияр, эләктер пальто төймәләренне", — дип. Ул барыбер тыңламаячак. Аның кызу канлы, усал, башбирмәс икәнлеген белә иде мөгаллим. Ләкин болай ук кызу холыклы дип уйламый иде. Әле ул бөтенләй әллә нинди кешегә әверелде. Әйтерсең, зур крепостьны алырга баручы полководец.

Солтанморат белән Корманай арасы — алты-җиде чакрым чамасы. Менә шул юлны "һә" дигәнче үтәргә кирәк. Шушы юл арасы, әйтерсең, олы бәхет өчен кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен үтү. Үттең — бәхет дәрьясына барып чумдың. Ул дәрьядагы бәхет бөтен илгә генә түгел, җир йөзендәге һәммә юксылларга җитәчәк. Русия караңгы баздан күтәрелеп чыгып, бөтен дөньяга нур сибеп яшәячәк. Бай ил бит ул! Аһ, аның җирләре, урманнары, сулары, алтыны, көмеше, гәүһәре, мәрҗәне, асыл ташлары... — ниләре генә юк аның. Табигатьнең иң киң, хозур, бай җиренә урнашкан бит ул. Хәлбуки, Американың эшчесе дә Русия буржуеннан хәллерәк яши. Ни өчен шулай ул? Чөнки Николай патша тота белмәде ил дилбегәсен. Чәнчелдерделәр җебегәнне. Йөзтүбән капландырдылар. Бетте. Корыды. Яңа тормыш килә! Бәхетле тормыш! Ил юксыллары рәхәт яшәячәк! Ялган, алдау, шәфкатьсезлек,

көчленең көчсезне рәнжетүе, урлашу, гаделсезлек, хаталану, ялгышу, бер дә юкка кеше башы ашау кебек күнелсез хәлләрнең барысы, һәммәсе бетәчәк. Ә үзе бөтен көчен, кирәк икән, соңгы тамчы канын шушы бәхетле яңа тормышка бирәчәк!

Шулай уйлый Галимҗан. Ул әле менә Октябрь революциясе, Гражданнар сугышы еллары вакытында күпме каннар коелып, мөмкин кадәр тырышып-тырышып төзегән барлык матурлыкнын җимерелеп, илнең йолкынган әтәч хәлендә калачагын, төрмәгә әвереләчәген белми дә, күз алдына да китерә алмый. Чир даими рәвештә аны буып торачак. Шулай булуга карамастан, кешеләргә бәхет китерә торган яңа җәмгыять өчен ул көн-төн, ял итми, армый-талмый эшләячәк. Борыны белән җир сөрергә кушсалар, аннан да чирканмаячак. Иң зур бәхет — халык өчен хезмәт итү. Моны шәригать тә, бәндәчелек тә мактый. Менә шунын өчен җанын фида кылачак ул. Әмма халык өчен яшәп тә, "халык дошманы" дигән хурлыклы исем алачагын ул әле белми. Алдана Галимҗан. Ул гына түгел, йөзләр, меңнәр, миллионнар алдана бүген. Кем, нәрсә алдый аларны? Наданлык, фикер сафлыгы, мантыйк ярлылыгы, яшәү кыйбласын ялгышу, бөек кодрәтнең кайда икәнлеген белмәү фаҗигасе алдый. Адәм сөякләре өстендә төзелгән җәмгыять гадел, алдаусыз, бәхетле җәмгыять була алыр микән?..

---

## Журналыбызның киләсе санында укыгыз!

*Чәчмә әсәрләр*

Ләбибә Ихсанова. Кемгә сөйлим серләремне... *Повесть.*

Ркаил Зәйдулла. Кечкенә кешеләр. *Хикәяләр бәйләме.*

*Шигърият*

Гәрәй Рәхим, Әхмәт Рәшит, Шамил Анак, Мөдәррис Вәлиев *шигырьләре.*

*Публицистика*

Мөсәгыйт Хәбибуллин. Һуннар, болгарлар, кыпчаклар һәм бүгенге татар халкы. *Тарихи-фәлсәфи уйланулар.*

*Әдәби тәнкыйть*

Сәгыйть Хафизов. Әдәбиятта базар заманы.

Миләүшә Фатыйхова. Һади Такташ иҗатында шәхес.

Журналның бу санында шулай ук латинча имлада уку күнекмәләре, "Имеш-мимеш түгел" рубрикасында язучылар тормышыннан кызыклы хәлләр, әдәбият һәм сәнгать тарихына караган күпсанлы башка язмалар тәкъдим ителәчәк.

ШИГЪРИЯТ

# ҺӘР АГАЧНЫҢ ҮЗ ҖИМЕШЕ...



*Кулымда — каты тышлы, калын бер китап: 1968 елда чыгарылган "Беренче карлыгачлар" җыентыгы. Онытылып торган икән: 60 елларда яшь шагыйрьләрне шулай җыйнап, бер китап-тышлык эчендә күрсәтү гадәте бар иде шул. Үзем дә "Дус-лык" исемле уртак китапта басылу сөенечен татыган идем (1965 ел). Китапны янә актарып чыктым, авторларын —шагыйрьләрне карадым... Әһә, сугышчы-шагыйрь Гиз эль-Габид белән башлана икән. Аннан — Уфадан Рәшит Фазлыев... Утыз яшьлек шагыйрьләр — Рәшит Гатауллин (минем бертуган абыем!); урын өстендә ятып, шигырьләрен теш белән язучы батыр рухлы Гакыйль Сәгыйров, шахтер егет — моңлы Рифкать Закиров, Чиләбедән талантлы Салисә Гәрәева... Алардан яшьрәкләр — Данис Хәбибуллин, Ренат Харис, Фирая Зыятдинова, Зөлфәт, Разил Вәлиев...*

*Карасана, нинди исемнәр, нинди янәшәлек бит, ә? Әйе, китап басылуга утыз ел узган, кайбер авторлар инде гомер көзенә атлый (быел Г. Сәгыйров, Р. Закиров, С. Гәрәева һәм Рәшит Гатауллиннар инде 60 яшен билгелиләр!), ә берәүләре — ир уртасы булып җиткән. Әмма иң кызыклысы шул: бу китаптагы авторларның берсе дә онытылмаган һәм берсе дә югалмаган. Әдәбиятта һәрберсенең урыннары бар; зурмы ул, биекме — башка мәсьәлә, — әмма шигъри хәрәкәттә, процесста, әлеге утыз елда бу исемнәр югалмадылар, төрле кимәлдә, "төрле телдә, төрле гамьдә, төрле ямьдә" шигырьләре белән укучылар күңелен яуладылар, дип әйтә алам. Әйе, бер күзәтүче буларак әйтәм...*

*Рәшит Гатауллин — әлеге "Карлыгачлар"ның берсе, ул чакта укытучы һәм мәктәп директоры, шигырьләре белән журналыбызда да күренеп алган иде. Аннары ул югалыбрак торды, сәбәпләре дә булгандыр... читтәге авторларга караш та үзгәребрәк китте бугай (урында, Уфада басылсыннар, янәсе!), матбугат һәм нәшрият та "диаспора"га якты йөз күрсәтмәде... Үзе дә бик актив булгандыр, дия алмыйм. Нәтиҗәдә ул, яңадан, 80 елларда гына "Казан утлары"нда күренә башлады. Башка басмаларда да дөнья күрде шигырьләре һәм 90 еллар башында Халисә Мөдәррисова, Рим Идиятуллиннар белән бергә ул Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды. Рәшит — шактый еллар инде Уфада, "Кызыл таң" газетасы редакциясендә эшли, мәкаләләре,*

*шигъри бәйләмнәре еш басыла... Шигырьләрен җыеп, саллы гына бер китап чыгару уе белән дә яши — Уфадамы, Казандамы булыр аның өчен бәхетле бу вакыйга? — әлегә ул — күмәк китапларда яшәүче автор... Гәрчә, аның кайбер дуслары Рәшит шигырьләрен минекеннән өстен дә күрәләр. Мин моңа һич тә каршы килмим. Шулай, "күзләр күзгә охшап килми", үзе әйткәнчә. Ә күзен — ачымы ул, татлымы — һәркемнең үз җимеше...*

*Хәерле булсын! Озак яшик, язык әле, дуслар!*

Рәдиф ГАТАШ

# Рәшит Гатауллин

## КҮЗЛӘР КҮЗГӘ ОХШАП КИЛМИ ИКӘН

* * *

Теләсәм дә мин җыр язалмадым
Тукай тиклем Тукай хакында.
Җанда йөргән сүрелмәс шул моңны
Язалмаган өчен тартынмам...

Яза алмам. Сибгат рухы рәнҗер,
Туфан түзмәс, Наҗар оялыр.
Болай да бит бик еш кузгатабыз
Тукай тиклем Тукай туфрагын.

Сабый чактан килгән сихри моң ул,
Җирем җыры, теле әнкәмнең.
Кешеләргә әйтер сүзләремне
Шул туган тел аша әйтәмен.

Буыннарга калган җан азыгы,
Кешелеккә калыр моң, аваз.
Ул — халкымның
Иң мөкатдәс җыры,
Гомер буе сынмас моңлы саз!

* * *

Нигә, йөрәк, ашыгасың
Басулар киңлегенә?
Сөенәсеңме көннәргә,
Дөнья иминлегенә?

Күренми дә, беленми дә,
Әллә кайда бүз тургай,
Зәңгәр күктә яшел җирне
Әй мактап сайрый шулай.

Әй сайрый тургай, моңаям
Шул кырлар киңлегендә.
Иләсләнми күңелләре
Язларда кемнең генә?

Чылтырап үтәр бу язлар
Җәйләргә алмашынып.
Яшел болыннарны күмәр
Сандугачларның моңы.

Ә әлегә зәңгәр күктә
Бүз тургай тавышлары...
Коела, күктән коела
Зәп-зәңгәр сагышларым.

## Курай

Сәхнәләрдә уйнар өченмени
Сәхраларда үскән бу курай?
Бүген яңгырый нинди сарайларның
Мәрмәр залларында ул шулай?
Далаларда үскән курай бит ул,
Ил җилләре аңа моң биргән.
Кояш нурларыннан коелган ул,
Чәчкәләрдән энҗе сибелгән.
Чишмәләрнең җыры күчкән аңа,
Урман шауларыннан шомланган.
Яңгырларның көмеш суын җыйган,
Моңсулаткан көзге томаннар.
Бал кортлары шуннан ширбәт эчкән,
Чыклар төшкән аяз таңнарда.
Кояш, җилләр белән ярыша-ярыша
Үскән бит ул кыя-тауларда.
Тамырлары белән тоташтырган
Җирнең гамен, илнең моң-зарын.
Сәхраларда — аның туган җире,
Далаларда иле — курайның.
Җир тавышы — җирдә якынырак,
Ил тавышы — илдә ачырак...
Сәхнәләргә җыры сыймас сымак,
Мәрмәр заллар аңа тар сымак.
Курай уйный — йөрәк канатлана,
Алпамышка алышыр көч керә.

Курай уйный — көлә, елый дөнья,
Давыллана, ярсый үч белән.
Курай уйный — дала, таулар иңри,
Курай уйный — иңри бар җиһан.
Ир җырына, курай тавышына
Бар язмышы белән ил сыйган.
Курай уйный... Нигә бу сәхнәләр,
Мәрмәр заллар аңа, алкышлар?
Курай белән телгә килә тарих,
Күз алдына баса язмышлар.
... Ир кулында чакта ил кырында
Уйна әле, уйна, кураем.
Моңнарыңда синең җир гамьнәрен,
Ил гамьнәрен ныграк тоямын...

* * *

Бу күңелнең шундый моңсу чагы...
Очып китте парлы аккошлар:
Кызганырлыкмыни, сокланырлык
Аккошларга тигән язмышлар...
Кошлар киткән чакта
Көзге урман
Сагыш, моңга тулып, ни сөйли?
Киткән кошлар китә — ни хакына?
Калган кошлар калса — ни тели?!
Киткән чакта әллә соңгы җырны
Җырлап китә микән аккошлар?
Шул кошларның соңгы җырларында
Әйтелмәгән нинди сагыш бар?
Сизәме икән күңле аларның да
Берәрсенең язын кайтмасын?
Төнбоеклар үскән зәңгәр күлдә
Зәңгәр дулкын тагын какмасын?
Көзләр көзгә охшап килми икән,
Китми икән... Шуңа күңелсез.
Бер чак көзне минсез каршыларсың,
Йәки каршылармын мин синсез...
Гомерем көзе килер, яфрак коелыр
Мин үтәлми калган юлларга.
... Аккош булып түгел, кеше булып
Соңгы җырны ничек җырларга?



# Нәҗибә Сафина

## ӘЙТЕГЕЗ ЯШЕН... АЙНЫҢ?!

* * *

Җир шундый ул, тетрәгәч тә,
Яшәвен дәвам итә.
Тетрәгән җир асларына
Кешеләр генә китә.

Мәхәббәткә юлыкканнар
Шулай икәнен белә...
Җаннары тетрәп торса да,
Күз яше аша көлә.

* * *

Тәрәзләрне каплап куеп була, —
Керми тора кояш нурлары.
Күңелләрне булмый каплап куеп,
Түгелә дә түгелә моңнары.

* * *

Мәхәббәт хакында язма, —
Инде, диләр, картайдың.
Кем белә, әйтегез яшен
Ярын көткән яшь Айның?

* * *

Зимагурлык —
этләргә дә авыр...
Кешеләргә килде
шундый дәвер.

* * *

Кайбер кеше гомере буе
бикләргә ачу тота.
Әмма йөрәген читлектә
тотуы белән ота.

* * *

Акыл кергәч, ах итәсең:
Ничек исәр булынган...
Әмма акыллы гамәлләр
Исәр чакта кылынган.

* * *

Илдә солтан булмаса да,
Илгә солтан чират тора.
Нидән алай икәнлеген
Солтан булганнардан түгел,
Олтан булганнардан сора.

* * *

Ут булсаң, сүндерерләр.
Су булсаң, сеңдерерләр,
Таш булсаң, йә атарлар,
Җиргә салып таптарлар.
Сүнмә, сеңмә, атылма,
Чит табаннан тапталма!
... Хөкем юк ул үз җиренә
Туфрак булып ятканга.

* * *

Бар акыллы, бар ахмак...
Җирдә бар хак вә нахак.
Булса да акыл ахак,
Кызыкмый аңа ахмак.

* * *

Акылы белән югары
Түбәндәрәк тора.
Хикмәт нидәлеген
Тамырлардан сора.

* * *

Авылыннан китсә дә кеше,
Кавеменнән китмәсен.
Кавеменнән киткән кеше
Бәхет өмет итмәсен!

* * *

Тоттым дигәч, югалды төн, —
Очып китте галәмгә.
Көтеп торам, корым булып
Кайтачак ул... каләмгә.

* * *

Син мине кол иттең,
Син мине тол иттең.
Син мине җыр иттең,
Хыялдан чын иттең, —
МӘХӘББӘТ!!!

* * *

Мин көн көтеп, күзем ачам , —
Төн килә.
Шатлык көтеп җаным ачам, —
Кем көлә?

Җанымда төн... җанымда шом —
Караңгы.
Ямый алмам җаным белән
Җаның салган яраны, —
Ерагайттың, ерагайттың
Араны...

* * *

Туган тел ул — җан тамыры.
Тамырсыз җан баермы?
Туган җирдән туган тел тик
Җыя ала ваемны.

* * *

Ташкын көттем — ташкын килде,
Юып китте җанымны.
Давыл көттем — килде дә ул
Ватты өйгән тавымны, —
Килде шундый һәлакәт —
Шундый олы Мәхәббәт...

* * *

Хөкем итү кирәк микән
“Шатлык урлаганнарны”.
... Фикъһе фәне хөкем итсен —
Ялгыш зурланганнарны!

* * *

Газапларны ләззәтләрдән
Аералмас хәлдәмен.
Ярый әле сер сыярлык
Бар бердәнбер каләмем.

* * *

Ак кәгазьгә кара белән
язулар кайчак ялган.
Кара төнгә күңел нуры
Бары хакыйкать язган.

* * *

Балык түгел, син халык бит,
Хаклык бит син, беләмсең!
Телең, җиреңне алсалар, —
Җаның үзең бирәсең...

* * *

Җир минеке, —
Анысы бер бәхәссез.
Җан — минеке,
Әмма бер бәһасез.

* * *

Каберлекләр хәзер
миллионнар.
Шунда, бәлки, җанга
бер сан бар?

## Чәчмә әсәрләр



Айдар Хәлим

# АВЫЛДАШ

*Чаллы рәссамы*
*Миңнехан Шәйдуллинга багышлана*

Моңсу. Бик моңсу.

Сезгә бу кадәр моңсулыкны ничек аңлатырга, ә?

Алдан ук кисәтеп куярга тиешмен: гөлләр, үсемлекләр һәм, әлбәттә, агачлар үстерү буенча белгеч, ягъни, заманча әйткәндә, яшелләндерү буенча инженер — мөһәндис мин. Кешеләр дөньясын бик белеп бетермим, шуның аркасында әллә нинди көлке хәлләргә калам. Нәрсәне яшеллән-дердек соң без, яшеллек мөһәндисләре, гомеребез буе? Әлбәттә, яшеллекне яшелләндердек. Әүвәле корыттык-саргайттык та, аннан яшелләндерергә маташып карадык.

Мин менә әле дә яшелләндереп ятам. Тольятти шәһәренә яшеллән-дерүчеләр кинәшмәсенә килгән идем. Бөтенрәсәй күләмендә үткәрелгән һәм килүе-китүе белән өч көнгә сузылган бу искиткеч моңсу песнәкләр базарында хәтта бүген, апрельнең егерме икесендә, бер генә бөрене дә яшелләндерә алмыйча, Калуга, Новосибирскилардан килгән Николай Ивановичлар белән бергә, теләсәм-теләмәсәм дә, кем әйтмешли, “компания хакына”, байтак кына яшел шешәләрне яшелләндереп, ашказаным чирен кузгатып, тау күчергән адәм сыман арып-талып, кунакханәгә кайтып егылдым әле менәтерәк. Һәм менә шул сәбәпле, нәрсә эшләргә белми, түшәмгә төкереп ятам.

Башыма әллә ниткән уйлар килә башлады.

Әйтегез әле, мин, яшелләндерү мөһәндисе, ошбу шәһәрне беренче тапкыр күрмәгән булсам, үз гомеремдә “кичерү” сүзенең күптармаклы мәгънәләрен аңлап өлгергән булыр идем микән? Ай-һай, ай-һай, дим мин. Шулай да, аларны аңлау өчен миңа мотлак Тольятти шәһәренә килергә кирәк иде микән? Аннан, бу сүзнең катлы-катлы эчтәлеген төшенү өчен бернинди сәбәп, чыгырдан чыгарырлык вакыйга да булмады бит әле. Юк, башымнан чыкмый гына бит бу шайтан котырткан “кичерү” — тукмак белән тукмап, сыргавыл белән сөреп чыгарасың мени аны?! Юк, җәмәгать, миннән көләргә ашыкмагыз әле. Төпченеп китсәң, үзегез дә аңлап җиткермисездер әле бу кәлимәнең бихисап мәгънә нечкәлекләрен, шулай бит? Әйтик, менә сезгә гомумән “кичерү” — хиссияти хозурлану, ярсу-яралану, ярга сугылып, тынычлыгыңны югалту, шартлар хәлгә җитсәң

дә, сиздермәү һәм башкалар, һәм башкалар. Бу бер булдымы? Менә сезгә тагын “кичерү” — һәммә җанлы кемсәне һәм җансыз нәрсәне. әйтик, мәһабәт агачларны, бостандагы гөлләрне күздән кичерү, ягъни мәсәлән, беренче мәртәбә күреп, монсыз башмак сыман күз сирпеп булса да, нәрсәгәдер ышану-инану, фикер туплау. Монысы ике булды, шулаймы? Менә сезгә янә бер “кичерү” гәламәте — гомер кичерү, бу халәтне инде, җәмәгать, теге, бая телгә алган монсыз башмак кебек кенә кичереп булмый, үзегез дә чамалыйсыздыр. Гомер кичергән кешеләр мондый кичерүне шактый катлаулы, четерекле нәрсә диләр... Һәм менә, ниһаять, тагын бер “кичерү” — кемнедер ярлыкау, җир тырнап җылап, үз гаеп-гөнаһларын йолуны ялварган кешене гафу итү, кичерү... Аллага шөкер, бу тарафтан күнелем тыныч, Тольяттида, мондый ярлыкауны миннән, йә булмаса, үземнән көткән адәм юк. Әмма, нишлисең, барасы җире, бер танышы-дусты, туганы булмаган чит-ят шәһәрнең ташландык кунакханәсендә аунап яткан башны нинди генә килде-китте уйлар измәс!..

Кайда гына булсам да, чагыштырырга яратам мин. Хәер, үземнең үткән юлым да чагыштыру аша алга атланган аралык булды бугай. Үзем гомер кичергән Чаллы һәм соңгы көннәрдә генә күземнән кичергән Тольятти арасында тырышып-тырмашып, аларның аеры, кабатланмас, үзенчәлекле чалымнарын эзләсәм дә, әллә-ни һуш китәрлек нәрсәләр таба алмадым: аларның беренчесе, Тукай бабай язганча, “тел вә лөгать алмашып” яшәгән “урыс җирендә”ге Татарстанда, икенчесе, тарихи хәтергә туры калып әйткән очракта, татар җирләрендә кара кан булып оешкан Рәсәйдә, тагын да аныграк итеп билгеләгән хәлдә, Идел уртасында, Жигули дип йөртелгән Җигүле Таулар укасында урнашкан булуына карамастан, бу ике автобашкала, КамАЗ һәм ВАЗ вилаятьләре, игезәкләр сыман охшаш булып чыкты.

Тольятти дигәннән. Алтмышынчы еллар башында Италиядән сатып алынган ФИАТ автозаводы төзелә башлаганчы аның исеме Ставрополь иде. Бу нинди Ставрополь? — диярсез сез. — Кафтау итәгендә бер Ставрополь бар иде бит инде, монысы каян килгән? Һәм соравыгыз дөрес булыр. Алтмышынчы еллар уртасында Италия компартиясе җитәкчесе Пальмиро Тольятти үлгәч, Ставропольне Тольятти исеме биреп яшелләндерделәр. Кайчандыр унсигезенче гасыр башында каракытайлар басымы астында Жунгариядән Рәсәйнең Идел түбәненә, Кафтау капкасы — Ставрополь казаклары җирләренә килеп төпләнә башлаган калмыкларны тышкы чикләрдән аерып, ил эченә, аның ашказаны булган Иделгә куып чигендерү, шулай итеп империя өчен яралып килгән куркыныч көчтән арыну ниятендә Җигүле Таулар җәясендә калмыклар өчен төзелгән резервациягә матур алдак итеп Ставрополь исеме бирелә. Әмма патша калмыкларны бирedә көчләп тота алмый. Унтугызынчы гасыр урталарында барыбер Түбән Идел-Кафтау арасындагы далаларга күченеп бетәләр алар. Хәзер Ставрополь-Тольяттида галәми телескоп белән эзләсәгез дә бер калмык әсәрләре таба алмассыз. Ул бүген, әлбәттә, чын урыс шәһәре.

Әйе, ике автобашкала, игезәкләр сыман охшаш булып чыкты: гүяки ниндидер милләтсез, телсез һәм денсез газраиллар булачак яңа Чаллы шәһәренең генераль сызымын сызып та тормаганнар, җитез яһүди абзыйлар моның өчен бүленгән акчаны Газраиль дип аталган илләрендәге кесәләренә күчергәннәр дә, Тольятти шәһәрен Чаллыга утыртканнар да куйганнар.

Аларның икесендә дә иң кыерсытылган сыйныф — чәчәкләр. Аларны үстерү өчен түтәлләр бөтенләй диярлек каралмаган, каралса, алар кара тузан туздырып, җәй буе иңрәп ята; аларның икесе дә адәм баласын йорттан йортка, урамнан урамга мөмкин кадәр турыдан йөртү өчен түгел, ә мөмкин кадәр башын әйләндереп, миен миңкетеп, уратып йөртү өчен салынган; аларның икесе дә урам, сукмак, торатуар дигән түшенчәләрдән азат — Чаллыда, мәсәлән, тыныч кына һава алыштырып йөрергә дип урамга чыккан авырлы хатын, торатуар эзләп, тора туар; аларның икесендә дә киң автострадалар гына хакимлек итә —безнең кебек җәяүле, мобильсез

хадимнәр бу автострадаларның ян-ягына сылашып, бәреп-имгәтеп китә күрмәсеннәр дип, башларын артка борган килеш алга барырга, җәен көмеш тузанда, газ-ягулык түкерекләрендә тончыгып, көзен исә ләмпычрак янгырында коенып хәрәкәт итәргә мәҗбүрләр.

Бу ике шәһәрдә агачлар да иң кыерсытылган кавемнәргә керә — аларны буйга житә башлау белән кисә-аудара башлыйлар, күләгә, күрәсең, иң куркыныч нәрсә; йортларны да йортлар дип атау дөрес булмас иде — күп катлы, ишекләре тычкан тишекләрен хәтерләткән, диварлары ата-инәсез, теге милләттәге сүгенү сүзләре белән бизәлгән сукбай куначалары — ночлежкалар алар; биредә урамнар исемсез, биредә ниндидер "күмплекс"ләр, бу күмплексләрдә һәр ун кешегә биш мильтон, жиде эт, төрбә-төрмә хөҗрәләрен хәтерләткән, кимендә ике кат тимер ишекле фатирдан сезгә әүвәле нәселле маэмай, аннан соң гына нәселсез адәмзат өрер; әгәр урамнарның исемнәре бар икән, алар Чаллыда артык шагыйрәнә-рәссами — Пушкин, Есенин, Шишкин, ә Тольяттида артык сугышчан-миллитаристик — Ворошилов, Буденный, Блюхер һәм тагын ниндидер маршал Плюхер булыр.

Күмплексләрдә кешеләр тыныч әңгәмәләшер, шагыйрьләр шигырь язар, гашыйклар оялып кына кочаклашыр, яшерен үбешер өчен иркә күләгәле, мәхәббәтле бакчалар, сквер, бульварлар юк — биредә һәр куак, һәр йорт арасы, һәр күләгә исәпкә алынган, кирәксә-кирәкмәсә дә кыек электр яктысы, тәртип сакчыларының күз-колагы белән тәэмин ителгән; аларда мәһабәт һәйкәлләр дә күрмәссез — ниндидер гарип-горәбә, төшенә керсә, куркытып уятырлык гыйфритләр; бишәр-жидешәр йөз мең халыкка нибары бер гомуми, димәк йогышлы чирләр таратучы мунча — ул да Политбюро карары һәм ул раслаган сызым буенча салынган...

Аһ, бу күмплексләр! Аһ, бу күмплексләрдә мәгънәсезгә булса да почмак алу өчен бушап калган мәһабәт авыллар, суелган мал-туар, черегән кызыл маллар, хуҗасыз калган уңдырышлы җирләр, кияү-кәләшсез картайган егетләр-кызлар, ватылган язмышлар, тәнен сатып, азгын чир тараткан зифа буйлар, урамда ата-инәсез калган ятим балалар, фатир алалмау, эшсез калу кайгысыннан эчкелеккә сабышкан әзмәвердәй сукбайлар, авыл белән шәһәр арасында мәгънәсез юл йөреп, җирдә, суда һәм һаваларда бәрелешеп, челпәрәмә килеп, вакытсыз әрвахлар исәбенә тулып калган авыл зыяратлары!..

Аһ, бу күмплексләр! Колакка "кәмпүтер" сыман гайре табигый яңгыраган бу нәмәстәкәйне татарчага "бистә" дип тәрҗемә итәргә мөмкиндер. Әмма аны урам дип тә, бистә-мәхәллә дип тә булмый. Кеше башын каңгырту, аңардан иҗтимагый сарык ясау өчен төзелгән мондый йортлар өере атамасы кайчандыр французлан урыска бары тик күмәклек мәгънәсендә генә кереп, соңгы елларда мәгънәсен бик тә кинәйтте — ул акылга зәгыйфьлек, күмәкләп тилерү, бергәләп акылдан язу мәгънәсендә дә яңгырый башлады. Әйтик, кемгәдер ымлап, сезгә "Анау кешедә күмплекс" дисәләр, димәк, белеп торыгыз — тегенә "житешми", ул "ычкынган", ул "того". Әгәр сезгә кемдер "Мин уналтынчы күмплекстә яшим" ди икән, сез, кинаяне аңлый торган кеше, һич тә икеләнмисез — аңа уналты тапкыр житешми. Димәк ки, егерме алтынчы күмплекстә егерме алты, кырык бишенче күмплекстә кырык биш тапкыр житешми икән бу алла бәндәләренә. Аптырамагыз, көлегез дә куегыз.

Минем үземә, мәсәлән, ундүрт тапкыр житешми. Мин чагыштырмача байлар күмплексендә яшим. Әйтергә онытып торам тагын, кеше баерак булган саен яшәгән күмплексенең саны кечерәк була. Яшеллекне яшелләндерәм дип чынлап та ундүрт тапкыр ычкындым һәм яшәү урыным да ундүртенче күмплекстән әләкте.

Әлбәттә, бу шәһәрләр Политбюро калдыклары. Шулай да "ленинчыл" Политбюрога рәхмәт укырга кирәк: илне бөтенләй урлап-талап бетергән һәм моның өчен хәтта сукыр тычканга да орден тараткан заманда, ярый әле, безгә, фәкыйрьләргә шундый булса да күмплексләр төзеп калдырган...

Кайчандыр иске Чаллы үзе дә бары тик Чаллыдан гына торган. Ни сөйләвем анлашылмый, шулай бит? Ашыкмагыз, хәзер анларсыз. Яңа Чаллыны төзибез дип мең еллык тарихы булган иске Чаллыны су астына җибәргәч, алмашынган кешеләр яңа Чаллының исемнәрен ифрат та ишәйттеләр һәм камилләштерделәр. Сидоровка бистәсен алыйк. Анда сирәк-сарак кына пенсионерлар, күбрәк кәҗә-сарыклар һәм этләр яши. Ул бердәнбер урамнан тора. Анысы да Сидоров урамы. Ә Сидоровны кем булган дисез сез? Ай-һай зур, ай-һай бөек кеше булган ул Сидоров әфәнде. Большевикларның нәрсә икәнлеген дә анлап өлгермәгән, гомерендә мәптек бусагасын күрмәгән батрак-чекист Сидоров бер үк көншәдән ике контраны —православие атакаен һәм мөселман мулласын дөмектергән. Әлбәттә, бу батырлык эзсез югалмаган — каһарман хөрмәтенә бистәгә, житмәсә аның бердәнбер урамына аның исемен биргәннәр. Дөрес эшләгәннәр. Һәм бу каһарман мөстәкыйль Татарстанны үз байрагы астында өченче мең елга алып чыгып килә. Рәхмәтләр төшсен аңа.

Яңа Чаллыда тагын бер бистә бар. Аны татарлар ЗӘП, урыслар ЗЯБ ди, ягъни “завод ячеистого бетона” була инде. Татарчага әйләндерсәк, күзәнәкле бетон, юк, гафу итә күрегез, бака күзле бетон бистәсе. Матур бит, җәмәгать? Әлхасыйл, “Сез ЗӘП-кә бармыйсызмы?” дигән сорауны тулы итеп биргәндә, “Сез күзәнәкле бетон заводы бистәсенә бармыйсызмы?” дияргә туры килә. Әлбәттә, әле күптән түгел генә бу урыннарда дистәләгән Баллы Каен кебек гүзәл авыллар шаулап утырган. Әмма яшеллекне корытып яшелләндерүчеләр, тишекле бетончылар кабиләсе хакимлек иткән Татарстанда бистәләргә эзсез югалган Баллы Каен исемнәре биреп утырып булмый бит инде!.. Аннан, безнең атаклы Чаллыбызда тагын бер бистә бар икән бит әле — анысын татарлар ГИС, урыслар ГЭС диләр. Ягъни, пашпортына туры китереп әйтсәк, “Гидроэлектрическая станция бистәсе”. “Сез су белән электр барлыкка китерүчеләр бистәсенә бармыйсызмы?” була инде монысы. Әлбәттә, борынгы заманнарда, әйтик, моннан егерме-утыз ел элек бу җирләрдә матур-матур Тубылгытау авыллары гөрләп торгандыр. Әмма су белән электр житештерүчеләр хакимлек иткән азат Татарстанда ниндидер Тубылгытаулар белән вакланып торалармыни!..

Монсу миңа. Аһ, бик тә монсу!..

Күземне йомам. Көзге өзектә пычрак чәчрәтеп, бистәдән бистәгә чапкан Чаллы автобуслары алдыма килә... Биш гасырга якын урысча укып, наданлашканнан наданлаша барган милләттәш хатын — кондукторның игъланы ишетелгәндәй була:

— Гражданый, прәбритәйти билити! Салуный рабутаит ыс талуный. Ыслидуши астануфка — хлипзабут!..

Йә, ходаа, чит шәһәрдә япа-ялгыз калсаң, нәрсәләр генә башыңа килмәс!..

Нәкъ шул мизгелдә, кемдер касыгыма төртте диярсең, сикереп тордым, калтыранган бармакларым белән пинжәк кесәсендә кармана-актарына башладым. Бәй, кесә шәрифләремдә Тольяттига китәр алдыннан гына авылдан, бертуган абыемнан килгән хат ята ләбаса! Киңәшмә мәшәкатьләре белән мин аны онытып җибәргәнмен икән. Яшибез болай булгач! Хатны тартып та чыгарам, яшәргән күзләрем белән йөгерә дә башлыйм: “... Син Тольяттига барсаң, Хәбир туган, Сөендекләргә керми калма. Аның хатыны маржалыкка маржа, әмма Сөендеккә, бәхетенә каршы, маржаның бик тә уңганы, кәттәсе туры килгән. Үзең беләсең, Сөендекнең әнисе Фатыйха абыстай безнең әнинең гомерлек әхирәте иде. Әтисе Закир абзый исә әтинең җан дусты булган. Аннан алар, чыбык очы булса да, безгә туган тиеш кешеләр. Кереп, күреп чык. “Туганның азары булса да, бизәре булмас”, дигән борынгылар. Сөендекләр авылга еш кайталар. Ул кайткан саен сине сораша, утыз елга бер булса да күрешергә иде, ди. Адресы...”

Барам, әлбәттә, барам! Бармый була диме? Авылдашка бармый буламы? Без, татарлар, бөтен дөнья буйлап авылдашлар бит! Кара әле,

мин дә инде, адәм актыгы, шундый бәхет-сәгадәтне онытырга мөмкинме?! Үзем дә сизмәстән, шатланып китеп, йодрыгым белән өстәлгә суктым. Әлү-әлү!.. Авырткан кулымны һавада селкетеп, киенә дә башладым. Әйе, әти белән Закир абзый бер кашыктан ашап яшәгәннәр. Әти сугыш яланында ятып калган, ә менә Закир абзый, кулын өздереп, исән-сау урап кайткан. Фатыйха абыстайга ул сугышка кадәр өйләнсә дә, нәсел маясы калдырырга өлгерә алмый. Сөендек аларның сугыштан соң беренче һәм соңгы сөенече. Шуңа күрә малайга безнең якларда сирәк очраган Сөендек исеме кушалар да. Ул миннән алты-жиде яшькә бәләкәйрәк булыр. Һәрхәлдә, Баллы Елга буйларында казлар көткәндә безгә тагылып үсте ул. Дәфтәр битеннән ясалган кәртләр белән уйнарга да өйрәттем әле мин аны. (Укучым моны берүк бозыклык саный күрмәсен!)

Безнең кояш чыктымы-юкмы, анысын әйтүе авыр, әмма шунысын беләм: Сөендек сигезенче сыйныфтан ары укымады. Колхозда башта төрле эшләрдә, аннан яңа төзелгән "Дуслык" дуңгыз күмпликсендә эшләп азапланганнан соң, хәрби хезмәткә китте һәм авылга бүтән әйләнеп кайтмады. Фатыйха абыстайга килсәк... Фатыйха абыстай... Туктагыз әле. Йөрәкне нидер чәнчеп алды. Бер генә минутка туктагыз. Рәхмәт, үтте. Закир абзый туксанны әвәләп барса да, ходайга шөкер, яшь карчыгы белән матур гына дөнья көтеп, җон тетеп дигәндәй яшәп ята. Яшь җиңгәчәйнең балалары ярдәмендә үзенә җитәрлек мал да асрый, умарталар да тота. Авылның мулласы вазыйфасын да башкара әле ул Закир абзыкай-гынам.

Фатыйха абыстайга килсәк... Фатыйха абыстай...

Мин урындыкка бөгелеп төштем.

Сөендекләргә барыргамы, юкмы? Әниләренең фаҗигале язмышын көтмәгәндә хәтерләренә төшереп, уңалган яраларын яңартмаммы? Корымаганмы Сөендек энекәшнең күңел агачы? Аның тамырларына җир катламнарыннан шифалы мәгъдән киләме? Корымаган хәлдә, бәлки аларны борчымаска кирәктер? Мин дертләп куйдым, гүяки миңа Сөендек белән очрашу өчен аның күңел агачының коруы, газиз әнкәсен онытуы хәлиткеч шарт иде...

Хәер, Сөендек, әйткәнемчә, миннән алты-җиде яшькә генә кечерәк булса да, безнең буын кешесе түгел иде. Илленче-алтмышынчы еллардагы искиткеч кыска аралык безнең буыннарны танымаслык дәрәҗәдә ераклаштырды да куйды. Без —Сталин, алар — Хрущев, без — балтырган, алар — икмәк, без —чабата, алар — итек, без — тальян гармун, патефон, алар — радио-телевидение буыны иде. Соңыннан аңлавымча, минем Казан авыл хуҗалыгы институтының яшелләндерү һәм җир-сазлык киптерү бүлеген тәмамлап, яшелләндерү буенча мөһәндис булып китүем дә шушы аерымлыкка каршы фетнә, бездән соң корый башлаган буыннар агачын яшәртү теләгенә бәйле булган икән. Мин аны ниндидер алтынчы тоем белән тойганмын, күрәсең. Яшәртү-яшелләндерү теләге үземнән соң тормышка юл алган буынны, фәлсәфи тел белән әйткәндә, инкяръ итү аша яшәртү булган...

Хәлсез генә күтәрелеп, урыныма барып аудым. Кичке сәгать алты да икән инде. Язгы озын көн, әле караңгы төшәргә иртәрәк иде. Тәрәзәдә ниндидер иртәләгән шәфәкъ һәм офыкны алсуланып кискәләгән болытлар. Әйе, вакыт дигәнең ага. Ага, чөнки аның эше юк. Ул кеше кебек ашыкмый, каударланмый, чәбәләнми. Чарасызлыктан һәм эшсезлектән бетәшкән карашым белән бүлмәмне күздән кичердем. Бәй, бирредә бер генә гөл дә юк икән. Радиосы өзек — акча юк, телевизоры, телефоны эшләми — акча юк. Боларын аңлыйм, ә менә гөл юклыгын һич тә аңлый алмыйм. Аһ, хәзер гөл үстерергә дә акча кирәк бит әле! Хәер, бу унике катлы бинада, беренче катта, байбичә шикелле җәелеп утырган, тузаны айлар буе сөртелмәгән карт фикусны исәпкә алмаганда, гөл ишараты юк та шикелле. Бәй-бәй-бәй, аның каравы, минем шыр ялангач торагым җан ияләре белән тулы икән ләбаса! Ярыклардан, тәрәзә яңакларыннан, шыксыз стеналардан, урыс кардәшләребез инануынча, һәр өйгә байлык-

мөлкәт ташучы жанварлар — тараканнар карап тора. Житмәсә, һәркайсы мыеклы. Мин чирканып куйдым. Ике төнемне монда ничек үткәргәнмен? Әйе, әйберләрне жыештырырга, Сөендекләргә барырга, шунда кунарга һәм шуннан ук кайтып та китәргә кирәк!..

Үзем исә һаман урында ята бирәм. Әйе, абыем дөрес язган, әнием Шәмсекамәр белән Фатыйха абыстай бер тамырдан яратылган ике гөлдәй яшәделәр. Балачагымда кич утырганда аларның үз язмышлары турында пышын-пышын сөйләшкәннәрен хәтерлим. Фатыйха абыстай, Айдарәленең унсигез яшьлек корьәнхафизәсе, утызынчы еллар азагында безнең Айтуганга килен булып төшә. Соңыннан белүемчә, таулар арасына сыенып яткан Айтуганга качып котылган ул. Закир абзыйга рәхмәт инде. Югыйсә, Фатыйха абыстайның башын да әтисе Суфиян мулла белән бергә Себердә черетәселәре булган. Үз гомерендә чебенгә дә кул күтәрмәгән әтисе кызу печән өстендә, көтмәгәндә халык дошманына әйләнә дә куя. Шулай, Келәвеш урманы аланында печән чабып яткан мулла абзыйларына авылдашлары үтеп барышлый әйтеп куймасынмы:

— Ай-һай, чалгың шәп чаба, хәзрәт!

Хәзрәт исә, ходай шомлыгына каршы:

— Шәп чапмаска, Николай чалгысы бит ул! — дип жавап та бирмәсенме!

Алты гына кәлимәдән торган шушы жөмлә житә дә куя Суфиян мулла башына...

Фатыйха абыстай да, минем әни дә гүр иясләре инде. Дөрес, әнием баш мие өянәге белән ахирәтеннән нәкъ чирек гасырга алдан китеп барды. Гомере буе ялгызлык кичерде ул Шәмсекамәреннән башка. Ел саен корьән чыкты ул Шәмсекамәре рухына!

Авылга кайткан саен мин аны күрми китми идем. Шулай бер тапкыр, урамнан үтеп барганда, ул мине чакырып алды.

— Кара әле, Хәбир, сиңа монавындый асалы паласлар ошыймы? — диде ул сандык өстенә таслап куелган өч паласны аерым-аерым идәнгә жәеп. — Монысы рауза чүпләме. Якты, зиһенле сурәт, әйеме? Монысы канәфер чүпләме. Өзелепләр тора, шулай бит? Ә монысы әүхәдия чүпләме. Бөгелешләренә игътибар ит!..

Мин тынсыз калдым. Асалы палас сугучы остабикәләр авылында туып-үссәм дә, минем мондый гүзәл сәнгать әсәрләрен, валлаһи-биллаһи дип әйтәм, күргәнем юк иде.

— Бәй, макта инде, нигә мактамыйсың? — Фатыйха абыстай көнбагыш мәмәс сыман ак, вак тешләрен жемелдәтеп кеткелдәде. — Берсен Сөендегемә мәһәргә, икенчесен булачак киленемә бүләккә, өченчесен булачак онык-онычкама истәлеккә дип суктым. Әйдә, егерме беренче гасырга чыксын минем бүләкләрем!..

Ул бу мизгелдә гадәттән тыш шат иде.

— Сүз таба алмыйм, Фатыйха абыстай, — дидем мин чынлап та уңайсызланып. — Сина, сүз остасына, сүз табуы да читен!..

— Табарсың әле, табарсың! Хәзер чишәбез аны, синең телеңне! — Ул сөйләнә-сөйләнә мич аралыгына кереп китте һәм мин яраткан балавыз сыман сап-сары, ачы балын күтәреп чыкты. — Мә, эч әле. Үзе салкын, эчендә ялкын!..

Аның теленең байлыгын, сихри сыгылмалылыгын белсәгез иде сез! Тукайны, хәтта Сәгит Рәмине яттан сөйли иде, мәрхүмәкәй. Үзе дә бәетләр, шигырь-жырулар чыгара иде. "Үзең чыгардыңмы? Үзең түгелдер лә!" дип үртәүчеләр булса, һич тә аптырамас, "Әйе, эти мәрхүм әйткәнчә, Тукайныкы булырга тиеш ул!" дип кенә авызларын яба иде.

Хәзер сез ишетәчәк "Самавыр бәете" дә үзенеке аның. Ялгышмасам, алтмышынчы еллар азагы, тагын да шул печән өсте иде булса кирәк. Яланнан кайтышлый сугылдым мин аларга, үнәчем бик тә сусаган, көйрәгән иде. "Сусаудан басарга яхшы, мә әле, авыз ит!" дип ул бу юлы да миңа ачы бал сузды. Аннан жәйге чолладә тәрәзә капкачлары ябылган,

салкынча өйнең алгы ягына алып керде, терсәк астыма мендәр ыргытып, асалы паласка янтайтып яткырды, үзе дә артына мендәр җайлаштырып, аякларын бөкләп утырды. Гел актан гына киенергә яраткан, зәңгәрсу яулыгын биленә төшереп, турыдан ачылган чәчләреңең алдагы көмеш учмасын гына күрсәтеп бәйләгән, аксөяк чырайлы, тәрбияле йөзле, зыялылыгы кыяфәтенә чыккан Фатыйха абыстай бу мизгелдә май урталарында котырып чәчкә аткан ак сиреньне хәтерләтә иде. "Халхуз эше беркайчан да бетми, Хәбир ыланкаем, әйдә әле, монавы нәмәстәне тыңлап карыйк, бер кирәге чыкмаса, бер кирәге чыгар", дип бәетне укырга әзерләнде. Бу аның өчен үзе бер бөек, илаһи йола иде, күрәсең. Әүвәле кара җирдә, кара җирдән соң балда һәм майда, актан-ак сөттә һәм сөзмә-катыкта җепшенеп буынланган ак бармаклы кулларын тез очларына куйды, борынгы чичәннәр, һун философлары сыман күзләрен йомды һәм, зиһенен җыеп, беравыкка тынып калды. Бу мизгелдә ул үзе дә комда ышкып ялтыратылган самавырга әверелгән иде. Тәрәз капкачлары арасыннан үткән кояш нуры кылыч булып бу алиһәне урталай ярган иде. Мин нәрсәдер сизендем. Бүлмәдә "Бәдәвам" ны хәтерләткән мәкам яңгырады:

Самавырның шарты алтый
Ки, эче — гәүһәр, тышы-балкый
Ки, самавыр берлә чәй эчсәң
Ки, гамең артыр, йөзең яктый...
Бу чәйнең шартлары бардыр
Ки — таң вакты берлә кайнар
Ки, килеп яныма утырса
Ки, чәй берлә кerә гамь-дәртләр...
Чәй эчмәсәң, хәлең начар
Ки, чәй эчсәң, йокың качар
Ки, гамьле чәй — ямьле әсәр
Ки, укысаң — кайгың басар...
Чәй эчәргә утырдым мин
Ки, калагымны тутырдым мин
Ки, калакны катык түгел,
Баллар берлә тутырдым мин...

Озак та үтми миңа, институттан КамАЗга юнәлеш алган яшь белгечкә, Сөендекнең хәрби хезмәттән соң, комсомол юлламасы буенча икенче бер бөек коммунизм төзелешенә — ВАЗга кайтып төпләнүе, маржага өйләнүе турында хәбәр килеп ирешә. Күз алдыма ни өчендер кара кырау суккан ак сирень рәвешендәге Фатыйха абыстай килеп басты. Мин ул чакта үземне бераз битәрләп тә алдым: "Нишләп әле ул сиреньне кырау сугарга тиеш? Халыклар дуслыгының өлгесе булган илебездә катнаш гаиләләр һәм мондый бәхетле гаиләләр азмыни хәзер?" Шулай да бу уй мине ээзәрлекләп газаплаудан туктамады. Гүяки, маржа белән Сөендек яшәргә тиеш түгел, ә аңарга, мин белмәгән кавем хатынына, ак сирень бакчалары белән Фатыйха абыстай өйдәш булып керергә тиеш иде. Икенче бер кайтуымда мин аны гадәттән тыш йончыган, таушалган, кыяфәттә күрдем. Әллә нинди яңгырлы-бозлы, эре чебеннәр гәүдәләрен күккә күтәрә алмый, җирдән сөйрәп йөри торган ел иде ул. Фатыйха абыстайның йөз сулары сулган, әле күптән түгел генә ак сөт кебек якты, тәрбияле, зыялы чыраен нәселсез җыерчыклар баскан, сүнеп калган күз төпләренә кара бөҗралар кунаклаган... Мине күрү белән ул җанлана төште һәм, кеше ишетмәсен дигәндәй, шикләнеп һәм як-ягына каранып, сөйләнергә керешә:

— Син җылама, Хәбир ыланкаем. Җылама. Авыр булса да җылама. Түз. Мин менә шулай түзәм. — Ул ун бармагын йодрыкка төйнәгәндәй яртылаш бөкләп, амин тоткандай итеп борын очына китерде. Шул мәлдә мин аның сул кулының "атсыз" бармагыннан сабый чакларымнан күреп өйрәнгән яшел ташлы балдагының ни сәбәпледер салынган булуына

тетрәндем. Ул исә сөяк булып каткан карашы белән шул йодрыкларына тупланып, ялвара башлады:

— И раббым, сабырлыккайлар бир! Сабырлыккайлар!.. Ун бармагым, ун фәрештәмнең канатлары бул! Ун фәрештәм, ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр! Ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр!..

Аның күзләре бер бөек эш башкарган кебек тәмам пыялаланды. Кинәт ул миңа таба борылды, әле генә төссез күзләреннән кайнар очкыннар очырып, шаркылдап көлә башлады:

— Ха-ха-ха-ха-ха! Хәбир ыланкаем, синең дә Ликсәндрең бармы? Безнең бит Ликсәндребез бар!..

— Нинди Ликсәндр, Фатыйха абыстай? Син нәрсә сөйлисең?!

— И-и-и, белмәгән кеше булып кыйлана тагын? — диде ул көяләнеп. — Бу хакта бөтен дөнья сөйли бит! Әле генә ырадиудан әйттеләр, кич белән тилебизырдан әйтәчәкләр. Минем Тәләттидәге Сөендегемнең улы бар бит — Ликсәндр кушканнар. Ха-ха-ха-ха-ха! Көл, нигә көлмисең, ыланкаем? Аны миңа сөяргә рөхсәт итәрләр микән? Әй, итмәсәләр, мин Брежневкә хат язам! — Ул мич арасындагы кисәү агачын алып, кочагында тирбәтә һәм шырды-бырды такмак әйтеп, идән уртасында бии башлады:

Уңар микән, уңмас микән
Яна онның белене,
Исән булсам, булам әле
Брежневнең килене!..

Мин күзләремне йомдым. Аларны кан баскан иде.
Фатыйха абыстай биюен дәвам итте.

Кызыл фылаклар жилферди
Мәсжед манарасында.
Мәсжедләрне хылуб иттек
Сәвит заманасында...

Фатыйха абыстай тилергән иде.

Ун бармагымны күз алдыма төйнәп, Ходай Тәгаләгә инәлдем: "Сабырлык-кайлар бир! Ун бармагым, ун фәрештәмнең канатлары бул! Ун фәрештәм, ун тапкыр төшереп, ун тапкыр күтәр! Ярабби!"

Ниһаять тынычланып, ул үз хәленә кайтты.

— Тигез генә яши күрсеннәр! Киленебез, маржа булса да, бик һәйбәт, бик унган ди, ыланкаем. Бәлки әле кайтып та күрерләр. Мәһәрләрем, асалы паласларым көтә! Ничек инде ул, маржа да булсын ди, уңмасын да ди, шулай бит? Мин аны ничек кенәләр хурлыйм ди, шулай бит? Бар, хурлап кара! Кемне хурлыйсың — үзеңне хурлыйсың, шулай бит? Мин, хак мөслимә, шул түбәнлеккә барам диме?!

Фатыйха абыстай бүлмәне балкытып елмаеп җибәрде.

Ул үз акылында иде.

Өченче бер кайтуымда мин аңың сөян кебек аксыл, кипкән гәүдәсен кемнендер ихатасында күреп калдым. Без абзый белән тагын да шул печәнгә китеп бара идек. "Бөтенләй алмашынды, бахыркай, — диде абзый. — Тәки сүнеп бара бит кеше дигәнең. Шулай йорттан йортка йөреп, мәтрүшкә күзе җыя..."

Арбадан сикереп төшеп, йорт ихатасына үттем. Бәбәй итәкле күлмәген кигән, аның өстеннән чәчкәле алъяпкыч бәйләгән Фатыйха абыстай миңа каршы чыкты.

— Ә-ә-ә, кайттыңмыни, Хәбир ыланкаем?! — диде ул минем белән исәнләшмичә дә. — Бик әйбәт булды әле бу!.. Мәтрүшкә күзенә синә да налук салам!.. Һәркемнән бер әчмуха мәтрушкә күзе! Бер карасаң, күп тә түгел, шулай бит, ыланкаем? Әмма шуны да бирмиләр... Авылдашларны әйтәм! Син дә бирмәссен микән?

— Ә нәрсәгә ул сиңа, Фатыйха абыстай? — дидем мин кызыксынып.

— Бәй, Тәлләттигә, бәбкәйләремә җибәрәм!.. Ул кулындагы эскәкне уйнатып алды. — Һәр күзне эскәк белән чүплим!

Берничә ел авылга юл төшмәде.

Әмма хатларда Фатыйха абыстай турында хәбәрләр килә торды. Аның кояшлы-караңгылы булып алмашынып яшәве авыл өчен күптән инде сер түгел иде. Авылдашлар аны үз итеп кызганды, аның кайгысын үз кайгысы итеп эчкә яшерде. Хатынының җәй көне кар көрәп, кыш көне тырма күтәреп печән җыярга чыгып китү очракларын Закир абзый сиздермәскә тырышты, дөньясын шул хатыны белән өстерәде, зиһене ачылган чакларда аны, берни булмагандай, сугым ашына да, коръән ашына да, кунак-мазарга да үзе белән йөртте. Менә, ниһаять, туган яклардан үкенечле хәбәр килеп иреште: үзе Тольяттиларга барып йөри алмаган, балалары кайткан хәлдә дә Сөендегә генә кайткан Фатыйха абыстай, баласының баласын сөюдән, аңа үз телен, үз иманын, үз бисмилласын сендерүдән мәхрүм ителгән Фатыйха абыстай, якты кайгысыннан бер генә бөртек кара чәче дә калмаган, үзе дә самавыр сыман саргайган, зиһен белән зиһенсезлек, акыл белән акылсызлык, бербөтенлек белән алмашыну арасында тирбәлгән Фатыйха абыстай, коръән битләре арасындагы зәгъфран чәчкәсе кебек кипкән-корышкан Фатыйха абыстай әбиләр чуагы өстендә үзенең әхирәте Шәмсекамәр кабере өстендә җан тәслим кыла...

Бу хәбәрне ишеткәннән соң йөрәк өянәге булып, мине шифаханәгә салганнар.

Аны алмашынган чакларында чыгып китеп югала торган урман эчләреннән, су-басу буйларыннан, җәйләүләрдән өч көн буе эзлиләр. Бу көннәрдә үлем-китем булмаганлыктан, зиратка кереп тә карамыйлар — мәетне көньякка китәргә дип туплана башлаган кара каргалар туплавы табып бирә. Алар яу булып каберлек өстендә өереләләр, кар да кар килеп авылга шом салалар һәм гәүдәне күтәреп, зираттан алып чыккач кына, авыл өстендә хушлашу божрасы ясап, ерак сәфәргә чыгалар.

Фатыйха абыстайны баш астына әтисенең коръәнен салып, зур хөрмәт белән җирлиләр.

Менә мин хәзер аның газиз улы һәм шул газизенең гаиләсе белән очрашырга тиешмен.

Әйберләремне алып, кунакханәдән чыктым. Яз тәмамланып баруга карамастан, агачлар быел яшәрергә ашыкмый. Җир әле булса җылынып бетмәгән, күрәсең, табаннарга туфрактан салкын сылаша. Һич кенә дә яфрак ярырга теләмәгән куаклар миннән, яшелләндерү мөһәндисеннән качканнар — артка чигенгәннәр кебек күренә. Ворошилов урамын кисеп, Луначарскийга үткәч, мин кирәкле йортны тиз таптым.

Лифт сигезенче катка йөгертеп күтәрде. Ишектә мин көткән "Мәкәримов С. З." урынына ниндиер "Макаренко С. З." дигән язуны күреп, мин бик гаҗизләндем — бутамаганмындыр ла? Шикләнеп кенә кыңгырау төймәсенә бастым. Зеңгелдәү бик көчле булып чыкты, ахры, мәйданчыктагы дүрт фатирның дүртесеннән дә яшелле-зәңгәрле аһәңнәрдә этләр өрде:

— Һау-һау! Гав-гав! Бр-брр! Ләң-ләң!..

— Пош-шол, Барсик! — каршысында мин басып торган фатир эченнән ир тавышы ишетелде. Келә ачылуга ишектән бик нык үзгәргән, әмма әле бала чакта, гафу итегез, маңкасын агыза-агыза безнең арттан тәпиләгән авылдашымны танып булган адәмзат күренде:

— Е-мое! Кемне күрәм!.. Исән генәме, Хәбир абзый!..

Сөендек мине ишек аша тартып алып диярлек кочаклады.

— Әйдә, чишен!..

Мин аның кулына күчтәнәчләремне сондым.

Өс киемемне кайсы чөйгә эләргә, аннан мине кайсы бүлмәгә алып керергә, аннан кая утыртырга белми бөтерелгән Сөендекнең авызыннан яшь, әле генә эчелгән аракы исе килеп куйды. Аяк астында уралган эт белән залга үткән арада йокы бүлмәсеннән йокының үзе сыман чайкалып, симез, билсез-

нисез генә турыдан төшкән квадрат гәүдәле, өстенә капланган мул халаты белән ниндидер хәрби мөлкәтне хәтерләткән ханым килеп чыкты.

— Хатыным Әлефтинә Петрауна була. — Сөендек мина таба ымлады. — Ты не мужеш, Әли, пристәвит, авылдашыбыз, туес землягыбыз дәдә Хайдар сам пришул!..

— Ага. Вижу.

Алевтина Петровна шундук аш-су бүлмәсенә чумды, суыткычны шалтыр-болтыр ачкалый, газ плитәсендә чаж-чож килә башлады.

Фатирда болыт астына бер кереп, бер чыгып торган эт куяшы яктысы һәм ачыган эт исе йөзе иде. Бирелдәге тормышның чагыштырмача житешлеге, хатынның безнең турыда кайгыртучанлык күрсәтеп, аш-су әзерләп маташуы күңелемдә разыйлык тудырды булса кирәк, телемә беренче күрешүдә гаилә башлыгына әйтелергә тиешле хушбүләк сүзләре килде:

— Бичәнең тәгаенен тапкансың, Сөендек туган. Маладис. Күзең очлы икән.

— Безнең күзләр, Хәбир абзый, үзең беләсең, солыдан әбчүк * эзләп очланды бит. — Сөендек мут елмаеп куйды. — Е-мое! Онытып торам тагын!.. Хәзер!..

Һәм ул тышкы ишектән юк булды.

Мин фатирны күздән кичердем. Гөлләр монда да күренмәде. Җиһазлар арасында Фатыйха абыстайның асалы паласларын, тәрәз кашагаларына элә торган чүпләмле тастымалларын эзләдем. Идән, хәтта стеналар келәм белән капланган булса да, асалы паласлар күзгә чалынмады. Күкеле сәгатьнең ике як канатында хуҗаларның ялгызак, парлап, балалары белән төшкән фотосурәтләре. Фатыйха абыстай белән Закир абзыйга гына урын табылмаган иде монда. Кечкенә китап киштәсе аллы-гөлле тышлыктагы чит ил детективлары белән шыплап тутырылган. Алар арасында Пушкин да, Тукай да шәйләнмәде. Кеше кулында майланып, таушалып беткән бу үтереш-суеш әсбапларыннан яңгырлы елда тозлап өелгән, җилдә җилләнмичә, сәнәктән үткәзелмичә сырсыган печән исе аңкый иде.

Шешәләре белән шалтырап, ниһаять, Сөендек килеп керде. Аның тирле борынынннан бөтен өй эче тирләгәндәй итте.

— Әйдә, Хәбир абзый, чәй әзер!..

Өстәлдә безне җылытылган кәбестә ашы, йомыркада куырылган дуңгыз ите, кәбестә бөккәннәре, тагын да тозлы кәбестә һәм Сөендек әле генә токчаеннан чыгарып куйган ярты аракы каршылады.

— Ничек кенәләр Тольяттига килергә иттең дә, ничек кенәләр безгә керергә иттең, Хәбир абзый!- дип өзгәләнде мине түргә утырта-утырта Сөендек. Аның һичбер тартынусыз саф татар телендә сөйләшүе, саф мәкамендә Фатыйха абыстай чалымнары ялтырап китте. — Рәхмәт, Хәбир абзый, яме!.. Әйдә. Әле, и ты с нәми!..

Газ плитәсе белән өстәл арасын шыплап тутырып, урталыкка килене-без Алевтина да утырды. Аның йөзендә кунакка булган куаныч та, үкенеч тә чагылмый иде. Киресенчә, ул үтәгән мәшәкатьләр көндәлек, табигый канунны тәшкил иткәнлектән, килен кеше миңа карата тәмам битараф иде. Мин аның өчен сорау билгесенә дә, өндәү билгесенә дә әверелә алмадым, күрәсең. Мин аның өчен гүяки сөекле иренең авылдашы, карындашы түгел, әле кайчан гына буш булган урындыктагы "Бу бәндә кайчан китәр икән?" дигән җиһаз гына идем...

Сөендек аракылы бәллүрләрне минем хөрмәткә тәкъдим итте. Сары чәчләре меңләгән вак, сырга сыман бөдрәләр белән калтыранган, бер күзе бер, икенчесе гүяки икенче басуда урак урган күзләрен уйнаклаткан Алевтина Петровна белән Сөендек өйрәнелгән алымнар белән эчеп

---

* О в с ю г — кара, чүп солы. Сугыштан соңгы елларда, кыш айларында, чүп солыдан арындыру өчен һәр гаиләгә кеше башына берәр центнердан орлыклык солы тараталар иде. (*Автор тәрҗемәләре*).

жибәрделәр. Мин үземне уңайсыз тойдым: ашказаны хастасын янадан кузгатуым турында укучыма әйткән идем шикелле инде. Хәлемне анлатырга тырышсам да, Сөендек ай-вайга куймады:

— Е-мое, Хәбир абзый! Син нәрсә, пнимаешь? Как не раднуй!..

— Бергәлек хакына! — Алевтина Петровна беренче тапкыр елмаеп җибәрде. — Сез инде бөтенләй! Бергәлек хакына яһүд тә асылынган.

Сөендек мине чын-чынлап буа, көчләп эчерергә кереште:

— Син аны, Хәбир абзыкаем, ашаганчы эч. Ашагач, исертми ул!..

Кешегә каршылык күрсәтә белмим. Шул сыйфатым аркасында күпме тапкыр көлкегә калдым инде мин? Бу юлы да бирештем булса кирәк. Нәрсә булса да булыр дип, ялкынлы суны бугазымнан эчкә үткәрдем. Ашказанымда нидер көйдереп алды, баш миемә, арка үзәгемә җылы шаукым йөгерде. Мин, көне буе диярлек кайнар аш күрмәгән мосафир, ипиләп кәбестә ашын менгезә башладым.

Бәллүрләр янадан тутырылган иде. Мин хуҗалардан авыл, әтиләре, вафат булган әниләре — Фатыйха абыстай турында бер генә булса да сүз көттем. Әмма алар сүзне миннән көтә иде.

— Хөрмәтле Сөендек туган һәм Алевтина Петровна! Сезнең белән очрашуга мин ифрат та шатмын... — дидем мин һәр сүзне авырлык белән сытып чыгаргандай. Мин бу минутта мөнбәрдән нотык токан райком вәкилен хәтерләткәнмендер дип уйлыйм. — Сөендекне утыз елга якын күргәнем юк иде. Сонлап булса да, сезләрне кавышуыгыз белән кайнар котлыйм. Сез вакытыгызны бушка үткәрмәгәнсез. Бик матур гаилә коргансыз, балалар үстергәнсез...

— Балаларыбызның икесе дә музыка мәктәбен тәмамладылар! — дип бүлдерде Сөендек. — Татарча да беләләр!..

— Мин бу бәллүрләрне сезнең тигез мәхәббәтегез, балаларыгызның матур киләчәге өчен тәкъдим итәм!..

— Е-мое, Хәбир абзыкаем! Рәхмәт сиңа, яме! Мәхәббәт —это... За мәхәббәт пьем, Әленушка! — Сөендек сыекчаны авызына койды да, урындыгын шыгырдатып, хатынына үрелде һәм, чупылдатып, битеннән үбеп алды. — Минем Әлиям... Минем Әлиям исән генә булсын! Танышкан чакларда, кхе-кхе... мине "Татарин мой, йөдрүний мой!" дип кенә сөя иде... — Сөендек көтмәгәндә ике йодрыгы белән өстәлгә шап итеп сукты, теге бүлмәдә тыныч кына яткан эт бу тавышка лүрт-лүрт йөгереп кереп, Алевтина Петровнаның бот араларында урала башлады.

— Акылсызланма, Саша!.. Ычкындың мәллә? Мин сине беркайчан да татар дип атамадым, ә бары тик "Тыгыз тәнлем минем, сөннәтлем минем!" генә дия идем.

Өстәл астында дау күтәреп, эт тынычлыгыбызны алды.

— Яле урыныңа, Мәкәримов! — диде Алевтина Петровна эткә аягы белән тибеп. — Урыныңа бар дим!

Нәселле пинчер стенага елышып кына үз урынына чыгып китте.

— Минем фамилиямне эт белән бутама, Әли! — диде Сөендек хатынына куркыныч караш ташлап. — Шашма, дим!

— Син мәзәкне анламыйсыңмыни? Шаярырга да ярамыймы?

Минем башта әллә нинди сораулар, уйлар кайнаша башлады. Кулга гармун аласы, "Карурман"ны сузасы, эчебездәге барлык сагышларны бушатасы, рәхәтләнеп үз телебездә сөйләшәсе, әрләшкән хәлдә дә үз телебездә генә әрләшәсе, барлык туган-тумачаларны, танышларны искә төшерәсе килеп китте.

Сөендек бушаган шешәсен өстәл астына шудырды да, аннан икенчесен тартып чыгарды.

— Авылга кайтканыгыз бармы соң? — дип сорадым мин Алевтина Петровнадан. — Сагындырамы?

— Балалар белән бер тапкыр кайткан идем. Миңа нәрсә калган инде анда? Сашаның әнисе үлгән. Әтисе янадан өйләнгән...

Фатыйха абыстайның улы кадәр улын бүләк иткән килене Айтуганда

үз гомерендә бер генә тапкыр булган икән. Бик тә аңлашыла бу — нәрсә югалткан ул анда? Туганнарын югалтмаган бит! Сөендекне үз итеп "Саша" дип кенә атавы да, иренең нәселдән килгән фамилиясен үз итеп эткә кушуы да аңлашыла. "Әни" дими, "Сашаның әнисе", "Әти" дими "Сашаның әтисе" ди бит ул шулай ук "үз итеп".

Кәбестә ашын, кыстамасалар да, урынына менгезеп куйган идем. Күлмәгенең изүе имчәкләренә кадәр ачылган, итәкләре тез башларыннан итләч бот урталарына менеп җыерылган Алевтина Петровна мине йомыркада куырылган дуңгыз ите белән сыйлый башлады:

— Ашагыз сез! Дуңгыз ите белән минтай — безнең төп азыгыбыз. Кибеттә бит барысы да кыйммәт хәзер...

Залда күкеле сәгать сукты. Санадым — тугыз тапкыр. "Миңа бик озакларга ярамый, — дип нәтиҗә ясадым мин үземә. — Иртәнге алтыдан да калмый Чаллыга сыпырырга кирәк!"

Шуны гына көткәндәй, Алевтина Петровна тагын бер бәллүрне үзегенә сендерде дә, өстәл тирәсен ду китереп, урыныннан күтәрелде һәм "Сезгә, ирләргә комачауламыйм" дип бүлмәсенә кереп ауды.

Ярыйсы гына кызып алган Сөендек бәллүрләргә янадан аракы салды, миннән тагын бер илаһи сүз көткәндәй, күзләремә текәлде. Иманым камил, җир йөзендә хәзер аңардан да бәхетлерәк кеше юк иде. Кайчандыр мин Баллы Елга буйларында күргән зәп-зәңгәр, инде хәзер зәңгәрлеге шактый сыекланган шул ук күзләр. Алар мин килгән шатлыктан елмаялар. Күзгә күренеп картая, тиресе бәлҗери, көпшәкләнә төшкән шул ук табак бит, шул ук, әмма әле генә аракыда җепшеп, үз абруен белеп иркенли, йомшара башлаган бәрәңге танау, шул ук, әмма алсулыклары уңган калын иреннәр — барысы да мин килгән шатлыктан куана иде...

Мин бу куанычның серен эзләп талчыктым. Бу "Нәрсә ул бәхет? Сөендек чын дәрәҗәсендә бәхетлеме?" дигән сорауга җавап табуга тиң иде.

Дөресен әйткәндә, мин бит Сөендек-Сашаның онытылган, үзе килеп күрмәсә, исенә дә төшмәгән авылдашы гына идем. Туганы, якын кардәше дә түгел, билләһи газыйм! Нидән иде бу куанычның сере? Җирдәнме? Җирдән булса, җирдә нинди сер бар? Суданмы? Судан булса, суда нинди сер бар? Һаваданмы бу? Һавадан булса, һавада нинди сер бар? Каннанмы бу? Каннан булса, канда нинди сер бар?! Мин шул сер иясе Фатыйха абыстай авазларын көтеп утырдым Сөендектән. Әмма бу авазлар һаман яратылмый иде.

Залда тагын сәгать сукты. Инде ун тапкыр.

Заман ничек кенә киеренке һәм файдасыз булмасын, вакыт ага.

Әйе, ага, чөнки аның эше юк. Шуның белән артык булдыклы, эшлекле булырга яраткан кешеләрне урынына утырта ул. Заман белән вакыт тигез, туры килүчән мөнәсәбәттә булса, тормышның кызыгы, җырның мәгънәсе калмаган булыр иде. Заман белән вакытны тигезләргә теләп, шәхес урталай ярыла. Дөресрәге, алар шәхеснең үзендә урталай ярыла. Әмма кайчан? Кешесенә карап. Акылына карап. Хиссиятенә, мөмкинлегенә карап. Вакыт берәүгә тулы файдага акса, икенчегә тулысы белән файдасызга агуы мөмкин. Бу инде тормыш — "торып тормыш" дип атала.

— Тормышлар ничек, Сөендек? — дидем мин икәүдән-икәү калгач. — Бик читен түгелме?

— Әйбәт, Хәбир абзый... Әйдә тәүдә күтәреп куйыйк әле... Син дә инде, әллә нигә бер килеп, утырасың как нерадный... —Ул эчеп җибәрде. — Кәбестәсеннән житеш. Минем Әлия тозлау-мозлауга ифрат оста ул. Кар эреп бетми, гөмбә ташый башлый. Анавы көнне, мин сиңа әйтим, безнең авылдан Сабирҗан танавы шикелле эре гөмбәләр алып кайткан, әй!.. Тормыш дигәннән. Аллага шөкер, Хәбир абзый. Үзем ВАЗда автомобильләр җыючы, хатыным аларны буяучы булып эшлибез. Алты ай акча алган юк, әмма, үзең күрәсең, ач-ялангач яшәмибез. Дүрт бүлмәле

фатирыбыз, машинабыз бар. Улыбыз Әлександергә егерме биш, кызыбыз Светланага егерме бер. Соңрак кайтырлар, үзең күрерсең әле... Гаиләле булырга йөриләр, Хәбир абзыкаем. Ике туйны бер юлы чәпәсәләр, ниләр генә эшләрмен дип төннәрен йоклый алмыйм... Балаларым бик тә әти җанлы, тәрбияле**ләр**, Хәбир абзыкаем! — Аның күзләре дымланды. Күнеле йомшарып китеп булса кирәк, керфек очларындагы яшьләрен сөртеп алды. — Минем балаларым!.. Әйдә, күтәр әле, е-мое, утырасың как нерадный!..

— Улыңның исеме Александр бит әле?

— Әйе, Әлександер. М-малай туса, син кушасың, кыз туса, м-мин кушам дип килешкән идек хатын белән. Шулай иттек тә куйдык. Кызыма м-м-мин куштым. М-монысы татар исеме —Светлана. Беркемгә дә әбидне түгел, шулай бит? — Ул нишләптер "м" хәрефендә, бигрәк тә "мин" дигән сүздә тотлыга башлады. — Тигезлек кирәк, взәимне сагласи кирәк, шулай бит? Ә м-минем м-малай — е-мое! — миннән күпкә озын, таза, берне чүкетсә, шифер кадагы кебек сеңәсең дә куясың! Ха-ха-ха!.. Ә-әй, бер утыргач утырыйк әле, Хәбир абзыкаем. Тот әле, тот! — Ул артка янтая биреп, тагын берне эчеп җибәрде. — Исем дигәннән. Без бит, Хәбир абзыкаем, урыслар арасында яшибез. Кем арбасына утырабыз, шуның җырын җырлыйбыз, шулай бит? М-менә м-м-минем исем-фамилиямне алыйк. Уңышсыз,шулай бит? Ну, ыхту такуй Мәкәримов? Ну ышты такуй Сөендек? Урыслар "с" урынына "х" өстиләр дә пырх-пырх көләләр. Хатынның фамилиясен алдым да куйдым. М-М-мак-карен-ко! Матур бит? Яңгырый бит? Юк, авыл өчен, синең өчен мин мәңгегә Мәкәримов! Бу бит суща фурмы. — Ул миңа фетнәчеләрчә күз кысты. — М-монда, Тәлләттидә, шәһәрнең ике йөз илле еллыгы уңаеннан бигрәк тә котыралар. Эстинкә Рәзин, Тимәфи Йәрмәк — аталарыбыз, пнимәете ли!.. "Выплывают эрәсписние Эстинки Рәзинә челны..." — Ул тавышын калынайтып, җырлап та маташты. —"Татар, чыгып тай моннан!" дип алар безгә турыдан-туры бәйләнми-бәйләнүен, әмма кысалар, малай, кысалар! Фатир алганда, аны киңәйткәндә, балаларга садик-мадик, сәтсиәл зашита мәсьәләләрендә М-Мәкәримовларны искә төшерәләр!..

— Мондагы татар җәмгыяте мәчет салдыра диләр. Татарлар белән аралашканың юкмы?

— Юк, Хәйдәр абзый. Андый нәбхәдимесне күрмим. Алар турында шәһәр гәзитендә еш язып торалар-торуын. Мижнәтсәнәлний рузен тараталар, дип. Мәктәп-фәлән, афтанумия тәлап итәләр, дип. Һич аңламыйм, нәрсәгә кирәктер инде алар. М-Менә без, Айтуган м-малайлары, югалып калдыкмы? Син институт бетереп, бик зур инжинир булдың. М-мин инде, сигез класс белән ВАЗ ның күренекле афтама-биль җыючысы булдым. Исемем ун ел буе пирдәвикләр тактасыннан төшмәде. Кирәк икән ике сминә, кирәк икән ял көнне дә эшләдем. М-монавы үләтләр *ысысырны* таркаткач кына, партияне аяктан еккач кына китте ул тактаның кадере. Бик тә кирәкле такта иде ул, югыйсә! Әйдә, тот әле берне, утырасың кәк нерадный!..

Минем алда авылдашым — татарның бөек, мең еллык байлыгының бөек исраф итүчесе — мөртәте утыра иде. Тагын да ачыклабырак әйткәндә, иленнән, теленнән, диненнән ваз кичкән папуасы — ләштер-лештер кабиләсе вәкиле. Аһ, моңсу, бик моңсу иде миңа! Кунакханәдәге чактан да моңсурак. Нигә килдем? Ә нәрсә көтә идем мин? Юк, яшәү мәгънәсе миллионлаган кешеләре белән бергә упкынга очкан бу ахырзамани чорда минем кемнедер милләтен, динен алыштырганы өчен генә гаепләргә хокукым да юктыр? Кем мин үзем — галәми хөкемдар түгелдер бит? Ярый, булды. Мин бүтән бу хакта уйланмаячакмын да. Кирәкми миңа яшеллеге дә, милләте дә, чурты да!.. Бүгеннән ук. Шушы минуттан, шушы секундтан ук. Менә тынычландым да. Тынычландым да шикелле. Шундук миемне тынычландыра торган уй сызып үтте: "Бу адәм татар дөньясында берәү генә. Берәү генә булырга тиеш. Әгәр алар икәү икән,

миңа элмәккә кирәргә кирәк. Әгәр алар чынлап та икәү икән инде, димәк, татар милләте мөртәтлек чорына кучкән". Менә сина, мә! Мин әле генә үземне тынычландым дип уйлаган идем. Эчемдәге халәтне мин һич кенә дә аңлата алмый идем. Мондый халәтне шул ук татарның "Әти үлеп ятa — көлеп эчемката" дигән мәкале белән җиткереп булыр иде шикелле.

Сөендек терсәкләренә таянды, башын учларына салып күзләрен йомды. Аның башы гүяки киселгән башак сыман кыелды да төште. Мин нишләргә белми, урынымда кыбырсып, Сөендекне һәм тирә-ягымны күздән кичердем. Аһ, шушы һич кенә дә кирәкмәс күзәтүчәнлек! Закир абзыйдан мирас булып калган чабата кашлар. Итләч түгәрәк йөз һәм озынча итләч танау. Чынаяк тоткасы кебек кечкенә колаклар. Ачык изүдән дөнья күрергә чыккан йонлач күкрәк. Ә Фатыйха абыстайдан? Бит алмаларында сакланып калган уймак чокырлар. Әлбәттә, зәңгәр күзләр. Әмма бу йөз, бу килеш-килбәт Закир абзый белән Фатыйха абыстайныкы, безнең авылныкы, безнең җирнеке кебек кара-кучкыл түгел, ә кәбестә суы кебек аксыл-сары, дуңгыз ите шикелле шешенке иде. Йә, хода, ашаган тәгам тән төкләрен дә үзгәртә мәллә?! Шулайдыр, шулай булмаса, һәр кавемнең үз ашы, үз эчемлеге, үз яшәү тәгълимате булмас иде! Хәтта үз тараканы да!..

Сөендек күзләрен ачты.

— Н-н-нәрсә, Х-хәбир абзый? — диде ул тәмам тотлыгып. —Ә-әйдә, с-с-сүзеңне әйт!

— Тараканнар, — дидем мин көтмәгәндә кунакханәдәге җанварларны исемә төшереп.

— К-күп шул. К-күршеләрдән к-керәләр. Ә-ә, т-тараканга да игътибар итеп т-торсаң!.. С-сүзеңне әйт!

Ул арыган иде. Бу гамьсез сөйләшүне тәмамлау ниятендә әйләндердем дә салдым:

— Мин бу тостымны, Сөендек туган, мөртәтлек хакына тәкъдим итәм!

— А-а-аңламыйм, м-монысы нәрсә т-тагын? Н-нинди м-мөртәтлек?

— Оптимизм аша килгән идиотизм хакына күтәрик, дим, яшәсен идиотизм!

— Әллә кайчан ш-шулай диләр аны! М-менә м-монысы өчен эчәргә б-була!..

Ул алдындагысын тагын эчеп җибәрде. Сүзләрнең мәгънәсен аңламады шикелле.

Ишектә кыңгырау челтерәде. Эт, гадәттәгечә чабып килеп, һау-һау өрде. Сөендек чайкала-чайкала ишекне ачарга китте.

Аннан, инде шактый соң булуга карамастан, шаулашып парлы егетләр һәм кызлар күренде. Сөендек егетләрнең иң озынын кулыннан өстерәп диярлек минем янга китерде һәм бер горурлык белән татарчалап таныштыра башлады:

— Хәбир абзыкаем, б-бу м-минем улым б-була. Абыеңа к-кулыңны суз. Руку пртәни! Ә әнә т-тегесе б-булачак к-киленебез В-валентина б-була. Әлександер, Х-хәбир абзыкаем диривнә бывал, картатайку-картинайку видал. По-татарски "картинәй" эскажи, ә? Минем өчен эскәжи?

— Заткнись. — Егет әтисенә нәфрәтле караш ташлады. —Тагын исерек.

— Исерек түгел, бераз эчкән...

— Үз телеңдә бытылдыйсың икән, димәк, исерек.

Улының мондый шаянлыгына игътибар итмәскә өйрәнгән Сөендек, берни булмагандай, алпан-тилпән килеп, янадан ишек катына китте һәм кызын кочаклап алып, минем тарафка тарта башлады.

— Монысы минем с-сөекле к-кызым С-светлана була...

— Кит әле, әти!

Светлана әтисенең кулын иненнән ышырып төшерде һәм яшьләрне аш-су бүлмәсенә чакырды.

Алар кереп тулгач, кечкенә бүлмә кысанланды да куйды. Александр әтисеннән ашарга сорады. Үтенечтә татарчага "тыгыну" дип тәрҗемә ителә торган "пожрать" дигән тәгъбир яңгырады. Алевтина Петровна яткан урыныннан гына яшьләргә суыткычтагы йомыркалардан тәбә әзерләргә боерды.

Яшьләрне калдырып, без залга үткәндә Алевтина Петровнаның юан беләкле, ыргак сыман куллары Сөендекне үз бүлмәсенә өермә сыман суырып алды. Ул, мыгырданып маташты маташуын. Әмма Алевтина Петровна аны ычкындырмады. Бүлмәдә нәрсәдер гөрселдәде — хатын ирен этәреп урынына аударды булса кирәк.

Мин, чишенеп, кәнәфидә җәелгән урынга барып яттым. Без эт белән бергә — залга туры килдек.

Аш-су бүлмәсендә төне буе магнитофон ырылдады. Ул төнге икедә генә тынды. Яшьләр, парлашып, буш бүлмәләргә кереп яттылар.

Мин шундук онытылганмын. Әмма бу йокы түгел иде. Гүя мин уяу килеш йоклыйм. Күз алдымнан Фатыйха абыстайның ак сыны китмәде. Әйтерсең, мин аның турында очы-кырые булмаган мексикан фильмы карыйм. Имеш, аны үзенең авылдагы агач йортыннан шәһәрнең күп катлы ятагына көчләп кертергә итәләр. Ул тартыша. Менә барысы да югала. Баксаң, сөргән җир икән. Менә ул иңеннән шуып төшкән ак яулыгын намазлык итеп җиргә җәя дә, намаз укый башлый. Түбәсендә җир кебек кара каргалар өерелә. Ул ун бармагын күз алмаларына терәп диярлек ходайга ялвара:

— И раббым, сагынычымны кире кайтар! Ун бармагымның ун фәрештәсе, Сөендегемә канатлар бирегез! Ун фәрештәм, Сөендегемне ун мәртәбә төшереп, ун мәртәбә күтәр!..

Каргалар югала. Фатыйха абыстай исә ак фәрештәгә әверелеп, кара җир өстеннән бөтерелеп-бөтерелеп, мәңгелеккә сеңә...

Бу манзарадан мин тәмам уянам, күзләремне шар ачам. Нәрсә җитми бу өйгә? Фатыйха абыстай җитми. Биленә төшереп бәйләгән ак яулыгы, йөзендәге яктылыгы, иманлы теле җитми. Тукта, ул бит бердәнбер Сөендегенә тел биргән булган?! Сөендектә ул тел бар бит, ул бит телсез түгел. Шулай да, кая киткән соң ул тел? Әлбәттә, Фатыйха абыстайның иманы җитми. Тукта, дим мин, ул бит бердәнбер Сөендегенә бисмилласына төреп, иманын биргән булган. Кая булган соң ул иман һәм үзәк матдәсе? Минем тәнем өзгәләнә, ачыргалана, чәнчешә башлый. Сендерә, үз иттерә алмаганмы ул аларны? Сендерттереп җиткермәгәннәрме? Сендереп җиткерттермәгәннәрме? Кинәт күз алдымда, һавада, утлы гөрзиләр белән *барыбер* дигән тәкъдир сүзе языла. Арыган чакларымда шундый күренешләр килгәли шул миңа. *Барыбер*. Ягъни, нинди телдә укысаң да, кем чанасына утырып, кем җырын җырласаң да, кем белән кавышсаң да, *барыбер*. *Ул барыбер булачак, чөнки бу илдә бары тик бәхетле генә булырга мөмкин*. Туган җиреңдә яшәсәң дә, яшәмәсәң дә, чәчкә үстерсәң, үстермәсәң дә, *барыбер*. Илленче-алтмышынчы еллар арасында тормышыбызда хасыйл булган афәт — *интербарыбер*. Шушы *барыбер* тигезлеген тәрбияләгән туган телсез мәктәп, туган телсез радио-телевидение, туган телсез урам ашамаганмы Сөендекнең телен һәм иманын? Бәлки ул дистәләгән миллион татарда бердәнбер нөсхәдәге мөртәттер? Мин эсселе-суыклы булып китәм. Эт аш-су бүлмәсенә чыгып, су эчә башлады. Сөендек ыңгырашты. "Юк! — дим мин тешләремне шыгырдатып. — Ул бердәнбер булырга тиеш. *Барыбернең бердәнбере*. Әгәр мондый мөртәт икәү булса, миңа асылынырга асыл агач эзләргә кирәк".

Эт урынына кереп ятты.

Өч бүлмәдә дә гырлап йоклыйлар иде.

Күкеле сәгать дүртне сукты.

Эт шыңшып куйды.

Сөендек мөртәтлегендә Алевтина Петровнаны гаепләү гадел булмас иде. Киресенчә, аны мактау гына фарыз. Алар Ходай Тәгалә алдында

икесе дә тигез, әмма бу тигезлек арасындагы кечкенә аерма шунда: Алевтина Петровна уйламыйча-нитмичә элмәк үрсә, Сөендек бу элмәккә тирәнтен уйлап, үз теләге белән барып кергән. Алевтина Петровнага, бу мәсләктән чыгып караганда, хатын-кызга, ни дисән дә, ир кирәк — гаилә кирәк булган һәм ул аны, милләт-кавемгә бүлмичә, үзе инануынча, "сөюе" аша тапкан, ул тел, иман аерымлыгы турында уйлап та тормаган, чөнки бу мирас аңа, ул уйлавынча, күктән һәм мәңгелеккә төшкән. Тел һәм иман бары тик аныкы гына булуы мөмкин. Сөендек тә, үзен-үзе ышандыруынча, булачак хатынын "сөюе" аша тапкан, әмма ул мондый җаваплы алымны кат-кат уйлап ясаган, үзен аклауның шартларын ачыклаган: аның теле дә, иманы да бүген-иртәгә бетәчәк вакытлы нәрсәләр. *Барыбер* бетәчәк байлыклар. Мәңгелек байлыгын — "сөюенен" җимешен сатып, ул үзеннән дә хәерчерәккә әҗәткә кергән. *Барыбер* бетәчәк патшалыкта патша булган һәм бөлгән.

Алевтина Петровна белән Сөендекнең кавышуы Төньяк Котып белән Африканы бергә кушып, яңа табигать, яңа климат, яңа кыйтга барлыкка китерү белән бер иде. Мәңге кушылмаска тиешле бу ике кыйтга, кушылып, яшәешнең тигезлеген югалта. Алар ике мөстәкыйль йолдыз, ике тәгълимат, ике иман, ике яшәү рәвеше. Мөстәкыйль булганнары өчен аларны кимсетү дә, гаепләү дә дөрес түгел. Бу ике яшәү рәвешенен бер булып төйнәлүе үзе генә дә бәхетсезлек инде.

Күрәсең, без, кешеләр һәм милләтләр, чәчәкләр һәм үсемлекләр үстергәндәге шикелле, чынбарлык шартлылыкларын инкярь итәбез һәм отылабыз. Әлбәттә, табигать кануннарын кешелек кануннары белән тәгәл тәңгәл куярга ярамый. Ә шулай да, шулай да... Без, кешеләр, тормыш чәчәкләре түгелмени? Бер чәчәкнең икенчесен үтерү аша гарип чәчәк атуы — мәгънәсезлек. Кабатланмас, нәселле чәчәкләр бер-берсен рәттән куйганны яратмый. Рауза белән канәфер үзара көнләшеп, бер-берсен хуш исләре белән буып үтерә, тончыктыра. Ландыш исә барлык чәчәкләр белән дә дошман мөнәсәбәттә. Чаган, өрәңге янындагы алмагач беркайчан да мантый алмый. Мичурин карт алмагачта чия үстереп карады, әмма кеше көлдерүдән уза алмады. Йылкы малы белән дуңгыз бер абзарда яши алмый — ат унбиш-егерме көннән ашказаны агуланып үлә...

Сәгать бишне сукты.

Мин сикереп тордым һәм киенә башладым. Эт тагын шыңшып куйды. Безнең бимазадан уянган Алевтина Петровна төрткәләде булса кирәк, күзләре шешенгән, чәчләре пумаладай тузгыган авылдашым мин юынып-кырынып азапланган арада аш-су бүлмәсенә үтте, чәй куйганнан соң, шатыр-ботыр килеп кичә калган шешә төбен эзли башлады.

— Е-мое! Эчеп бетергәннәр, Хәбир абзыкаем. — Аның тамагы карлыккан иде. Безгә баш төзәтергә дә калдырмаганнар. Күршеләргә кереп чыгыйммы?

— Кирәкмәс, Сөендек. Мина алтыда юлга чыгарга кирәк.

"Суыткычтан йомырка алып, дуңгыз маенда кыздыр!" — дип кычкырды Алевтина Петровна. — Әгәр бүген дә аракы тыгынсаң, өйгә кайтып керәсе булма, хайван!"

Без җиңелчә генә чәй эчтек.

— Аракы белән ничек? Еш кабасыңмы?

— Соңгы вакытта эчкәлим шул, Хәбир абзыкаем. Бөтенләй дә эчмәс идем... Нәрсәдер житми. Кемдер житми. Бушлык дим микән инде... Әллә ниткән үч котыра җанда. Югыйсә, гаиләдә дә тыныч. Әллә картая бару галәмәте микән бу, Хәбир абзый? —Ниндидер теләктәшлек көтеп, ул минем күзләремә текәлде. — Шул нәрсә көчәя барса, нишләрмен икән?

Егеттә өмет бар иде әле. Ул җанындагы чирнең исемен эзли иде.

— Авылга кайтып тор бераз, — дидем мин. — Сагынганнар анда сине.

— Быел кайтып булмас шул. Ике туй бергә килергә тора бит...

Урамда безне җылы җил каршылады. Көн инде тәмам яктырган

булса да, күк йөзе чекрәеп янган йолдызлар белән мыжгыган иде. Агачлар бу җылы төндә дә яфрак ярып өлгермәгәннәр икән.

Менә Ворошилов урамы буйлап уяулы-йокылы автобус күренде.

Хушлашканда ул мине кысып кочаклады.

— Килгәндә керергә онытма! Менә ничек рәхәт булып калды!

— Исән бул, Сөендек. Тагын күрешергә язсын.

... Чаллыга кайтып җиткәнче мин үземне битәрләдем: бәлки миңа җылы сүзләрне кызганырга кирәкмәгәндер? Бәлки мин авылдашыма нинди дер рухи ярдәм дә күрсәтә алганмындыр? Сорыймы соң ул аны? Татарстанга таба яшәрә барган урман акланнарында Фатыйха абыстай ак алъяпкычына Сөендегенә эскәк белән мәтрүшкә күзләре җыйган сыман күренде миңа. Бәлки чынлап та шулай? Бәлки ул мәтрүшкә күзләреннән Сөендек тә, аның балалары да савыгыр?

Камышлыны чыккач булса кирәк, әле балачагымда Фатыйха абыстай авызыннан язып алынган бәет хәтергә килде. "Кызын попка оттырган Мостафа мулла бәете" дип атала ул.

Зөлхәбирә күлмәк, әй, тектергән,
Итәгенә ыштуф тоттырган.
Әй, Мостафа мулла, ил мулласы,
Кәрткә уйнап кызын оттырган.
Кызыл гына тәпиле, әй, күгәрчен,
Сөбханалла диеп лә оча ла.
Озын гына чәчле Микулай поп
Сөйгән ярым диеп лә коча ла.
Чиркәү баскычлары бигрәк биек,
Тез буынкайларым тала ла.
Әнкәемә минем һич үпкәч юк,
Әткәемә хәтерем кала ла...

Мин ул чакта, әлбәттә, яшелләндерү буенча мөһәндис түгел идем әле.

"Юк, бу барыбер мөртәт, — дидем мин Чаллыда автобустан чыкканда. — Һәм татардагы берданбер мөртәт. Әгәр алар икәү булса, миңа һичшиксез асылыну өчен асыл агач эзләргә кала".

*Май-август 1997.*

*Чаллы — Чехово, Башкортстан.*

# ПУБЛИЦИСТИКА



Тәүфикъ Әйди

## СЕБЕР ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

### Бурычлар шундый ук

МИН БЕРВАКЫТ совет хакимиятенең Себер татарлары үсешенә, аларның мәгарифе һәм мәдәнияте күтәрелүенә зур мөмкинлекләр ачуын сурәтләп, моңа күп кенә мисаллар китергән идем. Аңлашыла ки, бу — тарихи хакыйкать иде. Ләкин шул ук хакыйкать өчен мин бүген басым ясап белдерергә тиеш: "зур" дип сыйфатланган ул мөмкинлекләр элекке караңгы дәвер белән чагыштырганда гына зур, чынлыкта исә алар бизмәнләнгән, чикләнгән иде. Этник себер татары шул җирнең төп халкы, аборигены булса да, ул совет дәверендә дә, беренче, хәтта икенче яки өченче рольне дә уйный алмады. Мисалга, Төмән өлкәсе җитәкчелегендә алар күп дигәндә бүлек инструкторы дәрәҗәсенә генә күтәрелде, шундый бәхетлеләрнең гомуми саны соңгы сиксән елда сигезгә дә тулмады. Совет дәвереңнең беренче елларында дөньяви урта яки югары белем алган һәм урысча эш йөртергә өзер булган татар хезмәткәрләре күп табылмас. Соңрак милли белгечләргә карата мөнәсәбәт тагын да салкыная — алардан милләтчелек эзләү, мәдәни җитлекмәгәнлек гонаһын "абайлау" гадәте тамыр җәя, татарның "бердәм совет милләте" оешуына карышуын күрү өскә калка. Мондый шартларда җитәкче булып үсәргә, карьера ясарга теләгән татар үз халкының уйланма милләтчелегенә, диндарлыгына каршы көрәшергә, катнаш никахка керергә һәм бүтән әхлакый корбаннарга барырга тиеш иде.

Татарга ышанмаучылык мөгамәләсен һәм сәясәтен 1979 елда Төмәнгә баргач мин үз күзем белән күрдем дә, тойдым да.

Читкә гел милли матбугатыбызны тарату, әдәбиятыбыз белән таныштыру өчен йөргәнлектән, мин һәр өлкәдә татарның күпме булуын һәм кайларда тупланып яшәвен ачыкларга тырыша идем. Статистика идарәләрендә мәгълүмат алу кайда да җиңел түгел, әмма Төмән бу җәһәттән барлык өлкәләрне дә узды — халык санын алу бүлеге мөдире миңа уңай җавап бирүдән катгый рәвештә баш тартты. Командировка белән редакциядән килүемне, мәгълүматларны матбугатта бастыру өчен түгел, эшемдә генә файдаланачагымны белдерү дә ярдәм итмәде — ярамый! Татарстан вәкиле — журналист һәм язучы

үзенең укучылары — милләттәшләре кайда һәм күпме яшәвен белергә тиеш түгел икән! Стратегик сер. Йөрмәсеннәр әле бердәм совет халкы укмаштыруга таяк тыгып, туган тел, туган мәдәният турында сафсата сатып!

Әлбәттә, статистика идарәсе түрәсе соңгы фикерләрен кычкырып әйтмәде, ләкин аның шулай уйлавы бөтен гамәленнән, шул исәптән, миннән кырыс сорау алуыннан сизелеп, бөркелеп тора иде. Тик бу юлы ул милли мәсьәләне инде шактый өйрәнгән, Идел-Урал буйларын байтак урап йөргән, җирле статистика идарәләре бусагасын күп таптаган үҗәтрәк зат белән эш итә иде. Кабинетыннан ярты сәгать буе чыкмыйча, миңа үз туксанымны ялыкмый төрлечә кабатларга, ахыр чиктә компартиянең Түбән өлкә комитеты эшлекләләренә шалтыраттырырга, алар белән үземә дә телефоннан сөйләшергә һәм йомышымның табигый, ихтыяҗи икәнлеген исбатларга туры килсә килде — идеология нигытмасы бераз чигенде, һич югы искерәк мәгълүматларны сыкрап кына булса да бирергә ризалашты!

Бүлек хезмәткәре белән аңлашканда тагын да бер тамашага юлыктым ич әле. Әлбәттә, җитәкчесе телефоннан әмер биргәнлектән, ул артык карышмады, ләкин Себер татары белән Казан татары аермасын аңлатып, ул мине тәмам шаккатырды. Эш шунда ки, мин анда Булат Сөләймановны да ияртеп барган идем. Үз исемемне атаганнан соң, әлеге ханымга:

— Ә бу иптәш — "Юность" журналы премиясе лауреаты, Союз күләмендә атаклы чын Себер татар шагыйре Булат Сөләйман! — дидем.

— Шулаймыни? — диде статистика кемсәсе, Булатка күз йөгертеп. Барыннан да бигрәк ул юлдашымның алагаем зур киез итегенә, авылда иләнгән һәм авылча гына тегелгән кайры тунына игътибар итепме, шундук аңа аркасын биреп, миңа гына карап сайрый башлады: — Себер татарлары Казан татарларыннан нык аерыла шул. Казанныкылар — чын европалы, аларда зыялылык, мәдәни җитлеккәнлек, затлылык сизелә. Аларны бездән аеру кайчак мөмкин дә түгел. Казан татарлары белән эш йөртү дә ансат, рәхәт...

Бу инде миңа салам кыстыру гына түгел, татарның ике этник төркеме арасына чөй кагу, Себер татарларын күрәләтә түбәнсетү иде. Икеләнмәскә мөмкин: бу кешегә Казан татары да икенче сорт кына булып тоела, ә башкасы инде янә дә түбән дәрәҗәдәге бәндә булып күренә иде. Булат өчен кыенсынудан йөрәгем кысылып куйды, тик мин монда да бәрелешкә керергә теләмәгәнлектән, нәфрәтләнүемне тышка чыгармадым:

— Вакытыгызны артык алмыйк, кирәкле мәгълүматларны барлыйк инде.

— Әйтәм ич: Казан татарлары — эшлекле халык, елгырлар, әдәплеләр!

Бу очрашулардан гына зур гомумиләштерү ясау, әлбәттә, ярамыйдыр, әмма Түмәндәге милләттәшләребезнең искәртүенчә, Себер татарларына карата мондый мөнәсәбәт "өлкән туган"нарда шактый ук тамыр җибәргән икән. Әнә шулай еш-еш йөзеңә төкергәләп торсалар, биленңне турайту, тормышта сәләтеңә лаеклы урынны алу кыенлашадыр. Шулай да кайберәүләрне айныту, аларның фикерен, мөнәсәбәтен үзгәртү өчен көрәш дәвам итә, бу юлда Себер татарларының уңышлары да юк түгел. Мин моңа "Тюменская правда" (29. XII. 1992) гәзитендә профессор Ю. Прибыльскийның "Тарих сабаклары" мәкаләсен укыганда ышандым.

## Галим һәм мәгърифәтче

"МИЛЛИ МӘКТӘПЛӘР тәҗрибәсенә багышланган чыгышлар мәсьәләгә яңача караш белән аерылып торды, — дип яза профессор. — Мисалга, танылган татар мәгърифәтчесе Изил Гарифуллин революциягә кадәр үз халкының тулаем грамотасыз булуы турында таратылган фикерләрнең дөрес түгеллеген күрсәтте. Ул дәвердә мөселман җәмгыяте ачкан мәктәп-мәдрәсәләрдә балаларның гарәп теле, Коръән һәм хисап өйрәнүе билгеле. Нәтиҗәдә татарлар укый-яза белү ягыннан урыс халкыннан калышмый. Гасырыбызның алтмышынчы елларында татар мәктәпләрен урысча укытуга күчерү гамәлгә ашырылды, бу исә туган телне онытуга, югалтуга китерде. Бу зарарны каплап бетерү әле дә кыен".

Ю. Прибыльский Изил Гарифуллин чыгышын бик үзенчәлекле "кыскартып" китерә, әмма без анысы өчен дә аңа рәхмәт әйтергә тиеш: татар яманатын саткан сыйфатламаларны урыс халкына гасырлар буе сеңдереп килделәр, шул ялган ташкынына урыс үзе каршы төшүе тансык хәл. Милләттәш галимебез исә үз чыгышында менә мондый дәлилләр китергән була:

"Элек гасырлар буена ана телендә укыган татарларның белеме башка халыкларныкыннан һич кенә дә түбән булмаган. Мәсәлән, 1897 елгы халыкны исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, Төмән губернасында татарларның укый-яза белүе урысныкыннан хәтта югарырак та булган: урысларның ир-атлары арасында — 17,5; хатын-кызлары арасында — 4,5 процент; татарларда ир-атларның 25,4; хатын-кызларның — 16,3 процент!"

Фикерләрен дәлилләү, архив мәгълүматлары белән ныгыту Изил Гарифуллин хезмәтләренең аеруча күркәм, аеруча отышлы бер сыйфаты. Моңа мисал итеп аның "Ватаным Татарстан" гәзитендә басылган "Баганалы олы юл. Ул кая илтә?" мәкаләсен китерергә мөмкин. Ул анда яшәешебездәге иң фаҗигале хәлгә —Себер татарларының йотылуына, урыслашуына туктала, бу эшкә милләттәшләренең ят тирәлектә сибелеп урнашуын һәм ят телдә белем-тәрбия алуын сәбәп итеп күрсәтә. Күләме җыйнак мәкаләдә татарларның яшәеш, эшчәнлек тирәлеге шундый дәлилле, күпьяклы сурәтләнә һәм анализлана ки, милли телләрнең һәм мәдәниятләрнең күкрәп үсүе, азчылык милләтләрнең күз күрмәгән, колак ишетмәгән уңышларга ирешүе хакында дистә еллар буе лаф оруларның бары саташу, ялган гына булуы аңыбызга барып җитә. Мисалга, "балаларыгызны урысча укытсагыз, алар алдында фән-мәдәниятнең барлык юллары киң ачылачак" дип, Себер татарларының инде ике буынын милли мәгариф челтәреннән мәхрүм иткәннәр. Нәтиҗәсе исә менә мондый икән: өлкә халык хуҗалыгында эшләүчеләрнең 7,3 процентын тәшкил иткән хәлдә, түбәнле милләттәшләребез аң-белем таләп иткән тармакларда — 5,7, фәнни хезмәткәрләр арасында — 6,7, инженер-техниклар арасында — 5,4, югары уку йортлары укытучылары арасында — 3,7, сәнгать белгечләре арасында 4,9 процент чамасында гына. Аның каруы авыр физик хезмәттә алар — 8,1 процент. Туган телен оныту дәрәҗәсенә җиткән, урысча гына аралаша башлаган Себер татарлары казанышы әнә шундый гына икән, аларның милли мәктәпләрен юк итү акландымы соң?

Изил Гарифуллин якташларының һәм милләттәшләренең тарихы, мәгарифе һәм мәдәнияте үсешен, Себер татарлары алдында торган бүгенге бурычларны, четерекле мәсьәләләрне гыйльми яктан тәгәл һәм әтрафлы яктырта, ул аларны халкының сәламәт рухлы, саф вөҗданлы, кайнар хисле улы буларак тикшерә, кимчелекләр өчен

җаны сызланучы олы шәхес сыйфатында, милли аңы инде тәмам томаланган бәндәләрне дә уйланырга мәҗбүр итәрлек китаплар чыгара, вакытлы матбугатта очерклар, рецензияләр, мәкаләләр бастыра. Аның Төмәндә соңгы елларда дөнья күргән "Мөхәммәт. Себердә ислам. Халык риваятьләрендә Күчем һәм Сүзге"(1993), "Төньякны үзләштерү елларында (1960-1996) Төмән өлкәсе татарларының социаль-демографик үсеше" (1997) брошюралары мәгълүматка байлыгы белән зур игътибарга лаек. Шуны раслар өчен соңгы китаптан кайбер өзекләр китереп узыйк:

"1989 елда исәпкә алынган татарларның 125 меңе генә Төмән өлкәсендә туган. 39,3 мең милләттәшебез Башкортстанда, 23,8 меңе Татарстанда дөньяга килгән".

"1969 елда өлкә татарларының 90,1 проценты көньяк авыл районнарында яшәсә, 1989 елда аларның 54,6 проценты төньяк автономияле округларда гомер итә. Милләттәшләребезнең югары хезмәт хакы түләнгән нефть-газ чыгару эшенә күпләп китүе аркасында 1970-1995 елларда егермеләп татар авылы тәмам юкка чыга, башкаларында исә кеше саны кими".

"Өлкә татарларының уртача яше 1989 елда 27 дән артмый (урысларда 27,9)".

"Бала табу ягыннан татарлар күрсәткече кайбер башка халыкларныкыннан югарырак — 1989 елда туган бәбиләрнең 10,1 проценты — безнекеләр (татарлар ул чакта өлкә халкының 7,3 процентын тәшкил итә)".

"Татар гаиләләрендә 1989 елда уртача 3,6 җан туры килә (өлкә халыкларында уртача — 3,4). Кызганыч ки, өлкә татарлары арасында катнаш никахлар һаман арта бара. Мисалга, 1989 елда өйләнгән милләттәшләребезнең 55,5 проценты гына татар хатын-кызын ала. Татар хатын-кызларының 50,3 проценты гына үз милләттәшенә кияүгә чыга. Соңгы вакытта исә милләттәшләребез арасында аерылышулар да киң тарала бара. 1979 елда аерылышучылар өйләнешүчеләрнең 18,2 процентын тәшкил итсә, 1989 елда инде соңгы сан 35,7гә кадәр арта. Мондый шартларда милләтебезнең сәламәт нигездә үсмәве аерымачык күренә: бу һәркайсыбызны уйландырырга һәм борчырга тиеш".

И. Гарифуллин китабында кызыклы мәгълүматлар шулкадәр күп ки, аларны тагын-тагын күчереп аласы килә. Әмма минем бурыч китап күчерү түгел, укучыларга Төмәндә яшәп иҗат итүче, туган халкына һәм бүтән милләт вәкилләренә мәгърифәт нуры сибүче милләттәшебезне таныту. Миңа аның белән 1997 елның җәендә очрашырга, өендә гәп корып таң аттырырга насыйп булды.

Изил әфәнде — йомшак мөгамәләле, әңгәмәдәшенә игътибарлы мөлаем зат. Холкы ягымлы, акылы сыгылмалы. Кыяфәтендә олпатлык, сабырлык. Беренче карашка, кирәгеннән тыш йомшак, либераль сыман күренә ул. Әмма эшчәнлеге белән таныша, гамәлләрен җитәрәк күзәтә башлагач, аның чынлыкта зур ихтыяр көченә ия, максатына ирешү өчен сәләтен бер йодрыкка туплый белә торган шәхес икәнлеген чамалыйсың.

Изил әфәнде 1928 елда Тубыл шәһәрендә укытучы Бәдретдин абзый гаиләсендә туа. Тубыл татар педучилищесен тәмамлаганнан соң, Казан пединститутының география факультетында белем ала. Тубылга өйләнеп кайткач, яшь белгечне беренче укыту елында ук унбишенче татар мәктәбенең әүвәл — завучы, аннары директоры итеп билгелиләр. Гаскәри хезмәтен үтәп кайтканнан соң, ул өлкә мәгариф идарәсендә инспектор вазифасын башкара, соңра тагын туган мәктәбенә җитәкчелек итә. 1958 елда исә ул партия эшенә чакырыла —Тубыл

шәһәр комитетында, аннары өлкә комитетында үгет-нәсихәт, фән һәм уку йортлары бүлекләрендә хезмәт итә. Новосибирск Югары партия мәктәбендә укыган елларын санамасаң, аның өлеге эше 1976 елгача сузыла.

И. Гарифуллин 1975 елда "Урал партия оешмаларының азчылык милләтләр арасында мәдәни төзелешне тормышка ашыру эшчәнлеге" дигән темага тарих фәннәре кандидаты булу өчен диссертация яклый һәм 1976 елда Төмән институтларында укыту эшенә күчә. Башта Индустрия институтында, аннары Югары милиция мәктәбендә, соңрак Төньякны үзләштерү мәсьәләләре институтында хезмәт итә. 1992 елдан башлап исә хәзергәчә Укытучылар белемен күтәрү институтында лекцияләр сөйли.

Изил әфәнде мәктәптә укыганда ук үзешчән сәнгатькә тартыла — җырлый, бии, спектакльләрдә уйный. Аның бу һәвәслеге студент елларында һәм мәктәптә укытканда бигрәк тә киң канат җәя. Ул унбишенче татар мәктәбе директоры вазифасын үтәгәндә Тубыл янә өлкә татарларының мәдәни мәркәзенә әйләнә. Илленче елларда монда татар педтехникумы гөрләп тора, techинститутта татар бүлеге ачыла, анда эшләргә Казаннан яшь галимнәр — булачак фән докторлары Гомәр Саттаров, Фәрит Хатипов, Азат Әхмәдуллиннәр килә һәм шәһәрнең мәдәни тормышына яңа рух өреп җибәрә. Татар телендә гәзит чыгарыла башлый. Татар мәдәният йортында концертлар һәм спектакльләр куела. Шушы шәһәрдә үскән, мондагы милләттәшләренең гореф-гадәтләрен, тел үзенчәлекләрен яхшы белгән Изил Гарифуллин (анасы — Себер татары) бу җанланышның иң дәртле-дәрманлы бер этәргеч көченә әйләнә. Гармунда һәм баянда да уйный белгән егетнең мәҗлесләр күрке булуы гаҗәпмени? Әмма иң әһәмиятлесе — Изилнең гаиләдә, аннары милли уку йортларында, бераздан исә милли мәркәзебез Казанда да чын татар рухы белән сугарылуында, ахры. Соңрак инде партия идеологлары аны ничек кенә милләтсезләндерергә тырышмасын, тоталитар системаның "интернациональ" тәрбиясе —чынлыкта көчләве нинди генә җимергеч булмасын, Изил әфәнде яшьлектә ныгыган иманына тугры булып кала — туган халкының сулышын буа торган гамәлләрдә катнашмау юлларын таба. Дилбегә йомшаганрак елларда исә КПССның Төмән өлкә комитеты исеменнән җирле оешмаларга таратыр өчен туган телендә рәсми материаллар — лекцияләр, әңгәмәләр язып бастыра. Әлбәттә, партия күрсәтмәләре рухында, бары кульъязма хокукында, ләкин инде күптән йотылырга хөкем ителгән телдә!

И. Гарифуллин алтмышынчы елларда вакытлы матбугатта актив рәвештә милли мәсьәләне яктыртырга керешә — ул чыгышларында татарларның һәм башка азчылык халыкларның ихтыяҗлары, үткәннәре һәм бүгенге тормышлары, югалтулары һәм казанышлары турында яза. Милләттәшләре алдында туган телдә лекция сөйләүдән дә, радио аша татарча тапшыру оештырудан да тайчанмый — бу эшләрдә үзе башлап йөри. 60-70 елларда мондый тырышлыкка кырын караучыларның да җитәрлек булуы сер түгел. Әмма Изил тукталып калмый, Төмәндә сулыш тарайса, Казан матбугатына юл саба. 1990 елда Төмәннең үзендә "Яңарыш" өлкә гәзите чыга башлау исә аның иҗади эшчәнлегенә пар канатлар куйгандай була — 1997 елның җәенә кадәр ул инде анда 35 зур күләмле мәкалә бастырырга өлгерә. Туган телдә иркен яза алырлык каләм ияләре җитмәгән хәлдә аның шулай актив катнашуы "Яңарыш" редакциясенә бер сөенеч булса, белемле, тәҗрибәле, киң карашлы галимнең чыгышлары туган телдәге басма сүзгә сусаган укучылар өчен үзе бер бәйрәм була. Чөнки ул милләттәшләребез өчен аеруча әһәмиятле темаларны яктырта, теге

яки бу мәсьәләгә карата төпле фикере, мәгълүматы белән уртаклаша. Моңа мисал итеп "Себер ханлыгы" елъязмасына 360 ел" ("Яңарыш", 1996, N 103) күзәтүен күрсәтү дә җитә. Ул анда Себер ханлыгы җимерелү фаҗигаләрен, шул дәвер татар каһарманнарының язмышын сурәтләп, милли аңны кайтаруга, ата-бабаларга ихтирам уятуга әһәмиятле өлеш кертә, әлеге елъязмага бәя дә бирә, аның эчтәлеген дә ачып сала.

Өлкәнең урыс матбугаты да И. Гарифуллин язмаларын бик теләп басуын искәртү урынлы булыр. Ул Төмән белән Казанда гына түгел, башка яклар матбугатында да күренгәләп тора торган автор.

Изил Гарифуллинның оештыру эшчәнлеге, мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре турында да зурлап сүз алып барырга мөмкин, чөнки аның хөкүмәт бүләкләре, мактаулы исемнәре нәкъ менә шул тармаклардагы тырышлыгы өчен бирелгән. Аның барлык басма хезмәтләренә дә тукталып тормыйм — туган ягын, туган халкын өйрәнүгә багышланган кайберләрен генә искә алдым. Алар күп, аларның һәркайсы укучыга ниндидер яңалык ача. Аларны укыганда: их, татар халкы яшәгән башка төбәкләрне, башка этнографик төркемнәребезне дә шулай өйрәнүче һәм сурәтләүче табылса иде, дип кенә уфтанырга мөмкин. Ләкин андыйлар сирәк туа, сирәк туганга кадерле дә алар!

## Нәсел ныклыгы

БӘДРЕТДИН Гарифуллин унбер бала үстерә, шулардан алтысы атасы юлыннан китә — мәгариф эшенә бирелә. Калганнары тегүче, төзүче, фельдшер, авыл советы хезмәткәре һөнәрләрен сайлый. Һәркайсы үзе сайлаган тармакта намуслы хезмәте белән таныла, җәмгыять өчен файдалы, үрнәк әхлаклы гамәлләре белән хөрмәт казана. Мин аларның барысы турында да язуны максат итеп куймадым, әмма Гарифуллиннарның төпчеге — Фатих әфәндене телгә алмау язык булыр иде, чөнки ул Төмән шәһәрендәге татарларга гына түгел, аның күп милләтле бүтән җәмәгатьчелегенә дә яхшы таныш. Ул моңа 1992 елда "Белем" мәдрәсәсен оештырып ирешә.

Төмән дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлаган, буй-сынга да, йөз-кыяфәткә дә Ходай мәхрүм итмәгән бу затлы, күркәм ир-егетне очраткач, азчылык милләтләре тәмам урыслашып барган өлкә үзәгендә ул ничек мөселман мәдрәсәсе ачарга җөрьәт итте икән, дип уйлыйсың. Мондый егет әллә ни михнәт чикмичә, дәүләт хезмәтендә дә үзенә лаеклы урынны таба алган булыр иде, мәгаен.

— Безнең төбәктә милли уяну, туган телне, мәдәниятне, динне яңадан тергезү хәрәкәте башлангач, мин дә бу кузгалышка үз көчемне һәм сәләтемне кушарга теләдем, — ди ул. — Гореф-гадәтләр нык сакланган гаиләдә үссәм дә, замана чирләре миңа да йокмый калмаган иде, билгеле. Әмма кайбер замандашларымның эчкечелеккә бирелүен, көнкүрештәге әхлаксызлыгын мин беркайчан да кабул итә алмадым. Милләттәшләремә яман гадәтләрнең йогуы мине аеруча тынгысызлый иде. Уйлана торгач, өнә шул бозыклыкларга каршы көрәшү өчен ата-бабаларыбыз тоткан ислам диненә кайтуны мин иң кирәкле гамәл саный башладым — аның нигезләрен өйрәнергә керештем.

Никахсыз гаилә кору, соңгы юлга догасыз озату, догасыз кушылган исем йөртү, хәрам ризык ашау, зина кылу, ятим балалар тудыру, гөнаһ кылуны искә дә алмыйча, хәләл гамәлләрдән тайчыну.

Илаһи зат иңдергән туган телдән, туган җирдан йөз чөерү — уйларга тотынсаң, аек акылга, ата-баба васыятенә туры килмәгән эшләр чамасыз киң җәелгән түгелме? Рухны изеп, кысып торган эскәнҗәләр бушый төшкәч, Төмәндә дә бу хакта күпләр уйлана башлый. Фатих әфәнденең ниятләрен хуплаучылар да табыла. Шуларның берсе — шәһәрнең геологлар училищесы директоры Раил Низамов үз биләмәсендәге бер бүлмәне мәдрәсә сабакханәсе итәргә риза була. Шәкертләргә остазлык итүне башта Ямбай мәчете имамы Габделрәшит Вахит үз өстенә алса, соңрак Баку дәүләт университетын тәмамлаган гарәп егете Багдат Суфи, аннары Истанбулдан килгән Ибраһим хәзрәт Алныачык әфәнделәр белем бирергә керешә. Шәкертләр саны тиз арада кырыкка җитә. Остазларның һәм дөньяви, һәм дини укымышы төпле булу "Белем" мәдрәсәсенең дәрәҗәсен күпләр каршында югары күтәрә. Чөнки монда гарәп язуын өйрәнү, догалар ятлау гына түгел, Коръәнне, гарәп телен, ислам фәлсәфәсен һәм башка гыйлемнәрне тирәнтен өйрәнү бурычы куела. Шунлыктан шәкертләр дә татардан гына түгел, казакъ, ингуш, Дагыстан халыклары вәкилләреннән дә туплана, хәтта мөселманлыкны кабул иткән бер студент марҗа да керә монда.



*Төмән өлкәсендәге Янбай авылы мәчете*

"Белем" мәдрәсәсе ислам теориясен өйрәнү белән генә чикләнми, саф әхлак җәелүгә дә өлеш кертә. Дини бәйрәмнәрдә йола буенча пакъ ризык әзерләп, мохтаҗларны да җыеп мәҗлес корулар, җомга намазларын мөмкин кадәр күбрәк мөселманнарны җәлеп итеп гыйбадәт кылу, анда вәгазьләр сөйләүләр Төмән шәһәре рухи тормышына яңа бизәкләр өсти. Җәен балалар өчен "Иман" лагеры оештыру да матур эз калдыра — яшьләрдә үз халкыңа мәхәббәт, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү, туган телдә милли әдәбият белән таныштыру, хәләл хезмәткә күнектерү, ниһаять, зур шәһәрдә сибелеп яшәүче татар балалары өчен милли мөхит булдыру гына да гаять зур әһәмияткә ия. "Белем" мәдрәсәсе шәкертләренең берничәсе нәкъ менә шунда

укыганда танышып гаилә коруы, Марат Мәҗитнең укуын дәвам итү өчен Мәккәгә китүе дә Фатих Гарифуллин тырышлыгының җилгә очмавын исбатлый.

Шунысы кызык: Фатих әфәнде марҗага өйләнгән, аның ике кызы классик гимназиядә инглиз һәм алман телләрен өйрәнә, фортепианода уйнарга керешкән. Алар татарча белми, әмма гарәп телен өйрәнә һәм намаз укый икән.

Нишлисең, бездә халыкларны механик катнаштыру, "тылсымлы" интернационализм белән сугару бик нык һәм системалы рәвештә тормышка ашырылды, моның корбаннары да хисапсыз булуы безгә яхшы мәгълүм. Ул мирастан арыну ансат кына бармаячак, үз милли нигезенә юл күпләр өчен сикәлтәле һәм озын салыначак.

Фатих әфәнде хәрәкәттә. Ул Казаннан, Төркиядән һәм гарәп илләреннән мәдрәсәсе өчен дәреслекләр, китаплар алдыру, Төмәндә Шәрекъ мәдәни үзәген төзү, Төмән университетында Шәрекъ телләрен укытуны юлга салу һәм башка уйлар, мәшәкатьләргә күмелгән. Татарларның Икенче Бөтендөнья корылтаена килгәч тә, ул әнә шул ниятләрен гамәлгә ашыру максатында эзләнде, фикердәшләре белән киңәште, Казаннан ярдәм алырга өметләнеп йөрде.

— Согуд Гарәбстанына баргач, телевидение аша Себер мөселманнары хакында сөйләдем, — диде ул. — Бик кызыксындылар. Әмма бу ил бездән ерак, Татарстан исә күпкә якынрак. Шунлыктан без Идел-Урал белән хезмәттәшлеккә күбрәк исәп итәбез, Татарстанның Рәсәй күләмендә генә түгел, халыкара мәйданда да абруе күтәрелүенә, диндәшләребез уңышлары артуына шатланабыз.

## Җитәкчеләр гамәле

1989 ЕЛГЫ халык санын алу мәгълүматлары буенча Төмән өлкәсендәге милләттәшләребез түбәндәгечә урнашкан:

| Шәһәр/ | район | саны меңнәрдә | шундагы бөтен халыкка карата процентларда |
|---|---|---|---|
| Төмән | | 31,5 | 6,6 |
| Түбән Варта | | 24,7 | 10,1 |
| Тубыл | | 15,5 | 14,0 |
| Сургут | | 13,7 | 5,5 |
| | Төмән | 11,5 | 13,1 |
| Нефтеюганск | | 10,7 | 11,3 |
| | Вагай | 10,6 | 38,3 |
| | Тубыл | 9,3 | 31,6 |
| Ноябрьск | | 8,2 | 7,0 |
| | Яркөү | 8,0 | 31,6 |
| | Совет | 5,2 | 7,0 |
| Нянган | | 4,9 | 8,9 |
| | Ялутор | 4,3 | 25,7 |
| | Түбән Тавда | 4,0 | ? |
| Салехард | | 3,5 | 10,5 |
| Ялутор | | 2,3 | 6,3 |
| | Аромаш | 1,7 | 10,2 |
| Калган җирләрдә | | 57,8 | ? |
| Барысы | | 227,4 | 7,3 |

Өлкә җитәкчелегендә төрки халыклар буенча баш белгеч булып эшләүче Илдар Шәрәпов югарыдагы таблица саннарына кайбер аңлатмалар да бирде.

— Өлкә халкы 1959 елдан бирле өч тапкыр чамасы артты, шул

исәптән, азчылык милләт вәкилләре саны да үсте, — диде ул. — Өлкәбездә 125 милләт вәкиле яши, шулар исәбендә 41 мең башкорт, 31 мең чуваш, 19 мең әзербәйҗан, 16 мең казакъ, дүртәр мең комык һәм үзбәк тә бар. Төркиләрнең гомуми саны 350 мең чамасы, мин менә шуларның милли һәм дини ихтыяҗларын өйрәнәм, мәгариф-мәдәният, социаль-экономик мәсьәләләрне, кадрлар әзерләүне хәл итәргә туры килә. Төрки халыкларның күпчелек өлешен татарлар тәшкил иткәнлектән, минем төп эшем дә аларга бәйләнә инде. Дәгъвалар күп, аларның һәммәсен тиз генә уңай хәл итеп булмый, шуңа күрә мине "татар мәнфәгатен сатып көн күрә" дип еш сүгәләр. Акланасым килми, әмма минем вәкаләт алар уйлаганча зур түгел шул...

Илдар Төмән өлкәсенең Тархан авылында туган этник Себер татары. Нәселе бохаралылардан. Авыл мәктәбендә татар әдәби телендә укыган, 1968 дә урыс телендә белем ала башлаган. Төмән университетының тарих факультетын тәмамлаган, укыткан, читтән торып аспирантурада белемен күтәргән, "Себер һәм Казан татарлары: этносәяси багланышлар" темасына гыйльми хезмәт яза башлаган. Булат Сөләйманов белән бергә Себер татарларының автономиясен кору хәрәкәтендә катнашкан. Бу хәрәкәт Себер татарларын Казан татарларыннан аеруга, мәгариф-мәдәниятне үстерүдә өстәмә кыенлыклар тудыруга китергәнлектән, соңрак бу хәрәкәттән читкә тайпылган. Хатыны — авыл кызы, өч бала үстерәләр. Үзе 17 яшеннән Төмәндә яши, монда туганнары күп. Кыскасы, ул үз җирлегендә нык басып тора, милли мәсьәләне хәл итүнең бөтен катлаулылыгын аңлый, туган халкына бары яхшылык кына тели. Әмма өлкә җитәкчелегендә 7 ел хезмәт итү дәверендә, минем тоюымча, аның гайрәте һәм һәвәслеге шактый дәрәҗәдә сүрелгән — зур түрәләрнең татарның үсеше өчен киң юллар ачарга бик үк атлыгып тормавы аны чамадан тыш сак булырга — югарыдан кушканны үтәүчегә әйләндергән, күрәсең. Бик үҗәтләнеп торсаң, абруйлы вазифаңнан колак кагуың да бар югыйсә! Миңа Төмәндә яңа танышларым шул хакта даими тукып тордылар!

Әмма мин Илдар Шәрәфнең Казан вәкиленә ихлас булышырга теләвен, кирәкле кешеләр белән бәйләргә омтылуын, Төмән өлкәсе татар җәмгыяте турында кадерле хәл мәгълүмат бирүен яшерә алмыйм.

— Алтмышынчы елларгача Төмәндә асфальтланган урам юк иде — дип дәвам итте ул сүзен. — Тротуарлар тактадан иде. Өлкә —чимал чыганагы гына, монда эшкәртү сәнәгате юк иде. Без чыгарган җир маен да нигездә Омск белән Уфа эшкәртте. Хәзер инде, шөкер, хәл башкача. Сургут нефть эшкәртү заводы, Тубыл нефть-химия комбинаты аякка басты, башка кәсепханәләр дә ишәйде. Әйбәт юллар сузылды, Төмән белән Тубыл заманча тәскә керде. Төмән торак төзелеше буенча хәзер Мәскәү белән Петербургтан гына калыша. Менә ике ел инде үз игенебез үзебезгә җитә...

Нефть һәм газ чыгару буенча Төмән өлкәсе Рәсәйнең төп базасына әйләнгәч, монда үзгәрешләр күп булуы табигый. Үзгәртеп кору дәверендә исә азчылык милләтләр рухи тормышы да җанлана башлый. Радио-телевидениедә татарча тапшыруларга нигез салына, "Яңарыш" газете ачыла, Төмән дәүләт университетында һәм Тубыл пединститутында татар төркемнәре барлыкка килә. Ләкин шуңа да карамастан, милли хәрәкәт эшлеклеләре ифрат көефсез.

— Барысы да күз буяуга гына корылган, — ди алар. — Әлеге югары уку йортларында чынлыкта татар бүлекләре ачылмады, Казаннан чын укымышлылар — татар теле һәм әдәбиятын яхшы белүче галимнәр эшкә чакырылмады, татар мәктәпләренә җибәрелергә тиешле студентларга үзе дә татар телен юньләп белмәгән кешеләр урысча гына лекция укый. Шәһәрләрдә шушы көнгәчә бер генә татар мәктәбе дә, бер генә милли театр да ачылганы юк. Авыл татар мәктәпләрендә туган тел-әдәбият укытучылары җитми, байтагында арыган-талган пенсионерлар гына кыштырдый...

Илдар әфәндегә шушы хакта сорауларымны биргәч, ул җитешсезлекләр барын таныды.

— Казан һәм Алабуга югары уку йортлары белән дә килешүебез бар, Казанда 17 студентыбыз укый, — ди ул. —Татарстаннан дәреслекләр, методик кулланмалар кайтартабыз. 124 авыл мәктәбендә туган тел укытабыз, әйбәт эшләүче мөгаллимнәребез дә бар. Тубыл һәм Түбән Варта яслеләрендә татар төркемнәре тупланды. Төмәннең Парфеново микрорайонында 17 мең татар яши, шунда татар классларь ачып карадык, таралып беттеләр. Көчебез җитми, күрәсең. Татарстан белән Төмән өлкәсе килешүен яңарту мәгариф-мәдәният мәсьәләләрен уңай хәл итәргә булышыр иде. Әйе, кызганыч, тырышлыгыбыз җитми. Төмәндә һәм Тубылда 117 укытучы әзерләп ятабыз, былтыр шуларның 18е диплом алды, ләкин шуларның яртысы билгеләнгән эшкә бармады, шәһәрдә калдылар. Әмма сез, монда эшләр харап икән, дип кәефсезләнмәгез, Янтык, Шыкча, Киндерле, Аслана мәктәпләре белән танышыгыз...

Өлкәнең Вагай һәм Яркәү районнарында баш җитәкче итеп татарлар билгеләнгән — бу инде милли сәясәттә яңа күренеш. Өлкә Думасының рәисе урынбасары да безнең егет — Фуат Сәйфетдинов. Нефтьче инженер. Төньякта туган, Төмәннең үзендә белем алган. Яшь, энергияле. Мәгариф, мәдәният дөньясыннан ерак торса да, Татарстан хәлләреннән беркадәр хәбәрдар.

## Аерылыргамы? Берләшергәме?

ТӨМӘНДӘГЕ милләттәшләребез арасында галимнәр дә бар. Геология-минералогия фәннәре докторы, профессор Русия табигать Фәннәре академиясе академигы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Нәриман Колахмәтов, медицина фәннәре докторы, профессор, халыкара медицина академиясе академигы Рәшит Җиһаншиннар әнә шундыйлардан.

1997 елның җәендә миңа Төмәндә татар җәмәгатьчелегенең бер җыйналышында катнашырга насыйп булды. "Ак калфак" җәмгыяте "Азатлык" радиосы хезмәткәре Фәридә Хәмит белән очрашу оештырган иде, менә шунда мин медицина фәннәре докторы, Төмән медицина академиясенең хирургия кафедрасы мөдире, профессор Фатих Низамов белән таныша алдым. Ул өлкәнең Казанка авылында туып-үскән, әмма тамыры Апас районының Лашчы авылына тоташкан егет булып чыкты. Егет дим, чөнки ул миңа һәр яктан егет булып күренде. Туган телен бик яхшы белә, мәдәниятебезнең тагын да көчләрәк үсүен тели, шат күңелле, шаярырга ярата, шундый җитди эштә профессор дәрәҗәсенә җитүенә карамастан, әле яшь, таза-сау, бөтен кыяфәте белән күркәм кеше.

Искәртелгән очрашуда да Төмән татар җәмәгатьчелегенең танылган вәкилләре катнашты. Алар арасында радиосөюче, шушы тар-макта халыкара ярышларда катнашып, чемпион исемен казанган, хәзер Төмән радио мәктәбе укытучысы булып эшләүче Зыятдин Низамов, Төмән университетының француз, алман телләре укытучысы, татар үзешчән сәнгатен үстерүне куәтләүче Равил Гыйлфанов, педагогик стажы 49 елга җиткән мәгариф ветераны Равилә Сафина (Себер татарлары мәгарифендә якты эз калдырган Фатыйма Галиәкбәрова кызы), башлап язучы шагыйрь Заһит Акбүләков, "Яңарыш" газете хезмәткәрләре, үз фирмасын ачкан табибә Вәсимә Биккина, этник Себер татарлары хәрәкәте узаманнары Әнәс Гаитов, Рифкать Насыйбуллин һәм башка милләттәшләребез катнашты. Алар монда читтән килгән кунакларны гына тыңлап калмады, якташларын борчыган фикерләрен дә уртаклашты.

**Мисалга, укытучы Гөлчирә Әминева:**

— Игътибар итәсезме, безнең арада яшьләр бөтенләй күренми ич, — диде. — Пенсионерлар, шулар яшенә якынаеп килгән кешеләр, иң яшь дигәнебез дә кырык ягына чыккан зат. Әгәр без милли хәрәкәттә борылыш ясый алмасак, киләчәгебез юк дигән сүз. Без яшьләрне үз

тирәбезгә җыя белмибез, шунлыктан туган тел, туган мәдәният йогынтысы елдан-ел тарая бара, катнаш никахлар өлеше арта.

**Фанера фабрикасы директоры Әлмирә Кәримова:**

— Туган телебезне өйрәнү, белү бик әһәмиятле — мин моны төрек эшкуарлары белән очрашкач, бигрәк тә яхшы аңладым. Урыс теле Русиядә генә кодрәтле. Мөселман илләре белән эш иткәндә безнең нинди мәдәният һәм дин вәкиле булуыбыз да роль уйный — татарлык диндәшләребез белән яхшы багланышлар корырга булыша. Аннары туган телебездә бик кыйммәтле мәдәният байлыклары тупланган — без аның кадерен белеп файдаланмасак, кешелегебез дә камил булмаячак.

**Равилә Сафина:**

— Элек безгә Казаннан еш-еш килеп торалар иде. Төмәнлеләргә филология фәннәре докторы Хәмит Ярми бигрәк тә күп булышты. Татарстанның әнә шундый юмарт ярдәме өлкәбездә милли мәгариф һәм мәдәният утын үтермәүдә зур таяныч булды. Хәзер барыш-килеш сирәгәйде, җитмәсә, татар икегә — себерлеләргә һәм казанлыларга аерыла башлады, бу милләтебезне саклауга һәм үстерүгә хезмәт итми...

**Әнәс Гаитов:**

— Без, себерлеләр, казанлыларны ят күрмибез, мин үзем алтынчы сыйныфкача татар әдәби телендә белем алдым, "Казан утлары" журналын даими укып яшәдем. Татарстан суверенитетын яклауны "Сыбыр" җәмгыяте үзенең намус эше санады, шул юнәлештә гамәл кылырга тырыштык. Әмма хәзерге татар әдәби теле Себер татар шивәсеннән аерыла. Аннары... без элеккечә бер генә төрле татар булып яшәсәк, безне килмешәк украин, поляк, чуашлар белән тиң күрәчәкләр. Ә без — җирле халык, димәк, автономиябез дә булырга тиеш. Ул чакта безнең милли ихтыяҗларыбыз да башкача канәгатьләндереләчәк, өлкә Думасында да, Кырым татарларыныкыдай квотабыз — вәкиллегебез булачак. Кырым татарлары үзенчә яши, без алардан киммени?..

Әнәс Гаитов чыгышында үз кабиләдәшләре өчен сызлану, аларны үстерү өчен яну барлыгын күрү һәм тою бер дә кыен түгел иде. Себер татарларының аерым этник берәмлек икәнлеген күтәреп чыгу, җитәкчелеккә үз таләпләрен куя гомум татар җәмгыятен борчый, аны зәгыйфьләндерә торган бер вакыйгага әверелде. Казанлылар моны зарарлы омтылыш санады, Төмән өлкәсе хакимияте исә бер урынына ике татар хәрәкәте белән эш итәргә мәҗбүр булды. Дөрес, кайбер җитәкчеләр моңа сөенде генә, хәтта әле бүленүгә астыртын рәвештә булыштылар да бугай, чөнки "сепаратистларның" икегә аерылуы империя файдасына хезмәт итәчәк, үзара көрәшеп хәлсезләнгән татарны йотып бетерүне ансатлаштырачак!

Соңгы дәвердә бердәм татар милләтен төрле кабиләләргә таркатып, алардан аерым этнослар барлыкка китерү хәрәкәте бик нык көчәйде. Баксаң, нагайбәк, керәшен, карагаш, нугай (нугайлыгын беркайчан да җуймаган халыкны күздә тотмыйбыз), татар-башкорт һәм башка милләтләр татар исемен ялгыш йөртә икән!

Татар — Рәсәй империясендә һәм СССРда урыслаштыручыларның бугазына төер булып тыгылган бердәнбер зур көч булды. Югалтулары аз түгел, ләкин ул һаман исән, һаман йотылуга карыша. Татарның үз йөзен, табигатен саклап иркле яшәр өчен көрәшүен бары "сепаратизм" итеп кенә күргән империя тарафдарлары бүген дә аны юк итү уеннан чигенгәне юк. Шуңа күрә татарлыкны какшату өчен төрле алымнар һәм чаралар кулланыла: тупас басым, Татарстан бәйсезлеген какшату, Татарстан белән аннан тышта яшәүче татарларның багланышын зәгыйфьләндерү, Башкортстанда татарны башкортка әйләндерү һәм башкалар, һәм башкалар... Ләкин бу гына әле җитми, күрәсең, тагын да нечкәрәк ысуллар куллану кирәк — татарны эчтән таркату, аны үз эчендә төркемнәргә аерып көрәштерү, әнә шулай җелеген суыру отышлы! Аны

күп милләтләргә әйләндерсәң, "бүлгәлә һәм хакимлек ит" шигарен җырлый-җырлый гамәлгә ашырырга мөмкин булачак инде. Татарның кайбер каһарманнары моны яисә аңлап җиткерми, яисә аңлы рәвештә шовинистларга хезмәткә кергән. Бушка гына түгел, әлбәттә!

Татарның төрле төбәкләргә сибелеп урнашуы, аның чыннан да төрле этнографик төркемнәрдән торуы, уртак милли татар дәүләте эчендә яшәмәгәнлектән, этнографик аерымлыкларның кимемәве шовинистларга мәкерле уеннарын уйнарга бик шәп мөмкинлекләр ача, билгеле. Әмма татарның тегебу кабиләсен генә йөрәгенә якын иткән каһарманнар уйларга тиеш ләбаса: аерымлыклар кайсы халыкта гына юк соң ул? Кешелек дөньясы бүген кабиләчелеккә һәм ыругчылыкка таба үсәмени? Тукай әйтмешли, өеңә карак кергәндә ир белән хатын юрган өчен тартышып ятса, аларны алда ни көтәчәк? Барын да югалтып бетерүгә китермәсме бу? Түбән өлкәсендә хәзер этник Себер татарлары да зур тизлектә шәһәрләшә башлаган. Шәһәрләрдә исә азчылык милләтләрнең йотылуы бик тиз баруын беләбез. Бигрәк тә милли мәдәният-мәгариф учакларың булмаса, азчылык күпчелек арасында сибелеп яшәсә! Казан татарлары себерлеләрдән дистәләрчә мәртәбә күбрәк булуга, Татарстан биргән дәүләтчелеге яшәүгә, анда шактый ук куәтле профессиональ мәдәнияте, мәгариф системасы барлыкка килүгә карамастан, милли йөзләрен җуя бара түгелме? Әгәр инде алар шундый хәлдә икән, себерлеләрне бернинди автономия дә саклап кала алмаячак — без ул автономия җимешен татып карадык ич инде!

Алман әдәби теле булмаса, Саксония алманы белән Бавария алманы үз шивәләрендә сөйләшеп бер-берсен аңлый да алмаслар иде. Үзенчәлекләрен дә саклыйлар, әдәби телләрен дә бик тырышып өйрәнәләр — бердәм нимес милләтен барлыкка китереп яши бирә алар. Нишләп без шулардан гыйбрәт ала белмибез икән?!

Әнәс Гаитов белән без соңрак шушы хакта фикер алыштык, ләкин иркенләбрәк сөйләшергә вакыт җитмәде. Мин аның ихласлыгына, үз кардәшләренә яхшылык теләвенә ихтирам белән карыйм, аңа төрле яктан таяк ашарга туры килүен беләм. Шул ук вакытта аның аерымлану омтылышын хуплый да алмыйм. Әйе, этник Себер татарлары мирасын барларга һәм җыярга, аларны гомум татар мәдәни хәзинәсенә тулырак кушарга, шулай итеп гомум татар йөзендә Себер татары чалымнарын арттырырга кирәк. Бу фикерне "Ак калфак" оешмасы җитәкчесе Бибинур Сабирова да яклады. Әгәр без татарны төрле якка тарткалап парчаласак, беребез дә максатына ирешә алмас. Аерым Себер этник татары гына түгел, татар милләте тулаем да тарих тузаны астында күмелеп калыр. Мәңгегә...

Шушы фикер белән килешкәнлектән, "Яңарыш" гэзите баш мөхәррире Азат Сәгыйтов Казан белән тыгыз хезмәттәшлеккә омтылуын белдерде.

— Татарстан белгечләре булышмаса, Түмәндә татар гимназиясе ачылуына, университетыбызда татар бүлеге тиешенчә эшләвенә, өлкәбездә милли сәнгать учакларыбыз җанланып китүенә өметләнү дә кыен. Бу эш ике төбәк арасында рәсми килешүләр төзеп үтәлергә тиеш.

Шунысы бераз күңелне юата: 70-80 еллардагы хәл белән чагыштырганда, хәзер Түмәндә татар язмышы хакында сөйләшерлек, нидер эшләрлек рәсми хезмәткәрләр дә, ачыктан-ачык барлыкка килгән ирекле җәмгыятьләрнең җитәкчеләре, активы да бар. Әмма, "башкорт" паспортлы милләттәшләребезне дә кушып исәпләсәк, саны 300 меңгә якын татарга алар бик-бик аз әле. Аларның гамәлләре исә ихтыяҗның уннан бер өлешен дә каплый алмый!

*Сәяхәтнамә*

# ӘМИРЛЕКЛӘРДӘ ОЧРАШУЛАР

## Түбәтәй — татарга виза ул

Кая барсаң да шулай көтелмәгән бер-бер хәл килә дә чыга... Рус таркаулыгы, битарафлыгы безне шулкадәр элэктереп алган ки, күпме теләсәк тә шуннан котыла алмыйбыз. Бу юлы да аның әлеге "күркәм" сыйфаты үзен сиздерде. Без Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә Ростов-Дон аэропортыннан сәгать биштә очып китәргә тиеш идек. Сиксәнгә якын пассажир инде таможня тикшеренүләрен дә узды, кыскасы, очып кына китәсе калды. Ә самолет юк та юк, Мәскәүдән килеп житмәгән, диләр. Хәер, көтә торгач, Ту-154 очкычы килде килүен... тик жиде сәгатькә тоткарланып килде.

Без Ростов-Доннан очып киткәндә 10 градус салкынлык иде. Дүрт сәгатьтән соң Әль-Айн аэропортына килеп төштек. Эссе, 33 градус. Мин тиз генә сумкадан табып алып Актанышның истәлек бүләген — түбәтәемне киеп куйдым.

— Суйган да каплаган, чын мөселман инде үзен, — дип көлемсерәделәр ростовлы юлдашларым.

— Чыраен барыбер Рязань чырае инде, — диде шунда берсе.

— Рязаньныкы түгел, Казан чырае. Кырыс кына төзәтергә туры килде үзен.

Шәрекъ стиле белән корылган, заманча жиһазланган аэропорт бинасына килеп кердек. Таможня үз эшен төгәл белә — килгән кунакларны жиз иләктән үткәрә. Менә минем дә чиратым житте. Русиянең "күркәм" сыйфаты мине тагын котыртып алды. Таможняда торучы яшь кенә гарәп хезмәткәре документларымны игътибар белән өйрәнде дә, Ростов аэропортының Әмирлектәге вәкиленә инглизчә нидер әйтте.

— Сезгә керү визасы ачылмаган икән, — диде ростовлы.

— Ничек инде?! — дип гажәпләндем мин. — Ростовта бернинди проблема да булмас, диделәр бит?!

— Әйе, барысы да тәртиптә, тик сезнең фамилияне виза кәгазенә кертергә онытканнар. Сезгә залда кунарга туры киләчәк. — Һәм ул елмаеп өстәп куйды: — Кәнәфиләр исән монда, куныгыз... Бер кичкә, кер мичкә, диләр бит. Хәзер Ростовка факс жибәрәчәкбез, иртәгә төш вакытына жавап килеп житәр...

Юлдашларым зур залга уздылар. Башымдагы Актаныш түбәтәе белән мин бер үзем монаеп тикшерү залында торып калдым.

Шулай аптырап басып торганда, ап-ак тешләрен ялтыратып яныма пакистанлы полицейский килде. Үзе минем түбәтәйгә карый, үзе елмая.

— Мин — мөселманмын, — дигән булам түбәтәемә бармак белән төртеп күрсәтеп.

Пакистанлы аның саен ягымлырак елмая төшә. (Пакистанлылар эмирлекләрдә полицейский булып килешү буенча эшлиләр икән.) Түбәтәемә карап, кайсы милләттән икәнемне чамаларга тели, ахрысы. Бәлки әле хәлемә дә кермәк[...]дер... Әмма тәртип икән — тәртип, ана буйсынмый булмый. Шулай да кырын күз белән генә тәрәзә аша күреп торам, әле минем юлдашларым Дибаига китмәгәннәр, һәммәсе дә ни булыр икән дип мине күзәтәләр. Үзләре хихылдыйлар, әйе, әйе, көлмиләр, хихылдыйлар:

— Элэктенме, татар, янәсе...

Мин һаман полицейскийга нидер аңлатмакчы булып: "Мөселманмын", — дип кабатлыйм, үзем түбәтәемә төртеп күрсәтәм. Шулвакыт балачактан ук өйрәнгән дога исемә килеп төшә һәм мин үзем дә сизмәстән кычкырып шуны укый башлыйм:

— Әгъүзе биллаһи мин әш-шәйтан ир-ражим...

Шулчак полицейскием елмаюдан туктады да, ашыга-ашыга каядыр китеп барды. Биш минутлап вакыт узуга, ул униформа кигән бер гарәп һәм Ростовның "Донавиа" авиапредприятиесе вәкиле белән кире әйләнеп килде. Үзара нидер сөйләшкәннән соң, мина таба юнәлделәр.

— Әйдәгез зур залга, юлдашларыгыз янына, — диде "Донавиа" вәкиле. — Полицейский һәм виза буенча җаваплы кеше сезне кызгандылар, иртәгә визаның факс белән киләчәгенә ышандылар.

— Вәт, татар, — дип каршы алдылар мине ростовлылар, шау-гөр килеп.

— Кадерле партиябезгә бәхетле балачагыбыз өчен рәхмәтләр яусын! — дидем мин һәм янә дә түбәтәемне капшап куйдым. Әһә, урынында икән.

## Бунгало

Дибаиның Насыйр-плацы безне якты йөз белән каршы алды. Бу мәйдан Мисырның беренче Президенты Гамәл Габделнасыйр хөрмәтенә шулай аталган (Насыйр — Советлар Союзы Герое да. Заманында ана бу исемне Н. С. Хрущев биргән иде). Әлеге мәйданның зиннәтле биналарында дөньяның эре банклары, халыкара оешмаларның офислары урнашкан. Бу мәйданнан әлеге башкаланың берсеннән-берсе матуррак проспектлары башлана. Шәһәрнең тын, яшел урамнарында һәрберсе заман архитектурасы үрнәге булырлык 4 һәм 5 йолдызлы кунакханәләр тезелешеп киткән.

Насыйр-плац элеккеге Советлар Союзының төрле республикаларында яшәүче рус телле халыкның очрашу, аралашу урыны булып та тора.

Мәйданнан ике кварталда кибетле, лавкалы урамнар башланып китә. Анда безнең шүрелэргә — татарча челнок шүре була инде — уптым товар саталар. Урамнар базарлы мәйданга килеп терәлә.

Базар тирәләрендә халык аеруча күп. Баш киеменә карап кемнен-кем икәнлеген бик тиз аерырга була. Мәсәлән, башына хатын-кыз яулыгына охшаган, озын ак тукыма ябып йөргән кешене очратасың икән, ул гарәп булыр. Әгәр "яулык"та бер бөҗра бар икән, аның хуҗасы Мәккәдә бер тапкыр булган дигән сүз, ике бөҗра исә — ике тапкыр хаҗ кылган дигәнне аңлата.

Һиндле мөселманнар исә тюрбан киеп йөрергә яраталар.

Пакистанлылар түбәтәй "пилотка" кия. Ә Әфганстаннан чыккан әфганнар, кайчандыр Политбюро әгъзалары кигән бүреккә охшаган түгәрәк башлык киеп йөриләр.

Ә инде Дибаида нәкышләп эшләнгән, матур бизәкле түбәтәй кигән урта яшьләрдәге ир-егетне очратсагыз — бу мин, ягъни, Актаныш татары булырмын...

Шәһәрдә йортлар нигездә җиде катлы. Һәрберсендә үзенә генә хас үзгәлек, бизәк бар.

Бирегә мәчетләрне аеруча матур төзиләр икән. Алар Дибаида бихисап, намаз вакытында урамнар бушап кала.

Шәһәрдән Әль-Айн аэропортына кадәр (180 чакрым) бик шәп автобан сузылган. Андый юллар Россиядә кайчан булыр, бер Алла белә, һәрхәлдә мин үзебездә андый трассаларны күрә алмам инде. 20-25 чакрым саен — автозаправка станциясе.

Тирә-юньдә иксез-чиксез чүл. Дөяләр, барханнар... Ә автозаправка станциясе янында пальмалар, хөрмә агачлары үсеп утыра. Туфракны бирегә бөтен дөньядан

диярлек китерәләр икән. Ә станциянен үзендә бер генә май, ягулык табы күрмәссен. Якында гына "шоп". Кереэбез. "Кондиционер"лар шаулый. Безнен бәя буенча уртача гына кибет. Ин мөһиме шул, чүл уртасында юк кына бәягә дә дөньянын төрле илләрендә эшләнгән жанын ни тели, шуны сатып алырга мөмкин. Гажәп бит!

Автозаправка станциясенен икенче ягында ап-ак манаралы кечкенә генә мәчет. Автомобилен станция хезмәткәрләре карамагында булганда, мәчеткә кереп намаз да укып чыгарга була. Мәчет каршына таһарәтләнү урыны ясап куйганнар. Анда, чүл уртасы булуга карамастан, кондиционеры да, жылы суы да, комганы да, хәтта кәгазь сөлгесе дә бар. Барысы да бушка.

Куптән түгел генә мин үзәк журналларнын берсеннән АКШнын элеккеге илчесе Джон Мэтлокнын Россия буйлап сәфәре тәэсирләре хакындагы язманы укыган идем. Ул: "Мин Л. Н. Толстой, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Ф. М. Достоевский кебек генийлар алдында баш иям, И. Е. Репин, В. М. Васнецов, А. М. Герасимов кебек рәссамнарнын әсәрләренә карап сокланам, әмма... Великие Луки аэропортындагы бәдрәфне гомеремдә дә онытасым юк", — дип яза.

— "Әй-йе, — дим мин үз-үземә: Великие Луки гына булсачы. Әмма Россия бик зур шул".

Әмирлекләрдән сәфәрдән кайткач, мина Ростов аэропортында тагын бер рус кешесе очрады.

— Әмирлекләрдән кайтуынмы? Анда чума, йә холера эләктермәгәнсендер бит?

— Жаным! — дим мин уфтанып. — Холера белән чуманы Әмирлекләргә Россиядән илтеп таратсан гына инде... Бездә анын өчен шартлар житәрлек...

Әмирлекләрдә үзеннен мөселман дөньясында икәнлегенне тоеп яшисен. Юллардагы шәһәр исемнәре күрсәткечләре шуны раслый: Әль-Кувейт, Әбү-Даби, Мәдинә, Мәккә, Әр-Рияд, Жидда...

Биредә бездә өзлексез чәйнәлгән мөселман, ислам фанатизмы да, ислам фундаментализмын да сизмисен. Берәү дә сине көчләп мәчеткә кертеп намаз укырга мәжбүр итми, башына чалма, тюрбан, түбәтәй кигезми. Ислам биредә — яшәү рәвеше, фикер йөртү рәвеше.

Шәрекъ илләрендә булгач, исламнын агрессив дин түгел икәнлеген, анын киләчәк буын дине булуын тоясын, сиземлисен.

Мин шул чак Татарстаным турында уйландым. Анда да бит жир мае чыгарыла, мәйтәм. Күп кенә түгел, бик күп. Ә ничек яшибез. Байлыгыбыз "Дуслык" нефтъүткәргечләре аша, Ангола, Мозамбик, Никарагуанын һәм тагын башка бик күп илләрнен якты киләчәгe хакына каядыр, төпсез упкынга акты да югалды... Хәзер дә югала тора...

Әмирлекләрдә төп унжиле гаилә-кланы бар. Илнен калган халкы төрле гарәп, мөселман дәүләтләреннән жыелган халык. Әмма алар төрле илләрдән килгән булсалар да, гарәпчәдән тыш инглиз телендә дә иркен анлашалар. Соңгы вакытларда биредә рус теленә дә игътибар көчәйгән. Россиядән килгән шүрләр белән аралашырга, товарны тиз арада үзенә ятышлы бәядә сатып жибәрергә кирәк бит.

Зиннәтләп бизәлгән дүрт йолдызлы "Флот-отель" кунакханәсенен холлында, йә булмаса бассейн янында мин элеге кунакханәнен Һиндстаннан килгән мөселман белән гапләшергә ярата идем. Аларны, әлбәттә, Татарстан кызыксындыра: "кяферләр" белән уратып алынган "атау"да яшәвебезгә шаккаталар...

— Синен нефтен бармы сон? — дип сорап куя шунда бер Һиндле мөселман.

— Ник булмасын, бар. Нефть суыру жайланмалары яшелчә бакчасында гына...

Әнгәмәдәшләремнен гажәпләнүдән күзләре зур булып ачыла.

— Ә нәрсә ул яшелчә бакчасы? — дип кызыксына икенчесе.

Мин уйлап-уйлап торам да, телемә килгән беренче сүзне әйтеп калырга

ашыгам:

— Бунгало...

Һиндлеләрнен гажәпләнүләре тагын да арта төшә:

— О, Аллаһ! Синен бунгалон бар?! Болай булгач син — әмир...

Кызганыч, алар авылдан "бәхет эзләп" чыгып киткәндә, жимерелеп, аварга торган өч алачыгыбыз калганын белмиләр шул. Ә нефтькә килгәндә, ул Актанышта күптән түгел генә чыгарыла башлады. Ни өчен, кем өчен чыгарыла, шулай ук Алла үзе генә белә торгандыр. Ә менә безнен элеккеге яшелчә бакчасында әлегә эшләмәүче бер скважина тора. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки аннан да жир маен суыртырлар.

## Шуравилар

Бу бай шәһәрдә мин бер генә хәерчене дә күрмәдем дип әйтсәм, ялган булыр. Ике кешене күрдем, алар мина элеккеге совет чынбарлыгын хәтерләттеләр.

... Ул базар мәйданында, шәрекънын жәннәт жимешләре сатыла торган кибет янында утырып тора иде. Ике аягы да юк, югары сыйфатлы куннән, ялтыравыклы никельдән эшләнгән протез. Узып баручылар бу адәм алдындагы пластмасс чәшкәгә ара-тирә дирхәмнәр, долларлар ташлап китәләр.

— Дух! — диде аны күргәч, Виктор Казаченко үзенен юлдашы Сергей Фроловка эндәшеп.

— Күрәсенме, анын башында әфган тюрбаны, бу анын иске танышыбыз булуы хакында сөйли...

Юлдашларым кайчандыр әфган сугышында катнашып, могжиза белән генә исән калган ир-егетләр иде.

Аяксыз шунда безне күреп алды:

— О-о, шурави! — диде. — Аннан кукрәгенә төртеп:

— Дух, дух, мөжәһид..., — дип кабатлады.

(Белмәүчеләргә анлатып китим: мөжәһидләр — әфган сугышында совет гаскәрләренә каршы көрәшкән әфганлылар, ә шуравилар — совет сугышчылары (кешеләре) була инде.)

— Пуштун? — дип сорап куйды Казаченко.

Дух "юк" дигәнне анлаткан ишарә ясады. Чираттагы сорауны Фролов бирде:

— Тажик?

— Үзбәк! — дип жавап кайтарды кичәге "дух".

— Ну, егетләр, сездән мәгарич! — дигән булдым мин. —Тылмачыгыз булам. Татарча белгәч, үзбәкчә дә анлашырга мөмкин.

Шуннан гәп кора башладык. Кәрим (аяксыз әфганнын исеме шулай булып чыкты) Кандагар янында "шурави"ларда өч ай әсирлектә булган икән. Шунда берничә рус сүзен дә хәтеренә сендереп калдырган. Аякларын сугыш тәмамланыр алдыннан гына совет снаряды кыйпылчыкларына өзелгән. Афәт вакытында барча туганнарын югалтып, япа-ялгыз калган. Озак вакытлар Пакистанда дәваланган. Америкалылар үзенә менә дигән протезлар ясап биргәннәр. Хастаханәдән чыккач, сугыштан, ыгы-зыгыдан туеп, Әмирлекләргә килгән.

Әнгәмәнен ин кызган чагында безгә тагын бер мөжәһид килеп кушылды. Анысына 40 яшьләр чамасы булыр, бер кулы юк. Үзе Әхмәт исемле икән. Язмышы Кәрим язмышына охшаш.

— Менә бу очрашу! — диде шул чак Казаченко. — Моны юмыйча булмый...

— Ара-кы, — дип елмаеп куйды Кәрим.

— Хә-рәм! — дип үз сүзен әйтеп калырга тырышты бер куллы Әхмәт, кырыс кына.

— Синен хәрәмең белән ерак барып булмас, — диде Казаченко кискен генә, һәм юлдашының жилкәсенә сугып, бәхәскә нокта куйды:

— Бар тизрәк кунакханәгә чап, анда запас бар бит.

Сергей Фролов рус аракысы кыстырып бик тиз килеп житте. Кибет хужасы "дух"ларның якташлары икән, шуңлыктан аның склад кебегрәк жиренә кереп, шешәдәге аракыны өчкә бүлделәр дә жәпләп тә куйдылар. Күпме кыстасалар да без Әхмәт белән "шайтан суы"ннан баш тарттык. Кәрим исә аракыны "шурави"ларда әсирлектә вакытта эчәргә өйрәнгән икән.

Эчтеләр, кабымлык кабып куйдылар. Аракы исә һәрвакыттагыча житмәде. Фроловка янә дә кунакханәгә "ак баш" артыннан барып килергә туры килде...

Бу вакыйгадан соң 15 минутлап та вакыт үтмәгәндер, базар мәйданында Фроловны пакистанлы полицейскийлар тоткарлады. Мескенне күз ачып йомганчы такси белән каядыр алып та киттеләр.

Ни булганын кичкә таба гына белдек. Фроловны спиртлы эчемлекне пропагандалаганы өчен кулга алганнар икән. Үзе дә ахмак инде, аракыны кунакханәдән челтәр букча белән ташыган икән. Рәсәй түгел бу сиңа!

Әйе, Әмирлекләрдә теләсә нинди спиртлы эчемлекне пропагандалау, куллану тыела. Моның өчен жәза бик кырыс. Фроловны да 30 көнгә төрмәгә ябып куйдылар. Дибаи шәһәре үзәгендә әфган сугышы ветераннарының очрашуы әнә шулай күңелсез тәмамланды. Ә без Ростов-Донга Сергей Фроловсыз гына очып киттек.

... Иртән багаж өчен акча түләргә дип Ростовның автопредприятие кассасында чират торам. Халык шактый гына. Чиратым килеп житте дигәндә генә, алдыма ниндидер майор килеп керде дә, кәгазьләрен касса тәрәзәсенә төртте:

— 200 нче йөк. Ике урынга. Новгородка каләр.

Мин аның тактсызлыгына хәйран калып, үземне яклап сүз әйтергә уйлаган идем, хәрби:

— 200 нче йөк — гроблар, солдат гроблары. Аларны Чәчәнстаннан Ростовка тимер юл белән рефрежератор вагоннарда китерәләр, ә аннан соң без бөтен Россия буенча туганнарына таратабыз. Шундый махсус батальон бар, — дип аңлаткач, үземә оят булып китте. Шушы көнгә кадәр 200 нче йөкнең ни икәнлеген белмәгәнмен икән... Берләшкән Гарәп Әмирлекләре башкаласы Дибаиның базар мәйданында очраган кулсыз Әхмәт белән аяксыз Кәримнең дөньядан туйган күзләре, нурсыз карашлары хәтеремә килде:

— Кем гаепле?..

**Ягъсүф ШӘФЫЙКОВ,**
журналист

# ФАҖИГАЛЕ ЯЗМЫШ

## ЯЗУЧЫ МИН ШАБАЙ ТУРЫНДА ЯҢА МӘГЪЛҮМАТЛАР



*Куе кара мыеклы, уйчан карашлы, чалара башлаган чәчләрен Такташныкыча артка ташлаган мөлаем бу кеше бүгенгәчә күз алдымда тора.*

*Бервакыт, Язучылар берлегенең коридорында тыйнак кына елмаеп баруын күргәч, мин аннан шатлыгының сәбәбе нидәлеген сораган идем.*

*— Соң, Рафаэль энем, яз җитә ич, яз! — дип, чын күңелдән шатланып җавап кайтарды ул.*

*Февраль урталары иде. Тышта чатнама суык. Урамнан узучылар якаларын күтәреп, борыннарын бияләй белән каплап тиз-тиз атлап йөриләр... Ә ул яз ди...*

*— Ленин бакчасыннан узышлый колагыма песнәкләр сайрашуы ишетелде. Борыныма шундый татлы, тансык ис бәрелде. Күтәрелеп карасам — ак тирәк бөреләре кояш нурлары астында җылынып, чак кына бүртеп, яз исе бөркеп торалар...*

*Мин Шабай яз килүен башкалардан алдарак сизеп, шуңа шатланып яши белде. Бу аның соңгы язы иде...*

### Уйналмаган скрипка

Мин Шабайны беренче чиратта оста хикәяче дип саныйм мин. Аның шактый шома язылган очерклары, яратып укыла торган повестьлары, заманы өчен уңышлы гына чыккан пьесалары, хәтта бер романы да бар. Әмма әдәбият тарихына ул үзенең искиткеч тәэсирле, җыйнак, моңы аңкып торган хикәяләре белән кереп калды.

Шулар арасында күңелемә иң якыны — "Уйналмаган скрипка". Хикәянең төп герое, ятим авыл малае, нииндидер могҗиза белән кулына бик затлы, кыйммәтле скрипка төшерә. Чит-ят күзеннән яшереп, ул аны жиргә, тирес өеме астына күмә. Күпмедер вакыттан соң скрипканы уен коралларын нечкә аңлый торган Фәтхи бабайга күрсәтә. Бабай скрипканы бик хөрмәтләп кулына ала, колагын салып, чиертеп карый, озак-озак тыңлап тора да, иясенә кайтара. Тирес астында яткан скрипкага черек тигән, ул элекке моңын, матур тавышын югалткан инде...

Бу күренешнең бик тирән эчке мәгънәсе бар. Кеше жанын, шул исәптән язучы күңелен дә затлы уен коралы белән тиңләп булыр иде. Аны да шулай тирес астына күмеп әрәм итү ихтимал...

Мин Шабайның ниндидер жыелыштан соң ачынып әйткән сүзләре әлегәчә колагымда яңгырый:

— Нишләп аз язасың, диләр... Мин бит ярты гомеремне төрмәдә черетеп үткәрдем... Яртьі гомеремне!

Чыннан да, М. Шабай үз гомеренең илле елыннан уналтысын төрмәләрдә, колонияләрдә, лагерьларда, сөргеннәрдә үткәрә. Бер бит кәгазь, сынык каләм кисәген таба алмыйча интегә. Исәнлеген югалта, имгәнә, гангрена башланып, чак үлми кала... Кайвакыт, ачы шаяртып: "Миндә нинди генә авыру юк! — дип әйтә иде ул. — Врачлар бавырымны, бөерләремне, ашказанымны дәваларга кирәк, диләр. Югыйсә, үләсең, имеш. Ә мин: ана хәтле мин әллә кайчан инфарктган үләчәкмен, дип әйтәм.

Икесе булды инде, өченчесен көтәм... Алайса, йөрәгеңне дәваларга кирәк, диләр. Ә мин әйтәм: Мин аңарчы яман шештән үләмен, дим. Миндә ул да бар. Аяк-кул сызлавын әйткән дә юк инде!"

Ул үлгәчтен хатыны көндәлекләреннән шундый юлларын табып, миңа күрсәткән иде: "Биш минут язам, бер сәгать ятып ял итәм..." Врачлар, аннан зарланып, ничә мәртәбә Язучылар берлегенә шалтыраттылар: "Ана больниска ятарга кирәк... Ә ул бездән качып, дәваланмыйча йөри... Хәле бик начар, кисәтеп куябыз... "Ул вакыттагы Язучылар берлеге рәисе Мирсәй ага Әмир аның белән кат-кат сөйләшеп карады. "Гомеремнең соңгы көннәрен шифаханәдә тончыгып ятаммы соң! — дип җавап кайтара иде Мин Шабай. — Санаулы көннәремне үзем теләгәнчә яшәп калыйм, ичмасам..."

Һәм ул үзенекен итте: 1963 елның кояшлы сентябрь иртәсендә якын дусты белән алма бакчасында серләшеп утырган чакта, йөрәге тибүдән туктады...

## "Мин хулиган идем..."

Мин Шабай 1913 елның 28 апрелендә Башкортстанның хәзерге Кушнаренко районында, Кара Тәкә авылында дөньяга килә. Алты яшеннән әнисе үлеп, ярым ятим кала. Әтисе акча эшләргә читкә чыгып китә, ә ул үз көнен үзе күрергә мәҗбүр була. Байларга тамак хакына ялланып, хезмәт итә. Бервакыт, абзар түбәсеннән кар чистартканда, егылып төшеп, аягын имгәтә. Бай аны шундук өеннән куып чыгара: авыру баланы бушка ашатып яткырырга аңарда Әндри казнасы юк, имеш...

Берничә елдан, әтисе бераз акча юнәтеп кайткач, тормышлары яхшыра төшә. Әтисе мал-туар, ат сатып ала, чын-чынлап дөнья куа башлый. Улын мәктәпкә бирә, тегесе бик яратып укып йөри. Ләкин колхозлашу еллары килеп җиткәч, аларны "раскулачить" итәләр, бөтен мал-мөлкәтләрен тартып алалар, әтисен мылтык белән алып китәләр. Мин Шабай исә качып котыла.

Унбиш яшьлек үсмер малай 1928 елдан ил буенча йөри. "Мин хулиган идем, — дип сөйли иде Мин ага бу еллар турында. — Карак шайкаларына кушылып, урлаштым да, сугыштым да, кеше таларга да туры килде. Кайда эләксә, шунда йоклый идек, нәрсә эләксә, шуны ашый идек... Ярым ялангач, ачлы-туклы яшәлде. Ул елларда безнең кебек ише ятим балалар буа буарлык булды. Бөтен вокзаллар, базарлар, тимер юл стансалары шулар белән тулы иде... Күбесе — минем шикелле "кулак" балалары...

1931 елның көзендә милиция хезмәткәрләре аны тотып алып, Уфа төрмәсенә утырталар. Бераздан аны Мәскәү янындагы Болошево станциясендә урнашкан Беренче номерлы ОГПУның яшүсмерләр колониясенә күчерәләр. М. Шабай бәхетенә, бу А. С. Макаренко алымнарын кулланып эшли торган яшьләр коммунасы булып чыга. Монда яшь тоткыннарны җәберләмиләр. Киресенчә, аларга ышанып, шәхесләрен ихтирам итеп, тәрбия эше алып баралар, тәмам бозылып беткән бандитларны да аякка бастырып, кеше итәләр. Саф күңелле, тырыш М. Шабай ударникларча эшли, яратып укый, колониядә килеш урта мәктәпне тәмамлый. Дөнья хәтле китап укый. Аеруча классик язучылар әсәрләрен укырга ярата. Шулар тәэсирендә үзе дә кулына каләм ала. Һәм колониядә утырган елларында (утызынчы еллар башы) аның беренче очерклары матбугат битләрендә басылып чыга.

1934 елның көзендә ул иреккә чыга. Казанга килеп, педагогия институтының әдәбият бүлегенә укырга керә. Ләкин тормыш шартлары авыр булганга, икенче курстан укуын ташларга мәҗбүр була. Коммунасын сагынып, тагын шунда кайта, күпмедер вакыт йөк төяүче булып эшли. Армиягә алынып, ике ел Ерак Көнчыгышта хезмәт итә, янадан Казанга килә, төрле урыннарда эшли. Ниһаять, "Яшь сталинчы" газетасына әдәби хезмәткәр булып урнаша. 1940 елда аның беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыга. Ул әдәбият өлкәсендә үз сукмагын табып, елдан-ел осталыгын үстереп, дәртләнеп иҗат итә.

Яшьләр газетасында эшләгән вакытта, М. Шабай яшь журналист, шагыйрь Рәхим Саттар белән дуслаша (Соңыннан Р. Саттар Муса Җәлилнең көрәштәше буларак танылды). Алар бергә эшлиләр, бергә ашыйлар, дигәндәй, икәүләшеп кызлар артыннан йөриләр. Серләре дә уртак була. Араларына кергән исемсез шымчы исә, аларның ни турыда сөйләшкәннәрен көне-сәгате белән түкми-чәчми тиешле органнарга җиткереп тора.

Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивында сакланган 0354351 номерлы

эштә теркәлгәнчә (архив номеры 18928), дуслар күбрәк милләт язмышы турында сөйләшкәннәр. Татарларны урыслаштыру, ассимиляция бара, дип зарланганнар. Татар теле бетүгә бара, болай булса, озакламый халык та бетәчәк, дип ачынганнар. Большевиклар сәясәте белән килешмәүләрен дә бер-берсеннән яшермәгәннәр.

Р. Саттар сугышка китеп котыла һәм озакламый әсирлеккә эләгеп, дошман тылында һәлак була. М. Шабайны исә, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, армиягә алмыйлар. Әмма шымчылар аның артыннан күзәтүне дәвам итәләр.

Бервакыт ул, "Сугышка ник үз теләгең белән китмисең?" — дип сорагач, болай дип җавап бирә:

— Ни өчен сугышыйм ди мин? Кемне яклыйм? Атамны юк иткән большевикларнымы? Халкымны җәберләгән, телен бетүгә дучар иткән Сталиннымы?

Алай гына да түгел, советка каршы юнәлгән мәзәк сөйли, СССР хәрефләрен русчалатып болай аңлата: Смерть Сталина Спасет Россию. Шымчы үз шикаятендә бу сүзләрне ишетеп торган шаһитларны дә күрсәткән. (Шикаять 1942 елның май аенда язылган).

Икенче бер вакыт, Сәхаб Урайский һәм Гали Хужи белән чак кына кәгеп утырганда, ул "халык дошманнары" Г. Исхакый һәм Г. Ибраһимовларны уңай яктан телгә алган, Г. Ибраһимовны кулга алу белән килешмәвен белдергән. Совет язучысы А. Толстойны бер чыгышы өчен "кара урыс", "шовинист" дип сүккән. Шундый ук карашларны ул башкорт дуслары Максуд Сөндекле һәм Баязит Бикбай белән аралашканда да ачыктан-ачык белдергән.

## "Колыма планетасында"

Мин Шабайны 1942 елның 21 ноябрендә кулга алалар. Төн уртасында килеп тентү ясыйлар, бүлмәнең астын өскә китерәләр, барлык кульязмаларын җыеп алалар, Мин Шабайны "Кара козгын"га утыртып алып китәләр. Хатыны Мәгдүдә һуштан язып, идәндә аунап кала. Ике айлык балалары Идегәй елаган тавышка гына аңына килеп, көч-хәл белән аякка баса. Баса дип, шул төннән алып аның йөрәге авырта башлый, бераздан ул инвалидлыкка кала.

Сорау алу беркетмәләреннән күренгәнчә, М. Шабай "контр" сүзләр сөйләнеп йөрүен инкарь итми, ләкин бернинди оешмада да тормадым, советка каршы яшерен эш алып бармадым, ди. Тик бу озакка бармый. Нәкъ 18 көн үтүгә аны тәмам сындыралар һәм 1942 елның 8 нче декабрендә ул үз кулы белән түбәндәге белдерү ясый:

"Далнейшее сопротивление считаю бесполезным. Осознав тяжесть совершенного мною преступления и желая искупить свою вину перед советским народом, я решил рассказать всю правду" (Белдерү урысча язылган). Бу юлы инде ул үзенә өелгән барлык гаепләрне дә таный. Янәсе, ул яшерен оешмада да торган, советка каршы актив көрәш тә алып барган, "бәйсез буржуаз татар дәүләте" турында да хыялланган.

Күп еллар үткәч, 1957 елда, реабилитация сорап язган гаризасында ул бу "чын йөрәктән язылган белдерүен" болай аңлата: "Тикшерүченең көчле басымы астында ("в силу насилия и угроз"), үз-үземә яла ягарга мәҗбүр булдым". Бу басымның ни икәнен без хәзер күз алдыбызга бик яхшы китерәбез. Ләкин болай тиз сынуның икенче сәбәбе дә була. Тикшерүче аны алдый — гаебеңне танысаң, сиңа берни дә булмый, имеш. Гаебеннең әллә ни зур булмавын яхшы аңлыйбыз, күп сөйләгәнсең генә. Шуңа күрә суд сине аклаячак яки шартлы рәвештә хөкем итеп, сугышка җибәрәчәк. Беркатлы М. Шабай аның сүзләренә ышана. Һәм, әлбәттә, алдана.

1943 елның беренче гыйнварында — нәкъ Яңа ел бәйрәме көне — ул барлык булган-булмаган гаепләрен санап чыккан беркетмәгә кул куя.

Монда болай диелгән: "Входил в состав антисоветского формирования, проводил антисоветскую националистическую работу, проводил вербовочную работу среди молодежи — работников литературы — для антисоветской работы, восхвалял фашистских оккупантов и высказывал клевету на состояние татарской культуры и советской литературы".

Шул ук елның 19 февраленә тикшерү тәмамлана. Әмма хөкемне М. Шабайга

бер елдан артык күтәргә туры килә. Бу арада ул сугышка җибәрүләрен сорап берничә гариза язып карый. Берсенә дә җавап килми.

1944 елның 8 март көнне махсус кинәшмә (өч кешедән торган законсыз оешма) аны җиде елга ирегеннән мәхрүм итүгә хөкем чыгара. Шул ук елның 23 июнь көнне аны этап белән Колымага озаталар. Ул "Пионер" приискасына эләгә. Башка тоткыннар белән бергә забойда эшли, алтын казый. Эш авыр, азык нормасы бик аз, җан сакларга да житми. Тап-таза ир-атлар да уртача алганда алты ай чамасы эшләгәч, хәлдән таеп егылалар. Аларны "расходка чыгарып", бозлы чокырга күмәләр. Алар урынына яңаларны китерәләр.

Мин Шабайның "шәхси эш"еннән күренгәнчә, 1944 елның октябрь аенда аны забойдан "эшкә яраксыз" дип "списать итәләр", лагерь шифаханәсенә җибәрәләр. Монда ул нәкъ бер ел үлем белән тарткалашып ята. Көч-хәл белән аякка баса. Һәм авыру булуга карамастан, башкаларга ярдәм күрсәтеп йөри башлый: кемгә су китереп эчерә, кемнең астын-өстен алмаштырырга булыша... Хәтта соңгы икмәк сыныгы белән дә уртаклаша. Тоткыннар аны "изге җан" дип атап йөртәләр. Иң усал, бозылып беткән бандитлар да М. Шабайны җәберләмиләр, әйберләренә дә кагылмыйлар.

1945 елның октябрь аеннан ул шул ук лазаретта санитар булып хезмәт итә. 1948 елда аны "Ледяной" исемле лагпунктка фельдшер итеп күчерәләр. Ә 1949 елдан ул инде "Северный" лагеренең лазаретында врач ярдәмчесе — лекпом булып эшли.

Әлбәттә, лазареттагы эш забойдагы каторжан эшенә тиң түгел. Әмма монда да кеше гомере бер тиен дә тормый. Менә, әйтик, бервакыт лазаретка кайдандыр зур начальник килеп төшә, шифаханәне "эштән качып яткан әрәм тамаклардан" ("придурoклардан") арчырга боерык бирә: Барысын да чыгарып атарга! Ярым ялангач, хәлсез бәндәләрне карга чыгарып тезәләр. Шунда катнашкан прокурор М. Шабайны күреп ала:

— Туктагыз, монысын атмый торыгыз! Мин аны беләм, ул бит "изге җан". Күпме эшләп тә, андый кешене очратканым юк иде...

Шулай итеп Мин Шабай үлемнән кала.

Икенче мәлдә, бер лагерьдан икенче лагерьга күчергәндә уголовниклар кәрт уенында оттырып, аны үтерергә җыеналар. Бу юлы аны конвой начальнигы коткарып кала. Эшнең кайда барганын сизеп, ул кагыйдәләрне бозып булса да, "изге җанны" үзе янына ала. Соңыннан Мин Шабай ана рәхмәт йөзеннән үзенең соңгы галифе-чалбарыннан баш киеме тегеп, бүләк итә.

1949 елның 28 июнендә Мин Шабайны, яхшы эшләгәнен искә алып, срогыннан элек лагерьдан азат итәләр. Ләкин Казанга кайтырга рөхсәт бирмиләр. Ул шул ук "Колыма планетасында" кала. Эш урыны гына үзгәрә — хәзер инде ул Водопьянов исемендәге приискада башта склад мөдире, соңыннан завхоз булып эшли. Кулында паспорты яки башка документы булмау сәбәпле беркайда да чыгып йөри алмый. Хәтта туганнарына хат язарга да рөхсәт итмиләр.

Шулай итеп бер ел чамасы "иректә" яшәгәннән соң, 1950 елның 22 июлендә тагын бер суд була. Бу юлы бернинди гаеп-фәлән эзләп тормыйлар. Элекке гаепләре өчен мондыйларны "повторник" дип атыйлар, аны, үзен дә чакырып тормыйча, мәңгелек сөргенгә хөкем итәләр. Сөрген урыны итеп шул ук Магадан өлкәсенең Спорный поселогын билгелиләр. Шул ук елның 31 августында ул яна урынга килеп, лагерьның хуҗалык эшләрен алып бара башлый.

Казанга ул тагы биш ел үткәч, Сталин үлеп, сәяси һавалар йомшара башлагач кына кайтып төшә. Ә тулы реабилитацияне тагы өч ел үткәч, 1958 елның уночэнче мартында ала.

Хатынының сөйләсе сөйли: "Мин кухняда бәрәңге әрчим. Ул яныма чыгып утыра да, күзләрен тутырып, миңа карап тора. "Син, балдыз, минем кайтуыма ышанасыңмы? Мин үзем ышанмыйм әле...""

1959 —1964 еллар арасында язучының "Бездә ел буе яз" исемле очерклар китабы, "Тормыш баскычлары", "Тормыш чакыра" исемле хикәя җыентыклары һәм "Уяну" исемле тарихи-социаль романы басыла (беренче кисәк). Ләкин сәламәтлеге бик начар булу сәбәпле, ул күпчелек иҗат планнарын тормышка ашыра алмый кала...

**Рафаэль МОСТАФИН.**

**Шамил
Әхтәмов**

# БӘЯН ГЫЙЗЗӘТ ХАТЛАРЫ

*Танылган әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, театр белгече Бәян Гыйззәткә бу айда 80 яшь тулган булыр иде. Кызганычка каршы, ул каты авырудан соң 1991 елның 26 маенда вафат булды. Без Бәян Гыйззәт белән ярты гасырдан күбрәк вакыт аралашып яшәдек. Танышлык Казанда, пединститутта укыганда, ярсу студент елларында башланды да, аяусыз сугыш елларында бәйләнеш өзелеп торса да, аннан соңгы чорда тагын очрашып, көрешеп яшәдек. Хәбәрләштек, хатлар алыштык.*

*Менә Бәянның сугыштан соңгы беренче хаты.*

*17 январь 1948 ел.*

"Шамил дустым!

Синең дөньяда яшәвең турында хәбәр китергән шатлыклы хатынны менә бүген алдым. Димәк, син исән! Бу бик зур, бик шатлыклы хәбәр. Димәк, мин уйлаганча, бу дөньяда мин бер үзем генә калмаганмын икән. Минем якын иптәшем, дустым турында сакланган тирән, җылы хатирәләрем онытылмый. Мин иске Шамилгә, акыллы, әйбәт иптәшем, фикердәшем Шамилгә язам бу хатымны.

Үзем турында төрле фикерләр ишеткән идем. Армиядан кайткач, барлау вакытында сине күргән кешеләр бар дип тә ишеттем, ләкин ышанырлык нигезле хәбәрләр түгел иде һәм тере булса язар иде, түзмәс иде, дип яшәдем. Бигрәк тә, "Совет әдәбияты" һ. б. урыннарда фамилиямне күрсәтергә тырышулар да үземнең исән булуымны дусларга белдерү өченрәк иде. Нәкъ бер ел элек, "Совет әдәбияты"нда мәкалә чыкты, ләкин бер ел үтсә дә, мине эзләгән хат язмады (лар). Шуннан мин синең исәнлек хәбәреңне ишетүемне юкка чыгардым, — чөнки хәбәр килмәде. Бу хатың да характерлы бит: син миңа хатыңны "Совет әдәбияты" аша җибәрмәгәнсең, театрга җибәргәнсең — димәк, син минем анда эшләвемне ниндидер башка чыганаклардан алгансың.

Үзем турында. 1941 елның... (августта булса кирәк, Ш. Ә) Сарманга укытырга киткән идем. Әмин дә шул районда укытты, без бергә, бер полкка армиягә алындык. 1942 ел март-апрель айларында сугышта булдым. Шунда мин Әминне югалттым. "Яраланды" дигәннәр иде батальон штабында (ул башка батальонда иде). Мин яраланып, госпитальгә эләктем, шунда Вахитның үзе белән хат алыша башладым. 2-3 хат алгач, Вахиттан Әминнең сугышта үлүе турында хәбәр килде. 1942 ел көзне Вахит та Калинин тирәсендә һәлак булды. (Аның турында Сылу язды) Вахит Әмин турында кайдан ишеткәндер, язып өлгерә алмады, шул турыда сорап язган хатым кире кайтты... Вахит үзе дә дөньяда юк иде... Бүгенге кадәр Әминнең кайда үлүен белә алмадым, шул — язгы сугышта булырга тиеш ахыры.

Сугышны бетереп, мин 1946 елның башында (өлкән лейтенант булган булып) Казанга кайттым. Академия театрында әдәби бүлек мөдире булып эшкә кердем. Өйләндем — 1946 ел башында ук, хатын мединститутта укый. Үзем Фәннәр Академиясе филиалы аспиратурасына укырга кердем, инде икенче ел бара һәм эшлим дә. Үземә квартира да ызгышып-талашып йөри торгач алдым. Тормышым әйбәт кенә барды моңарчы. Казанга килгән чакта миңа төшүен

мәжбүри. Әнә, син күргәнчә, бераз мәкаләләр язу өстендә эшлим. Әлегә ике зур эш алып барганлыктан күп яза алмыйм. Бирегә күптән түгел Нәби Зарипов[1] кайтты, Суворов мәктәбендә эшли. Корбанов Таһир[2] аспирантурада укый, Фәйзуллин[3], Мостафин[4] үлгәннәр.

Менә сина хәбәрләр шулар. Кайгылы хәбәрләр күп.

Үзең гаилә корып жибәргәнсең икән, укытучылыктан читтәрәк икәнсең, хәзер кайда эшлисең, планың нинди — барын да яз. Иптәшең эшлиме, кызың үсәме, исеме ничек, аларга миннән сәлам тапшыр. Син "бер хат кына язарга" вакыт табарга кушкансың, мин һәрвакыт язарга, сине күрергә, элекке кебек чын дус, иптәш булырга телим.

Сугыштан соң ике елдан артык Казанда торып, бер иптәш кеше тапмадым, ә чын дусларым... кайсы үлде, ә исәне кучеп киткән. Мин инде синнән дә колак кагарга тиешмени?

Үз тормышыңны тулысынча язган хатларыңны көтәм. Хуш, дустым Шамил! Синең дустың, Бәян. Минем квартира адресына яз. Исеңдәме фин сугышы вакытында[5] син Әмин белән Карл Маркс урамында тордың, мин Вахит белән Щапова урамында тордым. Минем квартира шул йортта. Яралы икәнсең, әллә бер аягың бөтенләй юкмы? Яраң нидән тора".

*Бәянга 60 яшь тулуны җәмәгатьчелек киң билгеләп үтә. Бу турыда миңа да язды ул.*

"Шамил!

Ике хатыңны алуга карамастан, жавап һаман яза алмадым. Гафу ит.

Әхтәм турында без Корбан белән эзләнеп карадык. Әмма КДПИ канцеляриясе "андый документлар бездә юк" дип, борып чыгарган. Шуннан соң мин Язучылар союзы аркылы мөрәҗәгать итәргә булдым. Менә ялдан кайттым, шуңа башлыйм әле.

Синең котлауларыңны алдым, бик зур рәхмәт. Үзеңә дә шундый ук теләкләр... Шул көннәр тирәсендә радио, телевидение, газеталар, журнал сүз әйтте. КПСС ОК һәм Министрлар Советы грамотасы булды, зур гына оешмалар адреслар биреп, күңелне күтәрде. ИЯЛИдә жыелыш булып, күп кенә әйбәт сүзләр ишеттем. Өфе якларыннан энекәшләр (барлыгы 17 кеше, әни дә шунда) өч машинага тәялеп килеп, бәйрәмне бик күтәрделәр. Рәхмәт дим аларга.

Синең Башкортстандагы хәлләр белән таныштырып торуың өчен бик рәхмәт. Белеп-тикшереп язылган булганлыктан, алар аеруча кыйммәтле. Бирэдә бу мәсьәлә белән кызыксынучылар бик күп. Алар кызыксынып кына калмый, әлбәттә, хезмәтләрендә тиешенчә жавап бирә бара. Ә бирэдә синең чыганакларга таянып биргән мәгълүматларың бик файдалы — үзенә күрә бер фәнни эш. Киләчәктә дә һәр белгәнне яза күр.

Нефтекамскига күчү теләге бар дигән идең, ул ничек тора? Безнең якларда булгансың икән.

Башкортстандагы мәктәпләр составын берәр ссылкамы, документ беләнме раслап булмасмы икән?

Син дә оныкларга күчкәнсең икән. Шулай инде дөнья дигәнең.

Карчыгыңа бездән сәлам диярсең.

---

[1] Нәби Зарипов — запастагы подполковник, 1917 елда Башкортстанның Караидел районында туган. Пединститутта укыганда балалар өчен язылган "Бикбатыр хәйләләре" (1940) поэмасы басылды. Сугыштан соң "Маяк йолдыз" (1965), "Утлы сукмаклар" (1940), "Ефәк гөмбәз" (1986) исемендәге китаплары басылып чыкты.

[2] Корбанов Таһир (1910) Казан пединститутының доценты. Хәзер пенсиядә. Муса Жәлилнең кардәше. Аларның әниләре бертуган. Муса турында "Кызыл чәчәкләр" (1990) исемле әсәр язды.

[3] Сугышка кадәр пединститутта укыган иде.

[4] Мостафин Мөсәгыйт (1909-1940) — язучы. Элек Мәскәүдә "Коммунист" газетасында эшләгән. Пединститутта укыды.

[5] Фин сугышы башлангач, тулай торакны хәрбиләргә биреп, безне фатирларга урнаштырганнар иде.

Хәзер ниләр эшлисең? Хатлар көтәм.
Дуслык сәламе белән

Бәян. 5/Х-78"

Синдә минем яшьлек фотолары юкмы, җибәрсәң, копияләрен алгач кире кайтарыр идем. Күп кенә рәсемнәремне таптым, үзем дә булдырдым".

*Бәян Гыйзәт кайбер хатларында 1979 елда үткәрелгән халык санын алуга мөнәсәбәтен белдерә. Хатның баштагы юлларында минем "Социалистик Татарстан" да басылган истәлек турында сүз бара.*

"Шамил!

Тиргәсән-тиргә, көттердем. Менә ул газета, менә синең бик матур тел белән язылган истәлегең. Зуррак итеп язасы бар, минемчә, барып чыгар кебек.

Козлов (инициалы онытылган) дигән бер автор барлык переписьләрне чагыштырып китап чыгарган (1981,82 еллар), шунда нинди милләт кайчан, күпме саналган турында кызык мәгълүматлар бар. Шул исәптән безне кызыксындырган мәсьәләләрдә уйланырлык урыннар бар. Мәсәлән, син тора торган тирәдәге халык безгә караганда соңгы сан алуда котырып үсә дә — ягъни башкаларны өстәп язу (приписка —тыела торган нәрсә) икәне күренеп тора.

Уфаданмы алдырып шуны карап чыксаң ярар иде (анда таблица бар). Миңа да җибәрерсең — үземнең кулга төшереп булмады.

Башка хәлләр?

Башка хәлләр элеккечә. Менә нәрсә: иртәгә Цхалтубага китәм, 10 сентябрьгә кадәр була ул путевка.

Гаиләңә, барыгызга да күп сәлам.

18/VII Бәян".

"Шамил!

Үзеңә һәм гаиләңә кайнар сәламнәр җибәреп калам.

Соңгы хатыңны күптән алган булсам да син сораган китапны кулга төшерә алмыйча күп вакыт узды. Ул аз тираж белән чыгарылган, ИЯЛИнең тел секторы үзе сатарга алынган булган (хәзер андый тәҗрибә бар), ә авторы — сатучы озак кына авырып йөрде.

Ниһаять, ул кулга керде һәм аны сиңа да җибәрәм.

Үз китабыңны озак тоткан өчен гафу ит. Әмма ул бирелә тик ятмады, аны бирелдәге иптәшләргә биреп, хәлне аңлатырга, миләренә сендерергә тырыштым. Анда үзең язган саннарның, искәрмәләрнең, кирәк булуы бар. Аннан соң берәр юл белән кулга төшерә алмассыңмы? Хәтереңнән чыгарма әле, ямe!

Кирәк булса тагын сорап алырга туры килүе бар, авырсынма инде.

Үзебезнең хәл искечә, яңалыклар юк сыман. Әле нәшрият миңа К. Тинчуринның 3 томлыгын төзүне тапшырды. Заманында 2 томлыгын чыгарган идем, хәзер өченче томына проза һәм мәкаләләрен янадан төзү кирәк булган.

Менә хәзер "Социалистик Татарстан"ның Җиңү көненә чыгарган санына 4 битлек мәкалә язып утырам — заказ бирганнәр иде.

Шамил! Җиңү көне белән котлыйм үзеңне. Сиңа сәламәтлек һәм әле күп еллар җир йөзенең өстендә тыйтаклап булса да йөреп ятуыңны телим!

Барысы өчен дә рәхмәт, бигрәк тә түземлегең өчен!

Бәян. 24.IV.85."

"Шамил дус!

Синең гаҗәпләнеп язган хатыңны укыдым. Гаҗәпләнерлек тә шул. Посылка мин ялга (Переделкино) киткәч почтага килә дә... бер ай ята. Ә бер айдан соң кире җибәрәләр икән. Кайткач почтага барсам — шулай диделәр.

Ә китап, әлбәттә, кирәк. Әлбәттә, яңа перепись булгач, тагы да өстәмәләр кертелүгә әзер булып торырга кирәктер. Әйе бит?

Сиңа үзебезнең онытылмас дусларны хәтергә төшерә торган "Алар сакта" китабының икенче тулыландырылган басмасын җибәрәм. Аннан соң Тукай, Әмирханның 100 еллыгына карата чыккан брошюралар өстим.

Үзем бер килеш ятам. Менә К. Тинчуринның 3 томын төзедем: беренче томның корректурасы килде дә инде.

Аннан соң 2 томлык "Татар драматургиясе" антологиясен төзергә бирделәр. (Һәр томы 70-75 табак). Шулар белән утырам.

Тирә-якта андый-мондый хәбәрләр юк бугай.

Менә шул. Әлегә исән-сау.

Бәян. 24.03.86."

*Шушы хат белән бергә милләт мәсьәләләренә караган төрле чыганаклардан алган мәгълүматларны да җибәрде Бәян. Менә алар.*

Ленин. Өченче басма, 12-том, 488 бит, аңлатмалар:

"Тептяри — Ново-башкир., отатарившиеся финские племена, живущие среди башкир, главным образом в пределах оренбургской, самарской и уфимской губерний".

*Менә, нинди әкиятләр дә бар икән дөньяда!*

"Автономияле Татар Социаль Совет җөмһүрияте төзү турында декрет.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карар бирде.

1. Россия Социаль Советлар җөмһүрияте Федерациясенең бер кисәге рәвешендә итеп, автономияле татар Социаль Советлар җөмһүрияте төзелә.

Бу җөмһүрияткә түбәндәге өязләр керәләр:

Казан губернасы *(өяз исемнәре санала)*

Уфа губернасы  Минзәлә өязе.

Самар губернасы *(өяз исемнәре)*

Вятка губернасы *(өяз исемнәре)* Сембер губер *(өяз исемнәре)*

Искәрмә: Татарстан җөмһүриятенә Уфа губернасының Бөре һәм Бәләбәй өязләрен кушу мәсьәләсе бу өязләрдә яшәүче хезмәт халкының теләге ничек икәнлеге беленгәнчә ачык калып тора. "Биш ел эчендә" (1920-1925) китаптан алынды. Казан, 1925, 4 бит дигән.

Постановлением ВЦИК от 14 июня 1922 г. К. Малой Башкирии присоединяется Уфимский, Белебеевский, Бирский, Златоустовский уезды.

Столица переводится в Уфу.

Журнал "Жизнь национальностей" стр. 5 № 13.

"Декрет о Большой Башкирии" от 14/VI. 1922 г. — тептярей 51% диелә. Кул куйганнар:

Бөтенроссия Үзәк башкарма Комитеты рәисе Калинин

Халык Комиссарлары Советы рәисе В. Ульянов (Ленин)

Бөтенроссия Үзәк башкарма Комитеты сәркәтибе Лутовинов"

"Шамил дуска сәламнәр!

Мина мәгълүм бер яшь тулу уңае белән җибәргән телеграмманы алып шатландым, рәхмәт!

Бу уңай белән газеталар, журналлар, радио-телевидение бераз ышкына алдылар, күңелне күрделәр.

Тәбрик итүчеләргә рәхмәтләр җибәрү вакытында, синең адрес алдында туктап калдым: телеграммаң бит Мәскәүдән. Тагы кая китте, бу мин әйтәм, бер вакыт китаплар җибәреп кире кайткан иде, хәзер инде бөтенләйгә улы-балалары янына күчкән булыр, дип нәтиҗә ясадым. Шуннан опера театры янындагы кафедрага улыңны эзләп киттем, ә ул күптән инде анда эшләми икән. Нәтиҗәдә иске адрес белән язу фикеренә килдем — кире кайтса, тагы эзләү дәвам итәр, дип карар кылдым. Менә бит хәзер: ил буйлап гизәсең.

Җамал апа Вәзиева белән сөйләшкәндә, син ана язган хатыңда авырып торам, дигәнсең икән. Ул нинди авыру, яралар сызлаумы, гомумән хәлең ничек? Соңгы вакытта язышмый башладык — ни булды?

Моннан бер-ике-өч ай элек Нәби Зариф (үзе белән әле генә телефоннан сөйләштем — басым күтәрелде, укол ясаттым, диде, тагы бакчада эшем күп, ди — аның яңалыклары шул диюем). "Социалистик Татарстан"да, "Бер дә онытылмыйлар" дигән мәкалә бастырды. Ул безне, теге "Кольцо"дагы көфер почмагын,

Вахитны, Әминне искә ала, күбрәк синең сугышта яралану тарихын озын итеп язган. "Шамилгә алып жибәр", — дигән идем, гадәтенчә икеле-микелерәк жавап бирде, бәлки киоскларда беткән дә булгандыр. Ә минем тагы бер данәсе бар иде. Юбилей вакытында өстәлне, бүлмәне бушатып, кәгазьләр арасына кергән, әлегә тапмадым. Тапкач, әлбәттә, жибәрермен.

Бирегә мирас комиссиясе оешып, Г. Исхакый язмышы хәл ителеп ята, жыелышларда ачыктан-ачык сөйләшүләр бара — хәбәрдарлык заманы бит.

Үземә исә К. Тинчуринның өч томлыгын чыгарганнан соң "Татар драматургиясе антологиясе"н төзүне тапшырдылар. Беренче томы чыкты инде, икенчесен төзеп бирдем (сүз башлары белән).

Монда Татарстанның законсыз рәвештә Башкортстанга кушылган өязләрен янадан Татарстанга кайтару турында сүз күтәрелде. Әдәби ел йомгагында бу юлларның авторы сөйләде, драматург — безнең якташ. Р. Хәмид яклады, шул сүзләрне, документлар белән ныгытып, әлеге мирас комиссиясенә һәм ИЯЛИ халкы алдында күтәреп чыктым. Бу турыда, бераз читләтебрәк, әлбәттә, безнекеләр Уфада декада ясап кайткач, ӨК секретаре Кадермәтов белән сөйләшкәндә янадан күтәрелде. Ул, әлбәттә, Уфада яңа житәкчеләр килгәч, мәсьәлә үзгәрер дигән тынычландыру алымын кулланды. Әлбәттә, алар мондый чакта сак булалар инде.

Анда, Өфедә дә бу мәсьәлә кузгалган, бер генералмы, полковникмы башлап йөри дип ишетәбез. Бу турыда берәр хәбәрең юкмы? Переписька хәзерләнү өлкәсенә тагы нинди "яңалыклар" ишетелә. Бу һәм моңа бәйле мәсьәләләр буенча Үзәккә, Пленумга ярдәмгә дип, син жибәргән мәгълүматларны да файдаланып, материал әзерләдем. Гомумән, перепись алдыннан иске алымнарга юл куймаска иде. Февраль пленумында андагы татар мәктәпләренең хәле турында Лигачев әйткәнне беләсеңдер инде. Хәзер бу хәл ни дәрәҗәдә тора икән? Бик акрын үзгәртәләр икән дип ишетәбез. Уфада булгалыйсыңмы? Татар мәктәпләре хәле матбугатта күтәреләме? Башкортның тарихы, Болгардан да "элек" башланган культурасы турында көчәнүләргә багышланган китап, брошюра, кисеп алынган мәкалә яки болай истә калган башка материаллар булса, әлбәттә, кайтару шарты белән, жибәреп торсаң бик шәп булыр иде.

Мин 6 октябрьдә Кавказга (Пицундага) иҗат йортына китәргә җыенам, шуңарчы хат-хәбәрләреңне жибәрә алсаң, бик әйбәт булыр иде. Б.".

*Тагын бер хаттан өзек:*

"Мин 1 апрельдә Уфага лекция белән барам — әлеге кызыксындыра торган мәсьәләләр белән инде ул. Хәбәрләренә караганда ул 2 апрельдә була, афишалар тараткannar икән. Җаен тапсаң килеп чык. Мин үземнең энем Гаянга төшәм, аның телефоны 24-10-90. Шуннан белешергә мөмкин булачак.

Шамил, "Татарстан яшьләре"ндә синең белән бер шәһәрдә яшәүче Сафина Нәҗибә халык санын алганда бозулар турында язып чыкты. Бу материал әлеге мәсьәләгә караган күп кенә яңа материаллар килүгә юл ачты. Ул синең белән бер почтовой ящикта яши икән: 452950, пер. Кувыкина, 3, кв. 74. Бәлки телефоны да бардыр. Син аны күреп яки шалтыратып танышсаң, минем сәламнәрне тапшырсаң һәм Уфага әлеге җыелышка чакырсаң, тагы бер егетлек эшләр идең. Гомумән, бу иптәш белән бәйләнешкә кереп бергәләп эшләргә иде сиңа! Әлегә хуш.

21. 3. 89. Бәян".

*Шагыйрә Сафина Нәҗибә Казанда яши, "Сөембикә" журналында эшли иде. Яңавыл районында туып үскән. Бу хат язган вакытта Нефтекамада тора иде.*

*Ниһаять, дустымның миндә сакланган соңгы хатын карап үтик:*

"Шамил!

Хатыңны һәм минем "тарихи" ачышны алдым. Рәхмәт.

Үзебез бер хәлдә. Менә 19 сентябрьдә Пицундага (Абхазия) ялга китәргә әзерләнәбез.

Кайткач, Язучылар союзы кушуын үтәп, эстетика буенча семинар эшен башлап җибәрергә туры килер, күрәсең. Һаман "төшеп калу" юк кебек әлегә. Әлбәттә, риза булдым.

Менә шул. Исән бул, авырма, саклан!

Бәян. 16. 09. 89."

*Никадәр оптимизм, дәрт һәм кеше өчен кайгырту бар бу сүзләрдә!*

*1990 елның язында, Ләйсән белән телефон аша сөйләшкәч, Бәянга инфаркт булуын, аның шифаханәдә ятуын белдем. Июль аенда Казанда булдык. Бәян фатирына берничә мәртәбә бардым. Ул өйдә генә йөри, урамга чыга алмый. Тынгысыз җан элеккечә тырыша, газит-журналларны күзәтеп бара. Сүз арасында Бәян 70 яше тулу уңаеннан үткәрелгән чараларны искә төшерде. "10 ай үткәч, Кремль дә юбилейны билгеләү кирәк дип тапты. ТАССР Югары Советы миңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирде," — диде ул. Тартмадан алып, миңа шул турыдагы Указны һәм значокны күрсәтте.*

*Сөйләшә-сөйләшә көннең ничек үткәнен дә сизми калганбыз. Ләйсән өйдә юк — эштә. Бәян аны ихтирам белән искә алды. "Врачларның эше шулай инде. Шифаханәдә дә эшләргә, өйдәге авыруны да карарга кирәк. Беренче инфарктан соң 30 елга якын яшәвем Ләйсәннең тырышлыгына бәйләнгән", — диде ул.*

*Бәян мине ишеккә кадәр озатты, элек транспортлар туктый торган урынга кадәр чыга торган иде, сүзгә мавыгып, әллә ничә трамвайны, троллейбусны үткәреп җибәрә торган идек, хәзер чыга алмый. Мин ишектән чыккач, үзенең хәле арулана баруын әйтте: "Элек мин ишекне биклəп кала алмый идем, менә хәзер анысына көч җитүе белән мактана алам", — дип көлемсерәде.*

*Бәян берничә мәртәбә шифаханәгә кереп дәвалана. 1991 елның апрелендә телефон аша сөйләшкәндә, Ләйсән Казандагы "Ливадия" санаториясенә бару өчен путевка алуларын әйтте. Бәян, санаторийдән кайткач, чыгып йөриячәгенә ышандырды.*

*Санаторийга барырга җыйналып йөргәндә, 1991 елның 26 маенда Бәянның талмас йөрәге мәңгегә туктый.*

*Үз гомерендә Бәян Гыйззәт күп тикшеренүләр алып барды. Аның әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә карата вакытлы матбугатта чыккан мәкаләләренең саны 200 гә якын. Ул җәмәгать эшендә дә актив катнашты, Язучылар берлегенең тәнкыйть секциясе җитәкчесе булды, шәһәр советы депутаты итеп сайланды һәм Русия театр җәмгыяте әгъзасы иде.*

*Минем күңелемдә Бәян һаман исән кебек. Озын буйлы, мөһабәт, төз гәүдәле Бәян, яшьләр шикелле җитез атлап, Ленин урамыннан Фәннәр Академиясенең Казан бүлегенә киләдер кебек. Бина алдындагы бакчада үткән гасырның атаклы математигы Лобачевский бюсты яныннан үтәр, йортка кергәч, хезмәттәшләре белән исәнләшер, хәл-әхвәл сорашыр, көнүзәк мәсьәләләр турында сөйләшер. Фәтхелбәянның эш көне шулай башланып китә иде.*

---

**Бу елның икенче яртысында**
**һәм 1999 елның беренче яртысында**
**укучыларга тәкъдим ителәчәк проза әсәрләре:**

Аяз Гыйләҗев. Тәмәкене ташладык, рәхәт яши башладык. *Киноповесть.*

Таһир Нәбиуллин. Качкын. *Повесть.*

Барлас Камалов. Хатирәләр янарган көн. *Повесть.*

Редакция папкасында шулай ук Гариф Ахунов, Зәки Зәйнуллин, Фоат Садри, Илдар Юзеев, Әнәс Галиев кебек танылган язучыларның әсәрләре бар.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ХӘЗИНӘГӘ ӨСТИК ӘЛЕ...

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕНӘ КАЙБЕР ӨСТӘМӘЛӘР

Татар теленең аңлатмалы сүзлеген кайчан да булса тагын бер чыгарырлар. Икенче басманы гамәлгә ашырыр алдыннан төзүчеләр, ихтимал, җәмәгатьчелеккә сүз салып, беренче басмага ниләр өсти аласыз, дип сорарлар. Шул чакта, бәлки, сүзлек томнарына мин өстәгәннәр белән дә кызыксынырлар. Ә сүзлек язмышы белән мондый кызыксынучылар аз булмас. Барчабызның фикеренә колак салынса, аңлатмалы сүзлек томнары шактый ук тулыланыр. Тел хәзинәбезне бөртекләп җыю-саклау һәр милләттәшнең күңел түрендә булырга тиеш дип беләм.

*БЕРЕНЧЕ ТОМГА ӨСТӘМӘЛӘР:*

АЕРЧА сүзенә янә бер аңлатма-өстәмә: юллар аерчасы. Аерчада басып торам. Юлым кайсы якка? (*Марат Кәримов, "Аргамак", № 1, 1995, 83 бит*).

АКБАЛ — үлән. Бу сүзне өстәү зарур. (*Мисалы — "Казан утлары, № 10, 1991, 153 бит. Ринат Рәхимов.)*

АЛКУ сүзен өстәргә иде. "Алкып аккач актык кар". (Әхсән Баян, "Елларга сәяхәт", ТКН, 1997, 221 бит.)

АРТЫКСЫНУ сүзе сүзлектә мисалсыз гына. Менә мисал: "Тик язмыш тәтегән бу бәхетне тора-бара артыксынды бугай", (*Вахит Имамов, "Нәзер", ТКН, 1991, 111 бит.)*

АСАУ сүзен өстәү сорала. Усал, тешләк ат. "Монгол аты, пони дисәң, зуррак, Асау күренә, йома колагын". *(Нури Арслан, "Казан Утлары" № 9, 1985, 53 бит.)*

АУАКАны өстәү турында уйлашырга иде. Авыз ачып карап торучы адәм. Чистай ягында әйтәләр.

АЧЫЙГЫ — әрнү, сызлану, иңрәү. "Йөрәк ачыйгысы белән мин шул турыда уйлап баш ваттым". *(Әнәс Галиев, "Казан утлары", № 7, 1994, 25 бит.)*

АНДЫШЫП (йөрү). Аңларга, төшенергә теләп. "Колагыңны салып, бик аңдышып йөре", (Хәсән Сарьян, "Нокталы өтер", ТКН, 1990, 105 бит.)

БАГЫМСЫЗЛЫК — бәйсезлек. *(Ринат Мөхәммәдиев, "Утлы таба өстендә", 1996, ТКН, 49, 62 битләр. "Татарстанның багымсызлыгы Казанда игълан ителсә дә, Мәскәү аны танымады"; "Багымсызлык хакында сүз чыкканда бу залның нинди нәфрәт ташкынына әверелгәнлеген заманында Татарстан Югары Советы Рәисе булып эшләгән Фәрит Мөхәммәтшин да яхшы белә".)*

БАЗНАТ (итү) — кыюлыгы җитү, җөрьәт кылу, "Евтушенко булса кирәк, хәтта Анна Ахматованың шигырьләрен кул эше дип атап, язып чыгарга базнат итте". (*Наҗар Нәҗми, "Казан утлары", № 8, 1996, 176 бит. Зәки Зәйнуллин, "Казан утлары, №, 1991, 55 бит.)*

БАЛӘЗАТ — шәхсән үзе, лично. Кәрим Тинчурин. *("Мәрҗәннәр". ТКН, 1967, 70 бит.)*

БАРЫМТА — ят хуҗаларның малларын куып алып китү өчен һөҗүм итү. "...

барымтага килгән һәртөрле юлбасарларын юкка чыгара торды". *(Нурихан Фәттах, "Сызгыра торган уклар", ТКН, 1991, 687 бит.)*

БИЛТӘК — тел кимчелеге булу, кайбер авазларны кирәгенчә әйтеп житкерә алмау, бозып әйтү. *(Барлас Камалов.)*

БОРАЛАК — вертолет.

БОРМАКАЙ — фикерен тиз үзгәртеп, әле болай, әле тегеләй уйлаучы, гамәл кылучы.

БУАНАК — капкын жеп. "Нәзек тәпие кыл буанак жебенә уралган песнәк кебек..." *(Аяз Гыйләжев. "Йәгез бер дога", "Казан утлары", № 12, 1993, 12 бит.)*

БӘКӘЛТӘШ — "Кашын да күзең, бәкәлтәшен дә үзен дигәндәй"... (Гариф Ахунов — Н. Исәнбәт, Фразеологик сүзлек, том 1, 363 бит.)

БӘЛАБАШ — тормыш жае, чынбарлык белән исәпләшмичә, орды-бәрде яшәп, үзенә бәла-каза тудырып йөрүче, бүтәннәргә дә маза салучы кеше. *(Барлас Камалов.)*

БӘПЧЕТҮ — ташны су өстенә берничә кат тиеп үтәрлек итеп ыргыту. "Ык өстеннән ташлар бәпчетеп уйнадылар". *(Гомәр Бәширов, "Җидегән чишмә", ТКН, II китап, 1978, 121 бит.)*

БӘРЕК — үткен, чая. "Бәрек бул, күзенә кер". *(Хисам Камалов, "Үлгәннән соң яздым", "Казан утлары", № 10, 1988, 47 бит.)*

БӘРХӘДӘРСЕЗ — аяусыз, мәрхәмәтсез, шәфкать белмәүче. "Көл итәргә туры килде инде Кеше дигән бәрхәдәрсез затны". *(Зөлфәт, ТКН, "Адашкан болыт", 1990, 100 бит.)*

БӨКСӘМ — гәүдәнең төп өлеше. "Бөксәмен чак сөйрәп йөри", *(халык сөйләменнән.)*

БӨТӘҮ (яра) — уңалмаслык, төзәлмәслек. "Аудан, сугыштан яраланып кайткан берәрсенең ярасы бик озак төзәлмичә, бөтәү ярага әйләнсә... иң элек аны искә төшерәләр иде", *(Нурихан Фәттах, "Сызгыра торган уклар", ТКН, 1991, 583 бит.)*

БҮШӘНЛӘНҮ — сәлперәю, купшаклану. "Олыгаюдан бүшәнләнгән йөзе алсулана барды", *(Атилла Расих.)*

ВАКЫФ — фонд. "Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия вакыфы". *("Казан утлары", № 11, 1996, 168 бит.)*

ВУРДАЛАК — убыр, өрәк. *(Ф. Кәрим, "Разведчик язмалары". ТКН, 1954, том 3.)*

ВӘНӘКЛӘНҮ — күнегү, гадәтләнү. "Елгада кер чайкап вәнәкләнгән иде Бибигайшә". *(Шәриф Хөсәенов. "Казан утлары", № 2, 1990, 96 бит.)*

ГАЙБӘТЛӘШҮ — үзара гайбәт сөйләшү. "Гайбәтләшеп алырга да өлгерделәр", *(Нурихан Фәттах, "Сызгыра торган уклар", ТКН, 1991, 145 бит.)*

ГҮЛБӘЧ — аралык. Гүлбәчтән... Сөембикә килеп чыкты". *(Гомәр Бәширов, "Җидегән чишмә", II китап, 1978, 63 бит.)*

ДАСТЫЙН (буйлы). "Дастыйн буйлы егет". *(Флүс Латыйпов, "Ак-карага тимәскә", ТКН, 1992, 123 бит.)*

ДИМ-ДӘЛАЛӘТ — агитация-пропаганда, коткы.

ДУЛМА — ваклап тарттырып, дөге белән катнаштырылган ит. *(Атилла Расих.)*

ДӘМНӘҮ — тәмен жиренә житкерү. "Чәйне бераз томалап, дәмнәп алабыз". *(Әхмәт Фәйзи. Әсәрләр, III том. ТКН, 1966, 316 бит.)*

ДӘҮБӘК — зур, таза, көчле. "... сукса тимер өзәрдәй дәүбәкне нигә житәкләп йөртергә кирәк?" *(Әхәт Сафиуллин, "Фәрзәнә", "Аргамак", № 5-6, 1996, 58 бит.)*

ЗӘРГӘР — алтын-көмеш остасы, асылташлар эшкәртүче. "Мәмләкәтнең иң оста зәргәре исемен күтәрүе генә житмәгән..." *(Флүс Латыйпов, "Хыянәт", "Казан утлары", № 11, 1991, 65 бит.)*

*ИКЕНЧЕ ТОМГА:*

КАЛКАЮ — калкып, тырпаеп тору. "Колагым... калкаеп тора". (Шәехзадә Бабич, "Зәңгәр жырлар", ТКН, 1990, 413 бит.)

КАМ-МӘМЕР (килгәнче) — тәмам исергәнче. "Кам-мәмер килгәнче сыйландык". *(Аяз Гыйләжев, "Казан утлары", № 12, 1993.)*

КАНДЫРУ — канәгатьләндерү. Сусынны, теләкне кандыру.

КАРМАЗИН — кызгылт төс. "Безгә дөнья кармазин. Безгә дөнья ал да гөл димәктән". *(Нәкый Исәнбәт, Фразеологик сүзлек, том I, 154 бит.)*

КАТМӘЛ — тиз арада, ашыгыч. "Катмәл генә кирәк булсаң, мин тамак кырырмын". *(Мөхәммәт Мәһдиев, "Ут чәчәге", ТКН, 1980, 44 бит.)*

КИРМӘН — ныгытма, крепость.

КОДЫРАЮ — масаю катыш ирәю, һавалану, кәперәю. "Әтәч түгел, бөркет диярсең, инде дә кодырая тавык янында, инде кодырая". *(Зәки Зәйнуллин, "Казан утлары", № 4, 1991, 20 бит.)*

КУЛТАБЫН — поднос. *(Таһир Таһиров, "Аһ, шул Ислам", "Аргамак", № 3-4, 1992, 44 бит.)*

КУЛЧАТЫР — зонтик. "... кулчатыр булмау, бигрәк тә яңгыр койганда, бик кыен хәл". *(Рәүф Бәхтияр. "Сукбай мажаралары", "Аргамак" № 1, 1996, 55 бит.)*

КЫЕРЛАУ — "Утны кыерлыйлар. Нигә? Янгынны сүндерү өчен". *(Рәфкать Кәрами, "Ындыр тулы кибән", ТКН, 1992, 263 бит (янган бүрәнәләрне, такталарны таратып ташлау.)*

КҮЛЕМнең өченче мәгънәсе — вакыт арасы. "Бер күлем арасында (әни) арбага якын көлтә ура". (Риза Ишморат, "Гомер сукмаклары", ТКН, 1987, 27 бит.)

МАЛТАШЫР (ир) — байлык табучы. *(Тәлгат Галиуллин, "Тәүбә" романы, "Казан утлары", № 1, 1996.)*

МАХЫ (бирү, бирмәү) — алдану-алданмау, сынату-сынатмау.

МОНДАР — могжизалы зат, моңга үтә бай кеше. *(Марсель Галиев, "Догалы еллар", "Казан утлары", № 9, 115 бит.)*

МӘМЕРЖӘ — чокыр-чакыр. "Зур, тирән мәмержәләр кар белән тигез җиргә әйләнгән". *(Галимҗан Ибраһимов. Өч томлык, том I, 400 бит.)*

МӘС (итү) — кинәндерү, ләззәтләндерү. "Җәй һавасы... аны тәмам мәс итте". *(Аяз Гыйләҗев. "Балта кем кулында?", "Казан утлары", № 8, 1990, 103 бит.)*

МҮЛЕК — озынборын яралгысы, русчасы — мотыль. "Мүлек йоткан чабакны йотты чуртан..." *(Нури Арслан, "Казан утлары", № 10, 1986, 3 бит.)*

НЫКЫШЛЫК — чигенмәүчәнлек, үҗәтлек, хәтта мәгълүм базулык. "... үз-үзенә ышанган бер ныкышлык белән кыстый". *(Гариф Ахунов, "Казан утлары", № 1, 1987, 94 бит.)*

ОЕШның икенче мәгънәсе. Оеш — гаилә гаҗәп үзенчәлекле социаль оеш ул (газетадан).

ОЧЛЫМ — шлем. *(Мөсәгыйт Хәбибуллин, "Аллаһы бүләге", тарихи роман, "Мирас", № 1-2, 1996.)*

ПЫРКУ — күзгә бәрелеп торган кыска. "Пырку итеп чәчне кистерәбезме?". *(Рифә Рахман, "Аргамак", № 3, 1996, 51 бит.)*

САБЫРга өстәп: сабыр канаты сыну.

Сынды сабыр канатларым,
Сабыр италмам инде. (Җыр).

САДАК — ук савыты. "Менә тагын садагыннан уклар алды". *(Марсель Галиев, "Казан утлары", № 1, 1997,163 бит.)*

САЛАМТОРХАН — мактанчык, кулыннан эш килмәсә дә һаваланып, шапырынып йөрүче. "Кеше эшен тикшереп картаючы саламторхан". *(Кәрим Тинчурин, "Мәрҗәннәр", ТКН, 1987, 58 бит.)*

САН-САВЫР — гәүдә, буй-сын. "Сан-савырларын тыгызлап, тән җөйләрен белендереп кигән модный чалбарлары...", *(Нәкый Исәнбәт, "Татар теленең фразеологик сүзлеге", 1 том, 318 бит.)*

САРАТАН — июнь ае, чәчәк ае.

СИЛӘЗӘН — ата үрдәк.

СЫКТЫЙ *(сагыз)* — нарат бүрәнәдән яки тактадан сыгылып чыккан чәер, сагыз. "Сыктый сагызы да кипмәгән саргылт капка". *(Мөхәммәт Мәһдиев, "Ут чәчәге", ТКН, 1980, 42 бит.)*

СӘЛАМ ТОРУ — аягүрә торып сәламләү. "Болар килүгә гаскәрләр сәлам торалар". *(Гаяз Исхакый, "Олуг Мөхәммәт", "Мирас" № 1, 1991.)*

СӘРМӘҮ (капшап тою). "... машина тәгәрмәчен аяклары белән сәрмәп баса-баса җиргә төште". *(Зәки Зәйнуллин, "Казан утлары", № 4, 1991.)*

СӘҮГЕЛДЕК — хатирәле бүләк, берәр илдә, берәр шәһәрдә булу истәлеге итеп ясалган нәфис эшләнмә, сувенир. *(Җәмил Зәйнуллин, "Шәһри Казан", № 30, 12 февраль, 1991, 4 бит.)*

*ӨЧЕНЧЕ ТОМГА:*

ТАРАМА — нәрсәнеңдер күп булып сибелеп яткан, үскән урыны. "Артта җәй, артта хуш исле Җиләкле тарамалар. Уйларым тарамалар күк Бу җиргә таралганнар". *(Сибгат Хәким.)*

ТИПКЕНнең өченче мәгънәсе: кимсетелеп, кыерсытылып яшәү. "Ата-анасы үлгәч, малай кеше типкенендә калды". *(Барлас Камалов.)*

ТӘКЕНҮ "*(ташы)* — әйбәт кенә эш майтарганда каршылыкка очрап, тукталып, аптырап калу.

ТҮНТӘРЕШ (ТҮҢКӘРЕШ) — переворот. "Әллә инде илдә контрреволюцион түңкәреш булган?" *(Ибраһим Сәләхов. "Казан утлары", № 4, 1988, 29 бит.)*

УКЫЛЫШЛЫ сүзен өстәргә иде. Җиңел, мавыктыргыч, кызыксынып укыла торган.

УШСЫЗ — сүз әйтер җае калмау. "Ильясның кинәт телсез-ушсыз калуыннан файдаланып..." *(Илдар Низамов, "Мәхәббәт хакы", ТКН, 1986, 55 бит.)*

ХАНТАМА — бар булдыгы: уй-теләкләре, омтылышы, нияте-ымсынуы. "Мусаның инде бөтен хантамасы озакламый булачак сәнгать-әдәбият бәйрәменә юнәлгән иде". *(Шәйхи Маннур, "Муса", ТКН, 1968, 24 бит.)*

ХӘЙРЕ ХАҺ — Яхшы теләктә. "Мин сезгә хәйре хаһ, шагыйрь!" *(Әхмәт Фәйзи. Әсәрләр, III том, 115 бит.)*

ЧЕМКӘ — кечкенә ботак, тармак. "Сындырып алып кил әле шуның бер чемкәсен". *(Гурий Тавлин, "Йолдызлар белән янәшә", ТКН, 1971, 57 бит.)*

ЧУМАРЛЫКНЫҢ икенче мәгънәсен өстәргә. — Кеше буе күренмәслек су яки кереп югалырлык биеклектәге үлән яки иген *(төшеп чумарлык, кереп чумарлык.)*

ЧУРАУ — чуалту, тузгыту. "Кара алашаның ялын чурый бит". *(Марат Әмирханов. "Таш һәйкәлләр", ТКН, 102 бит.)*

ЧЫДЫЕ (бетә) — түземең, чыдамың бетә. *(Флүс Латыйпов, "Ак-карага тимәскә", ТКН, 1992, 119 бит.)*

ЧЫТЛЫМ — бер бөртек тә, бер тамчы да, аз гына да. "Бу төнне өч кешенен күзенә чытлым да йокы кермәде". (Роберт Батулла, "Сөембикә кыйссасы", "Казан утлары, N 9, 21 бит.)

ЧЫТНАЙ *(ак)* — абсолют ак, тоташ ак, җете ак. (Саба-Икшермә төбәгендә кин таралган.)

ЧӨМӘКӘЙ — мөлдерәмә тулы, түбәләмә. Чиләккә бәрәңгене чөмәкәй тутыру.

ШӘЛКЕМ — тупланма, цикл.

ЫКСЫМ — җиренә җиткереп. "Бик ыксым егеткә охшыйсыз", *(Хәсән Сарьян, "Туган як хикәяләре", ТКН, 1972, 145 бит.)*

ЫЧКЫМ — үзенә үлчәп теккәндәй таман, чак булу. *(Нәкый Исәнбәт, "Татар теленең фразеологик сүзлеге", ТКН, 1990, II том, 123 бит. Шәйхи Маннурдан алып кертелгән.)*

ЯКМЫШ — күзикмәк, кыстыбый.

ЯРМАК — нәрсәнеңдер ярылган кисәге. Ике ярмак бәрәңге.

ЯУРЫН — янбыз. "... ат яурынын кочакларга күнеккән кәкре аяклары", *(Ркаил Зәйдулла, "Казан утлары", № 1, 7 бит.)*

ӘВЕРНӘ — хедер (комбайн әвернәсе. *(Җәүдәт Дәрзаманов, "Җир авазы", ТКН, 1987, 87 бит.)*

ӘРЕПТӘШ — әңгәмә-бәхәстә катнашучы. "Әрептәшләре белән принципиаль бәхәсләрне озак еллар дәвам иттерергә сәләтле иде *(Риза Фәхретдин. "Казан утлары", № 1, 1984, 156 бит.)*

ӘСӘРТӘ — "Клубыбыз иске бер амбар әсәртәсе". *(Гурий Тавлин, "Афәт", ТКН, 1996, 100 бит.)*

ҖИЗКАЛФАК — урман кошы.

ҖИСЕМСЕЗ САГЫМ — мираж.

ҖӘЯК — яңак. *(Нәби Дәүли. "Казан утлары", № 8, 1985.)*

**Барлас КАМАЛОВ**

*Сөйләм культурасы мәсьәләләре*

**Равия Абдуллина**

# ТЕЛНЕ КАЛӘМ САКЛЫЙ

"Сүз онытыла, язмак онытылмый", — ди халык. Радиодан ишеткән сүзләр, никадәр генә тәэсирле булсалар да, вакытлар үтү белән, истән чыга, онытыла баралар. Ә "ташка баскан" югалмый, газета төпләмәләрен алып, теләгән хәтле файдаланырга була. Алар барысы да халкыбызның язма истәлекләре. Язучыларыбыз да, галимнәребез дә, гади эшчеләр, җир кешеләре дә газетага язып, каләмнәрен чарлыйлар, гүяки сүз сәнгате ярышы бара.

Газета — сүз сәнгате ярышлары бара торган урын гына түгел. "Газета — көрәш байрагы" дип яза иделәр элек. "Тел кылычтан үткен, каләм телдән дә үткен" дигән халык әйтеме дә шул турыдадыр. Ленин бабай әйтмешли, агитатор гына түгел әле ул газета, ә эшне оештыручы да. Соңгы вакытта газетаның бу функциясе кимеде. Язып чыккан проблемаларны исәпкә алып, чара күреп, эшне оештырып бетермәле генә түгел, ахрысы. Ни генә язмыйлар хәзер газеталарга... Ышанырга да, ышанмаска да белмичә йөрерсең.

Тик шунысы бәхәссез: газета бүгенге көн өчен кирәк булган мәсьәләләрне яктырта. Ул көн артыннан өлгереп барырга тиеш. "Тимерне вакытында сугарга, сүзне вакытында әйтергә кирәк". Газетаның үз сүзләре белән әйткәндә, ул "кызу темплар белән" чыгарыла.

Тагын шунысы бар: "көн кадагына сугып", "кызу" әйтелгән ул фикерләрне укучы бик тиз итеп укый да белергә тиеш. Югыйсә, ул баш әйләндергеч тизлектә үзгәрә барган вакыйгаларны белмичә калачак, көндәлек хәлләрдән хәбәрдар булмаячак, кемнең нинди карашта торганын белмәячәк, "политик сукыр" калачак... Хәзер бит татар газеталары гына да әллә ничә исемдә. Әле, җитмәгәненә, латин хәрефләренә күчәргә кирәк, дип язалар. Алфавитны алмаштырсак, ниләр генә укырга өлгерә алырбыз икән?..

Газетада язганнарны, күп вакыт түкмичә генә "эчеп" барыр өчен аның теле нинди булырга тиеш? Әлбәттә, газета җиңел, халыкның барлык катламнары өчен дә тиз аңлашыла торган йөгерек тел белән язылырга тиеш. Аңлашылмый торган сүзләр, атамалар катнашкан язмалар, эчтәлекләре бик тирән булуга да карамастан, укучыга барып җитә алмыйлар. Хәзер газеталарыбызда рус-европа алынмалары да саклана, аларның кайберләрен гарәп-фарсы сүзләре белән алыштыру уены белән дә мавыгып киттеләр: "Нур өстенә нур дигәндәй, бертуган Кашаповлар ширкәтеннән Наилә Вилданова вакыфка үзләрендә эшләнгән дивар сәгате бүләк итте" *("Мәдәни җомга", № 10, 1996)*. Шартнамә тугыз маддәдән тора һәм анда Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе вәкаләтендәге һәм бергәләп башкарыла торган эшләр теркәлгән *("Сөембикә", 1994, № 3, 3 бит)*.

Халыкның барлык катламнарына да аңлашыла торган сүзләрне мәгънәсен аңлап җиткермәгән сүзләр белән алыштыру язманы укучыдан "ераклаштыра", ап-ачык фикерне дә томанга төрә. "Алар мәхкәмә карарына буйсынмыйча, мәрасим үткәрделәр" дигән җөмләне генә алыйк. Кем карарына буйсынмаганнар? "Мәрасим" нәрсә ул? Берәр ярышмы, күңел ачу кичәсеме, кеше үлгәч искә алу мәҗлесеме? Кайбер газеталарны укыганда, берәр сүзнең мәгънәсен аңлыйм дисәң, сораулар арты

сораулар туып кына тора. Ярый ла, җәя эчендә андый сүзләрнең анлатмасын биреп барсалар: "Франциянең Югары мәхкәмәсе (суды), мөселман кызларының мәктәпкә башларына яулык бөркәнеп йөрүләре тыелмаска тиеш, дигән карар чыгарган иде инде. Ләкин Рошель Бой төбәгендәге укытучылар, мәхкәмә карарына буйсынмыйча, мәрасим (демонстрация) үткәрделәр" *("Нур", 3 декабрь, 1996).*

Газеталарда калькалар (сүзгә-сүз тәрҗемәләр) көннән-көн арта бара: Быелның гыйнварыннан Русия журналистлары һөнәри карточкалар ала башлаячак. ...Карточка алуның беренче көннәрендә үк ташламалы медицина хезмәте күрсәтү, "кайнар линия" буенча ашыгыч ярдәмнән бушка файдалану, шулай ук страхованиенең редакцияләр һәм нәшриятлар тарафыннан түләнә торган төрле төрләрен кертү күздә тотыла *("Мәдәни җомга", 5 гыйвар, 1995).* Ул аеруча катлаулы булган җинаять эшләрен тикшерүгә махсуслаша *("Таң йолдызы", № 14, 1996).* Яз белән бергә Казанга Мәскәү артистлары да ешлый башлады *("Татарстан яшьләре", № 31, 1996).* Сезонлы продукция бирә торган тавыкларны 2-3 ел тотарга мөмкин *("Якты юл", № 103, 1995).*

Аңлашылып бетмәгән чит тел сүзләре анлауны кыенлаштырган, уку тизлеген киметкән шикелле үк, калькалар да язмаларның аерым урыннарын кабат-кабат укырга мәҗбүр итә: Ел саен бирелә торган төп һәм өстәмә ял вакытларында, бала караган өчен бирелә торган ял вакытында туры килгән йөклелек һәм бала табу буенча ял өчен пособие сырхауханәдән бирелгән больничный лист нигезендә йөклелек һәм бала табу буенча ялның барлык көннәре өчен дә бирелә *("Татарстан хәбәрләре", № 123, 1994).* Бала тапканнан соң акча артыннан йөргән хатыннар, бәлки, бу җөмләне аңлаганнардыр, мин исә, өч-дүрт мәртәбәләр укып та, бернәрсә дә аңлый алмадым... Бу озын җөмләне сүзгә-сүз тәрҗемә иткәнче, тәрҗемәче үзе анлаганнарын кеше дә аңларлык кыскарак җөмләләргә таркатып язган булса, әлеге кинәш бик тә файдалы булыр иде. Озын җөмлә булганга гына түгел, сүзгә-сүз тәрҗемә ясап язганга күрә, аның кыска җөмләсе дә тиз генә анлашылмый: Әгәр яшь ярымга җиткәнче бала караган өчен өлешчә түләнә торган ялда булган ананың йөклелек һәм бала табу буенча ялы башланса, ана бу ике якның берсен сайлап алырга хокуклы (Шунда ук).

Төп фикерне аңларга тырышмыйча, сүзгә-сүз тәрҗемә итеп бару кайчакта логикага сыймый торган фикерләр дә китереп чыгара: Бу зур булмаган фаҗигале белдерүне мин көнгә тугыз мәртәбә — бер сәгать аралаш укып чыктым: "Советлар Союзы гражданнары һәм гражданкалары!.. Бүген иртәнге сәгать дүрттә... Герман гаскәрләре, сугыш игълан итмичә, безнең илебезгә һөҗүм иттеләр..." *( Левитаннан тәрҗемә. "Социалистик Татарстан", 2 сентябрь, 1977).* Сугыш башлану турындагы хәбәрне "зур булмаган фаҗигале белдерү" дип әйтеп буламы? Кызганыч ки, тәрҗемәдә шулай килеп чыккан. "Бер сәгать аралаш" дигән калькасын да, татарчалатып, "сәгать саен" дип язарга була иде. Тагын бер мисал: Сессиядә Татарстан Президенты тарафыннан төзәтмәләр белән кире кайтарылган "Мәгариф турындагы закон" кабул ителде *("Шәһри Чаллы", 23 октябрь, 1993).* Бу җөмләдән безнең иш гади кешеләргә болай аңлашыла: президент язманы төзәткәләгән, эшләп бетерегез дип, кире кайтарган (укытучы, шулай, хаталы сүзләр астына сызып, яңадан эшләргә дип кире кайтара бит), болар исә... шул кире кайтарылган законны кабул иткәннәр...

"Төзәтмәләр белән кире кайтарылган" дигәнне "төзәтеп бирелгән" яки "кайбер төзәтмәләр кертелгән" дигән сүзтезмәләр белән язган булсалар, мондый хилафлык килеп чыкмаган булыр иде.

Л. Толстой: "Кешеләрнең берләнбер аралашу ысулы булып сүз тора, шуңа күрә, чыннан да аралашу була алсын өчен, сүзләрнең һәрберсен әйткәндә, төгәл һәм кирәкле төшенчәләр тудырырдай сүзләрне файдаланырга кирәк," — дигән. Толстойның бу фикере газета теленә карата аеруча туры килә. Чөнки газета фикере укучы күңеленә бик тиз һәм төгәл барып житәргә тиеш. Әгәр алай булмаса, газета үз максатына ирешә алмый.

Газета язмалары, автор аларны күздә тотамы-юкмы, дүрт төрле максатны тормышка ашыра:

1. Нинди дә булса мәсьәләне яктырта,
2. Нәрсәгәдер инандыра-ышандыра,
3. Нәрсәдер чакыра-өнди,
4. Уйландыра яки ял иттерә.

Бу максатлар мавыктыргыч сюжет ярдәмендә генә түгел, тел-стиль чаралары ярдәмендә

дә тормышка ашырыла. Кайчакта автор шундый кызык хәлләр турында яза, ләкин язманың теле коры, җөмләләре җансыз булганлыктан, аларны укыйсы да килми. Ә кайчакта юк кына вакыйганы да шундый матур тел белән тасвирлыйлар — аерыла алмыйча укыйсың. Язмага "җан кертә" торган хикмәт — әсәрнең теле. Телне матурлау өчен дип, текстка сыйфатлар, рәвешләр, канатлы сүзләр, фразеологизмнар кертеп кенә котылып булмый. Телнең күзгә күренеп тормаган эчке хасыятьләрен дә сизә-тоя белергә кирәк була. Шул хасыятьләрнең берсе — грамматика. Газета телендә иң зур кимчелек тә — җөмлә төзелешендә булган хаталар. Радио-телевидение телендә андый хаталар булса да, сөйләм үзенчәлекләреннән файдаланганлыктан, тиешле паузалар, теге яки бу сүзне әйткәндә тавышның көчен, югарылыгын яки әйтү тизлеген үзгәртү андый житешсезлекләрне артык бәрелеп тормаслык итеп яшерә, интонацион чаралар җөмләне дөрес аңларга ярдәм итәләр. Ләкин публицистиканың ташка басылып таратыла торган стиле — газеталар телендәге грамматик кимчелекләр әллә кайдан ташланып торалар. Мондый житешсезлекләр җөмләне дөрес һәм тиз аңлауга комачаулыйлар. Газета телендәге житди грамматик хаталары булмаган җөмләләр дә әле, интонацион тышчан һәм эмоциональлектән мәхрүм булганлыктан, күңелгә һәм зиһенгә бик тиз генә барып җитә алмыйлар. Публицистик стильдә язылган гади генә бер җөмләне алыйк:

"Кичә үткәреләсе зал табигать турында укучылар иҗат иткән рәсем, плакат, фотолар белән бизәлә". Башта: "Кичә үткәреләсе" өлешен укып, кичәге көндә үткәрелергә тиеш булган берәр нәрсә (мәҗлес, җыелыш һ.б.) турында сүз бара, дип уйлыйсың. "Зал" сүзен укыгач, "үткәреләсе" һәм "зал" сүзләрен бәйләргә тырышасың һәм алга таба укыйсың. "Табигать турында" дигән өлешне укыгач, аны алдагылары белән бәйләргә тырышып утырасың. "Укучылар иҗат иткән рәсем, плакат, фотолар белән" дигән өлешне тагын алдагылары белән бәйләргә омтылып карыйсың. Ниһаять, "бизәлә" дигән соңгы сүзне укыгач кына, "рәсем, плакат, фотолар белән" дигән кисәкне "бизәлә" белән ялгыйсың. Аннары җөмләне яңабаштан укый башлыйсың. Фикерләр ялгана, җөмлә тәмам аңлашылып җитә: Бу залда кичә үткәреләчәк. Ул залга укучылар иҗат иткән рәсем, плакат, фотолар куела. Алар табигать турында. Җөмләне тиз генә кабул итә алмауга рус теленнән калькалаштырылган "кичә" дигән сүзнең күпмәгънәлелеге дә комачаулаган. Аны рәвеш мәгънәсендә түгел, ә исем мәгънәсендә ("вечер" дип) аңлату өчен, "кичә" сүзенең алдына берәр аергыч куярга мөмкин булыр иде: "әлеге кичә", "бу кичә", "табигатькә багышланган кичә" һ.б.

Газета стиленең кайбер җөмләләрендә житди грамматик ялгышлар да була. Мәсәлән, иярүче сүзне ияртүчесе белән янәшә куймау аңлашылмаучылык китереп чыгара: "Балалар бакчаларында туздырылган Чечнядан сабыйлар кайтуга да әзерлек эшләре бара" *("Татарстан яшьләре", № 10, 1995)*. "Балалар бакчаларында туздырылган Чечня" дип укысак та, тормыштан чыгып, алай булмаганын аңлыйбыз. Ә бу материалны тарихтан хәбәрдар булмаган кеше укыса, ничек дип аңлар иде икән?

"Әгәр тешегез сызласа, сызлаган тешкә каршы яктагы кулыгызның беләзегеннән йөрәк пульсын эзләп табыгыз, шунда бинт белән ваклап туралган сарымсак бәйләп куегыз" *(1996 елгы календарь, 26 май)*. "Бинт белән бәйләп куегыз" дигән сүзтезмәдә тәмамлык белән ул ачыклаган сүз арасына, "ваклап туралган сарымсак" килеп кергән. "Ваклап туралган сарымсакны шунда бинт белән бәйләп куегыз" диясе урынга "бинт белән ваклап туралган сарымсак" килеп чыккан...

"Япония башкаласы Токио шәһәр зыяратында күмелгән авылдашыбыз Нәҗметдин бай һәм аның хатыны Шәмсениса 1919 елны мең газаплар белән авылдан качканнан соң, Пермь шәһәренә юл тоталар". *("Нур", 22 май, 1993)*. Хәзерге газеталарга ни генә язмыйлар... Әнә, Токиодагы якташларыбыз, зыяратка күмелгәч, качып китеп, Пермь шәһәренә юл тотканнар... Башта шулай дип аңлыйсың. Аннары гына, логик фикер йөртү нәтиҗәсендә генә җөмләне икегә бүлеп басарга кирәк булганын, аергыч оясының стилистик хата икәнен тоясың...

"Ә Массарава поселогында дуңгыз урлаган ирне берничә касә ут яндыра торган борыч сыекчасы эчәргә мәҗбүр иткәннәр" *("Татарстан хәбәрләре", 15 сентябрь, 1992)*. "Берничә касә ут яндыра торган" дигәнне укып аптырап торасың. "Авызны ут шикелле яндыра торган борыч сыекчасын берничә касә эчәргә мәҗбүр иткәннәр" дисәң, тиз аңлашылыр иде.

"Үз теләкләре белән тәненә тамга суктыручылар һәркөн газап чигәләр һәм

каты пешүдән өмет иткән теләкләренә ирешә алмыйлар", — дип яза "Заман" газетасы да үз тәннәренә тамга салдыручылар турында.

1952 елда Бандырмада дөньяга килгән Нүсрәт Чолпан Йолдыз университетының архитектура факультетын тәмамлаган" *("Заман", 16 декабрь, 1994).* Укырга дип кергән университетын тәмамлаган кеше Нусрәт Чолпан Йолдызмы? Нусрәт дигән кеше Чолпан Йолдыз университетын тәмамлаганмы? Икесе дә түгел икән. Нусрәт Чолпан дигән кеше Йолдыз университетын тәмамлаган. Өч ялгызлык исемен бер-бер артлы кую дөрес аңларга комачаулый.

"Кеше — төрле хокуклар һәм җаваплылыклар белән бизәлеп ярaтылган Аллаһы Тәгаләнең сөекле бәндәсе" *("Заман", 16 декабрь, 1994).* Бусы инде саваплы булам дип гөнаһлы булу... "Хокуклар һәм җаваплылыклар белән бизәлеп яратылган Аллаһы Тәгалә" дигән гөнаһлы гыйбарә (бу гыйбарә ислам дине белән каршылыкка керә, чөнки Аллаһы Тәгалә беркем тарафыннан да яратылмаган, ул үзе безне яраткан!) аергыч һәм аерылмышларны дөрес урнаштырмау аркасында барлыкка килгән. "Кеше — Аллаһы Тәгаләнең төрле хокуклар һәм җаваплылыклар белән бизәлеп яратылган сөекле бәндәсе" дисәк, андый хата ясалмаган булыр иде.

Логика белән каршылыкка кергән мондый җөмләләр сүзгә экономия ясау сәбәпле килеп чыгарга да мөмкиннәр: "Төрле еллардагы дөнья чемпионнарының монарчы әле беркайчан да уйнаганнары юк" *("Татарстан хәбәрләре", 4 июнь, 1994).* Хәбәр алдыннан аны ачыклаучы рәвеш хәле дигән кисәк җитмәгәнлектән, логикасызлык килеп чыга: үзләре дөнья чемпионнары, үзләренең монарчы уйнаганнары юк... Логикага ул хәтле җитди зыян китермәсәләр дә, сүзләр бәйләнешенә игътибарсызлык җитди стилистик хаталар китереп чыгара: "Күренекле рәссам Т. Хаҗиәхмәтовка У. Иманинең портет-рәсемен ничек иҗат иткәнлеге хакында мөрәҗәгать иттек" *"("Татарстан хәбәрләре", 29 июнь, 1994).* Хәбәр алдындагы җөмлә кисәгенең төшеп калуы телне бозган: "ничек иҗат иткәнлеге хакында мөрәҗәгать иттек" килеп чыккан. Хәбәр алдыннан "сорап" дигән сүзне куйган очракта гына да тел бозылмас, грамматик стилистикага зыян килмәгән булыр иде.

"Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаучылар дин һәм гарәп теле укытучысы, гарәп тәрҗемә-чесе, шәрык илләре белгечлеге буенча эшли алачаклар" *(Шәһри Казан", 8 сентябрь, 1995).* Төп фикер аңлашылса да, грамматик стиль хаталары күп бу җөмләдә. Иң беренче "буенча" бәйлек сүзе күзгә ташлана. "Шәрык илләре белгечлеге буенча эшли алачаклар" дигән өлештәге "буенча" рус телендәге по предлогының калькасы — монысы ярар инде. Ләкин "эшли алачаклар" дигән хәбәрне "гарәп тәрҗемәчесе", "дин һәм гарәп теле укытучысы" дигән сүзләр дә ачыклап килә бит әле. Алары да "буенча" бәйлек сүзе ярдәмендә бәйләнергә мәҗбүр булалар: "дин һәм гарәп теле укытучысы буенча эшли алачаклар", "гарәп тәрҗемәчесе буенча эшли алачаклар" килеп чыга. Димәк, рус теленнән по предлогын калькалаштыру дөрес түгел. "Дин һәм гарәп теле укытучысы, шәрык илләре белгече булып эшли алачаклар" дип, "булып" бәйлек сүзе файдаланылган булса, татар теле бозылмас, җимерелмәс иде. Татарча: "Кем булып эшли?" диләр. "Гарәп тәрҗемәчесе" дигән атама да дөрес түгел. Ул "ниндидер бер гарәпнең тәрҗемәчесе" дигән мәгънәдә яки "Гарәп иленнән килгән тәрҗемәче" мәгънәсендә аңлашыла. Ләкин бирелә мәдрәсәне тәмамлаучы кешенең "гарәп теленнән тәрҗемә итүче" булып эшли алачагы турында сүз бара.

Үзара бәйләнүче сүзләргә игътибарсызлык аркасында туган мондый хаталар газета битләрендә еш очрыйлар. "Дүрт миллион ярым! Оһо! Миллионнарча документлар, миллионнарча язмышлар, миллионнарча тормыш чишмәләре тибеп тора" *("Заман", №61, 1995).* "Миллионнарча тормыш чишмәләре тибеп тора" дигән купшы сүзтезмәгә тимик. Газеталар шулай купшы язарга яраталар... Ләкин купшылык белән генә эш бетми әле. Чөнки "тибеп тора" дигән хәбәрне әлеге купшы сүз генә ачыкламаган. "Миллионнарча документлар, миллионнарча язмышлар, миллионнарча тормыш чишмәләре" — үзара тезүле юл, ягъни тигез хокук белән бәйләнгән сүзләр. Бу тиңдәш кисәкләр барысы да, тигез хокуклы булып, "тибеп тора" хәбәрен ачыклыйлар. Шулай итеп, бу җөмләдә чишмәләр генә тибеп калмый, ә... "миллионнарча документлар тибеп тора", "миллионнарча язмышлар тибеп тора"...

Сүзләр бәйләнешен исәпкә алып бетермәү белән бергә, сүз сайлау мәсьәләсендә дә игътибарсызлыклар бар. "Даһи әдипнең 200 еллыгы көннәре алдыннан булдырылган әлеге бүләк ияләре шагыйрьнең туган көнендә игълан ителәчәк *("Мәдәни җомга",*

*№7, 1996).* "Булдырылган бүләк ияләре" дигән сүзтезмә белән газета нәрсә әйтергә теләде икән? Аларга шул рәвешчә, үзенең мөнәсәбәтен, нечкә кинаясен белдерәме әллә?

"Җыелышта ник бер колхозчы ләм-мим бер сүз әйтсен" *("Якты юл", № 103, 1995).* Бу җөмлә, гади сөйләм теленә охшатып, ягъни "халыкчан" булырга омтылып язылган. Ләкин "артык тырышып җибәрү" бар. "Җыелышта ник бер колхозчы бер сүз әйтсен" генә дип язылган булса да, авторның җыелышта бер сүз дә әйтмәгән колхозчыларга мөнәсәбәте аңлашылып торыр иде. Ләммим — "бер сүз дә әйтмәде" дигән мәгънәне аңлатучы гади сөйләм сүзе. Аны җөмләнең башында йә азагында өстәмә сүз функциясендә бирү (Җыелышта ник бер колхозчы бер сүз әйтсен. Ләммим. Яки: Ләммим. Җыелышта ник бер колхозчы бер сүз әйтсен), йә булмаса җөмләдән бөтенләй төшереп калдыру урынлы булыр иде.

"Алып баручы һәм баянчы ирле-хатынлы Бриллиант һәм Фуат туйлар, мәҗлесләр үткәрергә заказлар кабул итәләр *("Нур" газетасыннан белдерү).* Алып баручы дигәннән баянны алып баручыны аңларгамы, ирен алып баручынымы? Концертны алып баручынымы, мәҗлесне алып баручынымы? Ягъни конферансьенымы, тамаданымы? "Тамада" мәгънәсендә элек "армый" дигән бик матур сүз булган. Татар телендә "табын башлыгы" дигән сүз бар. Керәшеннәр туй мәҗлесен алып баручыны "аргыш" дип атыйлар. Бу сүзләр әдәби телебезгә кереп китсәләр, "алып баручы" дигән ясалма гыйбарәләрнең берсеннән булса да котылыр идек.

Каләм тибрәтүчеләргә мәгълүм: фикерне хисне үстерә бару рәвешендә тасвирлаганда, кабатлаулар файдаланыла ала. Мәсәлән, Һади Такташның шигъри юлларын гына алыйк:

Бер җирдә юк андый ак каеннар,
бер җирдә юк андый урманнар.
Бер җирдә юк камыш сабаклары
Андагыдай шаулый торганнар...

Мондый максат күзгә тотылмаганда, кабатлаулар стилистик хата итеп кабул ителәләр: "Мамадыш районының чакыру участогына хәрби хезмәткә чакырылу өчен, чакыру көненә 16 яше тулган 1978 елгы гражданнар, шулай ук призывка чакырылу срогы беткән яки элек төрле сәбәпләр белән хәрби хезмәткә чакырылмаган 1969-1977 елларда туган гражданнарның килүе мәҗбүри *("Нократ", 13 апрель, 1996).*

Бер җөмләдә бер үк кушымчаның берничә тапкыр кабатлануы да стилистик житешсезлек: "Беренче сентябрьгә әлеге мәктәпкә чыгарылыш классына алмашка беренче класска җиде яшьлекләр килә. Алар унбишәү" *("Татарстан хәбәрләре", № 121, 1994).* Беренче җөмләдә биш сүзгә юнәлеш килеше кушымчасы ялганган — ике сүзнең берсендә юнәлеш килеш кушымчасы! Әлбәттә, мондый җөмләләрнең хис-тойгы белдерү мөмкинлекләре юк, укыганда да интонацион бизәкләр белән житешсезлекне "яшереп" булмый. Гел бер төрле интонациягә дә йогынты ясый: эчпошыргыч монотонлылык тудыра.

Публицистикада урынсыз кабатлану ягыннан иң еш очрый торганы — изафә (исем + исем) конструкцияләре. Изафәнең беренче төре: баш килештәге исем + исем. Бу төр изафә —борынгы форма (өй түбә, күпер ян, Чаллы яр). Икенче төр изафә: Исем + 3 зат берлек сандагы тартым кушымчасын алган исем ( өй түбәсе, күпер яны, Чаллы яры). Өченче төр изафә: иялек килешендәге исем + тартым кушымчасын алган исем *(өйнең түбәсе, күпернең яны, Чаллының яры). Газеталарда икенче төр изафәнең бер үк җөмләдә берничә тапкыр кабатлануы еш күзәтелә. "Гыйнвар аенда Бөгелмә шәһәрендә № 4, 1996).* Бу җөмләдә бер-бер артлы биш изафә килгән: гыйнвар ае, Бөгелмә шәһәре, Бикиев призы, Татарстан беренчелеге, чаңгы ярышлары. Ә бу мисалда дистәдән артык изафә бар: "Казан шәһәренең "Монолит" клубында халык милли спорт төрләре буенча балалар фестивале узды. Анда Ленин районының "Сакура", "Лада", "Союз" клублары, балалар иҗат үзәге 13 татар гимназиясе һәм "Монолит" клубы җыелма командалары татарча көрәш, таяк һәм аркан тартышу, кул көрәше буенча көч сынаштылар" *("Татарстан хәбәрләре", № 93, 1994).* Менә шулай, чит тел исемнәрен бер-бер артлы тезгән шикелле, дистәдән артык изафә дә бер үк җөмләдә тезелеп киткән. Мондый җөмләләрне абына-сөртенә укымыйча, ничек укыйсың?

Хәзерге татар әдәби теле грамматикаларына тугыз заман формасы теркәлгән, аларның һәрберсенең төп һәм өстәмә мәгънәләре тәфсилләп аңлатылган. Кайбер

галимнәр татар фигыльендә заман формалары дистәдән артык, дип саныйлар. Татар фигыле грамматик яктан бик бай. Аның төрле мәгънә төсмерләрен белдерүдәге шәкли мөмкинлекләре күп булса да, кайбер публицистик язмаларда гел бер кушымчадан гына файдаланалар. Мәсәлән, хәзерге заман хикәя фигыль кушымчасы — а, — ә, —ый, — и бер үк текста үткән заманны да, хәзерге заманны да белдереп килә... Гали Вәлиев фәләненче елны туа, фәлән җиргә укырга керә, ...укый, ...сугыш башлана, ... Гали Вәлиев фронтка китә...зур батырлыклар эшли...аның батырлыклары фронт газеталарында мактала... шуннан бер эпизод китерәбез...көтмәгәндә дошман самолетлары килеп чыга...кара төтен генә күтәрелә...исән-сау әйләнеп кайталар...күп батырлыклар эшли...сугыш бетә...исән кайта...фәлән җирдә эшли...пенсиягә чыга...эшсез тора алмый...эшли...

Югыйсә, грамматикаларда гына да алты төрле үткән заман формасы теркәлеп килә!

Мондый озын, сюжетлы язмаларда кушымчаның мәгънәсе сүз сөрешеннән, контексттан аңлашыла. Тел ярлылыгы, язманы күңелсез итсә дә, артык күзгә бәрелми. Кыска гына хәбәрләрдә хәзерге заман кушымчасын үткән заман мәгънәсендә дә хәзерге заман мәгънәсендә дә куллану мәгънәсезлек китереп чыгарырга мөмкин: "Язучы Демьян Фәтхинең туууына 10 сентябрьдә 90 ел тула. 1943 елда һәлак була... Шагыйрь һәм тәрҗемәче Әхмәт Юнысның тууына 15 октябрьдә 80 ел тула. 1976 елда вафат була". Юк, бу юллар әлеге язучыларның тормыш юлын алдан күрәзәлек иткән фал китабыннан түгел. "Мәгариф" журналының 1996 елгы 9 санында. "Мәгариф" журналында гына түгел, болай язулар газеталарда, календарьларда да тулып ята, радио-телевизорлар да шулай сөйли. Алар татар теле укытучысы телендә дә бар...

Газеталар, көндәлек вакыйгаларны яктыртып барганлыктан, ашыгыч әзерләнә, ашыгыч чыгарыла. Ашыгыч эшләнгәнлектән, аның теленә әзер штамплар, таушалган гыйбарәләр, күп кулланыла торган төсен җуйган сүзләр килеп керә. Безнең бу мәкаләдә тел-стиль җитешсезлекләренә мисаллар иң популяр, иң яратып укыла торган газеталардан алынды. Район газеталарын укый башласак, андый хилафлыклар тагын да күбрәк күзгә бәрелә башлый.

Газетаны чыгаруда, бер яктан, редакция коллективы, икенче яктан, башка бик күп авторлар катнаша. Һәр авторның үз теле, үз стиле. Аларның шәхси тел үзенчәлекләрен саклау да кирәктер. Хәзерге газеталар дүртенче битнең азагына үз өсләреннән җаваплылыкны төшерә торган мондыйрак җөмлә бирергә яраталар бит: "Редакция фикере аерым авторларның фикере белән туры килмәскә дә мөмкин". Әгәр бу җөмлә язмаларның идея ягына гына түгел, тел-стиль үзенчәлекләренә дә нисбәтле икән, ул чакта газета тел-стиль җитешсезлекләренә караган мәсьәләләрдән дә ансат кына котыла, дигән сүз. Әмма "ташка басылган — ташка басылган" булып кала бирә. Телебезнең үсеш-үзгәрешләре язма истәлекләр хәтерендә сызылып кала. Әдәби телебезнең үсеш дәрәҗәсе, тел культурасы да, иң беренче чиратта, газета теленнән чыгып бәяләнә. Радио-телевидение, газета-журналлар киң халык массасына туган тел укытучысы хезмәтен үтәсен дисәк, газета теленә игътибар тагын да артырга тиеш була. "Ташка басылган елъязма" истәлек буларак, газетаның тел үрнәге тәрбияви көчкә ия, шуңа күрә ул аеруча әһәмиятле. "Телне каләм саклый", — дип юкка гына әйтмәгәннәр.

# АЛТЫН УРДА ӘДӘБИЯТЫ

**Мәгълүм ки, Алтын Урда дәүләтендә барлыкка килгән һәм хәзерге вакытка кадәр килеп ирешкән рухи мирас үрнәкләрен, нигездә, язма истәлекләр тәшкил итә. Әлеге ядкярләрнең төп өлеше чәчмә һәм тезмә ысул белән башкарылган төрле эчтәлекле әдәби әсәрләрдән гыйбарәт. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, алар асылда гарәп-фарсы классикасы тәэсирендә язылганнар яки, үткәндәге традицияләргә таянып, шуннан мөстәкыйль иҗади тәрҗемә ителгәннәр.**

**Бу язма һәйкәлләр гасырлар дәвамында төрки халыклар, хосусан татар әдәбиятының үсешенә сизелерлек йогынты ясаганнар һәм аның бай хәзинәсен тәшкил итәләр.**

**Дөрес, Алтын Урда әдәбиятының аерым мәсьәләләре ориенталистлар, тюркологлар, тел һәм әдәбият белгечләре тарафыннан мәгълүм дәрәҗәдә гыйльми яктан тикшерелгән. Бу юнәлештә эш хәзер дә дәвам иттерелә. Ләкин шунысын да билгеләп үтү зарур: аның нәтиҗәләре еш кына аерым фәнни даирәгә генә билгеле булып кала бирә.**

**Гәрчә соңгы елларда урта гасыр чоры дәүләтебезнең әдәби казанышларын өйрәнү мәктәп программаларына кертелсә дә, аларны киң гавәмгә тәкъдир итү һаман да җитди мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шуны истә тотып, без, журнал укучылары игътибарына берничә мәкалә тәкъдим итәргә булдык. Бу сезнең әлеге мәмләкәтнең язма мәдәнияте турындагы мәгълүматыгызны тагын да тулыландырырга ярдәм итәр дип ышанабыз.**

## Мөгыйнел-мөрид

XIY йөзнең беренче яртысында Алтын Урданың Хәрәзем төбәгендә “Мөгыйнел-мөрид” (“Мөридкә ярдәмче”) дигән әсәр барлыкка килә. Эчтәлеге белән үгет-нәсыйхәт һәм тәрбия темасына багышланган әлеге язма истәлек шигырь юллары белән язылган. Аның бердәнбер нөсхәсе XYI гасырга нисбәт ителгән рисаләләр тупланган бер җыентык арасында сакланган. Ул ниндидер сәбәпләр аркасында Төркиягә барып ирешкән һәм бу турыда тарихчы Ә.-З. Вәлиди үз вакытында язып та чыга.

Әсәрнең кем тарафыннан язылган булуы турында төгәл генә мәгълүмат юк. Әлеге мәсьәлә текстта да чагылыш тапмаган, ягъни соңыннан авторның исемен яки тәхәллүсен күрсәтү кебек традиция бу очракта сакланмаган.

Хива ханы Әбелгазый Баһадурның “Шәҗәрәи төрек” дип аталган мәгълүм әсәрендә “Мөгыйнел-мөрид” һәм аның авторына нисбәтле кызыклы гына белешмә китерелә. Аерым алганда, анда Хызыр иленнән Арсарыбай исемле бер кешенең Өргәнечкә барып, шундагы Шәрәф атлы шәехтән мөселман дине буенча гарәпчә берәр өйрәтмәләр китабын төркигә тәрҗемә итеп бирүен үтенүе турында бәян ителә. Әлеге шәех шул гозергә җавап рәвешендә бер китап төзеп, аны “Мөгыйнел-мөрид” дип атый һәм Арсарыбайга бирә.

Чыганаклардан күренгәнчә, дөрестән дә Өргәнечтә шәех Шәрәф дигән изге зат яшәгән һәм вафатыннан соң җәсәде шунда дәфен кылынган.

Каспий артында яшәүче төрекмәннәрдә Шәрәф исемле шәехнең "Рәүнәкъел-Ислам" ("Ислам чырагы") дип аталган шигъри әсәр язуы турында риваять сакланган. 1906 елда Хуҗалы мулла дигән бер укымышлының бу хакта А. Н. Самойловичка язган хатыннан аңлашылганча, аны әлеге шәех халыкның үтенече буенча башкарган һәм китап мәдрәсәләрдә уку әсбабы сыйфатында кулланылган.

Ашһабадтан ерак булмаган Нөхер дигән тау авылында әлеге риваятьтә сөйләнелгән шәехкә нисбәт ителгән кабер бар.

Әдәбиятчылар Г. Газиз һәм Г. Рәхим "Рәүнәкъел-Ислам" белән "Мөгыйнел-мөрид" шәех Шәрәф исемле бер кеше тарафыннан язылуына шөбһә юк дип белдергәннәр. Әмма А. Н. Самойлович әлеге әсәрне һич тә тәңгәлләштерергә ярамаганлыгын искәрткән.

Танылган ориенталист Н. П. Остроумов 1907 елда Ташкентта "Рәүнәкъел-Ислам"ны типография ысулы белән нәшер итә. Ул басмага бәяләмә рәвешендә язган мәкаләсендә А. Н. Самойлович, ни сәбәптәндер, аның авторы кем булуы билгеле түгеллеген белдерә. Мәгълүм булганча, поэманы 1464 елда Вафаи исемле шагыйрь иҗат иткән. Бу турыда текстның үзендә дә әйтелә:

Әй Вафаи, белгәнеңне күзләмә,
Белмәзеңне "белүрәм!" тиб сүзләмә.

Ә.- З. Вәлиди билгеләгәнчә, авторның Вафаи икәнлеге башка чыганакларда да раслана.

З. Б. Мөхәммәдованың бер мәкаләсеннән күренгәнчә, Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең кулъязмалар фондында "Рәүнәкъел-Ислам"ның шактый күчермәләре саклана. Шунысы да мәгълүм булсын, мөхтәрәмә галимәнең максаты башкачарак юнәлештә, әмма аның язмасы әлеге әсәрнең төрекмәннәр арасында электә популяр булуны һәм аңа мөнәсәбәтле кайбер башка мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итүе ягыннан әһәмиятле.

Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлеге фондында "Рәүнәкъел-Ислам"ның сигез кулъязмасы бар.

Төрек галиме Ә. Җәгъфәр углы үзенең карамагында булган "Шәҗәрәи төрек" һәм А. Н. Кононовның мәгълүм китабына нигезләнеп, "Мөгыйнел-мөрид"не шәех Шәрефкә нисбәт итә. Әмма Ә.-З. Вәлиди әлеге поэмага багышланган мәкаләсендә әсәрнең авторы турында әтрафлы тикшеренү үткәреп, аның шәех Шәрәф тарафыннан язылмавын белдерә.

"Мөгыйнел-мөрид" традицион кереш белән башлана. Аннан соң ул егермедән артык эреле-ваклы баба һәм фасылларга бүленә. Аерым алганда, аларда дини йола үтәү, әдәб, тәссауф мәсьәләләре күтәрелә. Текстның азагында аның язылу вакыты да күрсәтелгән:

Тарих йете йөз унөч ирде йыли,
Сәламегаләйкем галәйкем сәлам.

Аңлашыла ки, әсәр миляди хисап буенча 1313 елда иҗат ителгән.


Шигырь төзелеше ягыннан "Мөгыйнел-мөрид" урта гасыр төрки язма истәлекләре "Котадгу белек", "Гыйбәтел-хәкаикъ" вәзенендә язылган. Димәк, аның үлчәме мөтәкарибе мөссәмәне сәлим (фәгулен, фәгулен, фәгулен, фәгулен).

Әлеге әсәре татар әдәбияты тарихы яссылыгында да гыйльми нигездә тикшерелеп, кулланылышка кертелергә тиеш.

## Кыйссасел-әнбия

Пәйгамбәрләр турында һәм аларның тормыш юлларын тасвирлаган тарих китаплары гарәп, фарсы телләрендә урта гасырда күпләп язылган. Мәсәлән, шундый әсәрләрнең беренчесе Вәһһәб бине Мөнәббиһ исемле гыйлем иясенә нисбәт ителә.

XIY йөзнең беренче яртысында Алтын Урда дәүләтенең Хәрәзем төбәгендә төрки "Кыйссасел-әнбия" ("Пәйгамбәрләр тарихы") иҗат ителә. Ул нигездә чәчмә әсәр булса да, урыны-урыны белән анда шигырьләр дә урнаштырылган. Аның авторы турында тулы мәгълүмат юк. Бары тик текстның кереш өлешендә генә теркәлгән зур булмаган белешмәдән күренгәнчә, әлеге эшне Рабат Угызы дигән шәһәрнең казые Борһанеддин углы Насыйреддин башкарган һәм Насыйреддин Тукбога исемле бәккә багышлаган.



Чыганакларда Тукбога шәхесенә нисбәтле мәгълүмат күп түгел. Мәсәлән, инглиз ориенталисты Ч. Рье аны 1391 елда сәяхәтче Ибне Баттута чыгътайлы Галәведдин Тармаширин (1326 — 1334 еллар) солтанның Нәхшәб шәһәре янындагы лагеренда күргән чыгышы ягыннан монгол, ләкин мөселман Тукбога әмир белән тәңгәлләштерә. Тукбога тархан буларак "Идегәй" дастанында да телгә алына. Танылган язучы һәм галим Н. Исәнбәт аны текстта ялгызлык исем яки сыйфат булып та килгән булуы ихтималын яза.

Ядкярнең азагында шигырь юллары белән бәян ителгәнчә, хезмәт җиде йөз унынчы, ягъни миляди 1310 елда тәгәлләнгән. Урта Азия белгече, фольклорчы һәм һәвәскәр археолог Ә. Ә. Диваев, нишләптер, китап 1404 елда язылган дип белдерә.

1913 елда Казан университеты буенча алтын медальгә тәкъдим ителгән эшләр арасында тарих-филология факультетының IX курс студенты А. В. Ерофеевның да "Соломон (Сөләйман — Р. И.) патша турында мөселман риваятьләре" дигән хезмәте бар. Профессор Н. Ф. Катановның аңа язган бәяләмәсеннән күренгәнчә, дәгъва авторы "Кыйссасел-әнбия"не XYIII йөзнең азагында башкарылган дип белдерә һәм өлкән галим, бернинди аңлатмасыз, күрсәтелгән вакытны икърар итә.

"Кыйссасел-әнбия"нең текстында аның авторы үзенең хезмәтен язганда бик күп чыганаклардан файдаланганлыгын белдерә. Бу турыда ул еш кына "риваять килмеш", "хикәядә андаг килмеш", "риваять кыйлурлар", "риваятьдә килер", "хәбәрдә килер", "әйтмешләр", "бәгъзе әйтер", "бер кыйсса китабида күрдем" һ. б. дип әйтә һәм кайбер исемнәрне дә күрсәтә. Алар арасында, мәсәлән, Әбубәкер Сыйддыйк, Гомәр әл-Фарук, Госман Зиннурайн, Гали әл-Мортаза, Гайшә (Гайшә әс-Сыйддыйка бинте Әбубәкер әс-Сыйддыйк), Өммеһани бинте Әбуталиб, Өммегелсем бинте рәсүл, Вәһһәб бине Мөнәббиһ, Әбу Сәлмә, Билал Хәбәши, Әбу Габдуллаһ Йахуд Әбу Габделкәрим, Габбас (Әбу Фазыйл бине Габделмөталлиб бине Һашим әл-Корәйши), Кәгб әл-Әхбар (Әбу Исхак

Кәгб бине Маниг), Габдулла бине Габбас (Әбелгаббас бине Габделмөталлиб бине Һашим әл-Корәйши әл-Һашими), Суфйан (Суфйан бине Әсәд Йаход бине Әсид әл-Хазрами), Әсамә ибне Зәед (Әсәма бине Зәед бине Харис бине Сәрахил бине Кәгб бине Габделгазый әл-Кәлби), Әбусәгыйд әл-Ходдури (Сәгыйд бине Малик), Габдулла ибне Гомәр (Габдулла бине Гомәр бине әл-Хаттаб әл-Корәйши әл-Гадви), Җабер бине Габдулла (Җабер бине Габдулла бине Гомәр әл-Әнсари әл-Силми), Әбу Һөрәйрә (Габдрахман бине Сахраздәми), Әнәс бине Малик, Мөҗәһид (Мөҗәһид бине Җәбер), Хәсән басрый (Әбусәгыйд бине Җәгъфәр), Катада (Катада бине Дигамә әс-Садуси), Әбелхәсән Пашагрый, Әбузәр әл-Гаффари, Габдулла бинә Мәсгуд (Әбу Габдархман), Әсмәгый (Әбусәгыйд Габделмәлик бине Корәеб), Имамә әл-Баһили (Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Баһили), Гомәр ибне Хөзәен, Габдрахман ибне Гаиш, Хөзәйфә ибне әл-Йәмәни, Гаяз, Горуһ ибне Сәлмән, Хөзәйфә (Мәһшим бине Гатбә бине Рабигә бине Габдешшәмес бине Габделмәннаф бине Каси әл-Корәйши), Әбу Силми ибне Загый, Малик ибне Сагсагә, Габдулла ибне Руми (Әбу Габдуллаһ Мөхәммәд бине Рамазан), Әбу Әййүб әл-Әнсари (Халид бине Зәед Хазрам), Әбу Дәрдаэ (Гаваир бине Гамер бине Зәед Хазрам), Габдулла ибне Зөбәер (Әбубәкер бине әл-Гомәри бине Хаувилд бине Әсәд бине Габделгазый бине Каси бине Кәләб әл-Корайши әл-Әсәди) кебек күренеклеләр бар. Ул шулай ук Коръәннән аятьләр китереп, үзенең фикерләрен дәлилләли. Атамасы билгесез һәм "Җарел-бәйан" дигән тәфсирләргә дә сылтамалар очрый.

Профессор Г. Т. Таһирҗанов билгеләгәнчә, төрки каләм иясе эш барышында Фирдәүсинең "Йосыф вә Зәләйха" поэмасына да мөрәҗәгать иткән.

"Кыйссасел-әнбия" күчермәләренең борынгырак саналган хәзерге вакытта Лондондагы Британия музеенда саклана. Кульязманың үзендә аның язылу вакыты күрсәтелмәсә дә, Ч. Рье ул нөсхәне XY йөзгә нисбәт итә. Танылган галимнең әлеге билгеләмәсе белән профессор В. Р. Розен, һичшиксез, килешергә мөмкин икәнлеген яза үзенең бер мәкаләсендә.

Әсәрнең кайбер башка күчермәләре Париж Милли китапханәсендә, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлегендә, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең кульязмалар фондында бар.

Рабгузыйның хезмәте типография ысулы белән беренче тапкыр 1859 елда Казанда нәшер ителә. Дөрес, әлеге басмада бернинди дә шәрехләр, аңлатмалар бирелмәгән. Аның нинди кульязмаларга нигезләнеп төзелүе дә мәгълүм түгел. Шулай да П. М. Мелиоранский бу китап өчен Азия музеенда 361 сан белән саклана торган кульязманың файдаланылган булу ихтималын билгеләрә.

1915 елга кадәр әсәр Казандагы төрле басмаханәләрдә ун тапкыр бастырыла. Шунысын да билгеләп үтү зарур, ядкяр төрле, аерым алганда "Кыйссаи Рабгузый", "Кыйссасел-әнбия Рабгузый", "Кыйссасел-әнбия галәйһемес-сәлам", "Кыйссасел-әнбия" кебек атамалар белән дөнья күрә.

Китапның атамасына нисбәтле мәгълүмат текстның кереш өлешендә үк китерелә. Хосусан, анда автор үзенең әсәрен "Кыйссаи Рабгузый" дип билгеләгән.

"Кыйссасел-әнбия"нең өйрәнелү тарихы төрле чорларда төрле галимнәрнең исемнәре белән бәйле. Н. П. Остроумов Казандагы Рухани академиянең мөселманлыкка каршы миссионерлык бүлегендә укыганда ислам динендә пәйгамбәрләр турындагы өйрәтмәләргә багышлап хезмәт яза. Моның өчен ул Рабгузый әсәренә мөрәҗәгать итә.

Танылган тюрколог В. В. Радлов 1893 — 1911 елларда дүрт том күләмендә төрки шивәләр сүзлеген төзеп бастыра. Ул үзенең әлеге бибәһа хезмәтендә башка чыганаклар белән бергә "Кыйссасел-әнбия"нең лексик материалларыннан да киң файдаланган. Шулай ук Л. З. Будагов тарафыннан әзерләнеп, 1869 — 1871 елларда нәшер ителгән ике томлык "Төрки-татар шивәләренең чагыштырма сүзлеге" өчен дә әлеге әсәргә еш кына мөрәҗәгать ителгәнлеге ачыклана.

Мәгълүм ки, Коръәндә "Әсхабе кәһәф" дигән сүрә бар. Шәрекъта һәм

Көнбатышта әлеге сюжетка нигезләнгән шактый риваятьләр таралган. Италия галиме И. Гвиди бу мәсьәләне өйрәнүгә махсус хезмәт тә багышлаган. Аның татарларда булган вариантын Н. Ф. Катанов Кытайга гыйльми сәфәре вакытында 1891 елда Чүгүчәктәге Мөҗиб ахуннан язып алган һәм "Кыйссасел-әнбия"дәге шул ук текст белән чагыштырып, кызыклы гына нәтиҗәләр ясаган.

Галим шул ук сәфәрендә янә Яхъя, Зәкәрия, Гайсә, Мәръям турындагы төрки чыганаклар табып ала. Ул аларны өйрәнгәндә Коръәндә һәм Рабгузый әсәрендәге аларга бәйле мәгълүматка мөрәҗәгать итә.

Сөләйман турында Азиядә табылган риваятьләрне "Кыйссасел-әнбия" белән чагыштырып анализлау да Н. Ф. Катановның нәтиҗәле хезмәте.

П. М. Мелиоранский "Кыйссасел-әнбия"нең Лондонда саклана торган күчермәсендәге Салих пәйгамбәр турындагы өлешен ул вакыттагы Азия музеенда, Император җәмәгатьчелек китапханәсендәге кульязмаларда һәм Н. Ильминский нәшер иткән китаптагы шул ук бүлекләр белән бәрабәр куеп өйрәнә. Мәкаләсендә ул файдаланган нөсхәләр турында киң мәгълүмат китергән һәм үзе эшләгән тәнкыйди текстның урыс теленә тәрҗемәсен дә урнаштырган.

Галим Лондон нөсхәсеннән янә Исмәгыйльне корбанга китерү, Кәгъба төзелеше һәм Исхакның балалары турындагы өлешләренең дә күчермәсен алдырган булган. Ләкин ул матбугатка яңа хезмәтен әзерләп өлгерми кала. Соңыннан С. Е. Малов аларны Азия музеендагы, Дәүләт җәмәгатьчелек китапханәсендәге һәм Н. Ильминский басмасындагы шул ук вариантлары белән чагыштырып, аны урыс теленә өлешчә тәрҗемәсе белән бастырып чыгара.

С. Е. Малов янә борынгы төрки язма истәлекләр турындагы үзенең икенче бер хезмәтендә дә "Кыйсасел-әнбия"гә урын биргән. Анда Н. Ильминский нөсхәсе нигезендә әсәрнең авторы һәм аның китабы, Лут пәйгамбәр турында, китапның бетем өлешеннән өзекләр китерә. Шулай ук әлеге текстларның урысча тәрҗемәләрен дә урнаштырган.

"Кыйссасел-әнбия"нең тел үзенчәлекләре турында сүз йөртеп, Н. Ильминский үз вакытында әлеге ядкяр белән "Котадгу белек" телләренең якынлыгын белдерә. В. Р. Розен да Рабгузый әсәренең теле Йосыф Баласагуный поэмасының теленә ачкыч булуын билгели.

Әдәбиятчы Г. Рәхим әсәр борынгы, ягъни XY йөзгә кадәр булган чыгътай телендә язылганлыгын икърар итә.

С. Е. Малов тексттагы лексик материалның Көнчыгыш төрки характерда булганлыгын һәм әсәрнең Караханилар дәвере әдәбиятына якын икәнлеген күрсәтә дигән нәтиҗә ясый. Тюрколог Ә. Н. Нәҗипнең дә фикере шундый. Ул үзенең бер мәкаләсендә Рабгузый әсәрен өйрәнүгә багышлаган махсус хезмәтен нәшер итәргә әзерләвен яза. Ләкин ул басманы хәзерге вакытка кадәр әле күренгәне юк.

Рабгузый әсәре электә татарлар арасында киң таралган һәм яратып укылган китапларның берсеннән булган. Ул мәдрәсәләрдә уку әсбабы сыйфатында да файдаланылган һәм аның атамасы "Кыйссасел-әнбия" буларак киң таралыш алган.

"Кыйссасел-әнбия"нең халкыбыз арасында булган популярлыгы турында археографик экспедицияләр вакытында табылган аның кайбер өлешчә күчермәләре дә ачык дәлил. Шулай ук 1917 елга кадәр һәм аннан соң да нигездә шушы әсәргә таянып язылган төрле атамада, төрле күләмдә пәйгамбәрләр тарихының типография ысулы белән нәшер ителәү фактлары да шул турыда сөйли.

Әлеге әсәр үз вакытында татар язучыларының иҗаты өчен чыганак ролен үтәгәнлеге ачыклана. Мәгълүм ки, 1908 елда З. Һади "Яңа әсхабе кәһәф" дигән китабын бастырып чыгара. Язучының шәхси архивы сакланмау сәбәпле, әсәрнең язылу тарихы билгеле түгел. Шулай да әдәбият гыйлемендә аның Коръәндәге мәгълүм "Әсхабе кәһәф" сүрәсенә пародия буларак иҗат ителгән дигән фикерләр бар. Әлеге мәсьәләне ныклап өйрәнгәндә, пәйгамбәрләр турындагы кыйсса-риваятьләрнең гомумән, Рабгузый әсәренең аерым алганда, татар

әдәбиятына тәэсиренә, анда чагылышына ачыклык кертергә ярдәм итәр иде.

Кызганыч ки, Г. Рәхим хезмәтеннән соң "Кыйссасел-әнбия" татар әдәбияты тарихында да, тел гыйлемендә дә әлегә кадәр бөтенләй дип әйтерлек өйрәнелмәде. 1963 елда нәшер ителгән "Борынгы татар әдәбияты тарихы"нда ул бер җөмлә белән генә искә алына. "Татар әдәбияты тарихы"ның 1984 елда дөнья күргән беренче томында, дөрес, әсәргә игътибар чагыштырмача арта төшә. Әдәбиятчы М. В. Гайнетдинов тексттагы Йосыф турындагы кыйссадан "Бәһарият" ("Яз") дигән газәлне һәм бер дүртюллык шигырьне текстологик яктан әзерләп, "Татар поэзиясе антологиясе"нең беренче томында бастырды.

Борынгы әдәбият белгече Н. Ф. Исмәгыйлев вакытлы матбугат битләрендә укучыларны Адәм галәйһес-сәлам турындагы кыйсса белән таныштырды. Хәзер ул әсәрне тулысынча гамәлдәге татар хәрефләренә күчерү эше белән шөгыльләнә.

Соңгы елларда әсәр турында урта мәктәп уку-укыту программаларында мәгълүмат бирелү аның киләчәктә ныклап өйрәнеләчәгенә өмет уята.

"Кыйссасел-әнбия"не өйрәнү торышы башка төрки халыкларда да төрлечә. "Башкорт әдәбияты тарихы"ның беренче томында ул берничә тапкыр гына телгә алынып үтелә.

1895 елда "Кыйссасел-әнбия" Ташкентта бертуган Каменскийлар тарафыннан литография ысулы белән нәшер ителә. Соңыннан ул Голям Хәсән Гарифҗанның басмаханәсендә дөнья күрә. Шулай ук аның башка басмалары да билгеле.

"Кыйссасел-әнбия"нең Урта Азиядә үз вакытында таралыш алуы һәм каләм ияләре өчен билгеле дәрәҗәдә илһам чыганагы булганлыгы турында кызыклы гына дәлилләр бар. Мәсәлән, Ташкент өязендәге Акҗар волосте Чарпулад авылында мелла Кәбәй Тукпулат углы галәм җисемнәре турында язган хезмәтендә Рабгузый әсәреннән файдаланганлыгы турында белдерә.

Үзбәк әдәбиятчысы Фитрәт (Габдерәүф Габдерәхим улы — Р. И.) үзенең "Үзбәк әдәбияты нәмүнәләре" дип аталган хезмәтенең 1928 елда басылып чыккан беренче томында Рабгузый әсәренең Йосыф турындагы өлешен урнаштырган. Үз вакытында аның белән танышкан С. Е. Малов әлеге нөсхәнең фәнни әһәмияткә ия булганлыгын белдерә.

М. Бозрук үзбәк әдәбиятына гомуми планда анализ ясаган бер китабында шулай ук "Кыйссасел-әнбия"гә урын биргән.

Әсәр хәзерге вакытта да үзбәк филологларының игътибар үзәгендә. Мәсәлән, С. Хәйдәров үзенең кандидатлык диссертациясендә әсәрнең текстында дөньяви мәсьәләләргә бәйле элементларның да мәгълүм дәрәҗәдә урын алып торуларын раслый. Тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә Ү. Мирзакәримова, әдәби яктан тикшерүгә И. Останакулов мәгълүм дәрәҗәдә өлеш керттеләр.

Биш том күләмендәге "Үзбәк әдәбияты тарихы"ның беренче томында Рабгузыйга һәм аның иҗатына тиешле урын бирелгән.

Казакъ әдәбиятчысы М. Юлдашбәков борынгы төрки язма истәлекләр һәм аларның казакъ әдәбиятына мөнсәбәтен өйрәнүгә багышлаган хезмәтендә әлеге рухи мирасның бары тик шигырь белән генә иҗат ителмәгәнлеген, ә бәлки чәчмә ысул белән дә язылганнары барлыгына басым ясый. Моңа мисал итеп ул иң әүвәл Рабгузый әсәрен китерә.

А. Кыраубаева тарафыннан "Кыйссасел-әнбия"нең идея-сәнгатьчел үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлаган диссертация яклаган.

"Кыссасел-әнбия" әдәбият, тел тарихын өйрәнү өчен дә, урта гасыр төркигарәп, төрки-фарсы әдәби һәм фәлсәфи бәйләнешләрне ачыклауда да әһәмиятле чыганакларның берсе булып тора.

**Рамил ИСЛАМОВ,**
филология фәннәре кандидаты

*Мәдəниятебез тарихына*

**Энгель Нигъмәтуллин**

# ТОТКЫНЛЫКТА

***Күренекле галим һәм сәясәтче Йосыф Акчураның бай мирасы, кызганычка каршы, киң катлам укучыларга билгеле түгел. Соңгы елларда әдәби һәм сәяси мирасыбызга караш тамырдан үзгәргән бер чорда байтак әсәрләр инде укучыларга кайтарыла бара. Шундый язмалар исәбендә мин Й. Акчураның "Мәукуфият хатирәләре" исемле китабы да булырга тиеш дип саныйм. Китапта авторның Казан төрмәсендә тоткынлыкта яткан чагында туган уй-фикерләре, кичерешләре, күзәтүләре чагылыш тапкан.***

**"1906 ел, 8 март.**

Кыш кичәсе. Ябалак кар ява, әтрафка йомшак бер тынлык бирә.

Кечкенә кыңгырау куәтле суга. Өянәк тоткандай дерелдәп уянам. Инде иртә булды. Гаҗәп төшме?

Тагы бер сугу! Әүвәлгесеннән көчлерәк. Кыңгырауның теле өзелмәгәе. Лампамны яндырдым: сәгать дүрт кенә әле. Ишекне ачтым. Тыштан бүлмәгә дымлы суык җил керде. Йокыдан әле генә аерылган күзләремә ишек төбендә таптанган кылычлы полиция кешеләре чалынды. Күземне уам. Уяндыммы?

— Өегезне тикшерергә килдек.

Йокыда йөргән кебек, юл күрсәтәм. Бүлмәм тула.

Китапларым, кәгазьләрем, мәктүбләрем — сөеклеләремнән килгән мөкатдәс, самими сүзләр белән тулган ул сөйкемле мәктүбләрем, рухымның, бөтен хәятымның газиз нәрсәләре бер-бер артлы зобани кулларыннан кичә. Ләкин ул караңгы, соры кулларның сахабиларында мәхәббәт вә инсаниятнын илаһи балкышы бар. Хис итәм: күзләрендә йомшак, сөйкемле, хәсрәтле бер елмаю беленә.

Сәгать биш. Вакытсыз мөсафирларым татсыз вазифаларын бетерделәр вә кулга алынуым белән мәэмүр булуларын хәбәр иттеләр. Хәзерләндем. Киттек.

Кар ява. Һава юеш. Урам аулак. Аксыллыкка манылган кара күләгәләр, йомшак аяк тавышлары. Нәрсәгә вә ни өчен китерәләр? Гаҗәба! Хәзер төштәме мин?"

*Бераздан Йосыф Акчураның зур гаебе булмау ачыклана. Казан губернаторына жандарм ротмистры Протенский тарафыннан җибәрелгән донесениедә (1906 ел, 9 март) тәгәл фаш иткеч җинаять билгесе күренми. "Минем боерыгым буенча, 5 март кичен тентүгә дучар ителде һәм кулга алынды, — дип яза ротмистр, — чөнки Казандагы мөселман халкы арасында хөкүмәткә каршы идеяләр таратуы һәм сәяси ышанычсыз булуы турында мәгълүматлар бар. Моңардан башка 1905 елның 23 январенда Кабан буендагы Хрусталев йортында мөселманнарның яшерен җыелышы булды, өстәвенә Акчурин җыелыш сәркәтибе итеп сайланган иде. Аннары, мәгълүматлар буенча, соңгы вакытта аерымлану, рус халкына карата нәфрәтләнү фикере хөкем сөрә. Кайбер хәбәрләргә караганда, Акчурин социалист-революционерлар партиясенең Казан комитеты татар телендә бастырган "Думага бармагыз" исемле*

*проект авторы. Тенту вакытында Акчурин фатирында законга каршы килә торган бернинди әйбер табылмады, ләкин татар һәм төрек телләрендә язылган күп кенә хатлар һәм бер өем кулъязмалар алынды. Бу корреспонденция тәрҗемәче ярдәмендә күздән үткәрелә. Тикшерелеп беткәч, хөкүмәткә каршы алып барылган агитациядә Акчуринның катнашу катнашмавы турында йомгак ясау мөмкин булачак. Акчурин конституцион-демократик партиясенең һәм Россия мөселманнар берләшмәсенең әгъзасы булып тора, панисламизм һәм халыкны торгызу идеяләрен пропагандалаучы, Мисыр, Истанбулда торучы мөселманнар белән хатлар язышып тора" (ТДА, 199 ф., I тасв., 969 эш, 10-11 бб.).*

*Й. Акчураның пантюркизм фикерләре хакимиятне чынлап та борчыган, ләкин әлегә бу шөбһәләнү генә. Донесениеда хәтта сукыр кеше дә күрерлек үзара ярашмаган фикерләр бар: Й. Акчура эсер партиясенә дә тагылган һәм кадет дип тә танылa!*

*Март-апрель айлары (И. Акчураның төрмәдә утырган вакыты) — Дәүләт думасына сайлаулар барган вакыт. Й. Акчураны сайлау кампаниясеннән читләштерү хакимиятнең төп максаты була. Әгәр Й. Акчура әһәмиятсез кеше булса, мондый ыгы-зыгы тумас та иде. Әмма ул күренекле шәхес булган. Менә берничә факт.*

*Беренчесе — Казанның танылган мөселманнары губернаторга адресланган гаризалары:*

*"4-5 март арасындагы төндә потомственный почетный гражданин Йосыф Хәсән углы Акчурин кулга алынды. Ябып кую аркасында аның сәламәтлегенә зарар килү мөмкинлеген күздә тотып, чөнки аның йөрәге нормаль эшләми, без, түбәндә кул куйганнар, җаваплылыкны өстебезгә алып, ваше превосходительстводан аны эш ачыклаганчы төрмәдән чыгаруны, шулай ук эшне мөмкин кадәр тизрәк тикшерүне боеруыгызны түбәнчелек белән үтенәбез" (ТДА, 199 ф., I тасв., 369 эш, 17 б.).*

*Әлеге гаризага Мөхәммәтрәхим Габдерәшит улы Юнысов, Мөхәммәт Закир улы Апанаев, Мөхәммәтшакир Мөхәммәтҗан улы Казаков, Исхак Мөхәммәт улы Апанаев, Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев, Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитов, Таҗетдин Мангушев, Хөсәен Асаневич кул куйган.*

*Икенче факт — "Вечернее эхо" газетасында басылган репортаж (1906 ел, 7 март). Репортажның соңгы элешендә ике төрле аңларга урын калмаслык иттереп янау яңгырый: "Һәм жандарм һәм жандарм булмаган җирле властьтан партиябезнең актив эшлеклесе булган Й. Х. Акчуринны кулга алынуының сәбәпләрен аңлатуны көтәбез. Телеграф аша хәбәр алган партиянең үзәк комитеты Петербургта үзәк хакимияттән аңлатуны таләп итәчәк."*

*Өченче факт — Петербургтан, эчке эшләр министрлыгы каршындагы полиция департаментыннан Зубовский имзасы белән җибәрелгән телеграмма. Телеграмма мәхбүсне азат итү мөмкинлеген күздән тотарга кирәк диган киңәш бирелә.*

*Күргәнебезчә, Й. Акчура ягында көчле терәк: сәүдәгәрләр һәм промышленниклар тора. Болар белән хакимият исәпләшергә мәҗбүр. Киң җәмгыять фикере дә үз ролен уйнагандыр. Й. Акчураның кулга алынуының икенче көнендә үк Фатих Әмирхан Ризван Алушига болай дип яза: "Бу көннәрдә Казан башыма тар булып тора. Юсеф Акчуринны арестовать иттеләр; хәлфәм Гассарны арестовать иттеләр, бәлки үземне ушбу көннәрдә арестовать итәрләр."*

**"10 март.**

Пычрак, томанлы бер бүлмә. Төтенле лампаның кадерле яктысы. Авыр, тонык бер һава. Өстәл артындагылар борыннарын кәгазьләреннән аердылар, мәгънәсез, йокылы күзләрен хайвани бер ахмаклык илә безгә чөйделәр; ачуланган кебек иделәр. Пристав:

— Утырыгыз! — диде вә китте.

Мин уянган вакыттан бирле хәятымны тәкрар хәтеремнән кичерәм, бөтен фикерләрем бер ноктага туплана: "Ни өчен кулга алындым?"

Бераздан озын буйлы, озын сары чәчле, поп кыяфәтле бер яшь кешене китерделәр. Таныштык. Исемнәребезне яздылар, әйберләребезне алдылар, төрмәгә озаттылар.

Ярабби! Керүгә бәдрәф исе безне каршы ала. Вәхши хайван кебек хәвефләнеп, куркып баккан ике кеше күренә.

Ике аркадашым, миннән үрнәк алып, бүлмәне адымларга башладылар.

Кыскача таныштык. Бәхетсезлеккә юлыкканнарның хөрсезлек белән якалашканнарын аңладым. Берсе тәкрарлый:

— Аһ, исереклек, аракы... Барысы анардан...

Бүген артык пошаман иде. Инде берничә мәртәбә тәүбә итә. Ләкин барысы да файдасыз. Аркадаш! Син янә эчәчәксең, янә бу мәхбәс дигән чүплеккә атылачаксың!"

*Әлеге кәефсезлек вакытлы булса кирәк. Чөнки Й. Акчура, мәгърифәтче буларак, кеше рухына, адәм аңына ышаныч, өмет баглаган кеше була. 1904-1905 елларда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укыган лекцияләрендә, ул мәсәләи, мондый фикерләр әйтә: "Джон Стюарт Милль "Мантыйк гыйлеме"ндә җәмгыятьләрнең никадәр төрле, күпсанлы элементлардан төзелгән булганын, вакыйга-күренешләрнең никадәр күп вә каршылыклы сәбәпләр аркасында барлыкка килгәнен бик гүзәл күрсәтә. Стюарт Милль кешеләр табигатеннән алынган кануннарны сәбәп итеп китерү юлы илә тоташтыруны киңәш итә. Ягъни тарих кануннары рухи кануннар илә тәэмин ителергә тиеш, чөнки инсан аерым булсын, җәмгыять белән булсын, даимән инсан вә инсан табигатеннән дәлилләнгән кануннарны инсан җәмгыятьләренә дә яраштырырга мөмкин."*

**"12 март.**

Кичә эчендә чирканыч исләр белән тулы бүлмәдә мәхәббәт белән эретелгән ләтыйф вә нурлы җәмгыять төзелде. Гүя ләззәтле бер музыка илә тибрәнәсең. Өстәл өстендә чәчелгән җимешләр, чәй чынаяклары мәгънәви зәвыкларны матди ләззәтләр белән котлый... Бу рухани бәйрәм белмим ничә сәгать дәвам иткәндер, һәрхәлдә сәгатьләр минуттан кыска иде! Әтрафыбыз ямьсез мохит, пислек вә билгесезлек, әмма бу якты, пакь вә бәхетле хыял гадәттән тыш бер көч бирә.

Ләкин һәркемнең калебендә бәхетнең кыскалыгын хәбәр итүче бер тавыш бар: аерылачакбыз вә кем белә күпме вакытка... Шомлы минут килеп житте, аерылыштык, көлешкән йөзләребез илә елаган калебләребезне күрдек. Минем дә калебем елады, ләкин шатлык вә сәгадәт көенүдән артыграк иде. Очы күренмәгән бер лабиринтка сугылдым, ләкин мин аерылган галәмдә мине сөйгән — кабат әйтәм — мине сөйгән калебләр бар.

**12 март.**

Уяндым. Туры почмаклы тимер рәшәткәле якын тәрәзәдән яктылык керә. Ялгызлык. Тынлык. Үткән хөр заманны күрәсем килә.

Берничә көн элек бер музыка кичәсендә идек. Шуберт, Бетховенның сәмави даһиларыннан туган моңнар залга сирпелгән. Мин тик "аны" күзәтәм.

Ул рәшәткәгә таянган, мәрмәрдән Психея һәйкәлчеге кеби, хәрәкәтсез, кулы чигәсендә... Мин бүлмәдә, диварга таянып, Бетховенның рухи куанычы белән тулган сонатасын тынлыйм, бу һәйкәлчекнең очканын күрәм. Аһ, бу минутлар! Мәкерле, инсафсыз хакыйкать эчендә яшәү... Җәннәт, хыял минутлары! Мөмкин булырмы тагын бер сезнең белән кавышу?"

*Монда сүз бер рус кызы турында бара. Й. Акчура аны Нихаль дип, төрек исеме белән атаган. Дусты һәм фикердәше Әхмәт Фәриткә җибәргән хатында (1906 елның 25 декабрендә) Й. Акчура болай дип язган:*

"Хәзер дә Нихаль һәм мин, без еш күрешәбез. Күптән түгел иҗтимагый бер урында беренче мәртәбә татар телендә бер пьеса уйналды. Хәбәрнең тулылыгын "Мөхбир"дә укырсың. Без гел бергә булабыз. Ул инде аз-маз татарча аңлый башлады.

Танцалар барган вакытта Нихаль һәм мин киләчәк турында проектлар төзедек. Сәяхәтләр: Һиндстан, Мисыр, Швейцария. Ул педагогикага бирелгән. Җиңел әйберләрне яратмый. Танцаларга катнашмады. Без клубның (кичә шәһәрнең "Новый клуб" дип аталган шактый зур бинасында үткәрелде) зур залында түгел, ә кечкенә уңайлы залында утырдык; зур залның шау-шулы тормышыннан качып, пакъ вә тыныч минутлар кичереп ләззәтләндек. Рождествоның беренче көне башланды. Мин аның янына барам. Үземә охшаган бик матур Гайсәне — бер немец рәссамының фотография репродукциясе —

үзенә рождество бүләге итеп бирермен. Мин моны шушы көннәрдә Санкт-Петербургта сатып алган идем."

"Җомга көне. Шәһәр муниципалитет залында сәяси мәҗлес барды. Залга ике йөздән артык адәм җыелды. Күбесе эшкуарлардан, кечкенә ялтыравыклы күзле, чәчсез баш артлары. Мин килгән вакытта мәҗлес ачылган иде. Рәис кайбер әһәмиятсез шәйләр аңлатты. Бу күпкә сузылмады. Тынлык.

— Бер шәй сөйләргә теләгән юкмы?

Янә тынлык. Думага хәзерләнәләр. Һәркем башын ия; йөзләреннән ачык күренә: "Ни өчен безне газаплап монда китердегез? Ни сөйләрсез? Эшебез бар, йокыбыз да туймады." Үкенүле шелтә. Ләкин бу шелтә кемгә?

Рәис бераз сабырсызланып:

— Тәкрар әйтәм, сүз теләгән юкмы? — дип сорый.

Ниһаять, беренче рәттә утырган сәүдәгәрдән бер зат сүз алды. Ялгаусыз, ниһаятьсез, бер газап. Болай сөйләшүгә караганда, сүзсез Дума артыграк күренә.

Мин мөнбәргә таба юнәлдем. Ни булачак? Белгәннәр өчен нигездә мәгълүм, белмәгәннәр өчен соңыннан да билгесез, һәммәсе өчен буш, файдасыз. Берничә шәй сөйләрмен: кайберләре алкышлар, кайберләре күңелсезләнеп чырайларын сытачак. Мин, бала кебек, бу алкышлардан мәмнүн калачакмын! Ул таушалган сәүдәгәрдән соң мөнбәрдә һәм ярсулы сөйлим! Соңыннан алкыш... Бәхәсләшү... Хаклы күренгән арзу. Тагы берничә нотык. Янә бәхәс. Ул хыял минутлары!

Ишек гүя күңеле яратмаган вазифасында зарланып ачылды:

— Чәй әзер, килегез.

**14 март.**

Сәгать ике. Пычрак урамнардан бер казак белән полиция юлдашлыгында шәһәр хәбесханәсенә озатылачакбыз. Өч-биш аркадаш озатырга килделәр. Аларның самими холыкларыннан ярсулы бер көенү илә аерылыр көн. Калебемдә нәрсәдер купкан кебек булды. Әйләнеп карадым: дымлы күзләр миңа багалар.

Кечкәнә урамнарда төрле нәрсәләргә төбәп карыйм.

Чиркаыч бер капка, калын тимер рәшәткәләр, униформалар. Йөзләрендә мәрхәмәтсез бер күңеллелек.

— Әйдә, кер!

Артыбыздан капка матәм тавышы белән ябылды... Кечкенә идарә бүлмәсендә исемебезне сорадылар, буебызны, хәтта тешләребезне тикшерделәр. Әйберләребез, өс-башыбыз тикшерелде. Ниһаять, бер зинданчы дүрт йозаклы ишектән үткәреп, берничә яшь кеше белән тулган бер бүлмәгә кертте. Тавышлар, кул кысышу...

Караңгырак бүлмә. Кечкенә тәрәзәләрдән житәрлек яктылык керми. Кечкенә ишек, бик калын диварлар инсанда авыр хис тудыра, үзеңне бер тимер чынаяк эченә бикләнгән кебек тоясың. Өч тарафта караватлар тезелгән, уртада, ачык калган мәйданчыкта ике тар өстәл куелган.

Бүлмәдә миннән башка тагы адәмнәр бар. Бишенче март кичәсендә шәфәкъ алдыннан кулга алынганнар; күбесе дарелфөнүн студентлары; озын чәчле, кырыкларына җиткән бер шәһәр мәэмүреннән гайре барысы яшь: егерме-егерме биш яшьләрендә.

**16 март.**

Һәркем билгеләнгән вакытта бу каберда җирләште. Билгеләнгән вакыт... Бәлки кайберләр өчен гомерлеккә... Тәгәлләнергә күп калмаган романны, "Помпеяның соң көннәре"н укып бетерергә теләдем. Циркның караңгы зинданы. Юнанлы Глокус вә христиан Олинтус анда арысланнарның ерткыч тырнаклары, ач тешләре белән ботарланган; берсе гөнаһсыз, хөкем астында торучыларга куәт бирә, икенчесе ниһаятьсез, илаһи бер иманны вәгазьләүче, мәхәббәт изгелеге иясе. Бу тар, караңгы, юеш бүлмә каршысында яктылык, меңнәрчә халыкның кайгысына сөенгән, шуклы хәят илә әсәрләнгән цирк... Мәйданда канлы көрәшләр, җир кан белән пычранган. Кан исе килә. Халыкка,

бу ярсыган румалыларга кан күрү, кан исенә туену вәхши бер зәвыкъ, бер ләззәт, бертөрле җәннәт бирә, бакыралар, көләләр, әсәрләнәләр.

Христиан Олинтус... Бу бер куәт, шундый куәт ки, бөтен золымнар җәмгыятен, мәдәниятын тар-мар итәчәк. Христианлыктан кабынып киткән илаһи шәхеснең сәмави нәсихәтләреннән, артык бөтен галәмне каплаган гадәләтсезлектән, кешеләрнең бер кыйсеме әһәмиятсез алтын-көмешкә күмелгән, тырышсыз, идеялсыз, файдасыз хәятларын иң кабахәт бозыклык, иң канлы вәхшилекләр кичерү белән мәшгуль көн, иң бөек кыйсемнең өмедсез бер ачлык белән очрашуыннан туган...

Христианлыкның нидачылары, рәсүлләр инсаният өчен үзләрен оныталар. Олинтус өч-биш минуттан соң, һәр әгъзасының кубарылып ботарланганын онытып, зиндандагы аркадашына христианлыкның иң саф иманын, мәхәббәт вә гафу итүне инандыру белән мәшгуль! Олинтус барлыкка килгән христианлыкта бер ялгызы түгел. Рума шәһәрләре циркларының һәммәсендә берничә Олинтус вәхши хайваннарның хиссез тырнак вә тешләре илә ботарланган килеш сәмави бер диннең нурлы сүзләре илә афәткә тарган рәфикъларын юаталар вә туры юлга кертәләр иде, — инде бу заман дөньяның бөек бер инкыйлабы башланды... Инде әтрафымда мин күргән бу яшь рухларның максимумында Олинтустагы ялкынлы мәхәббәт вә иман бар. Күбесе инсаният бәхете өчен үзләрен оныталар, идеалларына бөтен гади ләззәтләнүләрен корбан итәләр. Аларны бу зинданда бикләгәннән соң ерткыч хайваннарга түгел, Сибириянең мәрхәмәтсез суыкларына хәзерләгән хөкүмәт яңага каршылык күрсәтү вазифасын башкара.

Мин бу идеал корбаннарын хуплыйм; ләкин дөнья янә иске әйләнешендә дәвам итәчәк, кешеләр, бәхетсез кешеләр янә бәхетле булмаячак!.."

*Камерадагы иптәшләре белән аралашу һәм инглиз язучысы Э. Бульвер-Литтонның мавыктыргыч романын уку Й. Акчура күңелендә яңалык өчен көрәшүчеләр образын җанландыра. Телгә алынган роман персонажлары — инсафлы, батыр йөрәкле шәхесләр, алар фәхешлеккә баткан золым дөньясына каршы торалар. Глокус һәм Олинтус — иман, бөек идеалларны таратучылар — үзләренең трагик язмышларын батырларча каршы алалар.*

*Й. Акчураның психологик торышы гаҗәеп: бер яктан, ул ярсулана, ә икенче яктан, аның эчке эмоциональ симфониясен тынычлану, киләчәккә ышану хисләре чолгап ала. Бу хәл тормыш тәҗрибәсеннән, Европа тәрбиясе киңлегеннән килә: Й. Акчура Парижда Сәясәт фәннәре институтында һәм Сорбоннада Югары дәресләр институтында белем алган, Эмиль Бутми, Альбер Сорель, Теофиль Функ-Брентано, Анатоль Леруа-Болье, Дюркгейм, Леви-Брюль, Тардэ, Оман, Сеньобос һ. б. лекцияләрен тыңлаган. Шуңа күрә ул сәясәттә дә берьяклы, утилитар, ортодокс карашлардан мөмкин кадәр азат булырга тырышкан.*

**"19 март.**

Ике лампа куе, җирәнгеч һаваны ерта алмыйча, сары бер яктылык илә җемелди. Башым авырта. Ниндидер бер авырлык күз кабакларымны баса. Газаплы йокыга талдым.

Кечкенә бер түшәктә җиде кеше ята. Уң тарафыма зәгыйфь, хәстә, шешенгән бер адәм, сул тарафыма озын сөрсегән чәчле бер математик туры килде. Көчкә сыендым; шулкадәр бу авыр йокы мине талчыктырды. Мин уянганда һава танымаслык бер хәлгә килде, сулаганда авыр ис белән зәһәрләнгән иде. Бәхетсезлек уртаклашкан аркадашларым гырылдыйлар.

Тәрәзәгә якынлаштым, ике катлы тәрәзә җиллеген ачтым. Ух, суык бер хәят, хөр, чиста һава!

Соңрак кабат йокыга киттем. Иртән йокыдан торганда, аркадашлар бу көннең бөтен хезмәтләрен миңа калдырганнарын хәбәр бирделәр. Кичә алар фикер алышып, тәгъбирләрендә бер "конституция" тәртипкә салдылар: алфавит буенча һәр көн берәр нәүбәтче гомуми хезмәтне башкарып чыгачак.

Бүлмәне җыеп, икмәкләрне кисеп, чәй хәзерләп вазифамны башладым.

Бәхетсезлек вә сәгадәт кешеләрне җитезлек белән таныштыра. Шундый сәгадәт бардыр ки, бер-берен гомердә бер мәртәбә дә күрмәгән ике адәм бер

анадан туган кебек, кочаклашып үбешәләр! Шундый бәхетсезлек заманнары да бардыр ки, бер-беренең канына сусаган ике дошман бер минутта мәңгегә дус булырлар! Өстебезгә төшкән бәхетсезлек безне бер кичәдә дуслаштырды."

*"Конституция" төшенчәсе Й. Акчурага бик таныш. Әле 1899 елда ул сөргеннән качып, Тунис аркылы Франциягә килә. Парижда Садри Максуди белән дуслашып китә, яшь төрекләр даирәсе белән элемтәне торгыза, аларның башлыклары Әхмәт Риза, Габдулла Җәүдәт, Сабахетдин белән таныш була. Яшь төрекләрнең төп максаты — 1876 елгы конституцияне яңарту иде. Алар карашынча, конституция һәркемгә, аның этник яки дини аерымлыгына карамастан, тигез хокуклар, азатлыкны гарантияләргә һәм бер дәүләт эчендәге төрле миллиятләрнең союзын барлыкка китерергә тиеш. Үзенең бу юнәлештәге фикерләрен Й. Акчура 1904 елның мартында язылган "Өч тарз-и сәясәт" исемле әсәрендә үстерә.*

**"20 март.**

"Конституция"без уртаклык мәгънәсендә аңлашылган иде: "коммуна", кием вә ятактан гайре, шәхси милек танымый, өлеш, ашау әйберләре вә башкасы, һәммәсе уртак. Егерме дүрт сәгать берничә санлы кыйсемгә бүленгән вә һәр кыйсем билгеләнгән бер эшкә чикләнгән: иртән сәгать сигездә торабыз, өйләгә кадәр чәй эчелеп беткән була. Соңыннан өйлә ашына кадәр һәркем уку-язу белән шөгыльләнә. Барысы җентекле тәртипкә салынган, катгый бер программага нигезләнгән. Һәр көн бер аркадаш нәүбәт алып, "канун нигезе"н саклап, "коммуна"ның хезмәтен үтәргә тиеш. Канун нигезенең гадел хәл ителүе зарур булса яхуд башка мөһим бер мәсьәлә килеп чыкса, "коммуна ул көнге нәүбәтченең тәхет рәислегендә бергәләп фикер алышып, күпчелек тавышы белән карар бирә.

Билгеле, бу уен, бала уены, ләкин кеше рухы карышуы өчен гыйбрәтле бер уен. Кечкенә коммуна күпмегә яшәячәк?

**22 март.**

Кичке сәгать тугыз. Бүлмәдәге өстәл тирәсенә тезелеп, тавышсыз укыйбыз. Берничә вакыттан соң ишек ачыла: кулга алынуыбызның сәбәпләрен белдерү өчен чакыралар.

Чиратым килде. Мин дә киттем. Лаванда исе белән туган бер кечкенә бүлмәгә керттеләр. Озын буйлы бер жандарм ротмистры нәзакәт белән утыруымны әмер итте. Укырга сорау алу кәгазен сузды. Мин бу кешене карап чыктым: ефәк кебек йомшак чәчләр, алтын пенсне артыннан сыекча күзләре ялтырый; йомшак таза яңаклар; сәнгатьчә бөдрәләнгән сары мыек; рәтле кечкенә борын; пөхтә, жете кызыл авыз, ак тешләр. Киеме пайтәхет тегүчеләренең кием тегү мастерскоеннан чыгып, бу көн сахибына килешеп тора, гүзәл вә яңа. Өстәл өстендә яткан куллары, бөек бер игътибар белән чистартылган тырнаклары. Һичбер боеручы кырыслык күрсәтмичә, ягымлы дәшә.

Ялтыравыклы танца залларында декольте ханым-кызлар белән кул-кулга көязләнеп йөрү яхуд йомшак, кечкенә, ярым караңгы бер будуарның мендәрләрендә жәдитчә киенгән гүзәл бер хатын белән тез-тезгә утырып, шагыйрәнә әңгәмә кору өчен яратылган бу гүзәл яшь, шаңлы офицер бөтен Казан шәкертләрен куркыткан, энергияле, бик эшчән, аусыз вә турылыклы господин Протенский иде!

Мин гавамият иштиракия (с. д.) партиясенә катнашучы булуда вә ул партиянең фикерләрен татарлар арасында таратуда гаепләндем! Бу асылсыз, мәгънәсез гаеп ителүемнең ялгышлыгын сөйләдем. Язуымны таләп итте. Русча белмәгәнемә күрә, үзенең язуын үтендем. Кабул итте. Күзләренең ялтыравы артты, ачусыз йөзенә гасаби бер төс керде. Йомшак куллары хәрәкәтләнде: кәгазь битенә хәрефләр, кәлимәләр куна башлады.

Минем җавабым бетте. Ул да дәшми утырды. Кайбер шәйләр турында сорадым. Кызыгып җавап бирде. Бүлмәдән чыгуыма, аякка басып сәламемне кайтарды.

**24 март.**

Калебем өзлексез тетри вә бу миңа бер ләззәт бирә!

Менә таң атты. Ачык, ләкин тимер рәшәткәле тәрәзәдән гүзәл бер илнең язы, яз таңы керә. Күгәрченнәр очышалар. Офык бик чикләнгән. Каршыда югары дивар, мунча.

Моңлы чаң тавышлары ишетелде. Мин күпме вакыт хөр идем? Күпме вакыт, бер минутка булсын, хөрриятемә көйләнә белдем? Ни өчен куәтле бер кул бугазымны кыса? Ул тимер кулның мәрхәмәтсез көчен иң кайгылы заманнарымда тоям.

**25 март.**

Куәтле бер яктылык белән тавышлы бер музыка йокымны ачты. Нинди гүзәл көн! Болыннар яшелләнәчәк, агачлар яфракланачак, чәчәкләр ачылачак. Без боларны күрүдән мәхрүм.

Бу көннең гүзәл бер гадәте бар: тотылган, хәбес ителгән кошлар, залим кошчыларының читлекләреннән алынып, сөеклеләренә кавышырга очарлар. Ул заман бу кошчыкларның йөрәкләре сөенеч белән никадәр сулкылдар!

**27 март.**

Ике аркадаш озатылачак дигән хәбәр ишетелде. Китүчеләрдән берсе яшь бер юрист, икенчесе һәнүз сәясәт давылының хәрәкәтенә кушылган, талантлы хыялпәрвәр бер егет иде. Сигез-ун көнлек танышлыгым дәвамында юристның рухын, идеалын, пакъ хыялын күрдем.

Кичен китүчеләр шәрәфенә концерт биреләчәк иде. Һәр икесе алтынчы камераның иң яхшы музыкачылары иде. Юрист Ике каһарман дуэтын көр, аһәнле бас илә башкарды. Бөтен камера бу яшьләр күз яшьләрен түгеп, тын гына тыңлады. Князь Игорь ханга шагыйрәнә үзенчәлек белән җавап бирә, егетнең тавышы сәмави бер ләззәт илә күтәрелә, оча, җәелә; ул да князь Игорь кебек ватандашларына хөррият яулауны намуслы бер әсирлектән өстен күрә иде.

Бу авыр, җитди дуэттан соң аркадаш кискен вә көлемсерәүче сатираны, үч алу өчен төзелгән хорны осталык илә, илһамланып идарә итте. Бу музыка бөтен камераны берничә вакыт хакыйкатьтән ераклаштырды. Шаркылдап көлү тавышлары яңгырады: Куропаткин, Стессельләр, белмим кемнәр, тиешле җәзасын яхшы гына ала иде.

Бөтен мәхбәс китәчәкләрне озатырга җыенды. Бүлмәдә киеренке, тәэсирне көчәйткән тавышлы дулкынлану бар. Зинданчының кисәтүләренә һичкем колак салмый. Ниһаять, аерылачак вакыт килде. Аһ, бу тетрәткеч минутлар! Әүвәл юрист аркадашы доктор илә кочаклашып, самими үбеште. Алар тавышсыз елады, күзләреннән эре-эре яшь тамчылары акты. Соңыннан һәммәбез кочаклаштык, үбештек, елаштык. Бу арада авыр, тирән тавыш белән "Вечная память" җырланды.. Аерылышуның ахырында көчле тавышлар "Марсельеза"ны башлады, бүлмәне яңгыратты. "Якында күрешербез..." — дигән өмидле елмаеп, ишек төбендә җыелган мәхбүсләр, тавышларын көчәйтеп, тынычландырып вә юатып кычкыралар иде:

> Отречемся от старого мира,
> Отряхнем его прах с наших ног..

**30 март.**

Гомумән бер язгы гасаби төн. Белмим нинди юллар белән бөтен төрмәгә гомуми гафу итү хәбәре таралды. Кичен, сәгать унны сукканда назирларда, мәэмүрләрдә хәрәкәт: генерал-губернатор киләчәк. Димәк, асылда генерал-губернатор азат итәчәк.

Тәшвишләнеп көтеп тору. Һичкем тынлыкны сакламый, һичкем күнегелгән йомышы белән шөгыльләнми; сабырсызлык, гасаби, гайре табигый күренеш, сөйләшүләр, аһәңсез җырлар, хәрәкәт вә гөрелте.

Докторның тавышы:

— Азат итү башланды. Страхатоновны чакырдылар.

Бөтен камераның йөрәге тибә... Берничә минут үткәч, янә гөрелте, янә аһәнсез җырлар, сүзләр.

Ишек авыр, авыр ачыла. Зинданчы дәрт белән кычкыра:

— Смирнов! Хәзерләнегез, азат ителәсез.

Аркадаш саубуллашуны онытыбрак, бер минут эчендә әйберләрен җыеп, камера ишегеннән атыла. Димәк, чын. Азат итәләр. Мине дәме? Ләкин һәрвакыт пессимизмга бирелүче мием инанмый. Шуның белән бергә йөрәгем тибрәнә, башымнан кан кача, тезләрем куәтсезләнә. Карлыккан тавыш белән сорыйм:

— Гафу, гомумиме?

— Юк... Белмим.

Өмидсезлек, газаплы уй: инсаннар инсаннарны иза итү юлын ничек яхшы беләләр, моның өчен ниләр генә иҗат итмиләр! Берникадәр онытылган хөррият берничә минутка күренде, ышандырды, соңыннан очты, юк булды, янә тоткынлыкта калган рухларны җәһәннәм газапларына дучар итте. Ләкин азат итү дәвам итә: менә Алексеев, менә Гассар — бәхетсез йомшак калеб, ул чынлап та яшь, даимән гаиләсе өчен кайгыра. Менә, ниһаять, әлфикер Зеленский."

*Сергей Николаевич Гассар Крестовников районында социал-демократлар партиясен оештыручы һәм актив эшлеклесе иде. 4 мартта аның йортында тенту ясыйлар һәм үзен кулга алалар. Тенту вакытында тыелган берничә брошюра һәм прокламация тапканнар. Алай да җитәрлек компромат таба алмыйлар, шуңа күрә артык озак тотмыйча, төрмәдән чыгаралар.*

*Кызганычка каршы, аның турында Й. Акчура тәфсилләп язмаган яки язып та, цензура үткәрмәгәндер. Сыйнфый көрәш теориясе буенча, Акчура белән Гассар ике капма-каршы полюста торалар кебек. Араларында мосахәбәләр булган булса да, Гассар, уйлавыбызча, артык сүз ычкындырмаган булса кирәк, чөнки камерада провокатор булу ихтималын да истә тоткандыр.*

**"1 апрель.**

Җомга намазларын мәхбәс иманы белән кылырга рөхсәт бирделәр. Гыйбадәтебездән соң имам әфәнде мине юатырга тотынды:

— Аянычка каршы, бөек затлар хәбәс булганнар: хәзрәт Йосыф, имам Әгъзам...

Минем бу юатуга җаным чыкрана: мин баламыни? Сүзен бүлдем:

— Һич әһәмияте юк.

Ул көннән бирле өч атна үтте, дәвам иткән әсирлектән туган газаплануга әүвәлге көнгә яз газабы да кушылып, һәммәбезнен түземлеген какшатты.

Бу кыска газап бөтен табынган данны изәргә, инсанны нәфисенә гайре вөҗүд алдында тез чүктерергә сәләтле булыр!

Янә җомга иде. Имамның вәгазен әһәмият илә тыңладым. Бу минем өчен бик югары! Кечкенә, бик кечкенә тырышлыгым. Кешелек дөньясының иң бөек инкыйлабларыннан хәрәкәт итүче берсенә юнәлдерелгән изге сүзләр белән юатылудан, бу илаһи сүзләрне тыңлаудан мин бер инсафлы сәмави зәвык казандым.

... Ишек ачылды. Ихтыярлы мәхбәс хезмәтчесе кулында гүзәл чәчәкләр бәйләмен күрсәтте:

— Акчуринга!

Сөмбел, миләүшә, энҗе чәчәге. Нинди нәфислек, нинди ис!

Ашыгып сорадым:

— Кемнән?

— Бер ханым-кыз китерде. Исемен әйтмәде.

Зинданны бер нур тутырды. Инде бөтен җиһан сәмави, саф букеттан гыйбарәт. Бәйләм яшел яфраклар арасында яшь, ак, хуш исле чәчәкләр илә бер матур яз иртәсендә яшел бакчага чыккан бер яшь кызны — "аны" — күз алдыма китерә.

Золымнан, һәрнәрсәдән өстен булган нур!

**2 апрель.**

Нурлы якшәмбе рәшәле киләчәгебездә парлак бер өмид ноктасы иде. Җитештек, сүнде.

Аһ, нинди хыянәтче бер мыскыллау! Бөтен Русия шатланган вә котылу илә сөендереп тәбрик иткән бу көнне хөкүмәт мәхбүсләрдән берсен Якутскида биш елга тереклек итәргә хөкем ителгәнен хәбәр итте. Якутск... Сибириянең мәңге карлар илә кәфенләнгән бу каберлек, әче суык дөнья. Анда сөрелү һәлак итүгә хөкем ителү димәк.

**8 апрель.**

Без төрмәдә. Ләкин һәркем дә мәхбүс түгелме? Зинданчыларга карыйм: һәр көн тулысынча эш. Безгә бу урын, бу хәят, әлбәттә, вакытлыча. Ләкин алар мәңгелек моңа хөкем ителгән! Без кичләрен пәрвайсыз, ял итәбез; алар һәр унбиш минутта сәгатьләрен карарга, йокламауларын исбат итәргә мәҗбүр.

Алар гынамы мәхбүс? Хәер! Менә бер эшче, менә бер мәэмүр, менә сәүдәгәр, сәнгатькяр — һәммәсе: бае, җаһиле, галиме бу дөньяда билгеләнгән, чикле. Шуңа күрә богауланган вә әсир тормыш алып барырга хөкем ителгән. Хөррият! Коры бер сүз, татлы бер хыял"

*Ни булган? Зиндан аркасында гына туганмы бу фәлсәфи фикерләр? Аларны чынга алсак, Й. Акчура бөтен киләчәген өметсезлек төтененә төргән була түгелме? Белгәнебезчә, төрмәдән чыккач, Акчура кул кушырып ятмаган, эшчәнлеген дәвам иткән. Алайса, ул фикерләр очраклы рәвештә генә әйтелгән булганмы? Минемчә, Й. Акчура заманның, Россия тарихының трагик язмышы дәвамлылыгын, мондый хәлләрнең озакка сузылачагын тоемлый. Ахирәттә, җиһанда исә яз, чәчәкле, иҗат итүче яз. Дөньяда — мәхәббәт, самими дуслык, өметләнү, күз яшьләре, җыр, китап... Бу чын бәхет, ләззәтләнү, сөенү. Ләкин, диалектик фикерләүче буларак Й. Акчура хәрәкәтнең, үсешнең каршылыклы булуын аңлый башлый, француз позитивистлары карашларыннан арына бара. Ә нигә соң төрле караштагы кешеләр, уртак бәхетсезлеккә таргач — дуслашалар, "коммуна" төзиләр, "конституция" кануннары буенча яшиләр? Нигә алар башка вакытта, башларына тай типкәндәй, низаглашалар, Россиянең киң җирләрендә яшәп, ник татулаша алмыйлар? Андый сорауларга дөньяның кайбер даһиләре җавап биргәннәр. Мәсәлән, Лев Толстой үзенең "Сугыш һәм солых" исемле романында. Сәбәп шул ук, Й. Акчура әйткән уртак бәхетсезлек. Башкача әйткәндә, дөньяның "экологик система"сы җимерелүеннән курку. Чөнки экология — гомуми тормыш, гомуми язмыш. Толстой сүзләре белән әйткәндә, "роевая жизнь человечества" ул. Менә шул уртак фикер кешеләр аңына сеңсә, дөнья исән-имин яшәячәк.*

**9 апрель.**

Көннең кичкә авышкан вакыты инсанга даимән тәэсир итә. Гомеребезнең бер көне югала, аның кире кайтуына ышану мөмкин түгел. Билгесез дулкынлану белән кайгыга төшәсең. Кичерелгән хәятның монда катнашуы да әһәмиятле. Бушлык, тавышсызлык; һичбер өндәүче хәят юк; бөтен манзара кайгыга баткан вә мәрхәмәтсез!

**15 апрель.**

Кичә вилаять сайлаулары иде. Уникесендә Алкинның вә ике мөселманның сайлавы буласы хәбәре бу йозаклы ишекләрдән, калын диварлардан үтеп безгә ирешә алды, ләкин һәнүз әлегә нәтиҗәләрен белмибез.

Инде ишеттек: сайландылар. Шул андагы вакыйгага анализ итә алуыма вә аңлата беләчәгемә инанам. Сөенәмме? Шөбһәсез. Хәлбуки кичә Алкин сайланды. Вә бу алмашынуга бәлки минем дә кечкенә генә хезмәтем тигәндер."

Сәетгәрәй мирза Шәһиәхмәт улы Алкин Акчураның көрәштәше, фикердәше. Аның турында "Вакыт" гәзите болай дип язган:

*"Сәламәт вөҗүдле, гүзәл кыяфәтле, нәзек табигатьле, гүзәл әхлаклы, гаять рухлы бер адәм. Казанда туды вә Казанның 3 нче гимназиясендә укыды. Казан*

*университетында юридик факультетта укыды. Гимназиядә укыган вакытта мәрхүм Шиһаб хәзрәт мәдрәсәсенә йөреп, мөселманча дәрес алды. Казанда судебный должностька кандидат булып торды. Соңыннан, 1896 нчы елда Казан Судебная палатасы округында мәшһүр присяжный поверенный Орловның вафатыннан соң, үзе присяжный поверенный булды. Ләкин ул вакытларда мөселманнарга, гәрчә тәртибе белән хокук дәресләрен укып диплом алсалар да, турыдан-туры присяжный поверенный булырга низам юклыгыннан, министрдан махсус рөхсәт алырга лазим иде. Алкинга да шулай рөхсәт ителде... Сәетгәрәй мирза Казан шәһәрендә шәһәр думасында өченче мәртәбә гласный булып тора, шәһәрнең мәктәпләр комиссиясендә әгъза, Казанның татар дарелмөгаллимин мәктәбендә попечитель... 1905 нче елда ноябрьдә Казанда "Казан мөхбире" исемендә татар телендә гүзәл бер газета чыгарыла башлады. "Русия мөселманнары иттифакы" әгъзасы. Шуның белән бергә Казанда мөселманнар арасында сәяси фикер таралуына вә к. — демократ программасының җәелүенә күп хезмәт итте. 1906 нчы елда Петербергтагы гомуми Русия мөселманнары җәмгыятендә булып, фикер вә каләм белән хезмәт күрсәтте. Министр Дурновога, граф Виттега керүчеләр вә иң башлап сөйләшүчеләрнең беренчесе шул Сәетгәрәй мирза Алкин иде. Бу мирзаның Мамадыш өязендә үз милке булган туфрагы бар. Аграрный һәм национальный мәсьәләләрдә фикере тәмам хөррият яклы булып, крестьяннарга җирле һич тәукыйфсез тиешле урыннардан, хәтта җәберләп булса да алып бирү тарафында. "(Вакыт. — 1906. — 23 апрель).*

**16 апрель.**

Бүген вилаять сайлауларының нәтиҗәләре тәмам беленде: өч мөселман, биш кадет; иртәгә шәһәр сайлаулары, анда да ничек кенә булмасын, йә мөселман, йә кадет.

Казан вилаяте мөселманнарын мактап сөйләргә булсын, хакларын яклый белделәр.

Бүген сайлаулар беткән өчен һәркем минем чыгарылачагымны көтеп тора иде.

— Хәзерләнегез.

Мин ашыкмадым, чынаягымдагы чәйне бетердем, аркадашлар белән саубуллаштым. Ул өч йозаклы авыр ишектән, ниһаять, чыгардылар.

Матур язның ягымлы, якты бер көне... Таш түшәлгән урамда ак, нәфис киемнәр илә, зонтиклар илә ханымнар, ханым-кызлар. Инде миңа һәрнәрсә, бөтен Казан гүзәл вә көлемсерәүче кебек күренә... Бүлмәмә дуслар тулды. Тәбрикләр, чәй, сөенеч. Ахшамда депутатлар шәрәфенә кунак итү. Мине дә чакырдылар. Нотыклар, тәбрикләр, тостлар... Анда миңа да хитаб булды, гүя бу көнге кадет мөселман җиңүенә минем дә тырышлыгым өстенлек алды."

*Й. Акчура хатирәләре аерым парча булып күренсә дә, чынлыкта алар катлаулы тарихи бер дәвер панорамасын фактлар һәм үзенчәлекле аһәң, төсмерләү, настроение белән тулыландырырга ярдәм итә. Әлегә кадәр безнең тикшеренүчеләребез күбесенчә фактларны өйрәнде. Кем әйтмешли, "факты — вещь упрямая". Ләкин, минем фикеремчә, алгы планда шәхес торырга тиеш. Аның уй-фикерләрен, кичерешләрен, сөенүләрен, көенүләрен тоймыйча, без тарихны аңламаячакбыз. Ә коры саннар, даталар, схемалар — болар гына бик аз!*

*Тагын бер мәсьәлә. Гомеренең күп өлешен Й. Акчура Төркиядә уздырган, анда хезмәт иткән. Бу аның татарлыгына тискәре йогынты ясамаганмы? Без моны тарихчыларга калдырабыз. Һәрхәлдә, Россия халыклары язмышында текә борылыш ясаган революция чорында Йосыф Акчура ил белән бергә булды. Менә шул барысын да аңлата дип уйлыйм.*

## Гурий Тавлин

# КУШАМАТЛЫ — ЮГАЛМАС

***З**әй төбәге керәшеннәре арасында кушаматы юк кешене очратуы кыен. Кушамат кешегә исеме белән бергә үк тагылып, аны башкалардан аеру хезмәтен үти. Мисалга мин үз исемемне генә алам. Гаиләләр саны йөздән аз гына арткан уртача зурлыктагы Урта Баграж авылында без сигез Гурий идек. Безне бер-беребез белән бутамас өчен, барыбызның да тик үзенә генә туры килгән кушаматы бар иде. Җәбрәй Гурие — киң маңгайлы, вак бөдрә чәчле, җор сүзле, бераз сакаурак, Җәрми Гуриенең әтисе Ермолай исемле, Телсез Гурие — әтисе бер сүз дә әйтә белмәүче Петр исемле чукрак-телсез кешенең улы, Мәтүн Гуриенең әнисе Матрена исемле, Сталин Гурий — юлбашчыга нәрсәсе беләндер охшаганга, Ибрай Гуриеның кушаматы адашыма нигә кушылганын әйтә алмыйм, Мучий Гурие һәм үзем Мулла Гурий — гарәп хәрефләре белән язылган иске китапларны җыйганга, кайбер аятьләрне, догаларны, Корьән сүрәләрен яттан белгәнгә такканнар иде миңа ул кушаматны. Ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар да кушаматтан мәхрүм түгел бездә. Мәсәлән, Сандыр Угәпие, Бүси Мариясы, Куыш Пидучиа, Илләй Тайсыясы, Луп Начтугы, Учыкай Барбарасы һ.б.*

### Буаз Микайла

Ул бик мут, кулы бер дә тик тормый, кайда ни очратса да, үзләштерми калмый торган Көҗи Микайласы (Михаил Кузьмин) дигән бәндә иде. Аның бер генә күңел биреп яратып эшләгән эше дә юк иде. Берара колхозда аны атлар карарга куйдылар. Шуннан соң авылда, Микайла төннәрен атларга ашатасы фуражны аз-азлап өенә ташый икән, дигән сүзләр таралды. Әмма мутлыкта дан алган агайны җинаяте өстендә тотучы булмады.

Озак үлекләгән шеш уйламаганда тишелде. Авылның Югары очында акылга зәгыйфь Митрофан исемле мәхлук бар, ул гомере буе бармакка бармак та сукмыйча көннәр буе йокы симертеп, төннәрен авыл буйлап буталып йөрергә ярата иде. Бер төнне ул таң алдыннан колхозның атлар дворыннан өстендәге кожаны астына муенына, корсагы турысына авыр капчык асып, өенә кайтып баручы мут агайны очратып:

— Микайла дәдәй, син нишләп юанайдың, буазландыңмы әллә? — дип сораган.

— Кара, өстенә бастың бит, парин, буазландым шул. Сизеләмени? — дигән җавап ишеткән тилемсә.

Митрофан:

— Алдыйсың, мин беләм, ирләр буазланмый, — дигән.

— Буазлана икән, парин. Мин колхозыбыз бияләренә яз көне (үзең дә карап тордың) айгыр сикерттем бит, шуның шомлыгыдыр, дим, буазлануымны...

Җүләр Митрофан көлеп әйткән:

— Алайса, моннан соң Көҗи Микайласы димәсләр, Буаз Микайла диярләр инде сине.

— Теленә салынма, дурак, — дигән мут агай.

— Мин дурак булсам да, буаз түгел, ә син буаз! Буаз! —дип, урамны сасыткан тилемсә.

## Бәла Питер

Питер — әнисе безнең авылдагы бер тол иргә кияүгә чыкканда мәһәр булып ияреп килгән күрше авылда туган малай иде. Безнең авыл малайлары аны баштук үз итмиләр. Беренче көннән үк аңа кимсетүле Бүтәкә кушаматы тагалар. Кордашларының үзен чит итүләренә Питерның исе китми, ул рәхәтләнеп үз урамнарында үсүче кызлар белән аралаша. Бүтәкә "борчак чәчәргә" — алдашырга оста, сөйли башласа, тыңлаучыларын авызына карата. Әнисе аны бирәүдән дә кыерсыттырмаска тырышып, иркә үстерә. Питр башлангыч мәктәпнең һәр классында икешәр ел утырып, хәреф танырга өйрәнгәч, кулына бүтән беркайчан да китап тотмый. Теге, алма пеш — авызыма төш, дип, алмагач астында алмаларны өзеп алырга иренгән хөрәсәннәрдән дә эшлексезрәк ата ялкау булып үсә. Борыны астында мыек төкләре күренә башлагач, ул кая гына барса да, кәләш ияртеп кайта торган була. Ишле гаиләләрендә, Питернең биш сеңлесе булып, артык кашык өстәлү аның әнисенә дә, үги әтисенә дә ошамый. Яшь кияү, ияртеп кайткан кәләше белән биш-алты көн юангач, аңа: "Җанашым, бездә, үзең күрәсең, кысан, иркенләп сулыш та алырлык түгел. Берәзга син өегезгә кайтып тор әле, әзрәк баш-күз алгач, мунчабызны торырлык итеп рәтләгәч, янадан барып алырмын сине, борчылма", — дип озатып җибәрә дә, ике-өч көннән яңа чәчбине ияртеп кайта. Шулай башлы-күзле булулары чамадан ашкач, әнисе аны:

— Бармакка чорнарлык та акылың юкмыни соң синең? Урамга чыгарлыгыбызны калдырмадың бит инде бу өйләнүләрең белән, и бала, бала, дип сукранганда, үги әтисенең:

— Синең, бала-бала, дигәнең бала түгел, чын бәла ул! — дигәнен кемдер ишетеп кала. Шуннан соң кинәт кенә Питернең Бүтәкә кушаматы Бәлагә алышына.

Тасма телле, эш сөймәс Питернең әллә ничә авылда әллә ничә баласы ятим үсте. Ул аларның берсенә дә алимент түләмәде. Ахырда Казанга китеп, андагы кирпеч заводында эшләүче бер чая хатынга йортка керде. Ирләр иркәсенә сусаган хатыны Питерга азып-тузып йөрергә ирек куймады, аңа ел саен бәбәй бүләк итеп койрыгын бозга катырды. Питер балаларын авылдагы сеңелләренә кайтарып ташлый торды, аларны сеңелләре үстерде. Ул балалар хәзер кайда, кемнәр, әйтә алмыйм. Питер үзе Казанда эшләгәндә өсте капкачсыз бетон болгаткычка мәтәлеп төшеп, җан тәслим кылды, диделәр. Тәзелеш җитәкчеләре күтмәгәндә бәлагә тарыган бәхетсез эшчесен матәм музыкасы уйнатып, зурлап җирләгән. Якыннары өчен гомере буена бәла булып җан асраган Питернең тормышы шулай бәлалеккә хыянәт итми чикләнгән.

## Папукай Пауал

Папугай түгел, Папукай. Ошбу кушамат аңа юып та арынып булмый торган кара тап кебек ябышты. Павел кеше ирештерергә, кемдер булып, аның сүзләрен үртәп кабатларга үтә хирыс иде. Булдыклы, унган егет иде үзе. Сугыштан офицер булып, түшен орденнар һәм медальләр белән бизәп, татарчасын "онытып" кайтты. Янәсе, ул инде ул түгел, бөтенләй башка кешегә әверелгән. Өйләренә кайтып бусагаларын атлап кергәч, аны күрү шатлыгыннан телсез калган әнисе белән уң кулын хәрбиләрчә чигәсенә терәп:

— Здравье желаю, анайка! — дип сәламләгән.

Әнисе аның сүзләрен аңламыйча:

— Пауал, син түгелме соң бу? Тилердеңме әллә, минем белән урысча сүләшәсең, оял. Ник үзебезчә сүләшмисең? — ди икән.

— Мин татарша белмас, унытқан, — дигән улы.

— Алай икән! Әллә малай чагыңдагы күк табагач алып җилкәңә сыдырганымны көтәсеңме? Мин синең түшеңә бакыр тәңкәләр тезеп кайтуыңа

карамам, сөякләренне сындырырлык итеп сыларммын! — дигән анасы ярсып.

— Кыйнамассың, анайка, мин бальшуй хәзер, прежней Папукай түгел, вот күр, мин — офицер! — дип, Павел әнисенә уң кулы белән инендәге сул погонын чәбәкләп күрсәткән.

— Булшуймы, бот буемы — әллә нәстәләрен күрсәтмә миңа. Сугышта атаңны очраткан булсаң, шуны әйт тә, урысларың жанына, артыңа борылып та карамыйча, китеп бар. Минем монда кеше көлкесе булып жөрүеңне күрәсем килми!

Әнисенең битләре буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен күрү Павелга "оныткан" татарчасын бик тиз исенә төшертә. Ул:

— Жылама, әни, сугышта мин әтине очратмадым, арам да булмады, жай да чыкмады, ачуланма. Кил әле, әйбәтләп күрешик, — дип әнисен кочып, күкрәгенә кыса.

Павел инде дөньяда юк. Ул күп еллар район үзәгендә жаваплы урыннарда эшләде. Жай чыкканда үзеннән көлеп, һич тартынмыйча, сугыштан татарчасын "онытып" кайткач, әнисенең чак кына табагач белән сыртын каезламый калдырганын искә алырга ярата иде.

## Урыс Симун

Ул безнең авылга бер маржа хәер эстәргә килгәч, икеме-өчме яшьтә чакта бала-чагалары булмаган гаиләгә уллыкка биреп калдырган кеше иде. Әнисе маржа булса да, керәшеннәр арасында үскәч, үз телен белми иде Симун. Аны уллыкка алган Аксак Микулай якын тирәдә дан тоткан оста тегүче иде, әмма Симун аның һөнәрен үзләштермәде, чабата тукуны яшьтән үк бөтән барлык һөнәрләрдән өстен күрде. Ул чабаталарны төрле фасонда — жиде юкәдән дә, тугыз юкәдән дә, башларын мөгезле итеп тә, түгәрәкләп тә, башмак рәвешле итеп тә үрә иде. Кемгә ниндирәк чабата кирәк, шундыйны: чуашларга — чуаш, мукшыларга — мукшы, урысларга — урыс, татарларга —татар, керәшеннәргә — керәшен, яшьләргә — яшьләр, хатын-кызларга — хатын-кызлар, картларга картлар чабаталары тукый һәм һәр атнаны Биш авылында (Түбән Биштә) була торган кечатна (пәнжешәмбе) базарына чабаталарын сатарга бара иде. Симун ясаган чабаталар ипле дә, жинел дә, матур да булалар, аларны ир-атлар да, хатын-кызлар да теләп алалар һәм яратып кияләр иде.

Бервакыт мин Симунның, базардан чабаталарын сатып кайткач, авылдашларыбызга:

— Мин бүген бер знакумымны кунакка килергә чакырып кайттым әле, — дип мактанганын ишеттем.

— Ул знакумың кем соң синең, урысмы, татармы дигәндәй? Нинди телдә сөйләштегез? — диде аңа бер агай.

— Чеп-чи урыс телендә. Мин, үзегез беләсез, урыс бит. Сез керәшеннәр арасында үссәм дә, ипилек-тозлык беләм урысчамны. Знакумыма мин безнең авылга ничек киләсен әйбәтләп аңлаттым. Син башта тал-талларны чыккач, умираллар буеннан үтәрсең, аннары тәбәнәк кенә кеңгелдекне төшкәч, безнең дум булыр, миңа гүскә кил, дидем. Аңа бушка бер кием чабатамны да биргәч, син дә урыс, мин дә урыс, жөрешик, дидем. Знакумым куанычыннан авызын колагына кадәр жырып, шпашиба, диде.

— Урысыңны аларча кунакка чакырганыңны үз сүзләребез белән дә аңлат инде син безгә, Симун. Тал-таллар, умираллар, кеңгелдек, дум дигәннәрен керәшенчәгә күчергәч, ничек була?

— Истә калдырыгыз: тал-таллары — урман, умираллары — зират, кеңгелдеге — таучык, думы — авыл. Мин знакумыма юл өйрәтеп, урманны чыгып, зират буеннан үткәч, тәбәнәк кенә тау астында безнең авыл булыр, дидем. Знакумым сөенеченнән күзләрен ялтыратып, карашу, диде. Юл өйрәтүемне бөтән кабатлаттырмады.

Авылда чабатачы Симунга кунакка ниндидер урыс килгәнен телгә алучы булмады. Килсә, андый яңалык телгә керми калмас иде. Урыс Симун гомере буе

чабаталар үреп яшәде, киң күңелле, бик юмарт кеше иде ул. Җәйләрен без — малайларны җимеш бакчасына алып кереп чия, крыжовник, кура җиләге, алма белән сыйлый иде. Ул сугышка киткәч, авылга бүтән әйләнеп кайтмады, үлгән хәбәре дә килмәде, юкка чыкты.

## "Әгаләм карабы"

Пәпәй Җәпиме (Ефим) хатыны Начтук белән иртән радиодан яңалыклар тыңлап, гадәтенчә чәй эчеп утыра. Радио:

— ... Русия космонавтикасы тагын бер зур уңышка иреште. Кичә Мәскәү вакыты белән 22 сәгать 37 минутта яңа Галәм корабы орбитага чыкты, дигән сүзләрне ишеткәч, йорт хуҗасы телен шартлатып:

— Татар урыслар ише дә, без бөтен нәстәдән коры калган кара керәшеннәр күк тә түгел, башлы, Алла биргәнне бәндәдән җәшерә алмыйсың, бик тә башлы, — ди.

— Нишләп син, сүз җугында сүз булсын, ата казың күкәй саламы, кодагый, дигәндәй, өч тиенлек акылы да калмаган карчык күк сүләнәсең, карт? — ди аңа хатыны гаҗәпсенеп.

— Колагың тулы чүбек булмаса ишеткәнсең, Әгаләм карабы орбитыга чыкты, диделәр бит. Моңынчы аны кем җасаганын әйтмиләр, космик караб дию белән чикләнәләрие, бөген түзмәделәр, шар жарып бөтен дөнҗага Әгаләм карабы, диделәр. Карабны кем җасаганны алда да әйтми җәшереп маташсагыз, дуңгызлыгыгызны дөнҗага фаш итмәсәм, татарлыгым корсын, дип, тавыш куптарып, катгый таләп куйгандыр Әгаләм урысларга. Татар — башлы, үҗәт, тешләгән жирен өзеп чыгармый тынычланмый ул. Маладис!

— Болай булгач, Айга да менә инде татарлар.

— Менәләр, Начтук, әбәзәтелне менми калмыйлар, — ди карты. — Хәзер аңа минем гүпче шигем юк. Беләсе ие, кайсы тирәнеке икән ул Әгаләм? Мужыт Бистубашы тумасы, теге, "Зәйдән без!" — дип, күкрәк төеп мактанучы Әгламдер ул? Районн гәзитен безнең авыллаш Абрый Ибаны чыгара, шуңа әле генә космоска чыккан карабны кем җасаганын сорап хат җазыйм әле, ул тучнысын беләдер, белми калмас...

## Җегерме колак

Бу сәер кушаматны Гүргигә (Георгийга) булачак классташлары мәктәп бусагасын тәүге кат атлап кереп, парталар артына беренче тапкыр кунаклаган көннәрендә үк тагалар. Укытучылары үз классына җыелган балаларның аң дәрәҗәләрен, тапкырлыкларын, зирәклекләрен, сизгерлекләрен тикшерә башлый. Ул, укучыларын берәм-берәм бастырып, аларның әти-әниләре, кайда торулары, гаиләләрендә ничә кеше барлыгы һәм башка нәрсәләр турында сораша. Булачак шәкертләре аңа төрлесе төрлечә, кайсылары чатнатып, кайсылары тартынып авырлык белән генә җавап бирәләр. Укытучы сорауларын еш кына юри буташтыра, әле тиз уйларга күнекмәгән сабыйларның күпчелеге югалып калалар.

— Синең күзләрең ничәү?

— Кулларың ничә?

— Бер кулыңда синең ничә бармагың бар?

— Ике кулыңда ничә бармак?

Чират Гүргигә җитә. Ул укытучының барлык сорауларына ашыкмыйча төгәл җавап бирә.

— Син аякларыңдагы һәм кулларыңдагы бармакларыңның ничә икәнен беләсеңме? — ди укытучы.

Малай бу сорауга тиз генә җавап бирми, күңеленнән саный. Укытучы аның җавабын артык көтми.

— Синең ничә колагың бар? — ди.

Бармакларын санау белән мавыккан Гүрги, җилел сулап:

— Җегерме, — ди.

— Колакларың җегермеме? — ди укытучы.

— Әй лә, җук, колакларым түгел, аякларым белән кулларымдагы бармаклар җегерме, колакларым ике генә, — дип, ялгышын төзәтә Гүрги, ләкин класстагы малайларның берсе шаркылдап:

— Җегерме колак, — дип шәрран яра.

Георгий бертуган энесе Михаилга да искәрмәстән кушамат таккан иде. Алар абыйлы-энеле авылдагы тегермән буасында көн дә балык каптыралар. Михаил хыялый малай, һәр шөгыльнең ахыры нәрсәгә тәрәләсен күзалларга, уйларга тырыша торган үҗәт малай иде. Буа буена төшкәндә ул һәрвакыт тоткан балыкларын нишләтәселәрен кайгыртып, балыклар эләксә..., дип, үзалдына мыгырдарга күнеккән иде.

Бер көнне шулай мыгырдана башлагач, абыйсы Георгий аңа:

— Җитәр, туйдым ләтчәләнүеннән, саруымны кайнатмый гына атла әле, — ди ачуланып.

Абый кешенең энесен шулай ачулануын кемдер ишеткән, күрәсең. Михаилга шул көннән Ләтчә кушаматы тигәнәк кебек ябыша.

Абыйлы-энеле ул егетләр икесе дә сугышта башларын салдылар. Алар әле кызларга гыйшык тотарга да өлгермәгәннәр иде шикелле. Аларның истәлекләре булып авылда сәер кушаматлары гына сакланып калды.

## Шайтан Гәверлә

Шайтан кушаматы Гәверләгә кино карарга баргач, суфлер будкасында йоклап калганнан соң бирелде. Клубта кино ул кичне, үч иткән кебек, тиз генә башланмады. Ярым буш клубта үсмер Гәверлә нишләргә белми буталып йөргәч, сәхнәгә менеп, суфлер будкасына кереп утыра да йокыга китә. Кино башлангач та уянмый, тәмләп борын сызгырта. Ул чакта авылларда электр юк, тавышлы кинолар күрсәтелмиләр иде әле, кинопроекторны эшләтергә токны гади эскәмиягә вакытлыча беркетелгән кечкенә динамомашинаны тамашачылардан чиратлап әйләндертеп алалар, клубта кино караучыларны бимазаларлык чит-ят тавышлар булмый иде.

Кино бетә, тамашачылар барысы да өйләренә таралалар. Клуб мөдире тамаша залы хезмәтен үтәгән амбарның эчен тикшереп тормый, ишегенә йозак салып, өенә кайтып китә. Гәверлә берни сизми, суфлер будкасында тәмләп йоклап кала. Кинәт бер мәлне ул нәрсәнеңдер ипле генә мерелдәвенә һәм битенә ниндидер йомшак нәрсәнең кагылуына күзләрен ача, дөм караңгылыктан башка нәрсә күрми. Шулчак аякларына басарга теләп кинәт күтәрелгәч, башын бик нык бәрә. Ул башы бәрелде дип түгел, аңа кемдер китереп орды дип уйлый һәм караңгылык эчендә ике яшькелт ут күреп, акырырга тотына. Гәверлә мәченең күзләре караңгыда ялтырганын белми. Кармалана, кулларын як-ягына да, артына да шудыра, алар һәр якта шома өслеккә тияләр, ә алды — буш... сандыкта бит ул!.. Аны монда кем салган, кем?.. Гәверлә елый-елый акырып, мүкәләп сәхнә буйлап барганда башы белән стенага бәрелә. Аннары сәхнә читеннән залга мәтәлеп, ниндидер эскәмиягә юлыга. Чү, клубта түгелме соң ул? Менә тагын бер эскәмия. Тагын...

Гәверлә, акырудан кинәт туктап, ишекне эзләп китә. Таба, ләкин ача алмый, ишек бикле. Ул төнне тынчу амбар эчендә ялгызы үткәрергә теләми, бөтен авылны дәррәү аякка бастырырлык итеп тимер ишекне әйләнә-тирәсендәге эскәмияләрнең берсе белән дан-дан кагып, сөрән салуын дәвам итә.

Күпмедер үткәч, урам каравылларга чыккан ике хатын клуб янына киләләр.

— Акырудан тукта, кем син? — ди хатыннарның берсе.

Гәверлә аңа ничек җавап бирергә белми.

Хатыннарның икенчесе:

— Төн уртасында клубта шайтаннан бүтән кем акырсын, шайтандыр?.. — ди, як-ягына каранып.

— Җук, мин шайтан түгел, Кәпит Гәверләсе, — дигән тавыш ишетелә ишек аша. — Алла хакы өчен коткарыгыз мине! Гомерем буе онытмам яхшылыгыгызны...

Хатыннар клуб мөдирен эзләп китәләр. Гәверлә елый-елый сөрән салуын

дәвам итә. Клубтан аны таң алдыннан гына коткаралар. Шуннан соң ул Шайтан Гәверлә дип йөртелә башлый, киногa йөрүен бөтенләй ташлый.

## Кар өсләп торна куган Филип

Безнең күршебездә Филип исемле, кулыннан теләсә нинди эш килә торган бер агай яши иде. Ул үзе ясаган скрипкада уйный, гармунын тарта, җырлый да белә иде. Анын "Укор купис" дигән урысча җыруы минем әле дә колагымнан китми. Филип дәдәйнең урысчасы ни дәрәҗәдә камил булганын тикшерерлек, аны бәяләрлек түгел идем әле. Бервакыт ул скрипкасына кыл эзләп, Чаллыга барган. Шуны сөйләгәнә төгәл хәтеремдә. Чаллының үзәк урамындагы бер кибеттән икенчесенә кереп йөри-йөри туя бу. Шунда моңа ике егет очрый.

— Менә бу агайның бер аягында алты бармак икәнен минем үземнең күргәнем бар, — ди егетләрнең берсе, Филип дәдәйгә күрсәтеп.

— Тукта әле, агай, синең бер аягыңда алты бармак бит, дөресме? — ди аңа егетләрнең Шәриф исемлесе.

— Жук, биш кенә, — ди аңа Филип.

— Чишенеп күрсәтми ышанмый инде ул, — ди Шәриф. — Әйдә, чишен инде алайса аягыңны.

Берәү булса, егетләр, юкка баш катырмагыз, юлыгызда булыгыз, дияр иде, Филип агай андый түгел, тротуарга утыра да аягын чишенә:

— Менә санагыз, алтымы? — ди.

— Алайса, теге аягыңда алты бармак инде, — ди аңа Габделхәй дигәне.

— Анысында да бишәү генә! — дип каршы килә Филип. Ләкин тегеләр үзләренекен итәләр. Филип агай чишенә аякларын. Шул чакны егетләрнең Габделхәй дигәне аның чабаталарын, чолгауларын эләктереп, урамның икенче ягына чаба.

— Менә чолгауларың, чабаталарыңнан да коры калдың, — ди Шәриф дигән егет. — Чап тизрәк артыннан7

— Әй, тукта, без алай килешмәдек бит, бир чабаталарымны! — дип йөгерә аның артыннан Филип дәдәй. Теге исә кулындагы чолгаулар һәм чабаталарны җиргә ташлап, артта калган иптәшен көтә башлый. Безнең агай аяк киемнәрен шулай җиңел генә кулга төшерүенә шатланып, аякларын киенергә утыра. Егетләр аның янындан:

— Җүләрлегеңне дөньяга күрсәтеп йөрмә бүтәнчә, — дип, узып китәләр.

## Кылый Илҗә

Безнең авылда атсыз калудан куркып, колхозга кермичә аерым хуҗалык булып яшәүче Кылый Илҗә бар иде. Ул данлы Чапаев дивизиясендә акларга каршы сугышкан кеше иде. Бер көнне Илҗә дәдәйне ашыгыч рәвештә Зәйгә, район үзәгенә чакыралар. Бара бу, аты үшән, көчкә барып җитәләр. Зәй белән Түбән авыл арасы 10 чакрым җир, яхшы атта җилдереп кайтып җитеп була, кайгырмый Илҗә дәдәй. Кайтырга чыгалар, авылга җитәргә ике-өч чакрымнар калгач, аты арый, туктала да, бер генә дә атламый. Илҗә дәдәй яңа чарага — атын бүләкләргә тотына. Бүләкләре — кринделләр. Кайта-кайта атына ашатып бетерә бу кринделләрен. Инде зират тавына житкән булалар. Ат янә туктап кала. Хуҗа кеше аны тегеләй дә, болай да кузгатырга тырыша, бармакларын кринделгә охшатып, атның авызына да китереп карый, юк, ат кузгалмый да. Шуннан соң Илҗә дәдәй атын тугарып, камыт, ыңгырчак, дилбегә, аркалык, түшлек ише әйберләрен зиратка кертеп яшергәч, өенә кайтып китә. Иртәгәсен атын алырга зират тавына килсә, алашасының канлы сөякләрен генә таба. Аны төнлә бүреләр ашап киткәннәр икән.

— Рәхмәт, бүреләр, сез минс тәки бәладән коткардыгыз. Атны сезгә инде күптән ашарга кирәк иде. Җалкы, кызларыма алган күчтәнәч — кринделләрем генә әрәм булды, — дигән ди Илҗә дәдәй.

Шәүкәт Галиев

# ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘР

## Хыялның чыны — яшьлектә

*Чибәрлек — яшьлек юлдашы.
*Матурлык — яшьлек алтыны.
*Кыз гомере иртәнге чык — балкып ала да оча...
*Керфеге белән йолдыз тузанын сөртә!
*Көзгесе дә чибәрләргә карарга ярата.
*Түбәночтан югарочка күз кысканны тоялар.
*Дию пәрие диләр иде, бию пәрие дә бар икән!
*Матурлыкның күзгә кереп торганы түгел, күзеңне ачканы кадерле.
*Качкан кызга карыйсы килә, япкан ашны татыйсы килә.
*Узганда бер күз төшерү өчен дә ятарканны сайлыйсың.
*Чибәрләр — үтә ялтырап атылган йолдыз сыман.
*Таң — көннең алсу йөзле кыз чагы — тиз үтә, тиз уна.
*Яшьлекнең матур төш икәнен "уянгач" төшенәсең.
*Яшьлек минутлары белән еллар буе хушлашасың.
*Йөгер яшьлек киләчәккә — мин сиңа кызыгам һәм алкышлыйм.

## Адәм баласы яратыр өчен яратылган

*Ярату сүзендә яр да, яра да бар!..
*Мәхәббәт җиде ятны үз иттерә, сигез үзне онытдыра.
*Күпер — ярларның бер-берсенә сузылып тоташкан куллары.
*Иң матур кеше — яратып баккан кеше.
*Ярату — күңел җылыңны кушып карау.
*Салкыннарның яратканы булмый.
*Һәр яшьлекнең үз мәхәббәте, һәр мәхәббәтнең үз җыры.
*Борынгы әби-бабайлар да үбешә белде микән?
*Мәхәббәтсез үткән көннәр — атмаган таңнар.
*Сөйгән ярлы кеше — иң бай кеше.
*Мәхәббәт белән нәфрәтнең уртаклыгы шунда — сәбәпләре истән чыкмый. Мәхәббәт ажаганнары күңелне балкыта.
*Балдыз — бал кыз!
*Ятка калган ярларда ят оныклар үсәдер...
*Яңа туган бала дөньяны елап яулый.
*Бала йоклый — анага ял.
*Йөзләгән баланы караган, үзенекенә вакыты калмаган.
*Бала — балласт түгел, канат ул.
*Ятим бала иртә өлкәнәя.
*Үги бала яңа әнисеннән өлкәнрәк тә була...

Ахыры. Башы быелгы 1, 4 саннарда.

*Бармакларда балдаклар да бар, житәкләргә бала гына юк.
*Сәфәрдә озаграк йөрсән, хатынын да кыз булып күренер.
*Бала күзен әти ача.
*Әтиләр күзен бала йомдыра...

## Ак кәгазь мәгънә вәгъдә итә

*Кәгазь битенә кызыллык китермә.
*Кайсы китапка караганда да ак кәгазь мәгънәлерәк.
*Каләм кәгазьне сагынган — ничек сыланып-сырпаланып йөри!
*Каләмен тирләсә, укучын тиргәмәс.
*Язучыны халык вөжданы тудыра.
*Шигърият жаны халыкта.
*Халык жаны иманда.
*Язучынын бәхете үзен онытып, ил-көнне кайгыртып яшәүдә.
*Үзеннән канәгатьсезлек — яна ачышларнын башы.
*Керфек очындагы күз яшен каләм очына төшсен.
*Талантлы әсәр — канатлы, биектә булыр.
*Сан да — талантны күрсәткән сыйфат.
*Беренче шигырьләр калды яшьли сөйгән яр сыман...
*Остара бара, чын тормыштан ераклаша бара шигърият...
*Кайсы шагыйрьнен гомер юлыннан бер юл шигырь дә калмый.
*Тере агачтан ясалган кәгазь, начар әсәр язгач, жансыз агачка әйләнә.
*Гонорар алса гонорлы була.
*Кульязмасыннан аякларын таныйсын...
*Авторы бар әсәрнен, әмма атасы-анасы гына юк.
*Горурлык дәрәжәсе сәләтеннән дә югарырак.
*Сүзен эчендә үзен бул!Халык ижаты — бабаларнын оныкларга юллаган рухи васыяте.
*Табышмак — жавабын табасы булганга борынгыдан килеп житкән.
*Зирәклек — сүзнен канаты, фәлсәфә — дәрманы.
*Мәзәк ул житми мәгънәсе булганда гына кызык.
*Тырнаклар эченә эләккән юаш сүз...
*Сүзлек — ин оста тылмач.
*Музыка теленә күнел тылмач.
*Син жыр көйлисен, жыр күнелне көйли.
*Аларнын моржасы да жырлый!
*Атказанган тамашачы.
*Гади артистлар күпме!

## Юл сукмактан башлана

*Бергә кушылган сукмаклар юлга әйләнә.
*Һәр сукмак та юлга әверелми.
*Юлчыга юл иярә.
*Тигездә юллар туры.
*Бормалы юллар хәйләкәр.
*Юраулынын юлы урау.
*Япан кырда багана да юлдаш — чыбыклары кешегә тоташкан.
*Тауга менгән саен офыклар чигенә.
*Тауда курыксан — туктау хәерле.

*Вокзал — вак ял урыны, эресе эләкми.
*Дөнья — вокзал, кемнең поезды кайчан китә...

## Дошманлык чыганагы — күңел сукырлыгында

*Күзен нәфрәт томалаган адәм явызлыкны җиңел эшли.
*Җәнҗаллык итә — җаны ял итә...
*Өзелеп яратканнар бар.
*Өзеп ташлардай дошманнар да юк түгел...
*Күңелгә шырпыдай кадалган сүз кылчыклары...
*Бездән күпсенгәннәр сез азсынырлык түгел.
*Мәкерле янында хәйләсез булмый.
*Дошманның ялагаена караганда, явызлыгы йөзенә чыкканы хәерле.
*Ерактагы белән дус, күрше белән тыныша алмый.
*Кем күңелендә дуслык чәчәге үстерә, кем — шайтан таягы...
*Шомлы заманнар тарихын шымчылар яза.
*Атаклылар тормышын шымчылар шәбрәк өйрәнгән.
*Сафлык турында сафсата сата сатлык.
*Сатлыкның шатлыгы юк.
*Дошман арткан саен дуслар кадерле.
*Дусларда әсирлектә калган чак та була.
*Озак яшәгән кешегә ялгызы күңелсездер...

## Картлык яшьлектән башлана

*Картлык — пенсиягә җиткән яшьлек ул...
*Уртак яз да яшьләргә — бер, картларга икенче төрле...
*Картлык — яшьлектә тапканнарны югалту.
*Картая-картая хәтер тая, вакыт тиз шуа.
*Картлык — оныта, яшьлек — ота.
*Әүвәл ромашкалар гел актан иде, хәзер сарысы зуррак...
*Яшьлектә — дөньяның чибәрлеге.
*Картлыкта үз чибәрлеге дә юк.
*Өлкәнәю өлкәсенә эләктек.
*Вакыт-сынчы адәм атлы әсәрен башта матурлый, аннары — боза...
*Пеләшләр теләктәшлеге — пеләштәшлек.
*Коелган чәч агармый.
*Бакыр башта — көмеш чәч...
*Карчыкның тавышы йомшак, карты колакка каты.
*Көчең кимегән саен эшең арта.
*Үзең картаясың, кимчелекләр яшәрә.
*Яшьлекнең көче зур эшләргә җитә, картның, көче яшәүгә китә.
*Айгыр кыланышы алашага килешми.
*Картайгач чәчәк тә күршенеке, кызлар да кешенеке.
*Уртак хисләр яшь аермасын яшерә.
*Төш күрергә күзлек кирәкми.
*"Мин сине гомергә ташламам", — диде туксан яшьлек егет.
*Яшәүне кайгыртып чаба торгач, яшәргә вакыт калмый.
*Яшәү артыннан чапканда әҗәл чабудан тарта.
*Картлык әкрен атлый да, вакыт узып китә.

## Эш сыекланса, сүзләр куера

*Җыелыш бара — эш тора...
*Сүз боткасы, фикер шулпасы.
*Трибу*наданлык*.
*Авызының биге юк, сүзләренең чиге юк.
*Сүз — бозау имезә.
*Сөтләтә дә бирсәче!
*Күпнең кадере аз.
*Сүзенең атасы-анасы юк — зинадан туган.
*Теленә сөял үсмәсен.
*Чүбек чәйнәп май чыкса, эшләр майлаган кебек барыр иде!

## Турысын әйтүче яныннан кыеклап үтәләр

*Мактаганда дәшмисең, тәнкыйть тигәндә тыелу читен.
*Сүз чыбыркысы сүс чыбыркыдан әчерәк.
*Ач карында тавыш күп була.
*Буш тамак каты кычкыручан.
*Саклана-саклана куркакка калган.
*Кычкырып пышылдаган, инде пышылдап кычкыра.
*Кабынып карамаган — януны аңламас.
*Кешенең иң аз белгән кешесе — үзедер.

## Ирену — ялкаулыкка ашыгу

*Эшчән кояшта эшли, ялкауга күләгәдә дә эссе.
*Ялкауның язы соңарыр, кышы иртәләр.
*Кем — үркәчкә, кем — корсакка май-мая җыяр.
*Ялкауның сәгате алда булыр — ашка ашыга.
*Бу адәмнең үзен танымыйм, бүксәсен кайдадыр күргән кук.
*Ялкауга бал кортлары да эшләми, тырышка гына җыялар.
*Рухы сәламәт эшсез яши алмас.
*Туң җанны тун да җылытмас.
*Ялкау озак яшәргә дә иренә.
*Мәнсезгә эш тәмсез, дөнья ямьсез.

## Комсыз ком ашар

*Авызын ачса, үпкәсе күренми — алтын тешләр томалый.
*Бармагы үзенә таба кәкре, кармагы — бүтәннәргә.
*Саранлыкка ул бик юмарт.
*Саранны сынау кыйммәткә төшә.
*Бирән бирәм димәс.
*Оятсыз оялуыңа исәп тотып алдый.
*Комсыз корсагы белән абынган.
*Көя дөяне дә ашап бетерә ала.
*Саклык — саранлык түгел, җыйнаксызлык — юмартлык түгел.

*Сан артыннан куып сансызга калган.
*Сараннан күп нәрсә кала, мәгънә генә калмый.
*Мие мин-минлек белән мөлдерәмә.
*Үзен күрсәтергә тырышканның күләгәсе дә зуррак.
*Баш миенә дан йөгергән.
*Һавалар җылына, кешеләр салкыная.
*Мокытлыкка юк кытлык.

## Әхлаксыздан имансыз туа

*"Җүләр сатып йөрдек", диләр — яхшы атларын сатканнар.
*Гәүдәгә төп кебек, үзе — төпсез...
*Чибәрлеге чикледер, оятсызлык чамасыз.
*Ярты сәгатьтә куен сәгате эшләп алган хатын.
*Акыллы кеше акыл җыяр, тилегә генә җай чыкмый.
*Буш кешегә ни тутырасың?
*Пычак — сөзгәк кеше кулына күчкән мөгездер.
*Дөньяга сыймаган ике тәкә башы бер казанга сыйган.
*Файдалы үләннәрне таптап файдасыз адәмнәр йөри.
*Аңа үз тормышы яхшыру гына җитми, бүтәннәрнең кайтыш булуы да кирәк.
*Үзле балчыктай ябышмак үзсүзле.
*Пычрак чистаны өнәмәс.
*Яман сүз яман күздән туа.
*Тәмсез телдән тәмле телмәр тумас.
*Тышка чыккан явызлыктан яшерен этлек яманрак.
*Кешенең өчтән бер өлеше су.
*Берәүләрдә анысы да болганчык.
*Карак иректәге гомерен урлый.
*Кыңгыр эш кыңгыраулы.
*Кояш түбәнәйгән саен күләгәләр зурая.

## Эчмәгән аракы дарудан файдалырак

*Эчсә — чама белми, эчмәсә чара белми.
*Эчмәсә — эшли алмый, эчсә — эше бармый.
*Ана сөте белән кергән акыл ата аракысы белән чыккан.
*Авызыннан аракысы кипмәгән.
*Буш вакытта — буш шешә, буш кеше.
*Аракылы башта кайнар уйлар чажылдап сүнә.
*Бер йөз грамм — кешене икейөзле итә.
*Аракы ашказанын да, баш казанын да боза.
*Кызмача каләм аек җырламас.
*Лаякыл айнык.
*Көн дә эчкәч, эчкечеме-түгелме икәнен ничек беләсең?
*Йотып алган — ятып калган.
*Аракылы башта — аркылы уйлар.

*1987 елга хәтле.*

# *Latin imlasьnda uqu yrnəklәre*

## ***Imeş–mimeş tygel***

### *Inde ajnьƣannardьr*

Qaraduƣan mədəniət jortьnda xalьqnьꞑ Qazan ədiplәre belən ocraşuь bara. Tɵrkem çitəkcese Mɵxəmmət Məhdief zaldaƣь xalьqnь şaƣir Rqail Zəjdulla belən tanьştьra. Şiƣerlәre bik əjbət, alarnь şəp tawъş belən uqьj da belə ikən. Cuwaşstanda tuьp yskən, kyptən tygel genə ɵjlənep, şunda bik zur tuj ytkərgən, ƣəçəjep dərəçədə qunaqcьllьq kyrsətkən imeş.

— Jazucьlar berlegennən qunaqlar ike "Volga"ƣa təjəlep bardьlar, bytən berkem tujьnda mondьj xəl bulƣanь juq ide, alar əle də... — ostaz yz syzen nicek təmamlьjsь bulƣandьr, tik anьꞑ çɵmləsen ɵstəl artьnda zur bulьp utьrƣan şaƣir kiəyneꞑ qalьn tawъşь "tygərəklәde":

— ... Əle də ajnьp çitə almьjlar...

Mɵxəmmət aƣaƣa, ƣədətencə kɵlemserəp, bu syzlərne çəpləydən bytən cara qalmadь.

### *Qajsьsь redaktor?*

Jazucь Məƣsum Xuçin rajon gəzite redaktorь bulьp eşləgəndə "Moskvic" şofjorь itep yz xolqьnьꞑ təmam qapma-qarşьsь bulƣan Isməƣilne aldь. Awьllarda jɵrep, kalxuz rəise kabinetьna kersələr, Məƣsum Xuçin kyzlegen sɵrtkələp torƣan arada, əꞑgəməne Isməƣil inde başlap ta çibərə ikən. Qьrƣa cьqsalar da şulaj, igencelərgə soraunь başlap ul birə. Qaraduƣanƣa kilgəc, idarədə aqca tyləp, kalxuznьꞑ it skladьna suƣьlalar bolar. Qunaqlar kitkəc, sklad mɵdire şundaƣь kalxuzcьdan sorьj:

— Tanьmadьm, kemnər buldь soꞑ bolar?

— Rajon gəziteneꞑ jaꞑa redaktorь ic.

— Şulajmьni? — di sklad mɵdire. — Alajsa, redaktor artьnda kyzlegen sɵrtep torƣanь kem ide?

### *"Tanьş moꞑnar" Zəfəre — Qaraduƣanda*

Tatarstannьꞑ Musa Çəlil isemendəge byləgen buldьru turьnda qarar cьqqac, Baltacnьꞑ rajon gəzite redaktorь Məƣsum Xuçin əjtep qujdь:

— Mondьj byləkneꞑ iꞑ berencese Ildar Jyziefkə birelergə tieş.

Şulaj bulьp cьqtь da. Cənki ul jьllarda tatar uqucьlarь arasьnda bu şaƣirneꞑ "Fərit-Fəridə"sennən, "Miləyşə"sennən, bigrək tə "Tanьş moꞑnar"ьnnan da populjarraq berni də juq ide. Qazannan artistlar kiləme, awьl yzeşcənnəreme — jaꞑƣьrawьq tawьşlь xiscən qьzlar "Tanьş moꞑnar"dan berər өzek uqьmьjca qalmьj.

Ber kənne Qaraduƣan awьlьna rajon yzəgennən agitbrigada kilgən ide. Ber qьz Rezidə rolenə kerep, "Tanьş moꞑnar"nь şulqədər matur uqьdь ki, bөten zal өnsez qalьp, romantik poema dulqьnnarьnda jөzə başladь. Əmma Rezidəneꞑ өzgələnep "Işetəseꞑme, Zəfər?" digən syzləre jaꞑƣьrauƣa, tьꞑlausьlarnь siskənderep, klubnьꞑ arƣь başьnnan çawap kilde:

— Işetə-ə-əm, çanьm!

Sənƣət kөcenə bujsьnьp, yz—yzen beleştermicə awaz salƣan ul jegetneꞑ iseme, cьnnan da, Zəfər ide şul.

Ş. JULDAŞ.

---

РАДИО
УКВ 73,97
Курай

«Курай» дулкыннарында —
сез яраткан җырлар.
«Курай» дулкыннарында —
иң яңа хәбәрләр.
«Курай» дулкыннарында —
игъланнар һәм реклама.

☎ 54-65-74, 54-75-53,
8-2-270-32-16

*Укучы сүзе*

* * *

"Казан утлары" журналын мин 1940 нчы елдан бирле ("Совет әдәбияты" вакытыннан ук) алдырам. Сугышта чакта гына аны укудан өзелеп тордым. Һәр санын саклап, туплап киләм. Алардагы бер генә язманы да укымыйча калдырмыйм.

Әле менә журналның быелгы 3 нче санынннан таныылган әдип Рабит Батулланың "Каләм яза, кәгазь түзә" дигән исем астында бирелгән язмаларын укыдым. Искиткеч язмалар! Шулар арасындагы "Күк капусы ачылгач" исемлесен укыгач туган кайбер тәэсирләрем турында гына сөйләп бирмәкче булам.

Язма белән танышкач, тормышымда булган шундый ук бер вакыйга искә төште. "Искә төште" дип әйтүем дөрес үк тә булмас, аның һичкайчан истән чыкканы да булмады, әле дә үкенечле бер гамәл булып, күңелемне тырнап, өшетеп тора.

Р. Батулла сабый чагында күктә серле яктылык күрүен бәян кыла. Шул хакта әбисенә сөйләп биргәч, ул: "Күк капусы ачылганын күргәнсең, улым! Изге теләкләр телә. Теләкләрең кабул булыр, иншалла", — ди. Бала үзенә кирәк нәрсәләрне тели — соңыннан бу теләкләрнең барысы да гамәлгә аша. Соңыннан автор: "Ә нигә мин Күктән татар халкына сәгадәтле тормыш сорамадым икән?" — дип сүзен тәмамлый.

... 1931 ел. Миңа 6 яшь. Күмәкләшү еллары. "Кулак исәбенә кертмәгәйләре" диптер инде, әти беренчеләрдән булып керде колхозга. Атыбызны, жигелгән килеш, арбасына сабан-тырма кебек эш коралларын төяп, колхозга илтеп бирде. Ат абзарын да, иген келәтен дә сүтеп илтте. Ишек алдыбыз шып-шыр калды. Шул чакта әниебез, өй алды баскычына утырып, тавыш-тынсыз гына озаклап җылаган иде.

Берничә көннән соң, күрше малае Солтангали белән алар йортының чормасыннан шыксыз, кара элпә канатлы бер кош тотып, әнигә күрсәтергә дип, безгә кердек.

— Ярканат бит бу! — диде әни. — Ул — төн кошы. Кошлар — ирек сөюче җаннар алар. Кич җиткәч, очырып җибәрегез сез аны, көндез Кояштан курка ул...

Кичен, без кошчыкны очырырга җыенгач, әни:

— Ярканатны ирекка җибәргәндә, баш очында тотып, теләгеңне әйтсәң, ул теләк кабул була. "Кошкаем, безне бу колхоздан коткара күр!" — дип әйтегез, аннан соң гына очырып җибәрегез, — диде. Әни сүзләренең мәгънәсен аңламасак та, без ул кушканча эшләдек: беренче булып Солтангали шул теләкне әйтте, аннан соң мин ул сүзләрне кабатлап, кошчыкны очырып җибәрдем. Ук кебек атылган кошчык караңгылыяктылыда күз ачып йомганчы юк булды.

Шуннан соң берничә ел үткәч, Солтангалинең япь-яшь имән кебек таза әтисе кинәт кенә үлеп китте. Берәр ел узгач, әниебез авырый башлады. Озакламый ул, 50 яшен дә тутыра алмыйча, җиде баласын ятим калдырып, вафат та булды...

Мин боларның барысын да теге чакта кошчыкны азат иткәндә әйткән теләк белән бәйләп карадым. Колхоз таралмады, ә безнең якыннарыбыз, чыннан да, колхоздан "азат булдылар". "Тели белсәң генә — теләк, тели белмәсәң — башыңа имгәк", — дигән уй кереп оялады күңелгә. Һәм шул уй гомерем буе җанны өзгәләде, гомерем буе хәтердән китмәде. Әниемнең вакытсыз үлеп китүенә үземнең дә сәбәпче булуымны тоеп яшәү гомерем буе эзәрлекләп килде мине.

Хәер, колхозлар да әниләрдән артык яши алмадылар. Алар да бүген авыру хәлендә, алар да үлем түшәгендә.

Шулай да бу мине бер дә шатландырмый. Әнинең дә теләге кабул булды бит, дигән канәгатьләнү хисе кичерергә тиеш идем бит, югыйсә...

Нурулла БИКМУЛЛИН,
Зеленодольск районы,
Васильево бистәсе.

*Котлыйбыз!*

## Диас Вәлиевкә 60 яшь



Драматург һәм прозаик Диас Назыйх улы Вәлиев 1938 елның 1 июлендә Татарстан АССРның Арча районы Казанбаш авылында туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Казан шәһәрендә уза. 1956 елда урта мәктәпне тәмамлагач, укуын Казан дәүләт университетының геология факультетында дәвам иттерә, аннан соң Кемерево өлкәсендә геолог булып эшли. 1965 елда Казанга кайта һәм, берникадәр вакыт шәһәрдәге геологик оешмаларда эшли, 1966 — 1973 елларда "Комсомолец Татарии" газетасында әдәби хезмәткәр вазифаларын үти. 1973 — 1975 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы югары әдәби курсларда укый. Курсларны бетереп кайткач, Д. Вәлиев профессиональ язучылык эшенә күчә.

Д. Вәлиев рус телендә яза. Матбугатта беренче тапкыр 1959 елда "Карта старика" исемле хикәясе белән күренә. Хикәяләре һәм повестьлары тупланган беренче проза китаплары ("День за днем", "Старики, мужчины, мальчишки") 1973 һәм 1975 елларда Казан һәм Мәскәү нәшриятларында дөнья күрә.

Д. Вәлиевнең язучылык сәләте драматургия жанрында аеруча тулы ачыла. "Намус хөкеме" драмасы 1971 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела һәм тамашачылар тарафыннан яратып каршы алына. Драматургның "Дәвам" исемле икенче героик драмасы тагын да зуррак уңыш казана. 1976 елда "Дәвам" пьесасы өчен Д. Вәлиевкә Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Шулай ук "Диалоглар", "Казанның Елга аръягы күрәзәчесе", "Үзенә хыянәт итсән" әсәрләре дә укучылар арасында киң танылу ала. 1981 елда Татарстанның, 1983 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Д. Вәлиев проза, публицистика һәм әдәби тәржемә өлкәсендә дә актив эш итә. Аның тәржемәсендә 1981 елда Г. Коләхметовның "Ике фикер" һәм "Яшь гомер" исемле атаклы пьесалары рус телендә дөнья күрә, 1990 елларда Мәскәүдә чыккан "Три лика", "Три похода в вечность", 1995 елда дөнья күргән "Охота убивать" һәм "Необыкновенные приключений двух друзей" исемле әкиятләр җыентыгы да игътибарга лаек.

Д. Вәлиев — 1973 елдан СССР Язучылар союзы члены.

**Редакциядән**: *юбилярны олы бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа иҗат уңышлары, исәнлек телибез.*

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — КАЗАКЪСТАНДА

10 июньдә Президент Н. Назарбаевның чакыруы буенча Казакъстанга килгән Татарстан делегациясе әлеге тугандаш республиканың яңа башкаласы Астананы рәсми тәкъдир итүдә катнашты. Җөмһүриятебез Илбашы М. Шәймиев, Татарстан Республикасы халкы исеменнән чыгыш ясап, казакъстанлыларны тарихи вакыйга — яңа башкала барлыкка килү белән тәбрик итте.

Президент Н. Назарбаев тантанага килгән күп кенә дәүләтләрнең җитәкчеләрен "Астана" медале белән бүләкләде. Алар арасында ТР Президенты М. Шәймиев тә бар — ул Татарстан һәм Казакъстан халыклары арасындагы дуслыкны ныгытуга зур өлеш керткәне өчен бүләкләнде.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ТЕАТР ФЕСТИВАЛЕ

27 май — 3 июнь көннәрендә Казанда төрки халыкларның "Нәүрүз" театр фестивале булып үтте. Аның барышында барлыгы 19 спектакль күрсәтелде.

Г. Камал исемендәге театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов ТЮРКСОЙ "Гран-при"ена (5 мең доллар) лаек булды. Анкара Төрек драма театрына Татарстан Театр әһелләре берлеге призы бирелде.

Фестиваль лауреатлары арасында Хакас драма театры, Тыва музыкаль драма театры, Уфаның "Нур" Татар Дәүләт драма театры, М. Гафури исемендәге Башкорт академия театры, Әзәрбайҗан Дәүләт яшьләр театры, Балкар Дәүләт драма театры, Казакъ Дәүләт академия балалар һәм яшьләр театры һ.б. коллективлар бар.

## ХАЛЫКАРА КОНГРЕСС

16 — 20 июнь көннәрендә Казанда "Газ, нефть промышленносте, энергетика һәм элемтә өчен яңа югары технологияләр" Халыкара конгрессы эшләде. Конгресста катнашучылар яңа технологияләр турында 50 дән артык доклад тыңладылар, "Татгазпром", "Оргсинтез" кебек предприятиеләрдә булдылар, "Казан ярминкәсе" үзәгендә оештырылган "Татарстан. Конверсия. Промышленность технологияләре. Бизнес-газ, нефть" дигән күргәзмә белән таныштылар, соңыннан Казанның истәлекле урыннарын, Сабантуй бәйрәмен карадылар.

Конгресс эшендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Халыкара һәм Россия технологик фәннәр академиясе президенты В. Алфеев, Россия "Газпром" акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе Р. Вяхирев, РФ экс-премьеры В. Черномырдин һәм чит илләрдән килгән күп санлы делегация вәкилләре катнашты.

## Ф. МӨХӘММӘТШИН — ФЕДЕРАЦИЯ СОВЕТЫ ӘГЪЗАСЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин 10 июньдә беренче тапкыр шушы дәрәҗәдә Россия Федераль җыелышының Югары палатасы — Федерация Советы утырышында катнашты. Федерация Советы аның вәкаләтләрен тулысынча таныды һәм раслады.

## ЯҢА ҖИТӘКЧЕЛӘР БИЛГЕЛӘНДЕ

Татарстан Республикасы Президентының 1998 ел, 28 май Указы нигезендә, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе итеп моңарчы Мамадыш районы хакимияте башлыгы булып эшләгән 45 яшьлек Экзам Самат улы Гобәйдуллин билгеләнде. Ул — авыл хуҗалыгы фәннәре докторы.

* * *

11 июньдә Татарстан Эчке эшләр министрлыгына яңа җитәкче — Федераль сак хезмәте полковнигы, элек Татарстан Президенты Аппаратында Иминлек хезмәте җитәкчесе булып эшләгән 37 яшьлек Әсгат Әхмәт улы Сафаров билгеләнде.

## ПЕН-ҮЗӘК УТЫРЫШЫНДА

Татарстан Язучылары ПЕН-үзәгенең 29 майда уздырылган утырышында оешмага яңа әгъзалар кабул ителде. Алар — шагыйрьләр Зөлфәт, Газинур Морат, Нур Әхмәдиев, юрист һәм публицист, Татарстанның халык депутаты Рәшит Вәгыйзов. Әлеге утырышта Казан урамнарына Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Михаил Худяков, Лев Гумилев исемнәрен бирү турында башкала хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә дигән карар кабул ителде.

ПЕН-үзәк бер еллык эшкә йомгак ясады, киләчәккә үзенең төп максатларын билгеләде. Шулар арасында язучыларның Һельсинкида уздырылачак Бөтендөнья конгрессында катнашу һәм татар әдәбияты үрнәкләрен инглиз телендә нәшер итү аерым мәсьәлә булып тора.

### ТЫН ОКЕАН КАҺАРМАНЫ ЮБИЛЕЕ

Татарстан Республикасының Санкт-Петербург каласындагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Ш. Әхмәтшин 60 нчы елларның иң шөһрәтле татары — атаклы диңгезче Әсгат Җиһаншинны кабул итте. Үзенең өч хезмәттәше белән берлектә, 49 тәүлек дәвамында Тын океанда яшәү өчен көрәшкән каһарман милләттәшебезгә шушы елның 13 июнендә 60 яшь тулды. Ш. Әхмәтшин ана, юбилее уңаеннан ихластан тәбрикләп, истәлекле бүләк тапшырды.

### ТАТАРСТАН МАТБУГАТЫНЫҢ МИЛЛИ БӘЙРӘМЕ

19 майда, Җәмһүриятебездә беренче тапкыр буларак, Татарстан матбугатының милли бәйрәме билгеләп үтелде. Шул ук көнне "Бәллүр каләм-97" исемендәге республика журналистлары конкурсына да йомгак ясалды. Җиңүчеләргә бүләкләр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында тапшырылды. Журналистлар арасыннан "Мисс "Бәллүр каләм-97" исеменә Татарстан Журналистлар берлеге идарәсе рәисе Римма Ратникова, ә "Мистер "Бәллүр каләм-97" исеменә тележурналист Ирек Мортазин лаек булдылар.

Газеталар бәйгесендә беренче бүләкне иң зур тиражлы "Татарстан яшьләре" яулады.

### ЯШЬ ИЖАТЧЫЛАР ФЕСТИВАЛЕ

20 майда Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында яшь иҗатчыларның шәһәр фестивале булып үтте. Аны "Сабантуй" газетасы, "Ялкын" журналы һәм Казан шәһәренең Балалар һәм яшьләр белән эшләү комитеты оештырган иде. Фестивальдә "Алтын каләм" республика конкурсының III турына йомгак ясалды, җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды. Бәйрәмдә әдипләребездән Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Хафизова, Ф. Яхин катнашты.

* * *

8-10 июнь көннәрендә Казанда Татарстанда яшәүче төрле милләт балаларының сәнгать фестивале гөрләп узды. Татарстан Мәдәният һәм Мәгариф министрлыклары оештырган әлеге бәйрәмдә яшь язучылар, рәссамнәр, музыкантлар һ.б. үз осталыкларын күрсәттеләр. Балалар Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р.Харисов, Мәгариф һәм Мәдәният министрлары Ф. Харисов һәм М. Таишев белән очраштылар.

### ХАТЫН-КЫЗЛАРЫБЫЗНЫҢ ГЫЙЛЬМИ УҢЫШЛАРЫ

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәре, сәнгать фәннәре кандидаты Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова Мәскәүдәге Дәүләт сәнгать белеме институтында "Татарстанның бизәү сәнгате: милли традицияләрнең чыганагы, хәзерге замандагы үсеше" дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Әлегә ул, Татарстанда гына түгел, Идел-Урал республикалары арасында да сәнгать фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә ирешкән бердәнбер хатын-кыз.

* * *

Казан дәүләт педагогия университеты укытучысы — "Казан утлары" журналының даими авторы Ләйлә Әхмәдиева-Минһаҗева Казакъстанда яшәүче аксакал язучыбыз — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Салаховның иҗатына кагылышлы кандидатлык диссертациясен яклады. Чыгыш ясаучылардан академик Т. Галиуллин, Татарстан Язучылар оешмасы җитәкчесе Р. Мөхәммәдиев, "Казан утлары" журналының бүлек мөдире М. Вәлиев һ.б. Ләйлә ханымның иҗади эзләнүләренә югары бәя бирделәр.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен, "Ля Примавера" Казан камера оркестрының сәнгать җитәкчесе, баш дирижер **Ростәм Юныс** улы **Абязовка** "Татарстан Республикасының халык артисты" дигән мактаулы исем бирелде.

# ЯҢА КИТАПЛАР

ИСЛАМОВ Р.Ф. **Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры**: *язма мирас, багланышлар.* — Казан: "Матбугат йорты", нәшр., 1998. — 250 бит. Тиражы — 500 данә.




Филология фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән гыйльми хезмәткәре Р. Ф. Исламовның әлеге хезмәте Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисырында барлыкка килгән язма мирасны, ике мәмләкәт арасындагы мәдәни бәйләнешләрне өйрәнүгә багышланган. Анда Алтын Урда дәүләтендә иҗат ителгән әдәби ядкярләрдән "Кыйссасел-әнбия", "Мөгыйнел-морид", "Рәүнәкъел-Ислам", "Хөсрәү вә Ширин", "Мәхәббәтнамә", "Җөмҗөмә солтан", "Кисекбаш", "Гөлстан бит-төрки"; мәмлүкләр Мисырында кыпчак-төркиләр идарә иткән дәвердә барлыкка килгән гарәпчә һәм төрки тарихи хезмәтләр, әдәби әсәрләр һәм башка характерда булган ядкярләр тикшерелә; ике дәүләт арасындагы мәдәни багланышлар тасвир ителә. Аларның ориенталистика һәм тюркологиядә, татар теле һәм әдәбияты тарихында өйрәнелү дәрәҗәләре билгеләнә, киләчәккә перспектив планнар тәгаенләнә.

Хезмәт төрле телләрдәге бик күп гыйльми чыганакларга таянып язылган, кушымтада байтак язма истәлекләрнең үрнәкләре бирелгән.

БӘЙРӘМОВА Фәүзия. **Безне онытмагыз:** *пьесалар.* — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 254 бит.




Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмованың иҗаты күпкырлы. Ул һәр жанрда диярлек җинел яза: проза, шигырь, публицистика. Бу җыентыгына исә язучының биш драма әсәре тупланган. Шулар арасыннан Һ. Такташның тормышын һәм иҗатын чагылдырган "Атылган йолдыз", шәхес культы чорында татар халкының фаҗигасен ачып биргән "Безне онытмагыз..." пьесалары аеруча игътибарга лаек. "Сандугачның балалары" исемле пьесада исә, әфган сугышы вакыйгалары, татар егетләренең аянычлы язмышлары сурәтләнә. "Безне онытмагыз..." пьесасы Казан татар яшьләр театры тарафыннан (режиссеры Ф. Хәбибуллин) 1989 елда сәхнәләштерелеп, тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителде.

Мөхәррире — Фәнзаман Баттал. Тиражы 3000 данә.

Индекс 73210



Язучы Юныс Сафиуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)